
ISSN 0206—4189

# Казан утлары

2.1987





# ШУШМА БУЙЛАРЫНДА

ФОТОХИКӘЯ (Дәвамы 186—187 битләрдә)

// КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

2

1987

## Бу санда

Г. АХУНОВ. Идел кызы. *Роман* . . . . . . . 3
Р. ГӘРӘЙ. Ник яшерим. *Шигырьләр* . . . . . 102
Р. ГАТАУЛЛИН. Тулпар атның тояк җиле. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . 106
М. ЮНЫС. Таңда Босфор аша. *Повесть* . . . . 112

ӘДӘБИ МИРАС

Р. ФӘИЗУЛЛИН. Хәтер. . . . . . . . . . 144
З. НАСЫЙБУЛЛИН. Без җаваплы. *Шигырьләр* . . . . . . . . . . . . . . . 145

Р. РӘКЫЙПОВ. Сакта. *Шигырьләр* . . . . . . 149

23 ФЕВРАЛЬ — СОВЕТ АРМИЯСЕ КӨНЕ

С. ШАКИР. Утлы еллар эзеннән. . . . . . . 151

ТАТАРСТАН — ТУГАН ТӨБӘГЕМ

И. МӘҮЛЕТХУҖИН. Тарихы бай, киләчәге якты. *(Баулы районы.)* . . . . . . . . . 157

ГАЛИМҖАН ИБРАҺИМОВНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

Ф. ХАТИПОВ. Психологизм остасы. . . . . . 161
Х. АБУШАЕВ. Г. Ибраһимов укыган иске мәдрәсәдә . . . . . . . . . . . . . . 167

БАКЫЙ УРМАНЧЕГА 90 ЯШЬ

Н. ИСӘНБӘТ. Зур шәхесләрнең берсе. . . . . 171
Г. БӘШИРОВ. Бәхетле иҗат. . . . . . . . 172
Ә. ЕНИКИ. Мәгънәле яшәү. . . . . . . . . 174
Н. АРСЛАН. Тылсымлы аксакал. . . . . . . 175
Ш. БИКТИМЕРОВ. Интернациональ рухлы рәссам. . . . . . . . . . . . . . . . 176

С. САБИРОВ. Давыллы еллар җырчысы. *(Сиринның тууына 90 ел)* . . . . . . . 177

ИСТӘЛЕК

Г. КУДАШЕВ. Хәсән Туфан — студент . . . 179

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

КОНКУРСКА

Ф. ДУНАИ. Гайрәт, акыл, гыйбрәт. . . . . . 182

ЯҢА ӘСӘР УКЫГАЧ

Р. ШӘРИПОВ. Әкият чынлыгы. . . . . . . 185

Шушма буйларында. *Фотохикәя*. . . . . . . 186

Культура тормышы көндәлеге. . . . . . . . . 188
Китаплар дөньясында. . . . . . . . . . . 191
Тышлыктагы сурәтләр. . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*

РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия*

МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ
ӘХӘТ ГАФФАР
МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
МӘДИНӘ МАЛИКОВА
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИННУЛЛИН
ФЛҮН МУСИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
НУРИХАН ФӘТТАХ
РИЗВАН ХӘМИД
НИЛ ЮЗИЕВ
АЗАТ ӘХМӘДУЛЛИН

Безнең адрес: 420066,
Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар:
баш редактор —53-07-60,
баш редактор урынбасары —
53-07-09,
җаваплы секретарь —53-07-09,
*бүлекләр:*
проза, поэзия, очерк —53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать,
хатлар —53-07-63.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

Роман Г. АХУНОВА «Дочь Волги» (вторая книга). Повесть М. ЮНУСОВА «Через Босфор на рассвете».
Стихи Р. ГАРАЯ, Р. ГАТАУЛЛИНА, Р. РАКИПОВА.
«Литературное наследие» — стихи З. НАСЫБУЛЛИНА.
23 февраля — День Советской Армии: очерк С. ШАКИРА.
В рубрике «Татарстан — родной мой край» выступление первого секретаря Бавлинского РК КПСС И. Х. МАУЛЕТХУЗИНА.
К 100-летию Галимджана Ибрагимова — статья Ф. ХАТИПОВА «Мастер психологизма», воспоминания Х. АБУШАЕВА о годах учебы Г. Ибрагимова в Оренбургском медресе.
К 90-летию Баки Урманче — статьи Н. ИСАНБЕТА, Г. БАШИРОВА, А. ЕНИКИ, Н. АРСЛАНОВА, Ш. БИКТИМЕРОВА. В номере отмечается 90-летие поэта Сирина.
Воспоминания Г. КУДАШЕВА о Хасане Туфане.
«Библиография»: рецензии на книгу М. Хабибуллина «Кубрат-хан», на сказку Батуллы «Приключения Алп-батыра».
Фоторассказ Р. ЯКУПОВА и В. ХАШЕВА о тружениках совхоза «Северный» Арского района.
На наших обложках — ювелирное искусство татарского народа и памятники Казани.

Техник редактор *Р. Сөләйманова*. Корректорлар *Г. Салихҗанова*, *И. Ихсанова*.

Производствога бирелде 1.12.1986 ел. Басарга кул куелды 12.01.1987 ел. ПФ 05015. Офсет ысулы белән басылд.
Кәгазь форматы 70×108[1]/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8).
Тираж 65049. Заказ В-504. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе,
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1987 ел.

# Гариф Ахунов

# ИДЕЛ КЫЗЫ

**РОМАН ИКЕНЧЕ КИТАП**



Шәяхмәт Солтанның күзенә карады. Төбәп, туп-туры итеп карады һәм туп-туры итеп, маңгайга терәп сорау бирде:

— Син үзеңнең гаепсез икәнеңә үзең ышанасыңмы? Ныкмы синең ышанычың?

— Совет властена мин бернинди хилафлык та эшләмәдем. Партия уставыннан читкә тайпылмадым, программасын тулысынча кабул иттем.

— Алай булгач, синең гаебең нәрсәдә дип табалар?

— Әләкче Нух Галләм теле белән әйткәндә, мин — сыйнфый дошман булган мулла кызын куенына сыендыручы. Мин — ярлы-ябагайны, төгәлрәк итеп әйткәндә, этием Садыйк картны — байларның гомерлек куштанын — землемер багана-сы чокырыннан корал кулланып куркытып чыгаручы. Димәк ки, бөек борылыш елларында, авылларны күмәкләштергән чакта бөгелеш ясаучы.

— Шулмы? Шуннан артыгы юкмы?

— Юк.

— Партдискуссия чорында син, яшьлегең белән мавыгып китеп, кыек-мыек сүз ычкындырмадыңмы?

— Айдаровлар нәселе белән, ике балам белән, илем белән ант итеп әйтәм: минем беркайчан да кыек-мыек сүз сөйләгәнем юк.

— Алайса, хуп. Мин синең туры сүзле икәнеңне, күңелеңдә бер генә дә алдау-ялганлау булмаганны сал агызган заманнарда ук аңлаган идем. Минем менә шуларны, Солтан, синең үз авызыңнан ишетәсем килгән иде. Бар син Мәскәүгә. Үзәк Комитетта кабул итүләрен үтен. Эшең уңышлы барып чыксын дисәң, беләсеңме, кемне сора? Шәймәрдән Ибраһимовны. Онытмадыңмы син аны? Без бит уналтынчы елны Камада, саллар будкасында очрашкан идек. Ул милли мәсьәләне нечкә аңлый торган кеше. Уналты яшеннән партиядә. Патша төрмәсен узган. Кронштадтны фетнәчеләрдән коткаруда катнашкан. Гражданнар сугышында аны Куйбышев 5 нче армиянең мобилизация начальнигы итеп куя, Саранскидан башлап Әстерханга чаклы арада ике йөз меңнән артык доброволец җыя ул. Кызыл сугышчылар әзерли. Егерменче елларны ул Төркстанда партия Үзәк Комитетыннан вәкил була. Хәзергесе көндә Үзәк Комитетта Башкортстанга, Татарстанга

---

Ахыры. Башы 1 нче санда.

шефлык итә. Бездәге хуҗалык эшләрен, экономиканы, культураны яхшы белә. Менә шулай, Солтан, Шәймәрдән Ибраһимовны сора. Заманында ул Ленин белән бергә эшләгән, Мулланур Вахитовны яхшы белә. Аңласа — шул аңлар сине. Менә минем сөйләшәсе сүзем, әйтер киңәшем шул иде сиңа. Юлларың уң булсын, кайткач, үземә генә хәбәр итәрсең, яме.

Шәяхмәт Айдаров яшьләргә хас бер җитезлек белән имән төбеннән күтәрелде, чалбарына ябышкан үләнне кагып төшерде, гимнастеркасының бил каешын сыпырып җибәргәч, тугарылган аты янына таба китте.

Солтанның күңеле өмет белән тулы иде. Шуңа күрә ул тарантас янына килеп җитүгә, Бәдретдин кучерның ай-вайга юл куймыйча, атны үзе җигәргә кереште. Колакларын шомартып, тешләргә урелгән кара туры айгырны ягымлы тавышы белән тынычландырып, аңа камыт киертте, дуганы камыт бавы белән беркетте, зыңгылдатып, камыт чөелдереген тартты, аркалык белән түшлекне пөхтәләп бәйләде, йөгән тезгенен дуга бөҗрасына кертеп, артып калган өлешен йомры кара дугага чорнап куйды, дилбегә тимерләрен йөгән бөҗрасына эләктергәч, яңгыравыклы көр тавыш белән әйтте:

— Булды бу, Бәдретдин абзый! Шәяхмәт Айдаровны хәзер Пәнҗәргә генә түгел, Парижга чаклы илтеп житкерә аласыз!

— Рәхмәт, туган. Авылны онытмагансың икән әле,— диде Бәдретдин карт.

Солтан белән абыйсы кочаклашып аерылыштылар.

Шәяхмәт урман аланыннан баганалы олы юлга чыгып китте.

Солтан Бүре Бадул эшли торган умарталыкны эзләп, шунда таба юл алды.

## VII

Наратлар әкрен генә шаулый. Юл бормаларында, казылмаларда күлләвекләр җыелып тора. Урман һавасы дымлы, шул дым белән бергә җир исе, ылыс исе, мурган яфраклар исе килә.

Умарталыкка бара торган юл биек стена булып үскән төз наратлар арасыннан узганга, бирегә аяк асты да куе үлән белән түгел, сирәк абагалар, нарат төпләренә укмашкан каен җиләге яфраклары белән генә бизәлгән. Җанны тутыра, үпкәләрне берьюлы чайкый торган нарат сагызы исе тирә-юньдә мул булып бөялеп тора иде.

Солтан әле нарат араларындагы биек абагаларның челтәр яфракларына күз сала, әле башын артка ташлап, шәмдәй төз наратларның зәңгәр күккә ашкынган бөдрә ябалдашларына карап тора. Авыл мәдрәсәсендә әллә-әллә кайчан Шәрифҗан шәкерт сөйләгән әкиятләр искә төшә. Аннары аның уйлары Тукай шүрәлеләренә, Такташның урман буендагы яшь каеннарны сискәндереп узган поездларына, поезд җиленнән тибрәнеп калган чәчәкләргә килеп тоташа. Шуларның барысы аның узган гомере булып оешалар...

Истәлекләре никтер минут саен яңарып тора әле аның. Әллә картаямы югыйсә? Тукта, нигә дип әле ул умарталыкка барырга булды? Нәрсә калган аңа анда? Бүре Бадулны күрмәсә, тора алмыймыни ул? Арка чокырын күрми дә тора ала бит...

Бу уй бик кинәт, көтелмәгәндә килде, хәтта сәерсендерде. Фәлсәфә фәненнән ул бер генә нәрсәнең дә очраклы булмавын, хәтта соң дәрәҗәдә очраклы дигән күренешнең дә диалектика законнарына буйсынганлыгын белә иде. Әнә шул хакта уйлау белән ул Бүре Бадул яшәгән умарталыкка ни өчен барганлыгына шундук төшенде. Соң аны Бүре Бадулның туганнан туган энесе Нух Галләм әләге белән партиядән чыгардылар лабаса! Кайдадыр күңелнең

түрендә яткан ачы бер нәрсә аны шушы юлдан куалый түгелме? Аның үзенә кара дошман булган Нухның абыйсы ниндирәк? Ул аны элек белә иде. Гайрәтле, типсә тимер өзәрлек ир иде. Хәзер ни хәлдә икән? Шәяхмәт абыйсы бик ышанып әйтте, Чишмәбайны аның әләге белән алып киттеләр, диде. Боларны Бүре Бадул ниндидер бер хакыйкатькә ышанып, үзен хаклы дип санап эшләгәнме, әллә, абыйсы Шәяхмәт әйтмешли, кара бер мәкер, көнчелек, кешеләрнең газап күрүеннән тәм табу тойгысы гына аны шул юлга этәргәнме?

Юл буенда тырпаешып утырган, инде ылыслары коелып бетә язган наратларның кәүсәләренә каз каурые рәвешле яртышар метр озынлыктагы тамга салып киткәннәр, тамганың астына калай савыт элеп куйганнар — чәерен агызалар. Кайсыдыр бер агачта тукран тукылдый. Ул Солтанның урманда икәнен исенә төшерә — ниндидер борчулы уйлар, мәшәкатьләр белән яшәмәскә куша кебек. Син, адәм баласы, Казаныңа кайтканчы буталчык уйларыңны онытып торыр идең, ди тукран. Бер-ике мәртәбә тук-тук итеп аермачык итеп агачка суга да, аннары тырррррррррр итеп тырылдап тора башлый.

Нарат урманы бетте. Алда ачыклык күренде. Ул да түгел, зәңгәрле-сарылы умарта өйләре белән балкып, зур бер алан килеп чыкты. Төсләрдән, кояш күплегеннән күзләр камаша, җан саташа иде. Ярсып, эт өрә башлады.

Кемдер усал тавыш белән этне тыйды. Каршыга битен сакал баскан, алача күлмәгенең җиңнәрен сызганып куйган төптәй нык, базык гәүдәле берәү чыкты. Солтан аны күргән мәлгә имәнеп китеп, баскан урынында туктап калды.

— Кем ул анда йөри эт өрдереп?! — диде Сакалбай һәм җөнтәс кашлары астыннан килүчегә төбәлде.

Солтан аның Бүре Бадул икәнен тәгаен белсә дә, күргән мәлгә аптырабрак калды. Ул аны сумаладай куе кара сакал баскан бер кеше итеп күрергә күнеккән иде. Участок милиционеры Нажия Уразаева колак төбенә аткан чакта минуты-секунды белән аның чәче, сумала сакалы чаларгандыр дип башына китерми иде. Шуңа күрә ул Сакалбайны күргән генә уңайга шикләнеп куйды: әллә Бүре Бадул урынына башка кеше килгәнме? Юк — Бадул бу. Гайрәт орырга әзер булып, күкрәкне киеребрәк басып торуы — Бадулныкы!

— Бу мин әле, авылдашыгыз,— диде Солтан, аңа таба атлап. Аннары ачыклык кертүне кирәк тапты.— Айдаров булам мин.

— Кайсы Айдаров — Шәяхмәтме?

— Юк, энесе.

Сакалбайның тавышы калын һәм көчле иде.

— А-а-а,— диде ул, исе китмичә генә.— Солтанмыни? Та-аак. Кайткан дигәннәрие. Нинди усал уйлар белән йөрү? Мине сагынып килүең түгелдер дип беләм?

— Ә нигә алай дисез, Гыйбадулла абзый? Әллә гел дә сагынып килгәнмендер?

— Булмас! — диде Бүре Бадул, тавышында мыскылчан бер әрсезлек чалымы сизелеп калды. Һәм ул, кунакка якын ук килеп, аның кулын эләктереп алды, икенче кулын җилкәсенә китереп салды, дөресрәге — әле һаман да көчендә икәнен күрсәтер өчен, Айдар Солтанның ул җиргә чүктереп куярга ниятләде, ләкин тегесе мәкерне алданрак сизеп өлгерде — баскан җирендә нык торып калды.— Рас килгәнсең, үз итеп карап кит минем биләмәне. Авыл хуҗалыгын яхшы беләсең дип ишеттем, кем белә, бәлкем, файдаң да тиеп куяр.

Ул әле һаман Солтанның кулын җибәрмәгән көе, үзе белән умарта йортына таба алып китте. Йортны таза нарат бүрәнәдән салганнар, түбәсен кайчандыр бик калын итеп салам белән япканнар, салам каралган; җил-яңгырлардан, кышкы суыклардан бүрәнәләр дә каралган, тик алар ныклыкларын югалтмаганнар, әнә шул каралыклары

белән хуҗаның үзе төсле үк базык һәм ышанычлы булып күренәләр иде.

Чылбырында килеш йолкынып өскә атылган тана чаклы кара эткә Бүре Бадул тагын бер мәртәбә: «Пшол!» — дип кычкырды, тегесе койрыгын бот арасына кыстырып, чылбырын сөйрәп, өйнең икенче ягына чыгып китте.

Аланның аргы башында, койрыгын селки-селки, тышаулы ат утлап йөри, аннан ерак түгел генә бик зур итеп өйгән печән кибәне күренә иде.

«Таза яши бу, таза», — дип уйлап өлгерде Солтан Айдаров.

Бадул аны өй эченә алып керде. Күз тышта калган иде — күргән мәлгә берни күреп булмады. Тик бераз ияләшә төшкәч кенә ярты өйне алып торган, агартылмаган мич, стенага элеп куйган ике көпшәле ау мылтыгы күзгә ташланды.

Тәрәзә буенда калын сайгаклыктан каккалап куйган агач өстәл, анда самавыр, калай кружкалар, агач кашыклар, тастымалга төргән ипи, агач җамаякта — утә күренмәле сап-сары сыек бал, аның эченә кереп, чыга алмыйча үлгән икеме-өчме бал корты ята иде.

— Әйдә, түрдән уз, Садыйк малае, — диде Бүре Бадул. Гүя, шуның белән ул Солтанның фәкыйрь бер крестьян гаиләсендә туганлыгын исенә төшерергә теләде. Бүтән сүз кушуны артыкка санап, өстәл буендагы имән түмәркәгә килеп утырды. — Менә шулай яшәп яткан көн. Әртил байлыгын арттырабыз. Узган елны идарәгә бер йөз поттан артык бал суыртып бирдем. Анысы әле саф табыш. Түрәләр ашап, үзләре белән алып киткәнне чутка салган юк.

— Нигә, түрәләр дә киләмени?

— Килә. Тикшерергә дә килә, эче пошканнан да. Агаең Шәяхмәт тә килеп чыккалый. Картайган, гайрәтле заманнары узган.

— Алай дисеңме? Ә ул ник килә?

— Мине тикшерергә. Габбас сеңлесе аташмак Нажия мине наган белән стенага терәгән иде.

Солтан кискен бәрелешкә керергә теләмәде. Аңа барыннан элек Бүре Бадулның күңелендә нинди мәкерләр ятканны белү кирәк. Тота-каба тотынсаң, ул аны белгертмәячәк.

— Шулаймыни? Сәбәбе чыкты мәллә? — дигән булды Солтан.

Боларны ул Шәяхмәт абыйсыннан ишетеп белә иде инде, әмма аңа Бүре Бадулның үз авызыннан ишетү хәерлерәк булыр.

Моңарчы карасына коелып, эчендә дошманлык саклап сөйләшкән Гыйбадулла Ядкаров, болыт арасыннан чыккан кояш кебек, бер генә мәлгә яктырып алды — ала-кола сакалы арасыннан эре ак тешләре җемелдәп китте:

— Булды инде, Солтан. Төрлесен кичердек. Әйдә, якынрак утыр, ни дисәң дә без — авылдашлар, бер болында аунап, бер үк чишмәләрнең суын эчеп үскән кешеләр.

Солтан бу вакытта үзенчә уйлап өлгерде.

«Без эчкән чишмәләр бер. Кан әйләнеше бер түгел. Синең тамырларда агулы кан ага. Кунагыңны якты йөз белән дә каршылый белмисең. Бүре кайчан да бүре булып кала...»

Гүя, аның уйларын утәли күреп торгандай, Бүре Бадул сусарган сакал эченнән сүзләрен сыгып чыгарды:

— Усаллашып утырма син, Садыйк малае. Кемнең гөнаһысы купме икәнен үлчәргә без Пәнҗәр побы түгел. Утыр, әйдә, эчегән бал эчәсеңме?

Кирәкми иде Солтанга бал эчү. Ләкин аңарда да бу минутта Айдарлар нәселеннән килә торган ярсулы кан уянган иде.

— Эчәм! — диде ул, усал ат кебек башын чайкап.

Гыйбадулла Ядкаров дүрт чиләк сыешлы агач мичкә күтәреп керде. Башын артка ташлабрак, кружкадагы балны бер сулышта

эчеп бетерде, каты итеп тамак кырды һәм шундук тыелгысыз бер ярсу белән сөйли башлады:

— Мин синең ник килгәнеңне беләм, Садыйк малае. Син минем ничек яшәгәнемне, нинди уйлар уйлаганымны белергә килгәнсең! Кайткан дигәч тә, уйлап куйдым,— килми калмас. И дөрес тә булып чыкты. Килдең! Белми бу дип, караңгы бер томана бу дип ялгышма, алдан ала белеп торам — Айдарныкылар тормышның кайнап торган агымында яшәүчеләр. Чүп-чар белән, вак-төяк белән кайнашмады Айдарныкылар. Әйе, кайнашмады! Нык холыклы, тамырлы-тамырлы кеше сез. Юк, мин бу сүзләрне әтиегез Садыйк картка карап әйтмим. Ул кол иде. Байбәтчәнең куштаны булды. Шулай дөмекте. Сезнең кан — Айдардан. Шакир хаҗиларга, Алабуганың урман хуҗаларына каршы бунт күтәреп, себер киткән Айдардан сезнең кан. Шәяхмәтнеке дә, синеке дә, хәтта ки әлерәк кенә Зартугайга кайтып төпләнгән ата пролетар Мөхәммәтшаныкы да!

Урмандай куе ала сакалы эченнән әрсез бер елмаю белән елмаеп, беркавым тын утырды. Аннары урыныннан кузгалып, өй эчен бер айкап килде. Үзе кебек үк таза, нык бүрәнәгә лапылдап килеп утырды.

— Әммәдәки мине бер сорау галәмәте борчый: бәхетлеме Айдарныкылар? Юк, син, Садыйкның төпчеге, мине тынычландырырга ашыкма. Бәхет сүзен мин коммунистлардан күп ишеттем. Мин сезнең андый сүзләрегезгә мохтаҗ түгел. Минем үз бизмәнем бар, балны мин үз бизмәнемә салып үлчим. Болын чәчәгеннән җыйганмы, карабодайданмы, әллә юкәдән үкме? Акылның да миңа кешедән отканы түгел, үз башымда туганы кадерлерәк. Тансык миңа андый акыл. Җитлекмәгән кәбестә төсле бәләкәй башлы кешеләрнең үзләренә юк акылларына төкерәм мин!

Ачы балдан һәм кайнарланып сөйләүдән ул тирләп чыкты, чалгы пәкесе белән тап-такыр итеп кырдырган йомры башын өстәлдә яткан шакмаклы тастымал белән сөртергә кереште.

— Бәхет дидемме әле? Бәхет ул, Садыйк малае Солтан, әгәренки бик беләсең килсә, рәхәт белән михнәт арасында эленеп тора. Әйе, рас, нигә күзеңне тасрайтасың? Син миңа теге заманнарда Габбас мулланың авылга дан Нөркәен әләктереп киткәч, сөенгәнсеңдер. Бәхеткә чумдым дип уйлагансыңдыр. Инде миңа шул чибәр-чураман өчен партиядән куылгач, сиңа рәхәт түгелдер. Шулаймы?

Солтан сүзнең кинәт шундый борылыш алуына, алай гына да түгел, нәкъ менә партҗыелышта Нух Галләм әйткәнчә килеп чыгуына чамасыз гаҗәпләнеп, урыныннан тора башлаган иде. Бүре Бадул аның җилкәсенә гердән дә авыррак йодрыгы белән бер генә басты — Солтан янә дә түмәркә өстенә лып итеп утырырга мәҗбүр булды.

— Тыңлыйсың килмиме? Әһә! Тыңларсың! Тыңлатырбыз! Мин чакырып китермәдем сине, үзең килдең, үзең минем дөньяма бәреп кердең.

Соңгы сүзләр Солтанны таң калдырды. Карасана, ул ничәмә-ничә еллар китаплардан укып белгәнне авылның гап-гади бер крестьяны аның йөзенә бәреп әйтеп тора: «Минем дөньяма бәреп кердең!» — ди.

— Соң шуннан? Нәрсә әйтмәкче буласыз, Гыйбадулла абзый?

— Мин бер генә нәрсәне әйтәм: бәхет — рәхәт белән михнәт арасында. Гомер-гомергә шулай булган. Теге чакта дөнья синеке иде, хәзер — минеке.

— «Минеке» дигәнен ничек аңларга боерасыз, Бүре Бадулла? — диде ачуы бер йомгакка төйнәлеп җиткән Солтан.

— Минеке, ягъни энем Галләмнеке, кызым Нисаныкы, улым Мифтахныкы, башка чыккан уллары Җиһангирныкы, Тәхәвинеке.

— Йә, йә, ни өчен сез аларны бәхетле дип санийсыз?

— Дөньяның бугазыннан умырып тотып, чүп-чарын коеп яши беләләр минем балаларым. Син, Солтан, минем энем Галләм белән мәдрәсәдә укыдың. Син минем Галләмем белән ат чабышына бардың. Син аны уздың. Син аны егып калдырдың. Ә менә бүген... ул сине егып калдырды. Югыйсә син миңа килә торган кешемени? Айдарныкылар Бүренекеләргә килә торган кешемени?

Солтанның җанын басып килгән ачуы кинәт юкка чыкты. Аның урынына акылы өзлексез бер хакыйкатьне тукый башлады.

«Син бирегә килеп дөрес эшләдең. Син боларның мәкерле кеше икәнлекләренә тагын бер тапкыр ышандың. Димәк, алар вакыты җиткәнче генә сарык тиресе ябынып йөриләр. Вакыты җиткәч, сарык тиресен салып ташлап, бүрегә әйләнәләр. Син моңа нык ышандың. Үз күзең белән күреп. Үз колагың белән ишетеп. Инде хәзер синең өстеңнән дә, Чишмәбай өстеннән дә язган кешеләрнең болар икәненә шигең юк. Бер гамчы да! Син үзеңнең чыннан да хаклы икәнеңә, үз хакыңны даулап көрәшергә кирәк икәненә иман китердең».

Солтан кинәт кенә урыныннан торды, Бүре Бадулга җилкәсенә кулын салырга ирек бирмичә, китәргә җыенып әйтте:

— Ярый, Гыйбадулла абзый. Сый-хөрмәтең өчен рәхмәт. Мин китим. Мине өйдә югалтканнардыр.

Кайда гына булмасын, гел өстен чыгарга, ни генә әйтмәсен, хаклы булып калырга гадәтләнгән Бүре Бадул кинәт хәвефкә калды: тукта, нигә килде бу мөртәт? Ник ашыгып китә? Авыз ачып ни актан, ни карадан бер сүз әйтмәде, мине сөйләндереп утырды да, кирәкле мәгълүматын алып бетергәч, инде китеп тә барамыни? Ул акыллы, мин дурак булып каламмыни?

— Юк, Айдаров, китмисең. Без әле сүзнең төбенә төшмәдек,— дип, бүре Бадул аңа таба килә башлаган иде, килеп җитә алмый калды, ишектән иелеп укытучы Зәйни Моратов килеп керде. Аның өстендә мәктәпкә йөргәндә кия торган затлы киемнәр түгел, кырга чыккан чакта кия торган яшькелт җилән, башында да эшләпә түгел, ямьшәйгән кепка, аягында күн итек иде. Аның мондый күренеше Гыйбадулла Ядкаровны каушатып җибәрде. Чөнки мәктәп директоры Моратов бер үк вакытта колхозда ревкомиссия башлыгы да булып эшли иде. Аны бит бирегә председатель Миңнулланың җибәргән булуы ихтимал. Гөнаһ шомлыгы — каршыда кунак, партиядән чыгарылган Айдаров, өстәлдә — мичкәсе белән ачы бал. Менә сиңа мә — каптым дисәм дә каптым.

Ләкин укытучы Моратовның сакал-мыексыз алсу-туткыл йөзендә усал нитят белән килү бер дә сизелми иде. Ул, башындагы аксыл-яшькелт кепкасын салып, укытучыларга хас әдәплелек белән, алга иелә төшеп исәнләшкәч, әйтте:

— Гыйбадулла абзый, мин сезнең хәлне белергә дип килдем. Ни эшләр бетерәсез? Исән-сау гына торасызмы? Бал кортларына ел килеше уңай булды шикелле? Яңгыры да, кояшы да, дигәндәй. Бу иптәшне кем дип белик?

Әле генә сырт йоннарын кабарткан, саллы-авыр сүзләрен тимер чөй кебек итеп мигә кагып кертергә тырышкан Бүре Бадул күз алдында үзгәрде. Кашны-башны җимерми, тавышны да бөердән чыгарып сөйләшми, урман күгәрчене кебек гөрләп кенә тора.

— Эшләр ярыйсы, иптәш сыйфат комиссиясе. Үзем дә борчылыбрак тора идем әле, нишләп, мәйтәм, Зәйни иптәш күренми? Балны суыртыр вакытлар да җитә, мәйтәм, кайчанрак ул эшне башлап җибәрербез икән? Колхоз идарәсе, мәйтәм, миңа быел ничә кеше бирер ярдәмче итеп? Сөяк-санагын җыя алмаган карт-корыны җибәрерме, әллә җилдән житез яшь-җилкенчәк килерме? Ә моны кем дисезме? Бу — безнең Зартугайның үз кешесе, атаклы Айдарлар нәселе бу, Зәйни иптәш. Казан каласында яши. Авыл хуҗалыгыннан зур бел-

геч, заманасында жир тетрәтеп йөргән большевик Солтан Айдаров, без аның белән икәү бергә революция өчен кан койдык.

Солтан сүзсез генә карап тора. Күңеленнән уйлый: «Каян килә кешегә шундый җитезлек? Ни арада сөйләве, ни арада мичкәдән калай кружкаларга бал агызуы?»

Әмма ягымлы-юаш кыяфәтле укытучы Моратов кирәк чагында холыклы да була белә икән. Ул балдан баш тартты.

— Гыйбадулла абзый, мин сезнең янга зур бер йомыш белән килдем бит әле,— дип, кулына тоткан кепкасын өстәл өстенә куйды, җиләнен салып, стена буендагы озын эскәмиягә ыргытты.

— Ярый, сезнең икәү генә сөйләшәсе сүзегез бардыр. Мин кузгалыйм, булмаса,— диде Солтан.

— Ашыкмый торсагыз иде, иптәш Айдаров. Мин сезне ишетеп беләм. Сез миңа бик кирәк. Бергә кайтырбыз. Әле сөйләшәсе сүземдә сезнең кирәк булуыгыз бик мөмкин,— дип дустанә елмайды.

Солтан, укытучы кешегә каршы килергә ничектер базмыйча, шулай да шактый ук уңайсызланып, тагын баягы түмәркә өстенә килеп чүмәште. Белеп тора: Бүре Бадул аның китмәвен өнәми. Әмма, берни дә кылыр хәл юк, укытучы үтенде. Ул калды, үзе дә директорны күрермен, Шәфика турында да, Мәхмүт белән Әхмәт турында иркенләбрәк сөйләшермен дип ниятләнеп тора иде.

— Хикмәт менә нәрсәдә, Гыйбадулла абзый,— дип Зәйни Моратов сүзен бик җитди итеп башлады.

— Сабыр! Бер генә минут! Сүзеңне онытмый тор,— дип, умартачы ишектән чыгып китте. Солтан аның учак көлен актарып, йомычкалар, коры ботаклар салганын, ут дөрләп киткәч, корымлы кара чәйнеккә су салып кайнатырга куйганын күрде.

Өйгә әйләнеп кергәч, Бүре Бадул әйтте:

— Инде менә сөйлә, мөгаллим. Бер дә тартынмый сөйлә. Ул арада чәй дә кайнап чыгар.

— Хикмәт менә нәрсәдә,— дип, Моратов баягы сүзен кабатларга мәҗбүр булды.— Мин бүген сезнең янга ревкомиссия председателе булып түгел, мәктәп директоры буларак килдем.

— Бәрәкалла, шуннан?

— Миңа сезнең улыгыз кирәк.

— Кайсы улым? Улларым күп минем.

— Төпчек улыгыз Мифтах. Тегеләре инде үзбаш яши. Аларының инде мәктәп белән алыш-бирешләре юк.

— Ярый, хуп. Улым Мифтах синә нигә кирәк булды?

— Мин аны мәктәпкә эшкә чакырырга килдем.

— Нинди эшкә?

— Хуҗалык эшенә — завхоз ярдәмчесе булырга.

— Торып тор, бу соң корыны бушка аудару түгелме?

— Юк, Гыйбадулла абзый, мәртәбәле эш ул. Без бит Зартугай җидееллык мәктәбен, Салагыштагы кебек, урта мәктәпкә әйләндерергә йөрибез. Бик күп яңалык кертергә, Зартугай мәктәбен әйләнә-тирәдәге үрнәк мәктәп итәргә ниятләнәбез.

Инде күңеле тынычланып өлгергән Гыйбадулла Ядкаров Солтан алдында үзенең дә төшеп калганнардан түгел, мәктәп директоры белән аяк терәп сөйләшерлек кеше икәнен күрсәтергә уйлады.

— Торып тор, сезнең ул «ниятләнәбез» дигәнегез һавадагы торна түгелме? Буш куыкларны мин үз гомеремдә күп күрдем. Төпчегемне мин үз урыныма умартачы итәрмен дигән идем.

— Карагыз әле, Гыйбадулла абзый, сез мине рәнҗетәсез. Минем буш сүз сөйләгәнемне сез кайчан ишеттегез? Исәнбай мәктәбендә эшләгәндә, без бишенче класс укучылары белән бергәләп, будильник сәгатенең механизмнарын кулланып, телеграф аппараты булдырдык. Лакланше элементы ярдәмендә электр тогы алуга ирештек. Мәктәп-

нең үзендә Исәнбай сельпосының бүлекчәсен оештырдык. Укучы балаларны сатучы ролендә күрү сәер, әлбәттә. Ләкин ни хәл итмәк кирәк,— заманасы шундый. «Минем җаныем шундый уңган — гармунчы да, җырчы да!» Мәктәптә уку әсбапларын гына түгел, өс-баш киемнәрен сатуны да оештырырга кирәк. Мәктәп янында яшелчә бакчасы, алма бакчасы, куян фермасы булдырырга кирәк. Юкса без кайчан өйрәтәбез балаларны эшкә. Трактор китерергә, тракторчылар курсы ачып җибәрергә кирәк.

— Ничек, иптәш Айдаров? Сез — авыл хуҗалыгы белгече. Булырдай эшләрме бу?

— Энергичный кеше көне-төне чапса, булачак.

— Рәхмәт, иптәш Айдаров. Менә шундый эшкә мин Гыйбадулла абзыйның улы Мифтахны чакырам.

— Нәрсә, Зәйни мөгаллим, син минем малайны мәктәпнең сәүдәгәре итмәкче буласыңмыни?— диде Гыйбадулла Ядкаров, юри кыланып.— Уйлап эшләгән эшеңме бу синең? Әнә Айдарныкылар ул эшкә теше-тырнагы белән каршы бит!

— Сез, Гыйбадулла абзый, юкка минем вазифага керәсез. Сатучы итеп чакырмыйм мин улыгызны. Завхоз ярдәмчесе итеп чакырам. Миңа җиңел сөякле, булдыклы, таза үсмер кирәк. Ике-өч елдан үзе завхоз булырлык. Зартугайны терәк мәктәп итеп районда гына түгел, республикада күрсәтә белүче кирәк миңа...

— Мифтах шуны булдырыр дип ышанасыңмы?

— Өч ел практика узса, булдырачак.

— Аңа ничә яшь икәнен беләсеңме?

— Үндүрте тулды. Белеме җиде класс. Кемгә тәтегән бу заманда андый белем?

— Ярый. Ул да хак. Белеме дә булсын ди, хуҗалык алып барыр өчен усаллык кирәк бит, тешләгән җиреннән өзә торган кеше.

— Анысы да бар Мифтахта.

— Каян беләсең?

— Мин бит аны мәктәп өчен буяудыр, кадактыр ише нәрсәләр кирәк булгач, язын, апрель аенда Казанга алып бардым. Хәтерегездәме?

— Барганын беләм.

— Алайса әйтим. Колхоз базары янында ул җирдән бер тәңкә акча тапты. Баксаң-күрсәң, андый акчаны кесә карактары юри ташлыйлар икән. Бәйләнә башлады Мифтахка өч үсмер. Безнең акчаны алдың, диләр. Кесәсен актармакчылар. Бал саткан акчасын алмакчылар.

— Кит аннан! Ул бит аны миңа әйтмәде.

— Егет кеше күп сөйли торган булмый ул. Ярый, караклар моңа бәйләнепме бәйләнә. Нишләде диген улыгыз?

— Нишләде?

— Әкрен-әкрен чигенде. Таш коймага арканы терәп куйды да беренче килгәненең битенә дагалы күн итек үкчәсе белән берне тондырмасынмы!

— Нүжәли?— диде Гыйбадулла Ядкаров, авызын ачып, урыныннан торды.— Йә, йә, шуннан?

— Кесә карагы, акырып, җиргә егылды.

— Ә икенчесе?

— Икенчесе дә җиргә капланды. Өченчесе шундый әлдерде, чаптар ат белән дә куып җитә алмассың!

Бүре Бадулның борын канатлары киерелде, тыны кысылды:

— Минем малаймы? Мифтахмы? Бәрәкалла! Мин бит аны җен әвәләгән малай, булдыксыз, җебегән дип, тагын әллә нәрсәләр дип тиргим. Менә кайда бүре нәселе баш калкыта! Ал минем малайны, Зәйнетдин, рас син аны таныгансың, ал, олы юлга чыгар, кеше ит! Тукта, торып тор. Мәктәп бакчасы дидең. Умарталык та буламы анда?

— Әлбәттә. Җиләк-җимеш бакчасы да булачак. Колхозның яңа белгечләрен, агрономнарын үстерергә ният.
— Ә кем өйрәтә аларны?
— Биология укытучысы. Районнан язларын агроном чакырырбыз.
Умартачының күңеле алгысыган иде бу минутта. Ул үзен яшь чакларындагы төсле ирекле, гайрәтле, бәхетле итеп сизә иде.
Зәйни Моратовның китәм дип ашкынуына да карамастан, ул аны туктатып кала алды, мәтрүшкә, бөтнек үләне салган хуш исле урман чәе белән, кәрәзле бал белән сыйлады.
Ул мөгаллимне һәм Солтанны (тешен кысып булса да!) авылга кадәрле ат белән илтеп куярга ниятләде. Әйдә, аңардан булсын яхшылык!
Ләкин — үкенечле хәл — тегеләр ат белән кайтудан баш тарттылар.
— Зартугай ерак түгел, шуның өчен генә җәйге челләдә ат алҗытып йөрмәгез. Әнә кояш та баерга якынлаша, кичке салкынча һавада җәяү генә кайтырбыз,— диде Зәйни Моратов.
— Җаны теләгән, җылан ите ашаган,— диде Бадул саубуллашканда.
Кояшның кичке җете нурларыннан серлерәк булып калган умарталыктан чыгып, ярты чакрымнар чамасы киткәнче, сүзсез генә атладылар.
Кура җиләге аланнары, шомыртлыклар очрады. Биек наратлыкка килеп керделәр — ниндидер бер ачыклыктан кыеклап төшкән кояш нурының нарат ябалдашларын алтын-сары төскә манганын күреп, туктап карап тордылар.
Әнә шул наратлыкта, җанны кинәндерә торган хуш исле биек агачлар арасында, күләгәле аулакта, Моратов беренче булып сүз башлады:
— Солтан абый, мин сезнең хакта да, хатыныгыз Нурия апа хакында да күп ишеттем. Сезнең икегезне дә авылда бик олылап сөйлиләр. Зартугайдан чыккан иң беренче югары белемле кешеләр дип горурланалар.
— Рәхмәт җылы сүзегезгә.
— Ә Шәяхмәт Айдаров, Пәнҗәр райкомының беренче секретаре, сезнең берәр туганыгызмы, әллә сез фамилиядәшләр генәме?
— Ул минем абыем.
— Айдаровлар... Атаклы фамилия. Минемчә, Шәяхмәт абыегыз профессиональ революционер булган? Гыйбадулла абзый сезнең хакта да, гражданнар сугышында бергә кан койдык диде шикелле? Сез аның белән бергә идегезмени?
— Мин Азин дивизиясендә сугыштым. Гыйбадулла Ядкаров Алабуга урманнарында партизаннар отрядында йөрде. Шәяхмәт абзыйны үлем баржасыннан коткарды.
— Ул хакта да ишеткәнем бар. Димәк, дөрес сөйлиләр. Мине гафу итегез, Солтан абый, никтер ул миңа ышанычсыз кеше кебек тоела. Сез аны якыннан беләсезме?
— Дөресен әйткәндә, иптәш Моратов, мин аны унбиш еллар чамасы күрмәгән идем. Бала чакта күршеләр идек. Аның абзыйсы — Салагышның Кысык Минҗан гражданнар сугышы чорында бернichә кешенең үлеменә сәбәпче булды. Кысык Минҗан улы Нух Галләм белән без икәү бергә мәдрәсәдә укыдык. Гражданнар сугышы чорында да тәртәләр бәрелеште. Ак офицер иде Галләмов.
— Әле дә исәнме?
— Исән. Казанда яши.
— Ничек исән кала алды?
— Әйтүе кыен. Заманга җайлаша белә, күрәсең.
Солтан үзе белән килеп чыккан хәлне дә сөйләп бирмәкче иде, ләкин тыелып калды. Моратовның ялгыш уйлавы, шәхси үчен ала дип нәтиҗә ясавы мөмкин...

— Сезнеңчә ничек? Мин аның улын эшкә чакырып, дөрес эшләдемме?

— Ничек дип әйтим? Аттан ала да туа, кола да туа. Олы уллары Тәхәви — бөтенләй башка кеше. Бүре нәселе дип башка да килмәс. Ягымлы, ярдәмчел. Бармагы да үзенә кәкре түгел.

— Анысы кайда соң?

— Минемчә, Зартугайда. Әтисеннән аерым яши. Инде үзенең өч баласы бар. Такта яручы. Тегермәнче Чишмәбай белән бергә җәмәгать каралтыларын салышкан. Әтисе белән йөрешмиләр имеш.

— Һы. Менә син, ә...— дип уңайсыз елмайды Моратов. Озак вакытка тынды.— Ә кызлары Ниса?— диде ул, урманнан авыл кырыена килеп туктагач.— Анысын беләсезме?

— Юк, анысын белмим.

— Ә Җиһангирлары?

— Анысын бөтенләй дә белмим. Яуморза ягында урман каравылчысы булып эшли бугай.

Авыл башына килеп чыккач, Моратов Солтанны туктатты.

— Иптәш Айдаров... бик тә гыйбрәтле нәрсәләр әйттегез бит әле сез миңа. Мифтахны чакырып ялгышмыйммы икән мин? Әллә тагын бер уйлап карарга мы?

— Беләсезме, иптәш Моратов, мин сезгә бернәрсә дә әйтмәдем диярлек. Мин бары тик пәрдәнең бер читен генә күтәреп, пәрдә артындагы тормышның бәләкәй генә бер өлешенә игътибарыгызны юнәлттем. Калганын белү — сезнең карамакта.

— Рәхмәт, акыллы сүзгә.

— Минем сезгә бер үтенечем дә бар бит әле, Зәйни иптәш. Быел сез җитәкләгән мәктәпнең беренче классына ике игезәк керәчәк. Әхмәт белән Мәхмүт. Алар Габбас мулла үлгәннән соң туган балалар. Үги әтиләре Чишмәбай бәлагә тарыган — кайда ул, берәү дә белми. Мин әнә шул балаларны күздән ычкындырмавыгызны үтенер идем.

Моратов, кесәсеннән бәләкәй блокнот чыгарып, малайларның исемен язып алды.

— Яхшы. Тагын нинди үтенечегез бар, Солтан абый?

— Башка үтенечем юк. Бер соравым бар.

— Әйтегез.

— Шәфика Уразаева быел ничәнчене бетерде?

— Бишенчене.

— Әйбәт укыймы?

— Әйбәт дип әйтү генә азрак булыр. Ул хәзер — безнең җидееллык мәктәпнең горурлыгы. Уйлап кына карагыз, уникe яшендә — шәхес! Музыка, җыр, бию — барысы аның карамагында. Рус әдәбиятын гөрләтеп укый, русчаны гөрләтеп сөйләшә. Татарчаны шул ук дәрәҗәдә белә. Ялгышмасам, ул русчаны сездә, Казанда чакта өйрәнгән. Рус мәктәбендә укыдымыни?

— Әйе. Без аны быел тагын Казанга алып китәбез.

Моратов кинәт күңелсезләнде.

— Җәл. Үкенечле. Мәктәпнең ярты ямен алып китәсез икән, Солтан абый.

Юлның калган ягын сөйләшми диярлек кайттылар.

Зәйни Моратов та, Солтан да үз өйләренә күмелгәннәр иде.

## VIII

Хәнифә аларны тыныч күңел белән, бер дә каушамыйча каршы алды. Чөнки ул инде аларның кайтканнарын кызы Шәфикадан ишеткән, көндез үк булмаса да, кичен бер сугылачакларына шикләнми иде.

— Бәрәкалла! Кала кунаклары кайткан икән. Әйдүк, әйдүк, төкле аягыгыз белән! Кызым әйткәч, күңелемә килде, мәгәр болар тегермән яннарын урамыйча түзә алмаслар дидем. Исән-аман гына кай-

тып життегезме? Пырахутларда бик кыен булмадымы? Балалар авырмадымы? Шушымыни Рафаел? Каяле, минем нәни кызым Санияне күрсәтегез әле,— дип сөйләнә-сөйләнә, Хәнифә тути әнисе артына яшеренгән сабыйны күтәреп алды.

Ул башына чытыр ак яулык бәйләгән, бала итәкле зәңгәрсу сатин күлмәк өстеннән ап-ак халат киеп куйган, аягында кызыл эчле тирән калош — сепараттан гына кайтып торуы булса кирәк.

Солтан инде каралты-кураны бер мәртәбә күргән булганга, йорт-җиргә ачалакланмады. Әмма яхшыны яхшы дип әйтмичә түзә алмый торган Нурия өйне бер мәртәбә күргән булса да, лапасны, бурабзарны, ак мунчаны, келәтне, чарлаклы итеп салган алты почмаклы йортны тагын бер мәртәбә карап-барлап чыккач:

— Гел дә кала суккан төсле булган бу, түтәй!— диде.

— Йорт-җирне житкезгәниек анысы, гөлкәем Нурия, әтиең заманнарындагы төсле итеп житкезгәниек, бигрәкләр дә уңган кеше ие бит Каюм абыең. Курше-колан да исе китеп, таңнар калып торадырые шул... Бигрәкләр дә көтелмәгәндә булды. Күршеләр әйтә, ялгышлык беләндер, кайтыр, диләр. Күршеләр дә бик кызгана Каюмны, үземнең дә жыламаган көнем юк. Балаларым да бигрәк яшь бит — аяксыздан кулсыз дигәндәй...

Хәнифә Нуриядән бишме-алтымы яшькә генә олы иде. Әмма ул теге чакта, Габбас мулланың кече хатыны булгангадыр, Нурия өчен инде олы кеше булып санала. Баксаң-күрсәң, ул чагында Нуриягә унике, Хәнифәгә нибарысы унжиде яшь булган икән әле. Шул чактан калган гадәте буенча Нурия аңа әле дә түтәй дип дәшә.

Әмма түтәй дигәнебез Нуриядән яшьрәк күренә түгелме соң? Зәңгәрсу сатин күлмәк, ак яулык, ап-ак халат, чулпы таккан озын кара ике толым (алары халатны салгач чыңлап килеп чыкты!), күкрәкчә-мазар кимәсә дә, ныклыгы белән калкып, тырпаеп торган мул күкрәкләр аның әле менә хәзер генә тулып пешеп житкәнен, бәхетле тигез тормыш белән яшәргә хаклы икәнен әйтеп торалар иде. Аның әнә шулай теләсә кем күзе төшәрлек таза-матур булуы, бит алмаларының алсуланып-янып торуы, авыр кайгы алдында да үзен мескен итеп тотмавы, бер яктан, Нурияне сөендерсә, ә менә шул бәхет дигәннәренә ирештем дигәч кенә янә дә ирсез калуы көендерә иде. Икенче мәртәбә тол кала кеше. Икенче мәртәбә итәк тулы бала белән кала бит.

Көянтә-чиләк белән су күтәреп, аларның авырлыгыннан сыгыла төшеп, Шәфика кайтты. Аның шушы ике ел эчендә сузылып китүенә таң калып, Нурия сеңлесенең җилкәсендәге көянтә-чиләкләрен җиргә алып куйды.

— И балам, нигә шул хәтле авыр күтәрәсең? Кечерәк чиләкләрегез юкмыни?— диде ул. Сеңлесе белән күрешергә дип, ике кулын берьюлы сузган иде, тегесе күңелендә ташыган хисләрен тыя алмыйча, апасын нәзек беләкләре белән муеныннан кочаклап алды. Нуриянең кайдадыр эчтә, күңел түрендә сакланып килгән туганлык хисләре кинәт кабынып, күзләрен яшь пәрдәсе каплады.

Солтан тизрәк читкә китүне кирәк тапты. Лапас күләгәсенә кереп, ботак чаба торган бүкән өстенә чүмәште.

Биредә салкынча. Сайгаклык тактаны утыртып эшләгән лапас стеналарына арата кагылган, араталарга өтергедер, кул пычкысыдыр, игәүдер ише столярлык кораллары кыстырып куелган; пөхтә итеп ясалган бәләкәй бер киштәдә ышкы, тигезләгеч, тагын нәрсәләрдер бар — боларның һәммәсен Чишмәбай әзерләгән, инде менә хуҗаларның юклыгыннан боегып яталар...

Ул, авыр көрсенеп, лапастан чыкты. Кояш инде баеган, шәфәкъ нуры тәрәзәләрдә кабынган, капкадан кереп килгән аклы-каралы ике казны, алар артыннан ияргән бәбкәләрне алтынга манып күрсәтә; моң-

су, әллә ничек моңсу да, күкрәкне чәнчеп тора торган басынкы бер сагыш та бар, адәм баласының олылыгы, бөеклеге, кабатланмас зат булуы күңелдә яңара; йә ярсып бер кычкырасы, йә аунап бер җылыйсы килә иде.

Ишегалды уртасында, аякларны аерып баскан хәлдә, Солтан Айдаров каралты-кураны тагын бер мәртәбә күздән үткәрде. Шулар янына тау башындагы җәмәгать амбарларын, тегермәннән ерак түгел, канау буена тезелгән терлек абзарларын, урман умарталыгындагы зәңгәрле-сарылы умарта өйләрен китереп куйды, су белән суга торган ындырларны китереп куйды — менә шуннан соң аның күз алдына Алып батырдай зур булып Чишмәбай образы, аның дөньяны яңартыр өчен, бизәр һәм матурлар өчен яратылганлыгы тулысы белән килеп басты...

Кулларына кармак чыбыклары һәм берәр тезмә балык тотып, ике малай кайтып керде. Солтан аларның Габбас мулла үлгәч туган игезәкләр икәнен абайлады. Капка төбендә туктап калган, чит абый белән күрешергәме-юкмы икәнен белми басып торган ике кара чутыр янына килеп, балык тезмәләрен әйләндерә-әйләндерә карады да, малайларны шаккатырып:

— Син Мәхмүт, ә син Әхмәт, әйеме?— диде.

Малайлар көлешеп алдылар.

— Ә син каян беләсең?— диделәр икесе берьюлы. Аларның чалбар балаклары да, күлмәк җиңнәре дә сызганулы, битләре, беләкләре, аяклары чуен төсле булып кояшта янган иде. Алар икесе дә шешенке кабаклы, ияктән маңгайга таба киңәеп киләгән битле — Солтан малай чакта, аннары Нуриягә өйләнгән чакта күргән Габбас муллага ике тамчы су кебек охшаганнар иде. Бер үйласаң, исләрең китмәле бу табигатьнең могҗизасы!

Малайлар аңардан җавап көтеп торалар иде.

— Каян беләсең дисезме? Ничек инде белмим ди? Сезнең берегез Мәхмүт, берегез Әхмәт булырга тиештер бит инде? Әллә киресенчә — берегез Әхмәт, берегез Мәхмүтме?

Шаярту уңышлы чыкты. Малайлар сөенешеп көлделәр. Һәм шул минуттан Солтан абыйларын дус күрделәр.

Өйгә кергәч тә алар, балык тезмәләрен әниләренә тоттырып, кунак абыйларына һөнәрләрен күрсәтә башламакчылар иде, әниләре балыкның ваграгын песигә сайлап алып, калганын коштабак белән үзләренә кире кайтарып бирде.

— Барыгыз. Ишегалдында чистартыгыз. Карагыз аны, чүбен, тәңкәсен теләсә кая чәчмәгез. Тизрәк, яме! Кунак абый белән кунак апайны сез тоткан балык белән сыйлап җибәрик әле бер. Алар сезгә әнә нинди күчтәнәчләр алып кайтканнар.

— Кайда? Кайда?— диештеләр малайлар, әсәренеп.

— Балыкны чистарткач, балыкны!— диде әниләре.

Малайлар, коштабакны күтәреп, ишегалдына йөгерделәр.

— И дә тиктормаслар инде менә. И дә йөремчәкләр! Төчкәнеч инеше дә, ындыр табагы да, бозау киртәсе дә калмый. Урманга җиләккә, мәтрүшкәгә барып чыгалар. Хәттинки Ары як болыннарына — Минзәлә ягына тиклем барып җитәләр.— диде Хәнифә, самавырын урләтә-урләтә.— Менә әле бу нарат күркәләрен дә кәрҗин белән алар апкайтып тора. Кәрҗинне Чишмәбай абыйлары үреп биргәние...

Стенада эленеп торган скрипканы күрсәтеп, Солтан сорап куйды:

— Әллә скрипкәдә дә уйныйлармы?

— Уйнамаган кая! Гармун уйный Мәхмүт, скрипкә уйный. Башта скрипкәдә Чишмәбай уйныйдырые, аңардан күрмәкче Мәхмүт зыңгылдатырга тотынды. Ай-һай, үзсүзле малай, колакларымны тондырып бетерде. Ачулансаң — мунчага барып уйный. Җүнлелеккә булыр микән ул, Солтан?

— Җүнлелеккә. Күңелен бездерә күрмәгез. Әллә скрипкәне дә Чишмәбай ясадымы?

— Ул ясамый кем ясасын! Үз кулы белән ясап бирде Мәхмүткә. Кечкенәрәкне, җайлыракны. Тыңлаган саен җылый авыл картлары...

— А-ла-ай,— диде Солтан сузып кына. Ә үзенең күңелендә дөньяның Моцартлары, Шопеннары, Чайковскийлары айкала иде. Әллә, ходаем, Зартугайда да бер даһи туып киләме?

Хәнифәнең соңгы сүзләрен ишетеп, почмак яктан Нурия чыкты.

— Әнекәйгенәем! Сигез яшьлек Мәхмүт скрипкә уйныймы?

— Уйный, җаным, уйный. Уйнамаган бер генә уен коралы да юк. Авыл көтүчесе белән көтүгә чыга. Көне буе аның быргысын кычкырта; кызлар-егетләр белән аулак өйгә бара — гармун уйнатып, теңкәсенә тияләр. Ул гынамы? Кесәсе тулы сыбызгы, каен тузы. Сандугач булып сайрый, әтәч булып кычкыра, күгәрчен булып гөрли, мәче булып мыраулый, эт булып өрә, чиный, [illegible]... Әкәмәт инде, әкәмәт! Тиатырга Мәхмүтне генә йөртәләр. [illegible] артыннан бөтен тавышны ул гына чыгарып тора. Тиле кеше әйтмешли, тагын бер мәртәбә сорыйм әле: җүнлелеккә булыр микән ул, гөлкәйләрем?

— Ә Әхмәт нишли? Әхмәт?— диде Солтан.

— Анысына гармун да, скрипкә дә кирәкми. Анысы кәгазь буйый, сурәт төшерә. Куяны да калмый, маэмае да. Дәфтәр бите саен әтәч сурәте — кып-кызыл кикрикле! Язуга тотасы дәфтәрләрен сурәт белән тутыргач, Чишмәбай бахыр, аңа бик калын дәфтәр алып биргәние инде. Туйганчы буя, дип. Буйый инде, җаным, буйый. Чишмәбаем гына күрә алмый шуларны...

Көрсенешеп куйдылар. Тынлык булып алды. Хәнифә Әхмәтнең фанер букчасын Солтанга китереп тоттырды: «Менә мә, кара, син укымышлы кеше, дөрес хәлме бу, түгелме?»

Солтан букчадан иплән кенә калын бер дәфтәр тартып чыгарды. Актара башлады. Анда казлар, әтәчләр, куяннар, атлар, сыерлар гади карандаш белән дә, буяу карандашлары белән дә күп итеп ясалган. Бит саен биш-алты. Солтанны гаҗәпләндергәне шул булды — рәсемнәр кылдый-былдый сызыклар гына түгел, туры нык сызыклар белән ясалган иде.

Нәни рәссамны уңайсыз хәлгә куймас өчен, Солтан букчаны бик әллә ни җәелеп актармады, дәфтәрләрне иплән кенә үз урынына салды да әнисенә тоттырды, ә күңеленнән: «Габбасның нәселе бетмәгән икән әле, әнә нинди талантлы балалары калган,— дип уйлады.— Ләкин әле аларны үстерәсе, кеше итәсе бар».

Шул минутта аның күңелендә бер яктылык балкып алды. Тукта, ул бит әнә утыз җиде яшеннән пенсионер булганы өчен гасабилана. Ә нигә аңа менә шушы балаларның тәрбиясе белән шөгыльләнмәскә? Нигә аларның үсүен, укуын, үзләре теләгән юнәлештә тәрәккый итүләрен барлап бармаска? Нигә гомеренең калган өлешен аларга багышламаска?

Табын янында Солтанны уйланырга мәҗбүр иткән тагын ике нәрсә булды. Берсе — өйдәге чисталык. Идәннәр сары гәрәбә итеп юылган, тәрәзә пыялалары шундый да пөхтә итеп сөртелгән, гүя анда пыяла да юк кебек. Икенчесе — оста кулы. Түшәм сайгакларын балта остасы шундый да тигез итеп кыскан, ике сайгак арасындагы ярык дәфтәр битенә сызылган сызык кебек кенә күренә. Стена буенда кулдан ясалган шкаф тора — ящиклары бар, киштәләре. Гап-гади үзе, әмма матур, пөхтә. Мич өйнең урта бер җирендә түгел, почмакта — зур мич, ипи сала торган. Үзе кершәндәй ак. Стенада бәләкәй генә сәгать, келт-келт итеп, вакыт санап утыра. Тәрәзә араларына кызыл башлы сөлгеләр эленгән, тәрәзә төпләрендә яран гөлләр, кына гөлләр кыпкызыл чәчәктә.

Өйнең икенче ягында, пыялалы ишектән зур агач карават, калай белән төрелгән галанка мич, тәрәзә башларына буйдан-буйга сузылган чуар кашага күренә. Бу чиста-пөхтәлеккә Нуриянең дә исе китеп карап торуын абайлап алды Солтан. Абайлады һәм үзенчә бәя бирде: әле авыллар ирешкән нәрсә түгел бу. Агач кароватларны, галанка мичләрне, тигез җәелгән түшәмнәрне — барысын, барысын Чишмәбай юктан бар иткән. Шуларның барысын Чишмәбайның эш сөючән хатыны Хәнифә чиста-пөхтә итеп тота. Әйе, әйе, Хәнифә куллары. Мәрхүм Рамазан солдат йортында да берни булмас иде, әмма идән–сәкеләре чыра пычагы белән кырып юудан яки ком белән ышкудан сөяк кебек сап-сары булып, шомарып калыр иде...

Табынны Шәфика әзерләде. Зур агач табак белән аш китереп куйды. Аның олылар кебек, табакның читен шакмаклы тастымал белән, бисмилла әйтеп сыпыруы Солтанга сәер дә, ягымлы да кебек тоелды. Аннары Шәфика зур агач чүмеч белән бик тырышып, аш бүлергә тотынды. Ашның шулпасын да, токмачын да ул тигез итеп салырга тырыша, өресен сөзеп алырга да онытмый, итен дә әләктерә. Солтан бу юка гәүдәле, җиңел сөякле сеңелләренең әкәмәт бер тырышлык белән, җиренә җиткереп эшләп йөрүенә, өстәвенә үсмер балаларга хас булмаган басынкы-житдилегенә аеруча игътибар итте. Күрәсең, ятимлек күңел түрендә утырып тора торгандыр. Зәйни Моратов бүген әнә ниләр сөйләде урман юлында: бөтен мәктәп аңа карап тора ди бит.

Хәнифә сыерын савып кергән икән. Кунакларга яңа сауган, өсләре күбекләнеп торган җылы сөт китерде.

— Сыерыбызның сөте бик тәмле. Эчегез, яме, җылы көе. Сәламәтлеккә файдалы дип әйтәләр. Әхмәтем белән Мәхмүтем дә, бәләкәчем Шамил дә сөтне бик ярата. Шәфика гына никтер өнәп бетерми.— Почмак яктан урап керде, нәрсәнедер исенә төшереп, шкафны ачып карады, аннары әйтте: — Гөлкәйләрем, сез миңа үпкәли күрмәгез тагын. Бу Хәнифә бигрәк мәнсез, безнең белән утырып бер чынаяк чәй дә эчми дип рәнҗи күрмәгез. Тагын сифаратка барасым бар. Бармасыем кана, персидәтелебез Миңнулла бик коры кеше, вакытында килеп житмәсәң, сөт аертырга килгән катыннарны көттереп торсаң, ыштыраф салырга да күп сорамый.— Шәфикага дәште:— Кызым, кунакларны сыйла, яме, урынны абыең белән апаңа келәткә җәерсең, анда һавасы да иркенрәк, салкынчарак та.

— Юк, Хәнифә түтәй, без кунып-төнеп ятмабыз. Безне анда Мөхәммәтша абзый белән Фәтхениса җиңгәбез көтеп торадыр. Бик зур рәхмәт сыйга-хөрмәткә, без кузгалырбыз. Хәлегезне белдек, йортжирегезгә куандык, елларга иминлек бирсен дә, Чишмәбай да насыйбы белән кайтып, тагын-тагын күрешергә язсын,— дип бик белдеклеләнеп сүз башлаган иде Нурия. Хәнифә түтәсе аңа бик остарырга ирек бирмәде:

— Юкны сөйләп торган булмасана, Нуриякәем. Гомер эчендә бер кайт та, пожар чыккан төсле, качып кит имеш. Булмаганны! Кунабыз әле, кунмаган кая ул! Мин сезнең белән ике авыз сүз дә сөйләшә алмадым бит әле, туганнарым...

Аның сүзләрен хаклы дип тапты Нурия. Ни генә димә, аны ул карап-багып үстерде, ул иркәләде, ул юатты. Аннары... балалар өчен дә, Сания белән Рафаэль өчен дә яңа йортның һавасы әйбәтрәк булыр.

## IX

Хәнифә, ак халатын тал кәрзингә салып, кулына сөт үлчи торган ак көмеш чиләген тотып, сепарат йортына китеп баргач, Солтан белән Нурия, Шәфиканы яннарына утыртып, әңгәмә корып җибәрделәр.

— Хәлләрең ничек соң, сеңлем? — диде Нурия.
— Әй-бә-ә-әәәт,— дип көйләбрәк әйтеп куйды Шәфика.
— Укырга уйлыйсыңмы соң?
— Белмим шул. Әни әйтә, укыма ди. Бар укыганың җитәр, миңа ярдәмче кирәк ди. Иптәш кызларым былтыр ук укудан туктадылар инде...
— Ә без сине Казанга алып китсәк?
— Әйем лә. Кирәкмәс. Әни дә риза түгел. Үземнең дә...
— Нәрсә «үзеңнең» дә.
— Үземнең дә барасы килми.
— Нишләп, үскәнем? Әллә безгә үпкәләдеңме?
— Юу-у-ук.
— Алай булгач, әйт инде дөресен, без бит сиңа чит кеше түгел,— диде Солтан, аңа таба иелә төшеп. Уңай җавап ишетмәкче булып әйткән иде, әмма үтә дә сизгер күңелле Шәфика «чит кеше түгел» дигәнне үзенчә аңлап, бөтенләй сөйләшмәс булды. Күпме генә тырышсалар да, алар аны бүтән сөйләштерә алмадылар.
Солтан сөйләшә белмичәрәк сөйләшүенә бердән үкенеп, үз уйларына бирелде: «Шәфиканы биш класс белән калдыру — яраган эш түгел. Үскәч, ул моны безгә гафу итмәс».
Төнге унберләрдә, Ужил урманы ягы шәфәкъ алсулыгын җуеп, авыл өстенә тынлык иңгәч, сепараттагы эшен бетереп, Хәнифә кайтты. Кичке биләмнән Әхмәт белән Мәхмүт кайттылар. Йөгерешеп уйнаганнар булса кирәк, икесенең дә борын канатлары киерелгән, мышкылдап сулу алалар иде. Аларның шаулап кайтып керүләренә почмак якта йоклаган балалар — Сания, Рафаэль, Шамил уяндылар.
Өр-яңа баштан рәтләнергә, урыннарны көйләргә, шул арада бер самавыр чәй дә эчеп алырга дип кенә көйләнеп торалар иде, кунакларны мунчага чакырып, Мөхәммәтша абзый килеп җитте.
Өй эче, ишегалды кеше белән, бала-чага белән тулды. Кайсы елый, кайсы ашарга даулый, кайсылары, берсен-берсе бүлдереп, кычкырып сөйләшә — әкәмәт тамаша. Тәмам кала кешеләре булып беткән, тынычлыккаияләшкән Солтан белән Нурия бу хәлләрдән беренче мәлгә хәтта каушап та калдылар. Әмма авылның Нурияләр инде күптән онытып үз җае, үз көе бар аның. Иң әүвәл Хәнифә Саниякәй белән Шамилгә — туптай түгәрәк базык малайга — сөт җылытып эчертте. Алар шундук тындылар, йомышларын йомышлаганнан соң, кая яткырсаң — шунда йоклап киттеләр. Арада иң бәләкәе — ике ай ярымлык Рафаэльгә ими имезделәр, шуның белән анысын да янәдән «нәүм базарына» озаттылар.
Игезәкләргә Хәнифә учак алдына куйган бер чүлмәк аш китерде. Тегеләре күз ачып йомганчы ашны ялтыратып куйдылар да:
— Әни, без иптәш малайлар белән урманга ат сакларга барыйк әле, яме, әни,— диделәр.
Әниләре бәхәс-мазар куптарып тормады, икесенә бер иске бишмәт тоттырды, учак көлендә пешерергә дип, ипи капчыгына салып, иске бәрәңге, ике сынык ипи, шырпы тартмасы белән тоз китереп бирде.
— Рәхмәт, әни, яме, әни,— дип, малайлар табан ялтыраттылар.
Шуннан соң безнең булдыклы Хәнифәбез, көндезен игезәкләр Төчкәнеч инешеннән тотып кайткан балыкны кар базыннан алып менеп, каймакта гына куырып, кунаклар алдына китереп куйды.

## X

Зартугайда алар нәкъ ике атна яшәделәр.
Нурия сеңлесе Шәфика белән урманга җиләккә йөрде, күп сәен

тегермән буасы артында, кеше күзе төшмәс аулак бер тугайда су коенды. Беренче көннәрдә Шәфика аның алдында чишенергә уңайсызланып аптыратты, чишенсә дә, таллар арасында үзен кочаклап тик утыра иде. Ниһаять, бер атна дигәндә, ул иялəнде, шулай бер көнне, авыл гадәте буенча, ялангач калганчы чишенеп бетте дә, кеше күзе төшмәскә тиешле урынын кулы белән каплап, әкрен генә елгага керә башлады. Тал чыбыгыдай нечкә буйлы, ап-ак тәнле, матур төз аяклы сеңлесен күргәч, Нурия, күз тигерүдән куркып, читкә борылды. Шапырдап су чәчрәгән тавышка әйләнеп караса, Шәфика инде суның тирән җиренә үк кереп җиткән иде. Йә ходаем, батмаса гына ярар иде. Ләкин, ул да түгел, сеңлесе, пошкырына-пошкырына, ак тәне белән бөтен елганы балкытып, куш аяклап тибә-тибә, йөзеп китте. Елга өстенә дулкыннар таратып, ул отыры эчкә керә, озын кара чәче су өстеннән боргаланып бара иде.

Нурия, каушап, аяк өсте басты.

— Бәбкәм, борыл. Кире чык, үскәнем,— дип ялварды.

Әллә сеңлесе ишетми, әллә ишетеп тә ишетергә теләми, һаман да куш аяклап тибә-тибә, дулкыннар тарата-тарата, бөтен елганы бер итеп йөзеп баруын гына белә иде.

Аны күреп, Нуриянең тәмам күңеле нечкәрде. Кайда гына булмасын, нинди генә кыен хәлләрдә калмасын, ул сеңлесен үзенә алырга, аны әтисенең төсе итеп сакларга, үстерергә, кеше итәргә тиеш. Зартугайның тегермән буасы янында, күктән кояш карап торган, җиләс җил үлән башларын сыйпап искән чагында ул шулай күңеленнән ант итте.

Малайларга эти кирәк. Эти булмаса, сыеныр ир-ат кирәк. Игезәкләр беренче көннәрне үк Солтан абыйларына сыендылар. Алар аңа гармун уйнап, скрипка уйнап күрсәттеләр. Аны төннәрен Уҗил урманына ат сакларга алып бардылар. Тышаулап җибәргән атлар урман аланында, пошкыра-пошкыра, муеннарындагы кыңгырауларын шалтыратып, чыклы сусыл үләнне утлап йөргән чагында, ат көтүчеләренең башлыгы Әфләтун карт аларны бүре явыздан саклап, озын артыш таягына таянып, тирә-якны бик уяу күзәткән чакта, малайлар учак ягып җибәреп, шуның тирәсенә җыелалар, көлгә бәрәңге күмәләр; аннары иске бишмәтне чыклы үлән өстенә җәеп, шуңа кырын ятып, Солтан абыйларының гражданнар сугышы хакындагы хикәяләрен тыңлыйлар. Гәүдәләре туракланып, кырга чыгарып ташланган комсомолецлар, Пәнҗәр төбегендә ярты күкне иңләп яткан хәрби пароход «Ваня-коммунист»ның елый-елый кычкырткан гудок тавышлары аларның күңеленә уелып калып, гомер буе сакланачак. Адәм баласының күңел байлыгы үзе кечергәннәрдән генә түгел, ата-бабалары сөйләгәннән дә җыела.

Учак ялкыны инде сүрелә төшә, урман караңгылыкка күмелә бара, атларның шәүләләре тонык ай яктысында аланның бер башыннан бер башына сузыла.

Әфләтун карт, иске чикмәнен бөркәнеп, таягына таянып, учак янына килеп баса:

— Кая сез, памушниклар, бәрәңгегез пештеме?

Кабыклары кара күмер булып янган ярмалы бәрәңгене учтанучка сикертеп, авызны пешерә-пешерә ашыйлар. Аннан да тәмле ризыкны авыл малае беркайчан да күрмәячәк, чит-ят җирләрдә, таш калаларда сагынып искә төшерәчәк...

Солтан, кулларын баш астына куеп, иске бишмәт өстенә сузылып ята. Күккә карый. Үзе өчен ачыш ясый ул шунда. Карале, урманда төнге күк йөзе бөтен нәрсәгә хаким булып әверелә икән бит. Иксезчиксез икән бит ул. Кап-кара җәймәсе эченә җыйган җемелдәвек йолдызлары белән, канатларын җәйгән гигант каракош булып, җир өстен каплап тора икән. Көндезләрен күз алдында күкрәп утырган

урманнар да төнлә караңгы күк астында, кечкенә һәм тәбәнәк булып калалар икән. Табигатьнең бөеклеге, мәңгелеге бәлки шулдыр. Тик аны һәркем үзенчә тоя, хис итә... Солтан бу мизгелдә һичектер күңел борчуларыннан арынып тора — аны алдагы билгесезлекләр куркытмый хәзер. Үз язмышы, Чишмәбай язмышы, табигать зурлыгы белән, мәңгелек галәм белән чагыштырып караган чакта, ул кадәрле үк зур булып күренми. Ил бар. Урманнарны, кырларны, авылларны һәм калаларны тутырып яшәгән кешеләр бар. Малайлар үсә, учак ягалар, көлгә бәрәңге күмәләр, сугыш гарасатларын тыңлыйлар. Җир йөзендә тормыш бара, яшәү дәвам итә.

Таң килгәнне белдереп, чутылдап сандугач сайрый, аңа кушылып, урман күгәрченнәре гөрли, кәккүк аваз сала. Ә нигә кәккүкнең тавышы бөтен урманны иңләми? Баксаң-күрсәң, боларның һәммәкәен Мәхмүт башкара икән ләбаса! Аларны Әхмәт инде кырыкмаса-кырык кабат ишеткән булса да, рәхәтләнеп көлә:

— Мәхмүш, Мәхмүш! Этләрне сугыштыр әле. Әй, юк, көчекләрне шыңшытып җылат. Айга каратып өрдер, бүредән курыкканнарын яса әле! — дип сөендекләнеп кычкыра.

Төнге серле авазлар, йолдызлар, җир өстен гигант канатлары белән каплап торган караңгы күк йөзе әкренләп юкка чыга, эри, тарала. Җир өстенә көн килә.



## XI

...Кунакларның китү көне малайлар өчен бик ямансу булды. Алар уйнамый да, көлми дә, табигать авазларыннан да ямь таба алмый йөрделәр. Әхмәт Солтан абыйсына бер дәфтәр рәсемнәрен бүләк итте. Мәхмүт аңардан калышырга теләмәде — кәтүктән һәм юка резинкадән көтүче курае ясап бирде. Солтан боларны башта алырга да теләмәгән иде, чөнки аның малайларга бирердәй лаек бүләге юк иде. Дөресрәге — аның өч җәпле бәләкәй пәкесе бар иде, тик ул пәке берәү генә иде шул. Мәхмүткә бирсәң — Әхмәте, Әхмәткә бирсәң — Мәхмүте коры кала. Пәкене Солтан бәләкәй Шамилгә бүләк итте. Болай гаделрәк. Ник дисәң — кайсына кайчан кирәк, алар пәкене Шамилдән алып тора алалар. Ә Казанга кайту белән, ул Мәхмүткә пионер быргысы белән барабан, Әхмәткә акварель буяу белән рәсем дәфтәрләре җибәрәчәк. Малайлар аңа гел яхшы билгеләренә генә укырга вәгъдә итәргә тиешләр.

Кунакларны алмага килгән колхоз айгыры кузгала башлагач, малайлар каушадылар, дулкынландылар, Солтан абыйларының бер алдына, бер артына төшәләр. Кунаклар белән бергә Казанга китә торган, сары фанер чемоданын тарантас башындагы печән астына күмеп азапланган Шәфика апаларына кызыгып карадылар.

Фәтхениса җиңги белән Хәнифә түти ишек алдында алъяпкыч итәкләренә күзләрен сөртә-сөртә, елап калдылар.

Тарантас башына кучер булып менеп утырган Мөхәммәтша абзый каерылып ачылган капкадан айгырны бик хәтәр җилләндереп алып чыгып китте. Хатын-кыз яныннан шаулап-җилләнеп узганың хәерле. Югыйсә күз яшеннән күл җыелганны көтеп торырсың. Ә менә урамнан җай гына, вәкарь белән генә барсаң да була. Күрсеннәр күршеләр «рабучий сыйныф»ның кем икәнен!

Авылны чыккач, Солтан абыйсына гозерен әйтте:

— Атны бик кумассың, яме. Безнең әле пароходка чаклы дүрт сәгатьтән артык вакыт бар. Шәяхмәт абый билет алып куярмын диде. Иркенләп бер сәхраларны карап барыйк әле.

Мөхәммәтша абзыйга шул гына кирәк тә. Аңа бит көн саен болай сәйран кылып йөрүләр тәтеми.

Дөнья ямьле. Юлның ике ягында, ат дугасы күмелерлек булып,

каерылып иген уңган. Арыш инде серкә очыра. Күктә, берсен-берсе уздырып, тургайлар сайрый, кырлар өстендә җылы дулкыннары тибрәнә. Матур Зартугай яклары. Урманы дисәң — урманы, даласы дисәң — даласы. Елга-сулары ташып тора. Ачык кырда — өем-өем әрәмәләр, кыр уртасында — ялгыз нарат, күкрәп үскән имәннәр. Борынгы бабаларыбыз килеп утырган чакта бу урыннар, мөгаен, кеше үтеп чыкмаслык кара урман булгандыр. Урман булмаса, кыр уртасында ялгыз имән ничек үссен дә, ызаннар саен нарат-чыршылар каян килсен? Камалилар ихатасындагы чыршы аллеясы да бәлки куе урманнардан калгандыр. Авылның яме булган ул чыршылар Камалилар бакчасын зыр-круглый әйләндереп алган. Алар бакчага күләгә дә төшерә инде, бәрәңге үсәргә дә ирек бирми, ләкин Камали кистерми аларны, авылның күз өстендәге кашы төсле саклап тота.

Нурия, әнә шуларны уйлый-уйлый, «бөтерчеген» күкрәгенә кыскан килеш, үзалдына дәшми генә бара. Солтанның үз уйлары — үзе белән. Шәяхмәт абыйсы аны урманнарны күрә белергә, Кама дәрьясында саллар агызуның матурлыгын аңларга өйрәтте. Солтанның урыны, бәхете бәлки авылда булгандыр? Җир төзүчеләр техникумында укыган чагында ул әле авылда калмавына үкенми иде. Бар уйлаганы авыл турында, аның ызансыз кырлары, аның киләчәге турында иде. Ул чагында шул үзе дә авыллардан кайтып керми иде. Хәзер ул эшләрнең һәммәсен аңардан башка хәл итәләр. Нуриягә авыл кирәкми, аңа нервы җепселләре кирәк. Ул баканы, куянны, диңгез күсесен күзен дә йоммый яра ала, аларны ул гадәти бер эшкә саный. Әллә Солтанга картаймыш көнендә авылга кайтырга кирәк микән? Менә эшләре генә хәл ителсә иде. Мәскәүгә барасы бар. Шәяхмәт абыйсы Мәскәүгә барырга кушты. Шәймәрдән Ибраһимов янына. Кабул итәрме ул аны? Җаны-тәне белән советныкы икәнен аңлармы?..

Шәфиканың да күңеле уй белән тулы. Ул беренче мәртәбә Казанга килгән чакларын, беренче класста укыган 50 нче номерлы мәктәпне, мәктәп каршысындагы циркны, олы әнкәсенең аны итәк астына яшереп циркка алып керүен күз алдына китереп бара. Тик аңа Зартугайда калган энеләре, энисе кызганыч. Ул бит аларны ашата, юындыра, күлмәкләрен юа торган иде...

Пәнҗәргә җитәргә җиде-сигез чакрым кала, тоташ кара урман башланды. Нарат урманнары уртасыннан узганда, чәер исе, кырмыска мае исе, дымлы туфрак исе борынга бәрелде.

Солтан бөтенләй әллә нишләде.

— Абый, әллә ял итеп алабызмы? — диде ул, хискә бирелеп.

— Юк, энем, монда дымлы, балаларга ярамас, аланда ял итәрбез,— диде Мөхәммәтша абзый.

Каен белән усак, шомырт белән миләш, карлыган белән кура җиләге куаклары янынннан узганда, Солтан тагын бер җилкенеп алды, чикләвек куакларын күргәч, аның бөтенләй тәкате калмады.

— Иртәрәк әле,— дип, бер генә сүз әйтте Мөхәммәтша абзый.

Баганалы олы юлга чыккач, баш өстендә кояш балкып тора башлагач, ул атын зур бер имән төбенә китереп туктатты.

— Менә монда инде курорт! Кояш дисәң — кояшы, күләгә дисәң — күләгәсе. Нурия килен, ял иттер балаларыңны.

Саниякәйгә өйдән алып чыккан күмәч белән шешәдән сөтне ашаттылар, Рафаэль әле йоклый иде, аны уятмадылар.

Атны тугарып тормадылар. Иртә иде әле. Нибарысы сәгать ярым килгәннәр. Мөхәммәтша абзый, Пәнҗәрдә кирәге чыгар дип, урман эченнән атка печән чабып алып килде; юл кожанын җир өстенә җәеп, кунакларны шунда утыртты, үзе бер түмгәк өстенә чүмәшеп, тәмәкесен кабызып җибәрде.

— Менә шулай, Солтан... Үткән гомер — сүнгән күмер. Кайтканыңкиткәнең югые диярлек. Бу юлы сөендердең. Әммәдәки күзгә күренден.

кулга тимәдең, пнимаеш. Сөйләшәсе сүз күп ие әле. Мәскәүгә барам диденң шикелле. Калинин янына керә алсаң, безнең Чишмәбай хакында да сүз кузгатып кара. Михаил Иванович аңлар. Халыктан чыккан кеше. Әйт Калининга, иллә дә шәп кеше ие Чишмәбай, диген. Авылның түбәсен яңабаштан япты, диген. Зартугай ул киткәннән бирле ятим, шуны сагынып яшибез, диген...— Аның кинәт күңеле тулды һәм ул, иренен тешләп, дегет белән майлаган күн итегенең башына карап, озак кына сүзсез утырды.

Юлның калган ягын Мөхәммәтша абзый атны гел юырттырып алып барды, юлаучылар ягына бер генә мәртәбә дә әйләнеп карамады. Пәнҗәрдә кунакларын Шәяхмәткә җылы кулдан тапшыргач, озын-озак юанып тормады, шундук кайту ягына борылды. Күрәсең, бер йомшаган күңеленең бөтенләй нечкәреп китүеннән курыккандыр...

## XII

Шәяхмәт Айдаров, Садыйк картның өлкән улы Мөхәммәтшадан һәм кече улы Солтаннан аермалы буларак, сүзнең кадерен белеп, чамалап кына сөйләшә, хатын-кызны ихтирам итә, тик хатын-кыз халкы белән зур эшләрне бергәләп башкаруны бигүк өнәп бетерми иде.

Пәнҗәрдәге ике бүлмәле, аз мебельле квартирында күрешүгә, иң әүвәл ул Нурияне, Шәфиканы, Саниянe, сабый бала Рафаэльне кайгыртты.

— Нурия ханым, иң башлап сездән гафу үтенәм. Сара апагыз өйдә юк. Аны район мәгариф бүлегенә укыту эшләре буенча чакырып алдылар. Күрәсең, тиз генә кайтмас. Ихтимал, без киткәнче кайтып җитә дә алмас.

— Кем ул «без»?

— «Без» дип әйтүем дөрес. Чистайга чаклы мин дә сезнең белән китәм. Калганын юлда сөйләшербез. Кухняда Сара апагыз пешереп калдырган ризыкларны җылытып ашарга туры килер. Зинһар, ач утыра күрмәгез. Солтан белән без киттек, ашап торырга вакыт юк, берәр җирдә тамак ялгарбыз. Сезнең карамакта — сәгать ярым вакыт. Көндезге уникедә без төп-төгәл өйдә булырбыз.

Нурия аның чырае бик тә җитди, сүзләренең артык төгәл булуына карап, көтелмәгән берәр хәл бар ахрысы, дип уйлады.

Энесен иртәнчәк, урамга чыккач, Шәяхмәт абыйсы әйтте:

— Солтан, тыңла мине. Без бик җитди эшкә керешәбез. Хатын-кыз алдында әйтеп тормадым, аларның белгәннән белмәгәне әйбәтрәк. Мин сиңа Зартугайда чакта әйткән кеше — Шәймәрдән Ибраһимов Чистайга килә. Иртәгә сәгать уннарда ул анда булачак. Татарстанның барлык төбәкләреннән райком секретарьларын, райбашкарма председательләрен шунда җыялар. Менә шул. Без, димәк, Ибраһимовны Мәскәүгә барып түгел, нәкъ менә Чистайда килеш, җылы кулдан тотарга тиешбез.

Солтанның эче җу итте. Үзәк Комитет вәкиле белән алай тиз очрашырбыз дип уйламаган иде бит әле ул.

— Мин нишләргә тиеш инде?

— Без синең белән икебез бергә, пароход белән барган чагында, синең исемнән Үзәк Комитетка хат язарга, аны иптәш Ибраһимовка биреп җибәрергә тиешбез. Бер генә минутны да бушка үткәрергә ярамый. Ятып калганчы атып калырга кирәк. Аңладыңмы?

— Аңладым, абый.

— Алайса, бик яхшы. Мин боларны сиңа хатын-кыз алдында әйтергә теләмәдем. Үзең беләсең, хатын-кыз затының идеаль дәрәҗәдә акыллы дигәне дә чамадан тыш кызыксынучан була. Резьбасы беткәч су тотмаган кран төсле, лыбырдарга ярата. Хат язганны син беләсең дә, мин беләм. Төшендерә алдыммы?

— Төшендем.

— Хуп. Алайса, без хәзер якындагы берәр ашханәгә кереп тамак ялгап алыйк.

...Пароходта аларга ике каюта бирделәр. Беренчесенә балалары белән Нурия урнашты, икенчесенә — Айдаровлар.

Чистайга хәтле бер тәүлек төшәргә тиешләр иде. Шунлыктан Шәяхмәт абыйсы Солтанга хатның эчтәлеген башта уйлап бетерергә, шуннан соң гына кәгазьгә төшерергә кушты.

Төне буе диярлек утырып язган хаттан менә нәрсә килеп чыкты.

*ВКП(б) Үзәк Комитетына*
*иптәш И. В. Сталинга*

*Кадерле Иосиф Виссарионович!*

*Дүрт елга сузылган авыр газаплардан соң мин Сезгә хат белән мөрәҗәгать итәргә булдым.*

*Казан җир төзүчеләр техникумының директоры вазифаларын башкарган чагымда миңа яла ягылды. Мине куенына мулла кызын сыендырган, авылда күмәк хуҗалык кору чорында партия үткәргән политикага каршы төшкән итеп күрсәттеләр.*

*Шул нигездә минем эшем башта партячейкада, аннары Казан шәһәренең Суконный райкомы бюросында, соңрак партия өлкә комитетында каралып, 1934 елның октябрендә, әләкче гаризасы нигезендә, мине партия сафыннан төшереп калдырдылар.*

*Партия исеменә бернинди дә тап төшермәгәнлегемне аңлату өчен, кыскача автобиографиямне язам.*

*1900 елда Казан губернасы, Алабуга өязе, Зартугай авылында туганмын. Әти-әниемнең төп һөнәре — игенчелек. Икесе дә ярлы крестьяннар. Әти 1932 елны, әни 1934 елны үлде. Әтинең бертуган энесе Шәяхмәт Айдаров — 1912 елдан профессиональ революционер. 1916 елдан коммунистлар партиясе члены, революциянең беренче көннәреннән кызылгвардияче. Хәзергесе көндә ул Татарстан АССРның Пәнҗәр райкомында беренче секретарь булып эшли. Абыем Мөхәммәтша Айдаров — эшче, революция чорында Ижевск заводында корал койды, Кама буенда кузгалган фетнәләрне бастыруда катнашты. Хәзер пенсиядә, авылда яши. Мин үзем, Айдаров Солтан Садыйк улы, 1918 елга тикле авылда, әтиемнең хуҗалыгында эшләдем. Башта мин мәдрәсәдә, аннары алпавыт Таминдар Тураев салдырган школада, 1913 елдан Алабуга шәһәрендә училищеда укыдым. 1919 елны үз теләгем белән Азин дивизиясенә барып кушылдым, кулыма корал тотып, Колчакка каршы сугыштым.*

*Гражданнар сугышы беткәч, мине Казанга, Шәрык Академиясе рабфагына укырга җибәрделәр. Бер ел укыганнан соң рабфакны ташлап чыгарга туры килде. 1921 елның ачлыгы, гаиләдәге фәкыйрьлек укуны өзеп торып, төрле кара эшләрдә эшләргә мәҗбүр итте.*

*1922 елдан 1925 елга тикле Казанда Җир төзүчеләр техникумында укыдым. ВКП(б)ның Татарстан өлкә комитеты мине авылга җир төзүче итеп җибәрде. Күмәк хуҗалык төзелеп беткәнче шул эштә эшләдем. 1931 елдан партия өлкә комитеты мине Казанга Җир төзүчеләр техникумына күчерде. Башта уку-укыту бүлеге мөдире, соңыннан, 1934 елның июленә кадәр, ягъни партиядән чыгарылганчы, директор булып эшләдем.*

*Җир төзү эшендә сыйнфый сәясәтне дөрес үткәргән өчен, ялгыз хуҗалык җирләрен колхозларга берләштергәндәге үрнәк эшләрем өчен Наркомзем мине бернича мәртәбә бүләкләде. Кулаклар шул эшләрем өчен күкрәгемә сәнәк белән чәнечте.*

*1919 елдан — комсомолда, 1925 елдан партия сафында. Наркомземда һәм Җир төзүчеләр техникумында 1932—1934 елларны партячейка бюросы члены булып сайландым. Партчистканы 1929 елның июль аенда уздым.*

*Партия сафларында торган чорымда миңа нинди дә булса гаеп ташлау дөрес түгел. Фактлар һәм бергә эшләгән өч иптәш биргән характеристика минем намуслы большевик булуымны, партиянең генераль линиясе өчен актив көрәш алып баргаңымны әйтеп торалар. Минем әле хәзер дә партия тормышыннан аерылганым юк. Авыр рухи газап һәм кайбер кешеләр тарафыннан мыскыллау-җәберләүләр кичерүемә карамастан, ниһаять, дүрт ел буена авыру булуыма карамастан, илебезнең иҗтимагый тормышыннан үземне читкә куймадым. Идея-*

*сәяси әзерлегемне югары тотарга тырышам, политэкономияне, марксизм-ленинизм тәгълиматын һәм башка фәннәрне югары билгегә тапшырдым. Хәзерге көндә читтән торып, финанс-экономия институтын тәмамлыйм.*

*Кадерле иптәш Сталин! Минем эшемә үзегезнең катнашуыгызны һәм миңа партия сафларына кайтырга булышуыгызны үтенәм. Партия эшенә гомеремнең азагына тикле турылыклы булырга, намуслы коммунист булып калырга ант итәм.*

*Большевистик сәлам белән —*
*Солтан Айдаров.*

*10 июль, 1938 ел.*
*Казан.*

*Минем адрес: Казан, Чернышевский урамы, 21 йорт, 15 кв. Партбилетымны Суконный райкомы алып калды.*

Шәяхмәт Айдаров Солтанның хатын, күзлек киеп, бик озаклап, төпченеп укыды. «Мин» дигән сүзне берничә урында сызды, тыйнаграк булганы яхшы, диде. «Наркомзем» сүзенең илгәме, республикагамы караган булуын ачыграк итеп язарга кушты.

— Төзәткәннән соң чиста ак кәгазьгә күчереп чык, караламасын үзеңә алып калырсың,— диде.

Үз гомерендә бик күп кәгазь язган, күп төрле анкеталар тутырган Солтанның, хатны ак кәгазьгә күчерергә керешкәч, никтер кулы калтырый, хәрефләре тигез төшми башлады һәм ул, җанындагы каушаукалтырануны басар өчен, бер сәгать, палубага чыгып, саф һава сулап керергә мәҗбүр булды.

## XIII

Чистай пристанендә Солтан белән Шәяхмәт Айдаровлар пароходтан төшеп калдылар. Шәяхмәт Айдаровның биредә төшәчәген белсә дә, Солтанның төшәсен белмәгәнгә күрә, Нурия бик аптырады.

— Ни булды тагын? — диде ул Рафаэлен күтәргән көе. Аның күзләре хәвефле елтырый, иреннәре агарып киткән иде.

— Берни дә булмады, энисе. Паника куптарма. Шәяхмәт абый миңа бер-ике көнгә Чистайда калып торырга куша. Нигә икәнен кайткач аңлатырмын,— дип, Солтан хатынын тынычландырырга ашыкты.

Нурия эшләрнең житди икәнен иренең күз карашыннан ук аңлады.

— Эшең беткәннән соң озак юанма, яме, әтисе, без сине дүрт күз белән көтеп торырбыз,— диде.

Солтан Чистайны беренче мәртәбә унөч яшендә, абыйсы белән сал агызып килгәндә күргән иде. Ерактан ук күзгә ташланган зур чиркәү, җимерек урамнар, тузан утырудан яшел төсләрен җуйган соры агачлар — барысы да әүвәлгечә, борынгы купецлар каласының бер төше дә үзгәрмәгән иде. Кама өстен тутырган саллар, баржалар, яр буйларына килеп ябышкан баркаслар, исәпсез-сансыз көймәләр дә шул ук иде. Аның кайсы килеп туктый, кайсы кузгалып китә, кайсы ачы тавыш белән өзеп-өзеп кенә сигнал бирә, кайсылары, сыер кебек, мөгрәп утыра иде. Солтанның күңелендә алар әллә кайчангы истәлекләрен кузгаттылар. Тик аларны иркенләп карарга бер дә вакыт юк иде. Шәймәрдән Ибраһимов белән көрешү, язмышын уңай якка хәл итү теләге бер генә минутка да исеннән чыкмый иде.

Партия активы барган бинага партбилетны карап, тикшереп кенә кертәләр булып чыкты. Шунлыктан Солтанның Ибраһимов белән көрешү, күзенә карап, чын дөреслекне әйтеп бирү хыялы тормышка ашмады. Хатны Шәяхмәт абыйсы үзе белән алып кереп китте.

Солтанга «Крестьян йорты»ннан урын бирделәр. Элекке авыллардагы каравыл өеннән әллә ни ерак китмәгән, тузанлы, урыны-урыны белән стеналарындагы штукатурлары кубып төшкән шыксыз, ярым караңгы бер бина иде ул. Солтан шунда көннең көн буе абыйсын көтеп утырды.

Шәяхмәт караңгы төшкәч кенә кайтты. Кыяфәте тоныкм мыегы сәлперәйгән, җилкәләре салынып тора, аягындагы күн итекләре тузанга баткан иде.

— Йә, ничек? Ничек? — диде Солтан, сабырсызланып.

— Хатыңны тапшырдым,— диде Шәяхмәт, бик артык җәелмичә.

— Алдымы? Нәрсә диде? Аңлатыбрак әйт инде.

— Аңлатып әйтү шул: эше бик тыгыз. Партактивка җыелган ике йөздән артык кешегә илнең хәлен сөйләде. Эчке һәм тышкы политикабызны аңлатты. Оратор. Ут чәчеп сөйли. Чибәр. Гади. Өстендә — минеке төсле гимнастерка. Татарларга хас кара түгел, аксыл чәчле, аксыл чырайлы. Мишәр бит ул, Сембердән. Күзләре зәңгәр, сөзеп карый, сынап. Республиканы белә — элеккесен дә, хәзергесен дә. Башкортларны да белә, Үзәк Комитетта ике республика өчен җаваплы икән. Петроградта очрашканыбызны әйткәч, Айдаровмы? — ди.

— Кара син аны, хәтере яхшы икән, татарча әйттеме?

— Татарча. Мишәр акценты беләнрәк сөйли.

— Йә, йә, шуннан?

— Нәрсә шуннан? Сораша. Халыкның кәефе ничегрәк? Күмәк хуҗалыкка мөнәсәбәт? Юкны-барны сөйләнеп йөрүчеләр күренмиме? Игеннәрнең торышы? Әйттем, сөйләдем. Тыңлый да белә...

— Ә минем йомыш?

— Аны да кузгаттым. Игътибар белән тыңлады. Хат язуың әйбәт булды, үтенечне кәгазьгә язмадыгызмы дип сорады. Хатны суздым. Хәбәр почта белән җиткерелер диде.

Солтанга моны ишетү бик тә кирәк иде. Димәк, хат тиешле кешесе кулында. Димәк, аның гозерен ишетәчәкләр.

— Бик рәхмәт, абый, бик рәхмәт,— диде Солтан, дулкынланып.— Инде мин нишлим?

— Иртәнге җидедә пароход киләсе. Уфадан. Шуңа билетыңны компостировать итәргә кирәк. Чистай пароходчылыгы белән сөйләштем. Булышырбыз диделәр. Менә, кирәкле кешеләрнең исемнәре.— Кулына кәгазь тоттырды. Өздереп карады.— Бер көн тормый юлга чыгасың. Юкса синең өчен Нурия ханым Казанда ут йотып ятыр. Безнең биредә ни өчен төшеп калганны аңлады. Акыллы хатын ул, сизгер. Бер көрешкәндә әйтеп калыйм: без — Айдарныкылар — корырак халык, талкан бик коры безнең. Кара аны, дорфаланып, Нурия ханымның җанын ашама. Сине бу хәлгә ул төшермәде. Ул синең өчен җанын бирергә әзер. Хат яз. Әмма... зар-моңнарыңны тутырма. Кстати, Мәскәүгә хат җибәргәнне дә беркемгә дә әйтмә. Бу дөньяда синең дусларың гына түгел, сине мескен итеп күрергә теләүчеләр дә бардыр. Реалист булырга кирәк безгә. Менә шул, энем. Инде хәзер сабыр гына җавап көтик. Сабырлык заманасы килде. Түземлелек заманасы.

...Җавапны бер ай, ике ай, ярты ел көттеләр — килмәде. Инде тәмам өметне өзгәч, кайгылы башны кая куярга белми йөргәндә, Солтанны Казан Кремленә — Наркомземга чакырып алдылар.

Бу — 1939 елның феврале иде инде.

Татарстан Җир эшләре халык комиссариатының партоешмасында, техникум партоешмасында түгел, нәкъ менә комиссариат партоешмасында, Солтан Садыйк улы Айдаровның эшен кабаттан карадылар. Фикер алышу көннең көн буе барды. Бу Мәскәүдән килгән хат буенча эшләнәме-юкмы, ул хакта беркем бер сүз дә әйтмәде. Айдаровны якыннан белгән, аның белән бергә техникумда һәм күмәкләштерү чорында авылда эшләгән иптәшләр чакырылды. Солтан чамасыз дулкынланды, бергә эшләгән иптәшләренең аның файдасына сөйләп торулары җанны киерә, нервыларны кылдай тартып китерә иде. Эшне кабаттан Үзәк Комитет КПК [1] сында карарга кирәклеге хакында карар кабул иттеләр. Тикшерү-

[1] КПК — Партия контрольлеге комитеты.

ләрен үтенеп, Үзәк Комитетка хат җибәрделәр. Тик Солтан шатланырга ашыкмады. Ул моны иң якын кешесе, арка таянычы Нуриягә дә әйтергә базмады. Ни өчен дисәң, әлеге карар ВКП (б) Үзәк Комитеты каршындагы Партия контрольлеге комитеты раслаганнан соң гына гамәлгә керәчәк иде.

Тагын бер айдан, ноябрь ахырларында, аны Үзәк Комитетка чакырып алдылар. Андагы җаваплы иптәшләрдән берсе — Андрей Харитонович Борисов — хат иясе белән озаклап сөйләште. Кыяфәте якты, тыңлавы игътибарлы булганга, Солтанның күңеленә тагын ышаныч кайтты, булган хәлләрне түкми-чәчми сөйләде. Борисов, Солтанны озаткан чагында, эшне кабат караячакларын әйтте. Кирәк булса, чакыртырбыз, һич югы, нәтиҗәсен әйтеп, хат язарбыз диде.

Солтанның еллар буена зарыгып көткән җавабы бәлки килгән дә булыр иде, моңа ил күләмендәге бер вакыйга комачаулады.

Ак финнар белән сугыш башланып китте.

Радиодан соңгы хәбәрләрнең берсен дә калдырмый торган Солтан, сугыш хәбәрен ишеткәч, агарынып китте.

«Бәхетсезгә-вакытсыз. Моннан соң инде Үзәк Комитет кешеләрендә минем кайгым булмас»,— дип эче көеп уйлады.

## XIV

Казан медицина институтының проректоры Суфиян Бикмөхәммәдович Сапаровны Сәламәтлек саклау буенча республика Халык комиссариатына чакырып, приказ тәртибендә әйттеләр:

— Ректорыгыз ялда. Көтеп торырга вакыт юк. Игътибар белән тыңлагыз: институтның студентлар тулай торагында эвакогоспиталь ачабыз. Бер ай срок сезгә, шул вакыт эчендә бина госпитальгә яраклы итеп җиһазландырылырга, медицина персоналы белән тәэмин ителергә тиеш.

Проректор, каушый төшеп, халык комиссарының аксыл чыраена, кулы белән һаваны ярып төшерүенә карап торгач:

— Бу бит... ни бит... бер мин генә башкарып чыга ала торган эш түгел, иптәш кем, комиссар...— диде.

Ләкин комиссар аңа озаклап сүз куертырга ирек куймады:

— Иптәш Сапаров, неужели сез бернәрсә дә аңламыйсыз: сугыш вакыты бит! Дискуссия ачарга вакыт та, мөмкинлек тә юк. Беренче таләп — торакны бушату. Икенче таләп — институттан ун врачны, әйе, кимендә унны, госпиталь карамагына бирү. Аңлашылгандыр дип беләм?

— Аңлашыла...— дип, авыз эченнән ботка пешереп алды Сапаров.— Госпиталь начальнигы да бездән түгелдер бит?

Кабинетта, бер читтәрәк, озын буйлы, чандыр-какча битле, хәрби киемдәге бер кеше утыра иде.

— Менә сезгә госпиталь начальнигы. Рәхим итеп танышыгыз. Андрей Семенович Солдатов. Совет органнарында озак еллар эшләгән тәҗрибәле оештыручы, энтузиаст. Кстати, аның хатыны Атаманова Татьяна Васильевна сездә — гистология кафедрасында,— диде. Үтемлерәк булсын өчен: — Профессор Майский кафедрасында эшли,— дип тә өстәде.

Шуның белән сүз тәмамланды. Икенче сөйләшү проректорның үз кабинетында булырга тиеш иде. Әңгәмәне нинди тәртиптә алып барырга кирәклеге инде Сапаров өчен ачык, ул аның өлгесен күреп, ишетеп кайтты. Институтның кафедра җитәкчеләрен үзенә чакырып, комиссариат әмерен аларга түкми-чәчми җиткерде.

— Сез җаваплы кешеләр. Мәсьәләнең җитдилеген аңлыйсыздыр? Тулай торакны бушатырга. Госпиталь өчен врачлар бүлеп бирергә. Срок бик кыска: иртәгә иртән исемлек минем кабинетта булырга тиеш. Таралырга мөмкин. Ә сез, Александр Николаевич, калып торыгыз. Аерым сүз бар сезнең белән...

Галимнәрнең башкалары чыгып беткәч, Сапаров ишекне нығытып япты, профессорга өстәл янынннан урын тәкъдим итте, көн яктысыннан ялтырап торган такыр башын сыпыргалап алгач, утырган җиреннән Майскийга таба сузылып әйтте:

— Киңәш бар, Александр Николаевич. Сезнең кул астында кандидатлык диссертациясе язган теге кем ... кем әле?

— Уразаеваны әйтәсезме, Суфиян Бикмөхәммәдович?

— Әйе. Исеме?

— Нурия Аббасовна.

— Сезнеңчә ничек, хөрмәтле профессор, Уразаева госпитальдә эшләргә яраклымы, то есть лаеклымы димәкче булам?

— Нинди вазифа йөклисездер бит?

— Әгәр без аңа патологик анатомия кабинетын оештыруны тапшырсак?

Александр Николаевич башын кырын салды, сөякчел бармакларын аралаштырып, иягенә таянды, шул чагында очлы кәҗә сакалы бүлтәеп, өскәрәк күтәрелде. Сапаровка ул ни өчендер югарыга карый, аны, проректорны, үчекләп карый кебек тоелып китте.

— Ягез, хөрмәтле...— дип сүз башламакчы иде, профессор аның ачы кискен тавышы белән бүлдерде:

— Уразаева — ике бала анасы. Дөрес, аның бала караучысы бар, ире дә, авыру сәбәпле, пенсиядә. Тик, беләсезме, без бит аның докторлык диссертациясен киләсе елга якларга куярга дип өметләнеп тора идек. Фән кешесе Уразаеваның...

— Сугыш вакытында үз җаеңны гына карап торып булмый, хөрмәтле профессор. Ил мәнфәгате — беренче планда. Комиссариат миннән шуны таләп итә. Ә мин — сездән.

— Гафу итегез, Суфиян Бикмөхәммәдович, ни өчен сез беренче кандидатура итеп Уразаеваны сайладыгыз?

— Хикмәт шунда, хөрмәтле профессор, теге чакта, сезнең белән икәүләп Югары аттестация комиссиясе өчен анкетасын барлаган чакта, ул никтер минем күңелгә кереп калды. Сөйләшергә осталыгы, логикасы белән дип әйтимме? Русчасы да бик әйбәт бит. Андый кешеләр күктән төшми. Дөрес әйтәмме?

— Анысы шулай. Күктән төшми...— диде Майский күтәреп кенә. Ул арада күңеленнән уйлап өлгерде: — «Алай да нык хәтерле кеше син, Сапаров. Онытмыйсың, ә? Җае чыкканны көтеп кенә торасың».— Ярый,— диде ул, урыныннан торып.— Мин Уразаева белән сөйләшермен. Аңлы кеше ул. Сүз тыңлый торган. Патриотик тойгысы да җитәрлек. Кем белә, бәлки, госпитальдә врачлык практикасы аңа докторлык диссертациясен якларга да ярдәм итәр. Тик, беләсезме, минем бер шартым бар: сугыш бетүгә, Уразаева тагын безгә кайта.

— Анысы сезнең үз эшегез, Александр Николаевич.

Профессор Уразаеваны сәгате-минуты белән чакыртмады. Ул аның белән сөйләшкәнчегә кадәр килеп чыккан хәлнең төрле якларын уйлап карарга тиеш иде. Әйтик, Уразаеваны госпитальгә бирү-бирмәү Майскийга бәйләнмәгән. Барыбер алачаклар. Мобилизация. Хәрби комиссариат повестка китердеме, рәхим итеп, әзерлән — син хәрби врач. Алдан әйтеп кую, повестканы кулыңа тоттырганчы, психологик яктан әзерләү — монысы менә кешечә булачак. Госпитальдә эшләү, кем белә, бәлки, аның биографиясе өчен дә файдалы булыр. Хәзер аны ире өчен табалыйлар. Айдаровның партиядән чыгарылган булуын ике сүзнең берендә Нурия Аббасовнага әйтеп торалар. Ә болай Уразаеваның мөстәкыйль үз биографиясе булыр. Йөзе ак, намусы чиста дигән сүз. Фән дөньясыннан госпитальгә күчү аның психикасына ничек тәэсир итәр — монысын әйтү — ай-һай! Сез мине җаным теләгән эштән аердыгыз, сез минем юлыма аркылы төштегез дип рәнҗеп йөрмәсме?

Иртәгесен Майский, Уразаеваны үз янына чакырып, кичнең кич буе

җанына тынгылык бирмәгән хәбәрне әйтте. Нурия кып-кызыл булып кызарды, аннары түше качты, иреннәре тетрәнде. «Диссертациям...» — дип кенә әйтә алды ул.

Тормыш бик кинәт, бер дә көтмәгәнчә үзгәреп китте. Кичә генә ул әле фән кешесе иде, бүген хәрби врачка әйләнде.

Мобилизациягә эләккән һәммә кеше — врачлар, фельдшер, санитаркалар, алар белән бергә мединститутның барлык студенты бер атна эчендә тулай торакның астын-өскә әйләндерде. Яшьләр шау-шуы, арзанлы ислемай, чаңгы мае исе, зәңгәр хыяллар белән тулып торган бүлмәләр дару исе аңкытып торган госпитальгә әйләнде. Ак халатлы врачлар, шәфкать туташлары, хәрби киемле кешеләр белән тулды. Алар арасында озын буйлы, кырыс чырайлы бер кеше хәрби киемнән гел очрап тора. Нурия аның Татьяна Атамановaның ире икәнен танып белде, сабыр гына күрешеп йөри башлады. Сабыр булуы шуңа; ул әле аның үзенә карата нинди мөнәсәбәттә икәнен белми, шуңа күрә аның күзенә бик чалынмаска тырыша, кем белә, Татьяна Васильевна иренә Нурия хакында, бәлки, тузга язмаган сүзләр сөйләп бетергәндер...

Бер үк эштә эшләп, берең башлык, икенчең буйсынган кеше булган чакта очрашмый тору мөмкин түгел. Солдатов патологик анатомия бүлеге начальнигы Уразаеваны, озак та үтмәстән, үзе эзләп килде. Нурия үзе карамагындагы ике врач һәм санитарлар белән бергә кабинетны әзерли иде. Солдатов, хәрби кием өстеннән җилкәсенә ак халат салган көе, бик кызу килеп керде. Исәнләште. Кабинеттагылар, эштән туктап, госпиталь начальнигын сәламләделәр.

— Нурия Аббасовна,— диде Солдатов, Нурия белән кул биреп күреште.— Мин сезнең ышанычлы иптәш, талантлы фән кешесе икәнегезне ишетеп беләм. Менә язмышлар безне очраштырды. Фәндә түгел, ил алдындагы бурычыбызны үтәгәндә. Мин бик өметләнәм, кабинетлар төзегәндә дә, врачлык практикасында да — һәр өлкәдә Сез үрнәк булсагыз иде. Сезгә карап башкалар тигезләшер иде.

— Рәхмәт, Андрей Семенович. Тырышырбыз,— диде Нурия.— Татьяна Васильевнага миннән сәлам әйтегез. Аңа хәзер институтта зуррак нагрузка белән эшләргә туры килер инде. Авыр булыр...

Шушы гап-гади сөйләшү Нуриянең күңелен күтәрде. Икенче көнне ул үзенә йөкләнгән эшкә тагын да җаваплырак бер тойгы белән килде. Булачак госпитальнең хезмәткәрләре дә ашыгып-ашыгып йөргәнне күрде ул. Хирурглар операция кабинетларын, терапевтлар рентген һәм процедура кабинетларын әзерләп бетерергә тырышалар иде.

Патологик анатомия бүлеген әзерләү барысыннан да катлаулырак булып чыкты. Бу блокта керү-чыгу юллары аерым каралырга, мәет яру өстәлләреннән башлап операция өчен кирәкле барлык инструмент кул астында булырга тиеш.

Мәшәкатьләнә-чаба торгач, Уразаева үзләренә кирәкле нәрсәләрнең байтагысын бер-ике атна эчендә әзерләп өлгертте. Медицина инструментларын аңа лабораториядән — Майский кафедрасыннан алырга рөхсәт иттеләр. Ләкин аның әле барыбер күңеле тыныч түгел, чөнки инде институтны тәмамлаганына тугыз-ун ел вакыт узып бара, аның больницаларда эшләгәне булмады диярлек. Бу хәтле җаваплы эшне ничек башкарып бара алырмын дип ут йотып йөри иде. Шул хакта ул беркөнне остазы Майский белән дә киңәште.

— Зарар юк. Тормыш үзе өйрәтә ул, Нурусйа. Синең шулай борчылып йөрүең үзе үк инде эшләреңнең барып чыгачагын әйтеп тора,— дип күңелен күтәреп җибәрде картлач. Ул аңа мединститутны ташлап бетермәскә, килеп йөрергә кушты.

Ул арада госпитальгә беренче яралыларны кабул итеп алырга дигән әмер килде. Бу хәл 1940 елның январь ахырларында, бик суык көннәрнең берсендә булды.

Госпиталь персоналы, баскан урыннан купмаслык булып, яралы кызылармеецларны көтә башлады.

Зур санитар машинасы алып килде аларны. Нурия сугышның нинди мәхшәр икәнен беренче мәртәбә менә шунда бөтен җаны белән аңлагандай булды. Гадәти вакытта, тыныч көннәрдә, больницада авыруларны махсус кабул итү урыны була. Иркен озын коридорның бер башыннан авыруны алып керәләр, аулак бер кабинетта аның «авыру тарихын» җентекләп язып алалар, өченче бер бүлмәдә кан саркып торган ачык яраларны бәйлиләр; кием алыштыру, ванна кертү янә дә башка урында эшләнә. Ягъни Нуриянең моңарчы авыруларны берәм-берәм генә кабул итеп, аларның һәркайсын аерым-аерым, зур игътибар белән карауларын гына күргәне бар иде.

Бүген — бөтенләй башкача.

Госпиталь итеп эшләнгән биш катлы тулай торакка ничә кешесы ала — барысын берьюлы китерделәр. Бер үк көнне, бер үк сәгатьтә. Врачлар алдына хәвефле, ыңгырашулы дөнья бөтен зурлыгы, ялангачлыгы белән килеп басты.

Яралылар төрле. Берсенең кулы юк, икенчесенең битен марля белән урап бетергәннәр, өченчесе култык таягына көч-хәл белән генә таянып килә. Берсен носилкага салганнар, ул, туктый алмастан, үзәккә үтә торган ачы тавыш белән кычкыра...

Нуриянең моңарчы да тормышта күргәннәре аз булмады, әмма госпиталь итеп корылган мединститут тулай торагында беренче көнне күргән-кичергәннәре, гомер буе күңеленнән җуелмас бер яра булып, кешелек дөньясының фаҗигасы булып, зиһененә сеңеп калды.

Моны ул соңгысы дип уйлый, ләкин алда әле аны нинди госпитальләр, нинди авырлыклар көткәнен башына да китерә алмый иде.

## Унынчы башлам

### I

Аяз иде ул көнне күк йөзе. Зәңгәр иде. Өрфиядәй җиңел ак болытлар күк йөзенең төрле почмакларында эленеп торалар. Гүя, шуларның шәүләләре төсле, Иделдә ак җилкәнле көймәләр туктап калган. Ослан тауларының итәгендә, яшел болыннарда сыер көтүләре, сарык көтүләре йөри. Ат көтүеннән аерылып калган ялгыз байталлар араннарда кешни иде.

Дөнья тулы матурлык, дөнья тулы иркенлек, дөнья тулы рәхәтлек иде!

Солтаннар гаиләсенең бу, мөгаен, иң истәлекле көне булгандыр. Җир төзү эшендә кабат эшли башлаган Солтан Айдаров Баулы якларыннан кайтып төшкән; Әхнәф Айдаров институт тәмамлаган; Шәфика Уразаева Казанда җиденчене бетергән — аның шатлыгы барысыныкыннан да күбрәк, чөнки ул инде тулы булмаган урта белем алган кыз. Хәзер теләсә кайсы техникумга, теләсә кайсы училищега барып керә ала. Хыялында — укытучы образы. Моның өчен ул Арча педучилищесын сайлады. Арчаның кай тарафта, Казаннан ничә чакрым ераклыкта икәнен дә белми әле ул. Техникумга керү өчен нинди фәннәрдән имтихан бирергә кирәклеген үзләре яшәгән йорттагы башлангыч мәктәп укытучысыннан сораштырды. Ул шат, ул бәхетле. Нурия апасына да, Солтан абыйсына да, институт тәмамлаган Әхнәф абыйсына да яратып дәшә, үз итеп дәшә, башка чактагы басынкылыгы әллә кая киткән.

Бу гаиләгә күңел тынычлыгы китергән тагын бер нәрсә бар. Биш яшьлек Санияне, өч яшьлек Рафаэльне җәйге балалар бакчасына — дачага алдылар, шунлыктан нәнкеләре Луиза Столбищега бер айлык ялга кайтып килергә мөмкинлек тапты.

Солтаннар гаиләсе бүген очар кошлардай иркәле.

Үзләре белән палатка алып чыкканнар иде. Солтан белән Әхнәф,

Иделнең ауларак тугаен сайлап, зур бер әрәмә төбенә палатканы корган арада, Нурия белән Шәфика юлда килешли көймәчеләрдән алган балыкны чистартырга керештеләр. Аннары Шәфика, яр буйлап йөреп, дулкын кагып чыгарган агачларны җыйды. Ул үзендә аеруча бер җиңеллек, күтәренкелек тоя, аны бүген болытлар да, су өстендә чайкалган көймәләр дә, Ослан таулары түбәсендәге күгелҗем урманнар да әйтеп бетергесез дулкынландыра. Ул тагын берничә көннән Зартугайга кайтып китәр. И сагынгандыр инде аны әнисе, и сагынгандыр энеләре! Ул аларны төшләрендә күрде инде. Аны Зартугай урманнары каршылар. Тегермән буасы каршылар. Ул Зартугайдагы иптәш кызларына җиденчене тәмамлаганлыкка бирелгән таныклыкны күрсәтер. Юк, ул аны әле күрсәтми торыр. Иптәш кызлары тәти күлмәкләрен күрсәтешеп мактана башласалар гына күрсәтер. Юк, аңарчы әле Арчага барасы, педучилищега керү тәртипләрен белешәсе, кирәкле документларын әзерлисе бар...

Маркиз утравына халык төркем-төркем булып килә. Утрауның төрле тарафларында палаткалар калкып чыга, учаклар кабына. Көймәләргә төялеп, каядыр елга эченә, вак утрауларга китәләр. Болар да дулкынландыра Шәфиканы. Ләкин аны иң нык дулкынландырганы ул түгел. Аны иң нык дулкынландырганы — сузып-сузып, моңаеп-моңаеп кычкырткан пароход гудоклары...

Моңлы тавышлы гудоклар аның сагынуларын яңарта, әнисен, энеләрен, иптәш кызларын искә төшерә, күрешәсе көннәрен...

Ярга дулкыннар кагып, пароход узды. Якыннан гына. Алар урнашкан яр буеннан гына. Пароходтагы халыкның барысы да палубага чыккан. Елга өстен балкытып килгән ап-ак пароход, андагы чуар киемле халык күзләрне камаштыра. Кемнәрдер пароходтан яулык болгый, яр буендагы егетләр аларга җавап кайтара — яшь-җилкенчәкнең шатлыгы эченә сыймый.

Пароходта тальян гармун уйнап җибәрделәр. «Иделкәем алкын»ны өздерә бирәү. Гармунның көмеш телләре сипкән ашкын моң су өсләре буйлап тарала, дулкыннарда тирбәлгән акчарлакларның чыелдавын күмеп китә. Яр буендагылар яткан җирләреннән башларын калкыттылар, малайлар — су чәчрәтеп уйнаган малайлар — ишелеп-ишелеп килгән гармун тавышына колак салып, баскан килеш тын калдылар.

Шәфикага кинәт әллә нәрсә булды — аның күз алдында бөтен нәрсә хәрәкәткә килде. Яр буендагы таллар, ком өстендәге кешеләр, дулкын канатындагы акчарлаклар — барысы бер якка авыштылар. Гармун аларны үзе белән ияртеп алып бара.

Моның чыннан да шулай икәненә ышанырга теләмичә, Шәфика зәңгәр күккә, бөдрә болытларга карады: болытлар да, күк йөзе дә әйләнә, дөнья бөтенләе белән әйләнә иде.

Габбаслар нәселе — гомумән дә моңлы нәсел, музыканы, җырны ярата торган нәсел. Энесе Мәхмүтнең скрипка белән, сыбызгы-быргылар белән, камыш курайлар белән җенләнеп йөрүе юкка дисеңмени? Нурия апасы ял сәгатьләрендә пианино уйный, «Галиябану»ны җырлый. Ярый, алар моңайсын да ди. Шәфиканың үзенең дә мәктәптә җырдан алган билгесе — «биш»ле. Ләкин әле аның шушы көнгә тикле гармун моңнарына җир әйләнгәнен, Идел әйләнгәнен, болытларның әйләнгәнен күргәне юк иде. Болар барысы рәхәт һәм болар барысы Шәфика өчен сәер яңалык...

Пароход инде күптән узып киткән, болытлар белән күк йөзе туктапып калган — тик ул гына башының җиңелчә әйләнү рәхәтлегеннән баскан җирендә тик тора.

— Шә-фи-ка-аааууу! — дип сузып кычкырган тавышка сискәнеп, борылып караса, аны чакыралар, кул изиләр имеш...

Кызышып киткән бит алмаларын кулы белән басып, апасы янына йөгерде Шәфика. Юка ситсы күлмәге аша ботларына җил үтеп керде, толымнары, аркасына бәрелеп, атынгалап бардылар.

— Утының кайда? — диде аңа апасы, килеп житүгә.

Шәфика кып-кызыл булып кызарды, җыйган утынын алып килергә дип, кире йөгерде.

Балык шулпасын таган асып пешерделәр. Чирәм өстенә корсак белән ятып, мәзәк сүзләр әйтешеп ашадылар.

Кояш баш өстендә балкып тора. Көн отыры бөркүләнә бара. Су коенып аласы булыр дигән фикергә килделәр. Инде әзерләнеп тә беткәннәр иде, Маркиз утравындагы халыкның умарта күче кебек гөжли, бутала башлавын күрделәр. Ул да түгел, халык йөгерешә, яр буена килеп туктаган су трамваена тула башлады.

Төркемнәр ярга ашыга, буталыш көчәя бара иде.

— Ни булган соң анда? Барыгыз әле, белешегез! — диде Нурия.

Әхнәф шунда йөгерде. Коточкыч хәбәр алып кайтты: сугыш башланган!

Бу минутта утраудагыларның күңеленнән яшен тизлегендә уй узды: «Кайчан? Кем белән? Ник?»

Бу минутта миләр бик кызу эшләде — һәркемнең булган хәлне тизрәк ачыклыйсы, беләсе, үзе өчен нәтиҗә ясыйсы килде. Менә шуннан башланды ашыгу-каударлану, шуннан башланды су трамваена йөгерүләр. Йөгермәсәң, су трамваена эләгә алмый калырсың да, син кайтканчы калада әллә ниләр булыр төсле иде.

«Сугыш» сүзен ишеткән беренче минуттан Нуриянең күңеле хәвефшом белән тулды. Балалар! Алар бит кичә, автобуска төялеп, бакчадачага киттеләр. Хәзер аларны Казанга кире кайтаралармы, әллә шунда асрыйлармы? Ашыгудан берәр уйламаган эш эшләп ташламаслармы?

Әхнәфнең эчен яндырып бер уй узды: Хәрби комиссариатка бүген чакырырлармы, иртәгәме? Аттестат алып өлгерәме? Хатыны Әкълимә кайтып өлгерәме Бөгелмәдән? Күрешмәсәләр, үкенечле булачак...

Солтан Айдаровның да күңелендә уй бар. Башкаларныкыннан бөтенләй аерым уй. Аны фронтка алырлармы? Авыруына бәйләнмәсләрме? Сорамасалар, ул, әлбәттә, авыру икәнен әйтмәс. Чакырырлар микән? Чакырмасалар — үз теләге белән, ирекле булып китәр ул. Рухи газаплардан котылуның бер әмәле кайчан да булса табылырга тиештер бит инде. Фронтка эләгә алса, ул үзен күрсәтеп карар иде...

Шәфиканың, әле дөньялар үзгәргәнне төшенеп житмәгән бу үсмер кызыйның да, үз борчуы бар: сугыш булгач, укулар өзелмәсме? Педучилищены япмаслармы?

Әнә шундый уй-борчулар белән алар палаткаларны җыйдылар, таганнан котелокны алып, учак утын сүндерделәр. Җиргә җәеп яткан җәймәләрне, ашаган савыт-сабаны ничек кирәк алай юл капчыкларына, кәрзиннәргә тутырып, су трамваена ашыктылар.

Сугыш беренче сәгатьләреннән башлап кешеләр аңына хәвеф һәм житдилек, ашыгу һәм ныклык салды.

## II

22 июньдә гитлерчыларның беренче һөҗүмнәрен үз җилкәсенә алган чик буе калаларының хәле ничек булгандыр, аны күз алдына китерүе дә кыен, чөнки Нурия Уразаева, Казандагы хәлләрне күрү белән үк, илнең язмышы кыл өстендә икәнен аңлады.

Урамда патрульләр, иярле атларга атланган милиционерлар йөри. Тигез сафларга тезелгән гаскәриләр, урам ташына дагалы итекләре белән чакылдатып баса-баса, каядыр узып китәләр. Ходаның бирмеш көне, иртә-көндезләрен йорт буйларына, урам чатларына чыккан аркаларына капчык аскан ир-атның, аларны озата чыккан хатын-кызның, бала-чаганың сулыгып-сулыгып елаган тавышлары саубуллашу сүзләре белән аралаша: тальян кемнеңдер күз яше булып сулкылдый, рус баяны аерылы-

шу сагышын урамның буеннан-буена түгә; бу моңнар, бу тавышлар көннән-көн күбәя, ишәя; вокзалларда товарняклар, махсус эшелоннар ул тавышларны, гармун моңнарын ил буйлап алып китәләр; булачак сугышчыларны төягән поездларның тәтеннәрендә эретеп юкка чыгаралар.

Дөнья кырыслана бара. Кешеләр ничектер үзгәреп, җыйнакланып киттеләр: тыныч заманнардагы төсле җәелеп сөйләшмиләр, хәл-әхвәл белешәләр дә китеп баралар. Тонык чырайлы, авыр эштән бирчәйгән зур куллы ир уртасы кешеләр, башка чакта хатыннарына иркә сүзне әйтергә әллә ни ашкынып тормаган йомыкый кешеләр гомер буе әйтмәгәннәрен бер мәртәбә әйтеп калырга ашыгалар. Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз дип, хәләлләрен кеше-кара алдында ук кысып кочаклыйлар, оялмыйча күз яше белән елыйлар иде.

Нурия Уразаевага берьюлы ике повестка килеп төште. Берсе — врач буларак, ул хәрби госпитальгә мобилизацияләнә, Казаннан беркая да китмәскә тиеш. Икенчесе — Аккош күленә балаларын алырга килергә тиеш. Ни хәтле тизрәк килсә, шул хәтле яхшырак.

Әхнәф Айдаровка да хәрби комиссариатка килергә повестка тоттырдылар. Нурия әллә ничек каушап китте. Гомердә булмаганча. Нишләргә? Әхнәфне юлга әзерләргәме, балаларны алмага Аккош күленә китәргәме, әллә берни дә эшләмичә, кулны кушырып, тик кенә утырыргамы? Зиһене чуалган, мие дүнгән иде.

Балаларны алмага Солтанны җибәрергә булды. Ләкин тегесе карышты да калды.

— Ни өчен? — диде Нурия, еларга җитешеп.

Ни өчен икәнен Солтан әйтмәде, тешен генә кысты. Чөнки ул балаларны алмага барса, хәрби комиссариатка барып өлгерә алмам дип курка иде. Әгәр дә шуны Нуриягә әйтсәң — сырт йоннары кабарачак. «Син — эгоист, үзеңне генә уйлыйсың, син мине дә, балаларны да уйламыйсың, син гомер буе шулай булдың!» Бар, шуннан соң тынычландырып кара син аны, юатып кара!

Нурия Солтан уйлаганны ярды да салды:

— Менә шундый чакта сынала инде ул ирләр...

Солтан бурлаттай кызарды.

— Яхшы,— диде гасабиланып.— Бик яхшы! Мин барам. Мин балаларны алып кайтам. Ә син... син... менә хәзер үк, шушы минутта ук минем гаризамны военкоматка илтеп бир.

Нурия, ире биргән кәгазьне укыгач, агарынып китте. Солтан үзен хәзер үк, бер көн дә кичектермичә, фронтка җибәрүләрен үтенгән. Сынатырга ярамый иде. Нурия тамак төбенә килеп бөялгән төенне йотып, мөмкин хәтле тыныч тавыш белән:

— Ярый, этисе, илтермен,— диде.

Хатынның артык сабырлыгы Солтанга «әртисләнү» булып тоелды.

— Син моны чынлап әйтәсеңме, әллә мине юатыр өчен генә юри риза булдыңмы? — диде ул, йөнтәс кашларын җимереп.

Ниһаять, Нуриянең сабырлыгы сынды.

— Җитте, Солтан! Сентиментальщина белән бер-беребезнең җанын корытмыйк. Син — ашка саласы тоз түгел, мин — кияүгә димләнгән кыз түгел. Туйлар узган, туннар тузган! Син миннән үтенәсең, гаризамны военкоматка илтеп бир дисең, мин риза булам. Тагын ни кирәк сиңа?! Эшләгән эшеңне уйлап эшлисеңдер, бала-чага түгел, авыру ир, гражданнар сугышын узган солдат!

Солтанның җанында көйрәгән ялкын бетмәгән иде әле. Нуриянең күз алдында ул энесе Әхнәф белән саубуллашты, хатыны ишетсен өчен нык тавыш белән:

— Көт мине, фронт юлларында очрашырбыз,— диде.

Нурия сизеп тора: Солтанның нияте изге. Ләкин шул изге һәм чын ниятенә ышанмыйлар дигән уй аның күңелен рәнҗеш белән тутыра булса кирәк.

Юл кожанын кулына тотып, аягына күн итек, өстенә землемер булып эшләгән чактагы кыр киемнәрен киеп, ул Аккош күленә балаларны алмага китеп барды.

— Документларыңны алырга онытма, сугыш заманы,— дип артыннан кычкырып калырга гына өлгерде Нурия, башкасына өлгермәде. Ире киткәч, күңелен үкенү хисе биләп алды, тик Әхнәфне юлга әзерләп бетерәсен уйлагач кына бераз тынычланды. Әхнәфне Татвоенкоматка озата барган чакта ул Солтан хакында ныклап сөйләшә ала бит әле. Солтан үзе барса, тәкәбберлегенә көч килеп, яки Нуриясенә үч итеп, аннан да бигрәк аны ничәмә еллар зур эшеннән, җаны теләгән эшеннән читләшеп яшәргә мәҗбүр иткәннәренең каруын кайтарыр өчен, фронтка китәргә ашкыначак. Туберкулез белән авырганын әйтмәс. Аны-моны тикшереп торыр чак түгел, кемнең кемдә эше бар дигәндәй, җүнле-башлы карамыйча, җибәреп куюлары да ихтимал. Ә бу «тәкәббер Тәхәви, горур Гарифулла» бер-ике айдан кәкре каен астына барып керергә дә күп сорамас. Фронтка бернинди ярдәме тимәгән көе! Йөр аннары военкомат юлларын таптап! Минем иремне хәрәкәттәге армиягә алырга тиеш түгел идегез дип исбат итеп йөр!

Солтан абыйсы ишектән чыгып кына киткән иде, Әхнәф ишеклетүрле чаба башлады:

— Карале, апа, мин нүжәли Әкълимәне күрми китәрмен инде? Нигә кайтмый инде ул? Белә бит китәсемне. Нишләргә инде миңа, ә?

— Туктале, Әхнәф, сабыр булыйк әле. Хатының бит уйнап йөрергә китмәде. Институт җибәрде бит аны — врачлар практикасына. Кем белә, бәлкем, ул да вокзалларда әрле-бирле сугыладыр. Җанын кая куярга белмидер. Поездлар бит сугышка китүчеләр белән тулы...

— Анысын беләм мин, апа. Эч пошканнан әйтү. Нүжәли күрешмәбез? Ә ул өч-дүрт көннән генә кайтып житсә? Карале, апа, әллә мин өчдүрт көнгә берәр жиргә китеп торыйммы?

— Акылың бармы синең, энем, әллә син шыр тилеме? Дезертир исемен аласың киләмени? И җүләркәем минем! Үзең әле житмәсә югары белемле специалист. Инженер. Берни белмәгән дөм сукыр, надан кеше төсле кыланасың...

— Әйе шул, апа,— дип, Әхнәф шундук килеште.— Җан әчеткәннән әйтү. Ярар, ни хәл итәсең инде, язмышың шундый булгач. Әкълимә кайтып житмәсә дә, китәргә туры килә инде.

Кичкә таба Нурия, аны әзерләп бетереп, хәрби комиссариатка хәтле озата барды. Татвоенкомат янына бер квартал кала күрделәр: урамны атлар, арбалар, тарантаслар бүлеп алган. Халык, халык, халык! Сабан туена жыелганнармы диярсең. Тик сабан туйларында төсләрнең жетелегеннән күзләр камаша торган иде. Бирегә — барысы да карадан, яки соры дан. Кара-кучкыл дингез төсле, чайкалып-гүләп тора. Якынрак килгәч, аерым төркемнәрне дә аерып була башлады. Кыңгыраулы, шлеячуклы атлар җигелгән иркен зур арбалар өстендә — бер-берсенең жилкәләреннән алып, кочакланышып утырган егетләр. Җырлыйлар, тартынып-нитеп тормастан, кызлары белән үбешәләр, саубуллашалар, үксеп елыйлар...

Военкомат капкасыннан яшьләр төркеме килеп чыкты. Өстенә гимнастерка, башына пилотка кигән гаярь бер егет, команда биреп, аларны сафка тезде, команда биреп, урам буенча алып китте.

Әхнәф биредәге хәлләрне күргәнче, үзен ничек кирәк алай тыеп торган иде, Нурия апасы белән саубуллашу минутлары килеп житкәч, күзләре кызара башлады, тулышты, эре яшь бөртекләре бите буйлап агып төшеп киттеләр.

— Апа, Әкълимәгә әйтерсең инде,— диде ул, жебегән борынын кул аркасы белән сөртә-сөртә.— Сине бик тә күрәсе килде диярсең. Карале, апа, мин диплом кенәгәмне сезнең буфет тартмасына салып куйган идем, үзең белгән жиргә яшерерсең әле шуны, яме. Әкълимә бүгенме, иртәгәме кайтып житсә, әйт — килсен, кем белә, бәлки, безне атна буе жибәрми

асрарлар. Военкоматта булмасак, казармада булырбыз. Сорашып белсен. Иренмәсен. Бигрәкләр дә үкенечле була бит, апа, Әкълимәне күрми китсәм...

— Кайгырма, энем, син моңарчы бәхетсез түгел идең әле. Кайтыр да, килеп тә житәр, насыйп булса. Инде күрешә алмыйсыз икән, ни хәл итмәк кирәк, син гаепле түгел бит, язмыштан узмыш юк.

— Апа, карале, минем армиягә алынганны Зартугайга да хәбәр итәрсең, яме — әти белән әнигә...

— Ярар, энем, ярар, итәрбез. Безнең хат бит аларга синекеннән алдарак барып житәр.

Икесе дә, елашып, бик авырдан аерылдылар. Нурия хәрби комиссар янына күзләре кызарган, борыны җебегән хәлдә барып керде. Әле фин сугышы заманында ук кабул иткән кеше — озын буйлы, ачык чырайлы Казаринов — бу юлы, көне-төне мобилизация белән шөгыльләнгәнгәдер, бик тә йончылган, калку кабаклы күзләренең төбенә капчыклар асылынган хәлдә, игътибарсызрак каршылады аны.

— Уразаевамы? — диде ул, күтәрелеп карауга.— Сезгә, Уразаева, Казан госпитальләренең берсендә эшләргә туры килер.— Алдында өстәл өстендә яткан бер исемлекне тартып китереп, «Уразаева Н. А.» дигән фамилия турысында кызыл карандаш белән тамга салды.— Наркомздравка барыгыз, анда кайсы госпитальгә икәнен төгәлрәк әйтерләр.

Нурия үзен ике баласы белән фронтка җибәрмәячәкләрен белә иде, әлбәттә. Шуны комиссарның үз авызыннан ишетү күңеленә тынычлык иңдерде. Ләкин әле Солтан мәсьәләсе хәл ителмәгән. Аңа ничек карарлар бит?

— Иптәш комиссар... сез мине гафу итегез. Ирем Айдаров гариза биреп җибәргән иде.

Казаринов гаризаны алды. Күз йөртеп чыкты.

— Ярар, калсын. Кирәк булса, чакыртырбыз,— диде.

Нурия шул сүздән соң иренең авыру икәнен, строевойга ярамавын да әйтергә кымырҗыган иде, әллә нишләп батырчылыгы җитмәде. Бер урында таптанып алгач, сау булыгыз дип, чыгып китте.

Солтан балаларны алып кайткан иде. Башта Сания, аннары Рафаэль йөгереп килеп, әниләрен кочаклап алдылар. Аяк атларга да ирек бирмиләр. Әллә, ходаем, алар да хәвефле көннәр килгәнне сизенәләр микән?

Әтиләре караңгы чырайлы иде.

— Йә, нәрсә диделәр военкоматта?

— Гаризаңны алып калдылар. Кирәк булса, чакыртырбыз, диделәр.

— Башка сүз әйтмәделәрме?

— Әйтмәделәр.

Солтанны ул гына канәгатьләндермәде. Кайнаткан чәйне дә эчеп тормастан, хәрби комиссариатка үзе китте. Аннан ул сөмсерләре коелып кайтты. Чөнки аңа «ак билет» биреп җибәргәннәр иде. Күңеленнән ул: Нурия, мөгаен, минем авыруымны, ничә мәртәбә дәва алуымны тәфсилләп сөйләгәндер, дигән гөнаһлы уй да уйлап өлгерде.

Көн күңелсез узды. Башка вакытларда балалар белән рәсемле китаплар карый торган Солтан бүген аларга якын да килмәде. Үзенә сырышкан Рафаэльне дә кулы белән читкәрәк этеп җибәрде.

Тегесе, идәнгә утырып, гарьләнеп елый башлады.

— Йә, әтисе, балаларның ни гаебе бар инде? Минем ни гаебем бар? Сугышка бит таза-сау кешеләр кирәк. Синең кебек шыңгырдавыклар белән нишләсеннәр анда?

Монысы инде чамадан тыш иде. Солтан бөтенләй дәшмәс булды. Кич буе карасына кабынып утырды. Һәм алар, ир белән хатын, берберсенә татлы йокы теләмичә, төнге уникеләргә кадәр селкенеп, бер-берсен рәнҗетеп йөрделәр.

## III

Тап-таза ирләр сугышка китеп, эш урыннары бушаганлыктан, Солтан Айдаровка Наркомземнан вазифаның зуррагын йөкләделәр. Һәм ул, Җир төзүчеләр техникумында эшләгән чакларындагы төсле, баш-аягы белән эшкә чумды.

Иртәләрен ул радио тыңлый. Фронтта эшләрнең отыры катлаулана барганын ишетеп, офтана, авыр итеп бер көрсенә; Нуриясе аңа көндезен ашарга дип әзерләп куйган бер телем ипине, колбаса яки сыр кисәген бик пөхтәләп газета кәгазенә төрә дә эшенә китеп бара. Нурия белән алар кичен генә очрашалар.

Шәфиканың Арча педучилищесына керү хыяллары җилгә очты. Луизаны өйдә бер көтү бала белән өелеп калган әнисе чакыртып алды. Шуңа күрә Нурия сеңлесе Шәфиканың быел Казанда укуын, Сания белән Рафаэльне бакчага илтеп, алып кайтуын үтенде. Сабыр табигатьле, буйсынучан Шәфика кая барсын — апасының сүзен тыңламый булдыра алмады. Җизнәсе Солтаннан ул уңайсызлана, ул аңа әрәмтамак дип карыйдыр сыман тоела, шуңлыктан бик әллә ни ачылып сөйләшә алмый иде. Арчага китәргә теләве дә әнә шуңардан иде.

Июль белән август бик киеренке узды. Мәктәптә әле укулар юк. Шәфика Зартугайга да кайтып китә алмый, әлегә укуга да йөрми, аның гомере хәзер шул кибетләренә, азык-төлек чиратларына чыгып, Сания белән Рафаэльнең көйсезлекләренә түзеп уза.

Нурияне Казанның колхоз базары артындагы әле төзелеп кенә ята торган госпитальгә беркеттеләр. Дөресрәге — аны күптәнге танышлары, доктор Ипполит Дмитриевич Тарибердиев чакырды. Өенә килеп. Карт врач Тарибердиев Казанда туберкулез белән авыручыларны дәвалаучының зур оста иде. Сугыш бик кинәт һәм бик дәһшәтле башланып киткәнгә күрә, тылдагы госпитальнең башлыгы итеп хирург булмаган кешене дә куярга исәпләгәннәр, күрәсең. Тарибердиевнең тәкъдимен Уразаева шундук кабул итте. Беренчедән, аны барыбер госпитальгә алалар, үзең белгән кеше кул астында эшләве җайлырак булыр, икенчедән, тыныч елларны Солтанга ничә мәртәбә ярдәм иткән кешенең үтенечен ничек кире кагасың.

Госпитальдә эшләргә тиешле барлык персонал — профессор үзе, бүлек начальниклары, врачлар, шәфкать туташлары, санитарлар, хуҗалык хезмәткәрләре һәм җыештыручылар — һәммәсе бергәләп, атна-ун көн эчендә мәктәп бинасын госпиталь рәвешенә керттеләр. Шул чагында Нурия Мәскәүдән һәм Кырымнан килгән врачлар белән танышты. Казан стоматология институтын 1940 елны гына тәмамлаган врач Садыя Сафина — тәбәнәк буйлы, камыт аяклы, чегән арбасыннан төшеп калган төсле кара-чутыр хатын — теш дәвалау кабинетын җиһазларга тиеш иде. Садыя ничектер аз сүзлелеге белән дә, авыр язмышы белән дә (аның ире 1940 елны армиягә алынган, кечкенә кызы ул югында туган, инде менә ире Фазыл сугышта йөри, кызын күргәне юк икән әле) Нуриянең күңеленә ятты. Финнар белән сугыш чорында госпиталь оештыру буенча азмыкүпме тәҗрибә туплаган Уразаева аңа кулыннан килгән барлык ярдәмне дә итте: приборлар табышты, мебельләрне кайдарак урнаштырырга кирәклеген аңлатты.

Нурия госпитальдә сере сыярдай бер иптәш табылганга шатланды. Аның үзенә бу юлы госпитальнең лабораториясен җиһазлау бурычы йөкләнгән иде.

Госпиталь инде әзерләнеп бетә язды дигән көннәрдә Ипполит Дмитриевич Тарибердиев персоналны киңәшмәгә җыеп алды. Сүзне ул кыска тотты, ягымлы итеп дәшүе белән һәммәсен дә үзенә карата алды:

— Хөрмәтлеләрем,— диде карт профессор,— сезне, мәгълүмдер ки, яралы сугышчыларны багарга, госпитальдә эшләргә дип укытмаганнар иде. Сез мондый авыр шартларны күз алдына да китермәгәнсездер.

Ләкин түзәргә туры киләчәк. Әйе, хөрмәтлеләрем, түзәргә! Ил язмышы кыл өстендә. Дошман бик явыз. Менә сугыш кына бетсен, тагын җылы бүлмәләргә, фәнни лабораторияләргә кайтырбыз. Ә хәзергә минем сезгә бер үтенечем бар: үзебезнең госпитальне ачканчыга хәтле, яралыларны кабул итә башлаганга тикле кул кушырып утыру ярамас. Гамәлдәге госпитальләргә барыйк. Тәҗрибә туплыйк. Күрик, белик, тырышыйк, күгәрченкәйләрем. Безгә авыр, фронттагыларга мең кат авыррак. Безнең туганнарыбыз анда гомерләрен кызганмый сугышалар...

Ышандырды карт профессор, йомшак мөгамәләсе, җылы сүзе белән ышандырды. Ә барыр җир күп. Халык теленә кереп урнашкан Шамский, Вишневский, Малкин, Старая клиника больницаларында, Арча кырында. Социалистик шәһәрчектә, Васильевода — уннан артык урында инде эвакогоспитальләр ачылган, анда җиһазларны, матрац-одеалларны барлыйлар, җитмәгән аппаратураны, приборларны җыялар; санитар машиналары белән бергә, яңа ачылган лазаретларга агач материалы, мебель, медицина инструментлары ташыйлар. Госпиталь эче яралылар белән тулып тора, төче кан исе дару исе белән аралашкан. Анда җырчылар килә, агитаторлар килә, баян тавышлары колакка чалынып кала — госпиталь тормышы үз җаена ятып бара шикелле.

Нурия госпитальләргә тәҗрибә алырга йөргән чакта тагын бернәрсәгә игътибар итте: кешеләр Казанның ышанычлы тыл каласы булуын, фронтка самолетлар, җылы киемнәр, азык һәм медикаментлар җибәрүен сөйлиләр. Йөрәкләренә якын итеп сөйлиләр Казанны. Сугыш барган яклардан Казанга хатын-кыз, бала-чага, галимнәр һәм язучылар күченеп килә.

Казан кайнап тора; хәвефле һәм ныклы, динамикалы һәм тәртипле тормыш белән яши. Казан ил йөрәгенең бер тамыры, аорта тамыры булып тибә.

...Тарибердиев госпиталенә яралыларны 27 августта китерә башладылар. Җәрәхәтләнгән сугышчылар белән беренче тапкыр гына очрашуы булмаса да, врач Уразаева авырулар кабул итүне бу юлы да авыр кичерде. Ул авыруларны машиналардан тәртибе-тәртибе белән төшерү, госпиталь эченә алып керү, урнаштыру өчен җаваплы иде. Институтта укыган чакта аларны, булачак медикларны, салкын канлы булырга, хискә бирелмәскә дип, ничаклы өйрәтеп килделәр. Юк, йөрәк таш түгел, йөрәк кысыла, чымырдап, ярсып талпына, күз төпләре кымырҗып, тыеп асраган яшьтән сызлый башлый. Кара инде, кара инде бер генә — аксыйтуксый атлаган култык таяклы кызылармеец егет нинди яшь; күп булса, аңа егерме биштер, нинди азапланып бара, күтәрмәгә аягын бәрмәсә генә ярар иде. Нурия аның яныннан саклап килә, ак халатлы шәфкать туташының кулына тапшырганчы, аксак егетне озата бара. Вакыт-вакыт ул носилканы да күтәрешә, чайкалдыра күрмәгез, тигез генә тотып барыгыз дип, киңәшен дә әйтеп җибәрә. Сугыш алдыннан Кара диңгездәме, Балтик буе кояшындамы бакыр төсле булып янган тап-таза егет, коеп куйган сындай, шундый да матур атлап бара, сокланмаган санитар юк үзенә, ләкин аның сул кулы төптән киселгән. Аның сөйгәне бардыр, алар әле берәр ай элек кенә айлы кичтә, су буенда серләшеп утырганнардыр, ул җан сөйгәнен кысып-кысып кочаклагандыр...

Нуриянең күңеленнән Солтаны белән тәүге мәртәбә очрашкан чаклары, Кама иделе, ак пароходлар, саллар, рабфак һәм институт еллары, Кабан күле буендагы зур бер өянке төбендә беренче мәртәбә егет куенына сыенулары яшен яктысыдай чагылып уза. Йөрәктән кан тамар дәрәҗәдә авыр була Нуриягә. Үзе өчен дә, кулсыз егет өчен дә...

Өйләренә ул хәлдән таеп, рухи газапланып, аякларын көч-хәл белән генә сөйрәп кайтып керә.

Солтан аңардан сорый:

— Нәрсә, әллә яралылар кабул иттегезме?

— Иттек,— ди Нурия. Ишек буендагы аяклы көзгедән үзенең агарып-күгәреп калган, җир төсенә кергән кыяфәтен күреп уза.

Кеше күңеленең дәвасы — вакыт. Беренче көннәрне бик куркыныч, бик дәһшәтле булып тоелган сугыш гарасатларына да күнегеп киләләр. Совет информбюросы әйткән хәбәрләрне — безнең гаскәрләр калдырып чыккан калаларны да сүзсез генә, тешне кысып кабул итәләр. Нурия Уразаева әкренләп госпитальдәге эшенә күнегә бара, яралыларны нык күңел белән, командирлар кебек, төгәл, ыгы-зыгысыз, паникасыз кабул иттерә; кул астындагы ике врач һәм сестралар белән лаборатор анализларны өлгертеп бара. Тәҗрибәле врач Нина Герасимова барлык инструментларны чиста-пөхтә итеп тота, кайчан карама, лаборатория ялт итеп тора, пробиркалар, кайчылар, шприцлар үз урынына куелган булыр.

Яралылар килә тора, терелеп китә тора. Госпиталь персоналы, фронттагы кебек, егылып китәрдәй булып хәлдән тайганчы эшли. Тыныч вакытта өч кеше башкарганны бер врач башкарып килә. Ярый әле госпиталь начальнигы Ипполит Дмитриевич кул астында эшләүчеләрнең хәлен аңлый торган булып чыкты, очраганда сораша, хәлләрне белешә, иртәнге оперативкаларда җылы сүзен кызганмый, әнә шул персоналны ыңгырашмый-нитми, тешне кысып, эшләп йөрергә мәҗбүр итә. Сугыш вакыты дип, һәрнәрсәне приказ-әмер тәртибендә генә куеп торса, ихтимал, нервылар да түзә алмас иде.

Өйдәге хәлләр дә үзгәрде. Айдаровлар гаиләсен Гажур йортыннан чыгарып, күршедәге ике катлы йортка фатирдаш итеп керттеләр. Солтан, Нурия, Шәфика, Сания, Рафаэль — барлыгы биш җан бер бүлмәгә урнашты. Анда нибары ике караватт куеп була, Шәфикага урынны идәнгә җәяргә туры килә. Аны апасы, район мәгариф бүлеге белән сөйләшеп, сигезенче класска рус мәктәбенә күчерде.

Гажур йортын госпиталь итеп корырга дигән карар чыкты. Шәһәр советы башкарма комитетыннан килгән вәкил — чәчен кыска итеп кистергән, аңа зур түгәрәк тарак кадап куйган, яшькелт гимнастерка, шундый ук төстәге итәк, күн итек киеп алган кырык яшьләрендәге хатын — мәсьәләне бик кискен итеп куйды, ике төрле сөйләшергә урын калдырмады:

— Бөтенесе фронт өчен! Бөтенесе Гитлерны дөмектерер өчен!

Сугыш бетүгә квартираларны элекке хуҗаларына кайтарып бирү хакында расписка тоттырдылар — ике көннән Гажур йорты эвакогоспиталь начальнигы карамагына күчте.

Торак хәлләре килеп чыкканда, Солтан Айдаров Бөгелмәдә командировкада, ул анда шәһәр халкын азыклы итү, кашлак җирләрне, тау итәкләрен бәрәңге бакчасына әйләндерү мәшәкате белән йөри иде. Ул кайтып кергәндә, инде Нурия сеңлесе һәм ике баласы белән Черноусовларның бер бүлмәсендә бөкшәеп утыра иде. Әйберләрне госпитальдән терелеп чыккан сугышчылар, олаучы карт белән бергәләп, күчереп куйганнар икән.

Гажур йортына озакламый Мариуполь шәһәреннән күчкән госпиталь урнашты.

Казан каласына көнбатыш районнардан эвакуация белән килүче хатын-кыз, карт-коры, бала-чага көннән-көн ишәйде.

Язучыларның Тукай клубы Мәскәү язучылары белән, университет, башкала галимнәре белән тулды. Чистайга, Чаллыга, Урал якларына берәм-берәм китеп барганчы, Казан аларны туендырырга, сыендырырга, күңелләрен табарга тиеш иде. Казан сугышка кадәрге елларга караганда бермә-бер артык ризык әзерләргә, өстәмә ашханәләр ачарга, типографияләрдә икмәк карточкалары басарга, магазиннарны, ишәйгән халык өчен, кирәгеннән артык эшләтергә тиеш булып чыкты.

Җил-давыллары, зәмһәрир суыклары белән кыш якынлашты.

Каланы туендырырга гына түгел, каланы җылытырга да кирәк. Утын бар — олаулар юк. Ягулыкны әзерләргә сугышка кадәрге гүәрдин

ирләр юк. Суык атналар буена, айлар буена сузылса, үзәктән ягып җылыту кочегаркалары ягулыксыз калсалар, көт тә тор — бөтен җылыту системасы шартлап юкка чыгачак. Совет информбюросы сугыш гарасатының, Гитлер Германиясе безгә көчләп таккан сугышның илгә нинди ватук җимерүләр, нинди үлем-һәлакәтләр китергәнен көн саен хәбәр итеп тора. Нурия госпитальгә барган чагында күрә: бүрекләренең колакчынын төшергән, пальто якаларын күтәреп куйган чал мыеклы, чал сакаллы өлкән кешеләр, үсмерләр, телогрейка өстеннән каеш буган, зур киез итекле хатын-кызлар эшкә барганда, эштән кайтканда, урам чатларына җыелалар, йорт стеналарына, яки багана башларына беркетелгән кара бүрәнкә төсле репродукторлар сөйләгәнгә колак салалар. Күрсенешеп, сүзсез генә таралалар.

Нурия Уразаевага октябрь аенда ук ике кубометр утын биргәннәр иде, ул инде бетеп килә. Күп дигәндә ике атнага сузарга мөмкин. Аннары кар базы кебек салкын бүлмәдә балаларың, авыру ирең белән шакыраеп утыру куркынычы туачак.

Госпиталь начальнигы врач Уразаевага алты кубометр утын алырга гортоп аркылы талон табып бирде. Тик моны сиңа берәү дә китереп бирмәячәк. Иделдә туңып калган утынны үзең барып, үзең алып кайтырга кирәк. Госпитальдә андый ерак җиргә барырдай транспорт та юк, санитар машиналарына утын төяп йөреп булмый, йөк машинасын үзең ничек булдыра алсаң, шулай җайларга тиешсең.

Якшәмбе көнне, төнге дежурдан соң, өскә киярдәй нинди җылы кием бар, шуларның барысын катлы-катлы киеп, Нурия Уразаева Идел буена китте. Солтанны анда алып барып булмый, суык тидерсә, аның үпкә авыруы тагын котырып китүе мөмкин, ә Шәфика балалар белән мәшгуль.

Нурия Бишбалтага — Петрушкино тукталышына хәтле шәһәр трамваена утырып барды, юлның калган өлешен, битен өшетмәс өчен, шәл белән төреп, җәяүләп узды.

Сугыш елының авырлыгы, балаларны ничек саклап калу хакында сагышлы-моңсу уйларына бирелеп атлый торгач, ул пристаньга җитте. Идел өстендә бәкеләрдән багор белән утын чыгаручы, Бишбалта төрмәсеннән китерелгән тоткыннар янына килде. Аларны кораллы конвой саклый иде.

Утын алырга килүчеләр төрле бәкеләр янындагы утын өемнәренә чират торалар. Чираты бер хәл, шакыраеп катмасаң, бер килеп тә җитәр, ә менә аны нәрсә белән алып кайтырга?

Суыктан калтыранган хәлсез картлар өзлексез таптаналар, Гитлерны эт еккырысы дип сүгәләр, авызларыннан томандай куе ак пар бөркелә, сакал-мыекларына укмашкан карны куптарып ала алмыйча интегәләр. Картларның өзек-өзек сүзләреннән Нурия аңлап алды: Осланга һәм Печишега йөк төяп килгән атлар Казан ягына буш кайткалыйлар икән, әнә шуларны эләктерергә кирәк. Бу хәбәр Нуриянең күңеленә җылы индерә, суык йөгергән аяклары бөтенләй сызлый башламасын өчен, ул баскан урынында тыпырдый, үзе белгән барлык төр «бию»ләрен башкарып чыга. Ләкин суык рәхимсез, ул биткә, борынга үрмәли, аркага үтә башлый. Дүрт сәгать буе чиратта торып, дүрт кубометр утынны бүлдереп алгач, теше тешкә тимәс дәрәҗәдә калтырана башлагач, аңар да ике олау туры килде. Олаулар артыннан теркелдәп кайта-кайта, арка-җилкә җылынды, битне гел суыктан каплап, дымланган шәл аркылы гына сулап кайтырга туры килде. Төнге сәгать уннар тирәсендә генә кайтып җитә алды.

Олаучы картлар утынны ишегалдына бушатып китеп бардылар. Ләкин аны ишегалдында калдырырга ярамый, иртәгә чаклы аны урлап китүләре ихтимал иде. Нурия өйгә кереп шул хәбәрне әйтте, әмма үзе шакыраеп каткан итекләре белән шуып китеп, лап итеп идәнгә утырды. Аны Солтан белән Шәфика көч-хәл белән торгыздылар, өстен чишендереп, юрган астына салдылар, шкафтан эзләп табып, аркасын, күкрәк турыларын спирт белән удылар.

Солтан битләре ут кебек янган хатынын кызганып, беркавым карап торгач, өстенә киенә башлады. Шәфикага да киенергә кушты. Алар икесе, күршеләре Мәсгудәне алып, ишегалдына чыктылар. Өчәүләшеп, черәшә-черәшә, утынны Черноусовларның утын сараена кертеп өйделәр. Керту бик авыр булды, чөнки бәкедән чыгарылган ике метр озынлыгындагы пүләннәр бозланып катканнар, тоткан чакта, кулдан шуып китәләр, икең ике башыннан тотмаганда, күтәреп барып та булмый иде.

Иртәгесен иртүк Нурия тагын Иделгә китте. Кәефе юк, арка-җилкәсе чәнчештереп тора, башы да авырта, ләкин утынның калган ике кубометрын җилгә очырып булмый иде. Ләкин анысын алып кайту кичәгесеннән дә кыенрак булды. Бәке янында чиратта торып туңуы гына җитмәгән, олаучы очрамый да очрамый. Ниһаять, туңуның соңгы чигенә җитеп, ник кадалмый шунда утыны да! — дияр хәлгә житкәч, инде кайтып китәргә исәп тотып торганда, бик тә арыган бер алаша белән баручы толыплы карт очрады. Нурияне кызганды бугай, булышырга булды.

— Әйдә инде, айса, кодача, аллага тапшырып төяп карыйк. Түлке белмим, ат чыдатыр микән? — диде.

Кайтырга чыктылар. Болытлы күк йөзе баш өстенә үк төшеп житкән. Җәяүле буран себертә. Урыны-урыны белән юлларга да салган. Идел өстеннән — тигез җирдән — ничек кирәк алай чыкканнар иде, аннан соң Петрушкинога хәтле ике урында казылма очрады. Кичәге көр атлар бу казылманы сизмәгәннәр дә иде, алаша мескен казылмадан чыга гына алмый бит. Көчәнеп тә карый малкай, уңга-сулга да тайпыла — камыт агачлары шыгырдый, юк, булмый.

— Иех! Авызын песи ялагыры, шулай булыр әле дип уйлаганыем аны.

Атны куалап-куалап та берни барып чыкмагач, олаучы карт, сакалмыегына ябышып каткан бозны ялангач кулы белән җебетеп кубара-кубара, Нуриягә әйтте:

— Без моның, кодача, һич югы, яртысын менә шушы казылма янында калдырып торыйк, яртысын теге якка чыгарып куйыйк,— диде. Тагын бер казылмадан утынны икегә бүлеп алып чыгарга туры килде. Шулай азаплана торгач, шәһәр башына да кайтып җиттеләр. Кышкы көн кыска. Ул арада күз бәйләнде, караңгы төште. Нурия күңеленнән туктаусыз теләк теле, ходаем, абзый киреләнә күрмәсен, утынымны ташлап кайтып китсә, нишләрмен, көне буе азапланганнарым юкка чыга бит, дип ут йотты.

Алда тагын бер казылма, шактый ук текә бер үр дә очрады. Утынның яртысын тагын бушаттылар — анысын Нурия саклап калды. Калган яртысын карт, үрнең аргы ягына бушатып, кире килде.

Үргә менеп җитсәләр — утыннан җилләр искән!

Кычкырып еламады гына Нурия. Карт сабыррак булып чыкты: китеп баручы олау-мазар юкмы дип, ул тирә-ягына карангалап алды. Олау юк. Әмма бераз арырак товарняк тора, өсләренә ак каеры тун кигән ике кызылармеец соңгы пүләннәрне, ике башыннан тотып, вагонга алып менеп баралар иде.

— Әнә! — дип, бик сәер чыелдык тавыш белән кычкырып җибәрде карт. Нурия, аны калдырып, вагоннар ягына чапты.

Товарняк шактый калку урында тора иде, йөгерә-йөгерә мышкылдап чыкты Нурия, ходаем, килеп житкәнче, поезд кузгалып кына китмәсә ярар иде дип, күңеленнән теләкләр теләде. Беренче уе — поезд башлыгын табу булды.

Озак эзләргә туры килмәде. Кызылармеецлар төсле үк каеры ак тун кигән, бүрек кашына кызыл йолдыз кадаган кырык яшьләрендәге бер кеше, саргылт мыегын чәйнәштереп, аның алдында күзләрен мут елтыратып басып тора иде инде.

Йөгерүдән тыны кысылган, әле һаман еш-еш сулу алган Нурия, ах-вах килеп, гозерен әйтте:

— Иптәш командир! Мин врач, хәрби госпитальдә яралыларны дәвалыйм. Ә менә сезнең сугышчылар минем көне буе азапланып Иделдән алып кайткан утынымны вагоннарга төягәннәр,— диде.

Командир, ике бармагын авызына кабып, ачы итеп сызгырып җибәрде. Шундук аның янына ике сугышчы йөгереп килеп җиттеләр. Командир аларны читкәрәк алып китеп, бармак яный-яный, нидер әйтте. Ул да түгел, вагоннардан башлар калыкты, ике метрлы итеп тураган пүләннәр вагоннан коела башладылар. Каеры тунлы кызылармеецлар аны, олаучы карт янына ташып, чанасына төяп бирделәр. Көлешә-көлешә, бер-берсенә төртмә сүзләр әйтешеп, һәм атка төрле яктан булышып, чананы үр өстенә үк менгереп җиткерделәр.

Нурия, күңеле җылынып: «Ә шулай да ходай бар дөньяда. Ходай ул — кешенең намусы. Намус бетмәсә, дөньяда яшәп була»,— дип уйлады.

## IV

Аларның хәзер кыш буена җитәрлек утыннары бар. Бала-чагалары белән җылы өйдә кыш чыга алалар. Әмма ике көн рәттән сигезәр-унар сәгать суыкта торып, Иделдән утын алып кайту кыйбатка төште Нуриягә. Ул авырый башлады. Ике аягы да тездән түбән шешә; тубыклары, госпитальдән кайтып урын өстенә егылгач, үзәкләргә үтеп сызлый иде. Ул арада муендагы бизләре дә күзгә күренеп кабара, зурая башлады. Иртәнге сигездә госпитальгә рапорт вакытына барып җитәргә кирәк. Нурия бик авырдан гына кузгала, инде угын кытлыгыннан котылдык, икмәк кытлыгыннан ничек котылырга дип уйлый. Ипине үзләренең йорт астындагы кибеттән Шәфика ала. Аның эшкә барасы юк, мәктәпкә бераз гына соңга калырга да була. Сугыш елы авырлыгын үз җилкәсендә татыган укытучы моңа әллә ни күтәрелеп бәрелми.

Шулай бер көнне, Солтан командировкада чакта, Нурия госпитальдән кайтып керсә, Шәфиканың бер дә чырае юк. Күз кабаклары да шешмәкләнебрәк киткән, әллә елаган инде. Нурия, аның чыраена карап, ни дә булса булган, дип уйлап та бетермәде, Шәфика, башын аска иеп:

— Апа, мин кибеттә кесәмнән ипи карточкаларымның икесен алдырттым. Берсе — синеке,— диде.

— Алдырттың?! — диде Нурия, берни аңламыйча. Зиһене кинәт бик кызу эшли башлады, битләренә шаулап кан йөгерде. Ул нишләгәнен белештермичә, Шәфиканың яңагына чабып җибәрде.

Шәфика дәшмәде. Ул чытырдатып иренен кыскан, күзеннән мөлдерәп яшь тама иде. Бераздан, аңына килгәч, Нурия аны кочаклап, үксиүкси елады. Аның тавышына, аның әрнүенә кушылып, балалар да еларга тотындылар.

Бик күп еллар узар. Нуриянең үз кызы белән үз малае Шәфика эшләгәннән дә кыенрак эшләр эшләрләр, ул аларга сукмас, сугарга дип күтәрелгән кулын кире алыр. Аның күз алдында иреннәрен кыскан, тавыш-тынын чыгармаган юка-чандыр гәүдәле сеңлесе басып торыр...

Ашау-эчү яклары үтә кысан булу өстенә рухи кимсетелүләр Нуриягә бик ардыра, җанын талап тора иде. Вакытлыча өйдәш булып кергән квартираның хуҗасы Черноусов, Солтан кебек хәрби хезмәткә ярамагангадыр, күчмә госпитальләрнең берсендә интендантлык хезмәтен башкара, хатыны, теш врачы булса да, никтер санитария врачы булып эшли. Ул беркатлырак хатын. Казан әйләнәсендәге тегермәннәрдән азлап-азлап он алып кайтуларын Нуриядән яшермичә сөйли; әбиләре Капиталина Ивановна — бик тә хикмәтле карчык — үзенең чыгышын Оболенский дигән дворяннарга китереп тоташтыра, ә үзе, өс-башын салмыйча, коридордагы сандык өстенә ятып йоклый. Югыйсә аңа дип әзерләп куелган диван да бар, карчык никтер ул диванга әйләнеп тә карамый.

Эшкә киткәндә дә, эштән кайтканда да Нурияне беренче булып Капитолина Ивановна каршылый. Чырае караңгы булмас. Аз гына елмая төшеп, һаман бер үк сүзне кабатлар:

— Доктор, сез кайчан үз өегезгә күчәсез инде?

Нурия нервыларын бер төенгә төйнәп тота.

— Тиз генә күчеп булмас шул әле, әбекәем,— ди ул үтә йомшак, ягымлы тавыш белән.— Сугыш әнә һаман бетми бит. Ә безнең үз йортыбызда яралы сугышчылар дәвалана. Бер эш тә эшләп булмый, әбекәем, кысан булса да, бергә яшәп торырга туры килә,— ди Нурия. Боларын ул кәефе бер генә дә китмәгән сыман, «әбекәе»нең хәленә кергән сыман әйтә. Акылы ычкына башлаган карчыкка тагын ничек аңлатасың.

— Шулай-мы-нии? — ди Капитолина Ивановна, башын чайкый-чайкый китеп бара.

Икенче көнне Нуриянең госпитальдән эт урынына арып кайтып керүе була, әбиебез тагын бер үк сүзне кабатлый:

— Сез үз йортыгызга кайчан күчәсез әле, доктор?

Нурия дә үзсүзле. Бер дә кәефе китмәгән сыман, вәземләп, озаклап, ни өчен үз йортларына күчмәүләрен аңлата башлый. Бу бит алар иркеннән түгел. Алар йортында яралы солдатлар дәвалана. Әнә бит әбекәйләрнең күршесендәге егерме биш метрлы гына квартирга да Мәскәүдән эвакуация белән кайткан ике сеңелне керткәннәр. Авиация заводында эшлиләр. Югыйсә инде ул егерме биш метрлы квартирада болай да нәни кызы белән солдатка яши иде бит...

— Шулай-мы-нии? — дип гаҗәпләнә Капитолина Ивановна.

Нурия аның хакында, әллә әбиебезнең картлык авыруы гел көчәя бара микән дип тә уйлый башлаган иде, әмма бер хәл аны ул уеннан кире кайтарды. Черноусовның хатыны Зинаида пианинода бик матур уйный икән. Нурия дә бит заманында композитор Солтан Габәшидән музыка дәресләре алып йөргән иде. Зинаида белән Нуриянең музыка җирлегендә серләре килешеп китте ләбаса! Нуриянең кызы Сания, музыкага кушылып, үзләренең бакчасында откан җырларын җырлый: Шәфика, иягенә таянып, моңсу күзләрен стенадагы диңгез пейзажына төбәп, тын гына тыңлап утыра. Алар янына кайчагында Солтан да мандолина белән килеп кушылгач, авыр моңсу кичләр, кара штора белән капланган ярым караңгы бүлмәләр яктырып киткәндәй була. Әллә шуның тәэсире булды — Капитолина Ивановна бүлмәдәше Нурияне, кайчан үз өегезгә күчәсез дип тинтерәтүдән туктады. Ул хәзер сандык өстендә дә йокламый, үзенә билгеләнгән диванда йоклый, хәтта, Нурияләрнең вакыты булмаган чакларда, бакчадан балаларын да алып кайтып куйгалый башлады. Черноусов үзе дә шушы хәлләрдән соң квартирантлары белән исәпләшә, хәлләрен сораша торган булып китте.

Дөньяның нинди генә фаҗигалары, нинди генә авырлыклары булмасын, караңгыдан яктыга чыгар өчен өй стенасына тәрәзә тишкән төсле, күңел юатырдай матурлыклары, гыйбрәтле хәлләре дә булгалый.

Сания белән Рафаэль йөргән бакчада Яңа ел бәйрәме үткәрергә җыеналар иде. Саниякәйгә Кар кызы, Рафаэльгә Төлке булып киенергә кушканнар. Нурия, үзенең ак төстәге иске ефәк кофтасын кечерәйтеп, Саниякәйгә күлмәк текте. Өйдә вакыты җитмәгәч, күлмәкне тегеп бетерергә госпитальгә алып килде. Кизү торган чакта буш вакытлар булмый калмый иде.

Төн. Утлар сүндерелгән. Дежурный өстәле янында, коридорда берәр генә ут яна. Авырулар, ара-тирә саташкалап, ыңгырашып йоклыйлар. Нурия ачып куелган ишектән коридорга, бүлмәләргә күз салгалап, Кар кызының күлмәгенә ялтыравыклы төймәләр тезеп утыра.

Төн урталары узгач, инде дөнья тынды, бераз гына үзем дә черем итеп аласы булыр дип уйлап кына бетергән иде, йокысызлыктан зарланып, Себер егете — озын буйлы чибәр лейтенант Новиков дежур бүлмәсенә килеп керде. Ул озакламый тагын фронтка китәргә тиеш.

Нурия аңар урын тәкъдим итте.

Новиков, рәхмәт әйтеп, Нурия каршысына килеп утырды.

Кизү врачның кулындагы бәләкәй ак күлмәк, өстәвенә доктор кешенең шул ак күлмәккә үз кулы белән ялтыравык төймәләр тезеп утыруы аның өчен көтелмәгән гаҗәбрәк бер хәл булды бугай.

— Карагыз әле, бу ни хикмәт? — диде Новиков, аксыл-сары кашларын күтәреп. Аның күксел акыллы-моңсу күзләре ачылып, тетрәнеп китте.— Дөньяда әле Яңа ел бәйрәмнәре дә бармыни? Безнең нәниләребез әле Чыршы бәйрәмнәрен дә күрә алалармыни? Ә мин, алты ай буена ут эченнән чыкмаган кеше, дөньяда инде чыршы да юк, бәйрәмнәр дә юк, тик дары исе белән пожар ялкыннары гына, үлем белән күз яшьләре генә торып калды дип уйлый башлаган идем. Ятимнәр белән толлар гына дип! Рәхмәт, доктор, сез минем күземне ачтыгыз. Болай булгач, сугышам әле мин, сугышам! Тешләрем белән умырам әле мин фашистны, бугазын чәйним әле мин аның!

Лейтенантның күзләре зур булып ачылган, яңак төерләре бүртеп чыккан — җаны ярсу белән тулган иде. Нурия, сестраны чакырып, Новиковка дару китертте. Лейтенант, Нурияның кулыннан дару төймәсен алган чакта, рәхмәтле күзләре белән бер балкып карады да, даруны су белән эчеп җибәрде. Кат-кат рәхмәт әйтеп, тынычланып, үз бүлмәсенә юнәлде.

Уразаева аның дежурлыгында булган хәлне госпиталь начальнигына хәбәр итте. Ипполит Дмитриевич, башындагы зур ак калфагын рәтлирәтли, дулкынланып тыңлады аны. Тыңлап бетергәч, әйтте:

— Бу гыйбрәтле хәл, Нурия Аббасовна. Әйе, гыйбрәтле. Комендантка әйтергә кирәк, бүген үк якындагы урманнан бәләкәй чыршы кайтартсын. Без аны бик матурлап бизәрбез. Юкса, карале, сугышчыларны без дару белән генә түгел, тыныч көннәрнең матурлыгын күрсәтеп тә дәваларга кирәк икәнен онытып барабыз түгелме?

## V

Садыя белән Нурияне сугыш вакытларының авырлыгы бер-берсенә бик якынайтты, дуслаштырды. Әле яңа гына кизү торган булса да, Нурия икенче көнне тагын Садыясы өчен эһ тә итмичә кизүгә бара, чөнки Садыяның хәле Нурияныкеннән кыенрак: аның ире Фазыл сугышка киткәннән бирле хәбәрсез, әнисе — җитмеш яшьлек карчык — урын өстендә, Фазыл армиягә киткәннән соң туган кызы Гөлфирә балалар бакчасында туенып тора; бу гаиләнең бәрәңгесе дә, ярмасы да, азык-төлеккә алмашырдай кием-салымы да юк. Бу гаиләнең тоткасы булган камыт аяклы, каратут йөзле, соң дәрәҗәдә ихлас күңелле, бетмәс-төкәнмәс оптимист җанлы Садыя бар. Ихтимал, Нурияне магнит кебек үзенә тарткан сыйфаты Садыяның — бөек оптимистлыгыдыр. Еламас-сыктамас, беркемгә дә зарланмас, моңсу гына көлеп куяр да, бәләкәй чегән аты кебек, арбасына төялгән йөген тарта бирер. Паекка бирелә торган сабындыр, шырпыдыр, тоздыр ише вак-төякне ул Биектау станцасыннан ерак түгел генә бер авылга ире ягыннан булган кардәшләренә илтеп, алардан ун гөрәнкә бәрәңге, бераз он алып кайтып, тормышның очын-очка ялгап алып бара. Ул гадәттә Нуриядән шимбә көнгә туры килгән кизүләрен алып калуын үтенә, чөнки ялга каршы кардәшләренә барып кайту аңа җиңелрәк.

Шулай ике врач, сугыш елы бәхетсезлекләре туганлаштырган ике хатын, берсе ауганда берсе яннан терәтеп, тырышып-тырмашып яшәп яталар иде, 1942 елның февралендә Нурия урын өстенә егылды. Кайвакыт аның температурасы 39 градуска, хәтта 40 ка хәтле күтәрелә, тамагы кибә, эче яна башлый, әмма өйдә су бирүче юк — Солтан эшендә, Шәфика укуда, балалар — бакчаларында. Нурия үзе хәлсез, урыныннан торып өстәлгә чаклы да бара алмый. Солтан белән Шәфика кайтып җиткәнче ул, әллә ниткән пожарлар белән саташып, өстенә янгынчылар шлангысыннан ут бөркегәнгә түзә алмыйча, төш күреп ята.

Садыя аның госпитальгә килмәвенә эче пошып, өенә сугылган иде — исе китте. Нурияе урын өстендә. Башына кулын куйды — ут кебек кайнар. «Ашыгыч ярдәм» машинасы чакыртып, больницага илтеп салырга туры килде.

Садыя аркылы хәлләрне белгән Солтан көн саен диярлек больницага килеп йөри. Нуриянең хәле рәтләнми, авызының тәме юк, тамагына ризык бармый — повидло яккан ипи телемнәрен ул балаларына булыр дип, кәгазьгә төреп чыгара. Аның әллә ни гомер температурасын тигезли алмый азапландылар. Югыйсә врачлары да бар, таныш профессорлары да килеп, җентекләп тикшереп киттеләр, юк, рәтләнми хәле. Дару юк, тәрбия җитешми.

Тәмам хәлсезләнеп, йөри алмый башлагач, авыруга мышьяк уколы бирергә булдылар. Ак халатлы, ак косынкалы фельдшер карчык Аверьяновна җылы йомшак кулы белән Нуриянең кулын тотып, иркәләп кенә әйтте:

— Бәбкәм, юньле-рәтле инәләребез юк. Барлык запасны госпитальләргә биреп бетердек. Кем уйлаган Казан каласында утыздан артык госпиталь булыр дип? Әгәр курыкмасагыз, мин сезгә уколны юан инә белән кадый алам,— диде.

— Үлеп китүгә караганда, терелү әйбәтрәк,— дигән булды Нурия.— Кадагыз, Аверьяновна, мин риза. Тулке бик авырттырмагыз, яме.

Әллә бик ихлас күңелдән эшләгәнгә, әллә карчыкның теләктәшлегенә нык ышанганга, шул уколлар ярдәм итте. Бер айдан температура нормальләште. Әмма укол үзе авыр да булган иде соң! Никадәр чыдам булмасын, үзе эшләгән госпитальдә яралы сугышчыларны сабырлыкка күпме генә өйрәтмәсен, укол кадаган чагында Нурия чытырдап караватка ябыша, йә йөзтүбән капланып, мендәрне тешли иде.

— Минем кулым йомшак, минем кулым — изге Мәрьям ана кулы, терелерсең, ходай кушса, терелерсең, бәбкәм, миңа рәхмәтләр укып яшәрсең әле,— дип сөйләнә Аверьяновна йомшак-көйле тавышы белән.— Авыруны аны врач кына түгел, авыру үзе дә терелтә. Моның өчен, бәбкәм, синең ише батыр холыклы, якты күңелле кеше булу кирәк...

«Авыруны врач кына түгел, авыру үзе дә терелтешә». Мәгънәле сүз. Госпитальдә файдаланырга кирәк булыр моны, күңелгә салып куйыйк әле.

Шәфика беркөнне аның янына балаларны алып килде. Саниясе бигрәк кызганучан бала: әнисенә карап торды-торды да күзеннән яшь ага башлады. Рафаэль әле сабый, сакау теле белән өйдәге хәбәрләрне тезә: «Рафик бәллә асаган. Сания — бүки. Әттә әйтә, аякны селкетмә. Сәфика елый. Влач апа мәми билде. (Монысы Садыя була инде). Ваня скәмиләдән упәтилә итте...»

Сандугачлар сайравын, күгәрченнәр гөрләгәнен тыңлагандай була Нурия. Ярый әле, сау-сәламәт чагында шушы бәләкәчләрне табып калды. Ярый әле, кайберәүләрнең юк-бар киңәшләренә колак салмады. Нурия шулар өчен яши, шулар хакына өзлекмәскә тырыша. Кулыннан килсә, сабыйларын ул үз яныннан бер генә минутка да җибәрмәс иде.

Көн артыннан көн уза, балалары белән очрашу аны яшәтә, үзен ирексезләп булса да тамагына кабарга, караваттан караватка ябышып йөрергә өйрәтә...

## VI

Ял алды көнне кичен больницага Садыя килде. Үзе генә түгел, янында бер ир кеше дә бар. Ир кешене Нурия күрү белән таныды — врач Рәхимов. Студент чагында факультетны шаулатырлык дәрәҗәдә яхшы укуы белән истә калган. Хәер, Рәхимовтан башка да институтта яхшы укучылар аз түгел иде. Кайчан карама, Рәхимовны кызлар чолгап алган, юк, ул «сердцеед» түгел, рәхимле кеше, теләсә кемгә ярдәм итәргә әзер иде. Кыска буйлы, чүкеч кебек нык гәүдәле, ачлыкны, эссене,

суыкны бердәй тигез кичерә ала торган Мисбах Рәхимов, сугыш алды елларында Кырымга эләгеп, «Тау кояшы» санаториенда баш врач булып эшли дигәннәр иде, димәк, ул да Казанга эвакуация белән кайткан. Карап карыйк, Нурия янына нинди җилләр алып килде икән? Җитмәсә әле аның ахирәте Садыя белән.

— Нуриякәем, мин сиңа кунак та алып килдем бит әле! — диде Садыя, үзенең беркатлылыгы белән дөнья шаулатып сөйли башламакчы иде, Аверьяновна, бармагын авызына куеп, аны тыела төшәргә чакырды. Садыя, бетте баш, калды муен, дигән кыяфәт ясап, Аверьяновна ягына күз атып алды да, шыпыртрак тавышка күчте: — Исендәме, Нуриякәем...

Көтеп бетерергә сабырлыгы җитмәгән Нурия аны бүлдерде:

— Син миңа врач Рәхимовны алып килгәнсең, сугыш башлангач, Кырымнан әниеңне, үзеңне, Гөлфирәкәеңне Казанга алып кайтты, дип сөйләгән идең, шулмы?

Хәрби кием өстеннән ак халат киеп алган Рәхимов:

— Йа ходай! Нигә син, Садыя, безнең институтның күз өстендәге кашы Нурия Уразаева янына алып киләм дип әйтмәдең?! Бу бит Нөркәй! Барыбызны тиң ятим калдырып, студент-землемерга кияүгә чыккан Нөркәй бит бу! — дип палатаны гөрелдәвек тавышы белән тутырып, Нурия койкасына якын ук килде, кул биреп күреште. Аннары, рөхсәт-мазар да сорап тормастан, иң якын кешесенә килгәндәй, койка янындагы бердәнбер ак табуреткага чүмәшеп тә өлгерде.

Садыя, халат итәген тарткалап, койка читенә урнашып алды.

— Безнең килүнең сәбәбе бер генә, Уразаева, сиңа «Ижминвод» санаториена кодаларга дип килдек без,— дип, сүзне турыдан-туры башлады Рәхимов.

— Анысы тагын нәрсә дигән сүз? — Нуриянең көрән таплар кунган ябык-саргылт йөзенә алсулык йөгерде.

— Миңа, Нурия ханым, «Ижминвод» санаторие базасында җәйге госпиталь оештыру бурычын йөкләделәр. Госпиталь яралы сугышчыларны түгел, чолганышта калып хәлсезләнгән сугышчыларны аякка бастыру өчен төзелә. Син, сабакташ, шунда җибәрүләрен үтенеп, үз кулың белән Наркомздравка гариза яз, мин аны үз кулым белән Кремльгә илтеп бирермен.

Нурия тирләп чыкты, каушаудан еш-еш сулыш ала башлады.

— Мин авырыйм бит әле, Мисбах... Гатауллович,— диде ул, ниһаять.

— Дөнья булгач, Нурия ханым, адәм баласы авырыр да терелер дә. Кыяфәтең синең ямьле, элеккесеннән дә нәфисрәк булып киткәнсең дип әйтимме...

Рәхимовның шул бер сүзе Нуриягә җитә калды. Ул, бик тиз тереләчәгенә сабакташын ышандыру өчен караватка сөяп куйган таякка таянып, тумбочка янына барып килде. Аннан бер бит кәгазь, каләм сабы алып, кулының әле җегәре юклыгын сиздермәскә тырышып, гариза сырларга кереште.

Садыя, күңеле нечкәреп, аның язганнарын карап утырды. Уенын барып чыкканына сөенде. Рәхимовка күңеленнән рәхмәт укыды.

Әнә шул көннән Нуриянең эшләре уңайга китте. Больница тәрәзәсеннән килеп төшкән март кояшының нурлары аны җылыта; тәрәзә артында, урамда, чыр-чу килгән чыпчыклар да аңа хәзер дөньядагы иң матур кошлар булып тоела; беренче көннәрне тамагына үтмәгән повидло белән бер телем арыш ипиен ул бөкләп кенә куя; аңа җан өреп киткән Рәхимовка, ахирәте Садыяга, аны онытмаган сеңлесе Шәфикага озын итеп хат язу, яз кояшы белән бергә күңелендә уянган җылы хисләрен кәгазь битенә түгеп ташлыйсы килү аны җилкендереп тора. Терелүедер, иншалла!

Күңел тойгыларына бирелеп утырган чагында Майский килде. Каяндыр юнәтеп канәфер чәчәкләре, бер банка карлыган вареньесы алып

килгән. Үзе элекке тыныч еллардагыга караганда ябыграк, сакалы агарып бетә язган, сөякчел чандыр кулы — гаҗәп хәл! — бу юлы җылы иде.

Нурия янында ул ярты сәгатьләр чамасы юанды. Больница персоналы барысы диярлек аның шәкертләре булганга, ихтирам йөзеннән, аңа һәм Нуриягә чәй ясап керттеләр. Нурия белән кара-каршы утырып чәй эчкән арада, Александр Николаевич Казанда булган кызыклы бер вакыйганы сөйләп алды.

— Безнең Казан, Нуруся, фән дөньясындагы йолдызлар белән тулды. Туксан академик! Кайчан да булса мондый хәлне күргәне бар идеме Казанның?! Исеме илгә танылган академик Арбени бездә. Остазы Павловның маймылын алып килгән. Шимпанзе, бозау чаклы маймыл, читлек эчендә үкереп утыра. Тамагына капмый, су эчми. Янына килсәң, читлекне ике куллап шундый дуылдата башлый, җир тетриме диярсең! Ни өчен шулай кылана? Сөйгәненең үлемен кичерә алмый. Күрәсең, кешеләр гаепле дип уйлый.

Нурия баштарак остазының бу вакыйганы ни өчен сөйләгәнен аңлап та бетермәгән иде, бераздан төшенде: дөньяда гомер юлдашыңны югалтудан да фаҗигалырак нәрсә булырмы?

Җир йөзендә сугыш бара, үлем котырына. Күпме хатын-кыз ирен, күпме ана баласын югалта. Ул югалтулар менә хәзер, кайдадыр туплар гөрселдәгәндә, барлык омтылыш бер максатка — Ватан азатлыгын саклап калуга юнәлтелгән чакта бөтен тулылыгы белән, барлык ачылыгы белән сизелми дә әле, бетәр сугыш, тынар туплар, менә шунда сугыш кырларында ятып калганнарның кайгысы өскә калкып чыгар. Маймыл булып маймыл парын югалтуга түзә алмый икән, адәм баласы моңа ничек түзсен...

Нурия профессоры килгәнгә күңеленнән бик хәтәр сөенгән иде. Иң авыр чакларда ярдәм кулын сузган эчкерсез остазына, акыл иясенә күңеле нечкәргән шушы минутларда җанында озак еллар асраган кадерле сүзләрен әйтеп калырга теләде:

— Александр Николаевич! Сез мине барлык бәла-казалардан, явыз кешеләрдән аралап килдегез. Мин терелдем әле. Рәхмәтемне мин фәнгә фидакярларча бирелгәнлегем белән раслап бирәм әле. Сезне сөендерер өчен, балаларымны, иремне сөендерер өчен терелдем. Сезнең бүген биргә килүегездән файдаланып сорап каласым килә... Рөхсәтме?

— Сорагыз, Нуруся.

— Мине «Ижминвод»ка — анда төзелә торган яңа госпитальгә чакыралар, барыйммы?

— Кайда әле ул санаторий — Татарстандамы, Удмуртиядәме?

— Татарстанда ул, Александр Николаевич. Иж дигәне аның Ижевскидан алынмаган, минем туган авылым Зартугай янындарак агып ята торган Иж елгасы бар. Әнә шул елга исеменнән алынган ул. Елга тамагында утыра ул санаторий.

— Так, так. Үзегезне генә чакыралармы, әллә гаиләгез беләнме?

— Гаиләм белән.

— Мин Сезгә ризалык бирәм, Нурия Аббасовна. Барыгыз Сез анда. Сезгә хәзер нәрсә кирәк? Ныгу. Ә ныгу нәрсә ул? Әйбәт туклану. Саф һава. Үләннәр. Әйе, әйе, саф һава һәм үләннәр. Алар анда җитәрлек булачак. Балаларга мәктәп булырмы?

— Нинди телисең, шундый мәктәп бар анда,— татарныкы да, русныкы да. Әле минем олы кызымның мәктәпкә керергә тагын ике елы бар. Балалар бакчасы-мазар булмаса, үземнең янымда әвәләнеп кыш чыгарлар.

Профессор саубуллашкан чакта аңа бер нәрсәне әйтте: кайда гына булмасын, хәзер, сугыш вакытында, кем генә булып эшләмәсен — еллар тынычлангач, ул янә дә мединститутка, гистология кафедрасына кайтырга, докторлык диссертациясен якларга тиеш.

— Киңәшме? Киңәш шул, күгәрченкәем, госпитальдәме, авылда-

мы — фәнни эшне туктатмаска! Медицина әдәбиятын укырга. Авыруларны күзәтергә, сорашырга-белешергә. Авыру тарихлары — бигрәк тә нервы белән бәйлеләре — сезнең өчен бик мөһим. Вәгъдәме, доктор Уразаева?

— Вәгъдә, Алексан...

Профессор аны үз гомерендә беренче мәртәбә ирененнән үпте. Шәкертенең ныклыгына, остазына тугрылыгына, кешелекле булуына сокланып үпте. Аның тереләчәгенә, яңадан җиң сызганып, давылланып-өермәләнеп, эшкә тотыначагына бер тамчы да шикләнмәде. Ул чиксез дулкынланган иде, шундый олы җанлы, кече күңелле кешеләр тәрбияли алганына горур иде. Аны, Нурусяны, күңелдәгесен яшерми әйтсәң, ярата, аның дөньяда барлыгы аңа көч бирә, күңелен нык итеп тотарга мөмкинлек бирә, ул аңарда дворяннар нәселеннән килә торган нәзакәтлек күрә, дөнья тоташы белән вәхшилеккә, үтереш-суешка корылган заманда бу бик мөһим иде...

Нурия дә көне буе дулкынланып йөрде. И дөньялар... Остазы аны онытмаган, аны ихтирам итә, аңа теләсә кайчан ярдәм кулын сузарга әзер. Болай булгач, яшибез әле, яшибез!

Тагын бер атнадан ул, үзен дәвалаган врачка ялынып, өйгә кайтаруларын үтенде. Расписка яздырып алып, аны больницадан чыгардылар. Өендә бер көн торып, йорттагы мохитка күнеккәч, госпитальгә барды. Тарибердиевтән янә урынга күчәргә рөхсәт сорады. Берәүнең дә кул астындагы әйбәт эшчесен җибәрәсе килми. Әмма Уразаеваның кыяфәте шул хәтле дә кызганыч, дәлилләре шул хәтле дә ышандыргыч иде ки, Ипполит Дмитриевич аңар эштән китәргә рөхсәт бирми булдыра алмады.

Нурия Сәламәтлек саклау буенча Республика халык комиссариатыннан командировка кәгазе алды. Мисбах Рәхимов анда, алдан вәгъдә иткән буенча, барысын да эшләп куйган, Нуриянең кабинеттан-кабинетка чабып мәшәкатьләнеп йөрерлеген калдырмаган иде.

Өйдә почта ящигында, аны Мисбах Гатаулловичтан килгән хат көтә иде. Хат кыска, бик эшлекле иде.

*Нурия ханым, больницадан чыккан булсаң, кош теле хәтле генә хат язып җибәр. Госпиталь әзер, врачлар тупланды. Лабораториягә сине, бары тик сине генә кабул итәргә исәп. Гаиләң белән кил. Сөйләшеп куйган бер фатирым бар — сезгә дип саклап торам. Солтанга күп итеп сәлам әйт. Көтәм.*

*25 апр. 1942 ел* — *Мисбах Рәхимов*

Солтан белән икәүдән-икәү генә киңәшеп, шундый карарга килделәр: өй җиһазын, артык-портыкны хәзергә Черноусовларда калдырып торырга. Шәфика җәйгә тикле, укуы тәмамланганчы, Зәйтүнә апаларында яшәр. Балалар икесе дә Нурия белән китәләр, Солтан үз җае белән, ягъни Наркомзем белән исәп-хисапны өзгәч килә.

Пристаньга Нурияне госпиталь аты белән Солтан төшереп куйды. Тарибердиев үзендә байтак вакыт намус белән эшләгән врачтан ат кызганмады. Ләкин Нурия пристаньда ике тәүлек буе китә алмый ятты. Пароход юк иде. Нәкъ шул көннәрдә гитлерчылар Горький шәһәрен бомбага тотканнар, пассажир пароходлары Горькийдан кузгала алмый азаплана-лар икән.

Тагын бер көннән пароход килде. Баш тыгарлык та түгел. Ленинград блокадасыннан чыга алган кешеләрне яңа җирләргә савыгырга алып баралар. Алар арасында бит-куллары тимгелләнеп беткән хатыннар, кара чәчләре юл-юл булып агарган яшь-яшь кызлар бар. Протез аяклы солдатлар, бит тиреләре сөяккә ябышкан сирәк сакаллы картлар...

Казан больницасында ике айдан артыграк яткан вакытта врачлар Нуриядә өч төрле чир таптылар. Малярия. Муен бизләре туберкулезы. Аяк ревматизмы. Кыскасы — иң хәтәр чирләр. Әгәр ул тормыш арбасыннан төшеп калмас өчен җан-фәрманга тырышмаса, ихтимал, әлеге

чирлар аны дәррәү егып салган булырлар иде. Менә хәзер ул инде исән, ике баласы белән яңа урынга килә.

Идел дәрьясы да, Кама буйлары да ул сугыш алдыннан күргән кояшлы тугайлары, су өстенә гармун моңнарын сипкән ак пароходлары белән каршыламады аны. Кара-кучкыл яки соргылт төскә буялган озын-озын баржалар тавышсыз гына узып баралар — өсләренә брезент ябылган; күрәсең, фронтка туплар, танклар, хәрби машиналар илтә торганнардыр. Мөгаен, шулайдыр, чөнки якыннанрак узган бер танкерның бортында мылтыклы ике кызылармеецның басып торганы күренеп калды.

Төннәрен Идел дәрьясы бигрәк шомлы, алар утырган пароход утларын яндырмаган диярлек, тонык булып шәүләләнгән маяк утларының сүлпән яктысына карап кына юлны дәвам итә иде.

Әле апрель азаклары гына булганга, елга өсте суык, кургаш төсендәге авыр дулкыннар пароход артыннан ишелеп-ишелеп калалар, пароход палубасында кичләрен түгел, көндезләрен дә үзәккә үтә торган суык иде. Нурия үзе дә палубага чыкмаска, балаларны да чыгармаска тырышты. Хәер, чыгарга бик тырышсалар да, чыга алмаслар иде. Йөрү юллары, коридорлар капчыклар, ниндидер ящиклар белән, мичкәләр белән тулы, пассажирлар — хәрбиләр дә, гражданскилар да кайсы каян урын таба, шунда башын төрткән, аркылы-торкылы ятып йоклаган иде...

... Яңа урында аларны госпиталь начальнигы Рәхимов белән Садыя каршылады. Икесенең дә чырае якты иде — Нуриянең күңеленә җылы йөгерде. Мисбах Гатауллович әзерләп куйган (хатта ук язган) йорт госпиталь бинасыннан ерак түгел, гадәти бер бүрәнә йорт, ишегалдына һәм урамга якка караган икешәр тәрәзәсе бар, койма белән әйләндереп алынган ихатасы шактый ук зур иде.

Өйгә кергәч, биткә бәрелгән рәхәт җылыдан эреп китеп, Нурия өс-башын салып ташлады, балаларын чишендерде, ярты өйне тутырып торган зур мичкә килеп, кулы белән аны тотып-тотып карады.

— Без торасы йорт әллә шушымы?

— Ошаса, менә шушы, Нурия ханым, әйбәтләп урнашыгыз, тамак ялгап алыгыз. Сәгать кичке дүрттә госпитальгә, минем янга сугылырсыз.

— Рәхмәт, Мисбах Гатауллович. Бик зур рәхмәт. Бу яхшылыгыгызны гомер буена да онытмам.

— Ярый, ярый, сезне урнаштыру минем вазифам ул,— дип, артык мактауга юл куймыйча, Рәхимов аны ярты сүздә өзде һәм ишекне шапылдатмый гына ябып чыгып китте.

— Начальнигыбыз бик төгәл кешегә охшап тора бит әле,— диде Нурия, ул чыгып киткәч.— Безнең җелекне суырып алмас микән?

Садыя, чуендай кара йөзен балкытып, сирәк елмая торган елмаюы белән елмайды.

— Ничава, Нуриякәем, бер дә борчылма, каты куллы кеше гадел була ул, мондый заманда каты куллы булырга тормыш үзе куша.

Садыя госпиталь складыннан алган азыклардан сөтле аш, бәрәңге боламыгы пешергән, чәй кайнатып куйган иде. Ике ахирәт бергәләп, табынга балаларны да утыртып, чүкердәшеп бер тәгам җыйдылар; Садыя юл мәшәкатьләрен сорашты, мондагыларны сөйләде, шулай итеп, аларның яңа урында яңа тормышлары башланып китте.

Озакламый Солтан да килеп җитте. Ул чагында инде майның азаклары җиткән, болыннар ямь-яшел, елга сулары ярларына кайтып төшкән, кырлар өстендә сабан тургайлары тирбәнә, уҗымнар хәтфә юргандай күпереп килә иде.

## VII

Мисбах Гатауллович Рәхимов, администратор буларак, ныклыгын, каты куллылыгын беренче көннән ук танытып өлгерде. Госпитальдә ул

көненә ике мәртәбә — иртән һәм кичен — рапорт ала. Эш урыннарында тавышланганны, юк-бар өчен низаг куптарганны яратмый. Аның җил-җил атлап, почмактан күренүе була, госпиталь хезмәткәрләре шундук бер-берсенә җиткерәләр:

— Әкрен. Тавышны бетердек. Майор килә.

Әйе, тәртип ярата майор. Госпитальгә аяк басу белән, күз явыңны алырдай ак халатны хәрби форма өстеннән җилбәгәй салып куя — кабинетларны, лабораторияләрне, ашханәне, йокы бүлмәләрен, палаталарны барлап чыга. Күзе бик очлы майорның: тумбочка өсләрен, шкафларны — сөртелгәнме, юкмы — бармагын ышкый-ышкый тикшерә, аз гына тузан булса, гаепләне эзләтеп таптыра, шундук шелтә белдерә, кисәтү ясый, кабинетына чакырып түгел, персонал алдында ясый — хәлсезләнеп кайткан сугышчыларны аякка бастырыр өчен үзен дә, кул астындагыларны да кызганмый.

Госпитальдән рөхсәтсез чыгып йөрү приказ белән тыелган. Приказ, калын хәрефләр белән язылып, ишеккә ябыштырылган. Авылларга борын төртүче юк. Күрше авылга май-күкәй алырга бару, кырларга чыгу, Иж тугайларын әйләнү — рөхсәт белән генә.

Туган якларны, гаиләләрне сагынган чакта, күңелдәге моңсулыкка түзеп торып булмаганда, Дәүләтов яшәгән агач йортка җыелалар. Дәүләтов — хуҗалык эшләрен алып баручы. Интендантлык хезмәтен үтәүче. Ул яшәгән йорт зуррак. Анда «Ижминвод» санаториеннан калган пианино бар. Нурия пианинода уйный. Айдаровны җырлаталар. Күңелләр шулай аз гына булса да юаныч таба. Андый юанычларның әле озакка барачагын беләләр, чөнки фронтлардан һаман шомлы хәбәрләр килә — хәбәрне радио да әйтә, дәваланырга кайткан сугышчылар да китерә.

Солтан белән үзләрендә очрашканнан соң, Дәүләтов аны ничектер үз күреп интендантлык хезмәтенә чакырды.

— Нәрсәдән гыйбарәт инде ул эш? — диде Солтан, бик әллә ни ачылып китмичә.

— Азык-төлек, кием-салым, кабинетларга һәм лабораторияләргә кирәкле приборлар, медикамент — һәммәсе дә Сезнең кулда булачак.

— Ягъни, гади тел белән әйткәндә, склад мөдире була торгандыр инде ул, әйеме? — диде Айдаров.

— Әйе, алай дип тә әйтеп була. Тыныч заманнарда. Хәзергесе көндә ул — интендантлык хезмәте. Шул вазифаларны өстегезгә алу белән Сез, Айдаров, хәрби хезмәттә саналасыз.

Болай бер уйлаганда, Дәүләтов тәкъдименең ымсындыргыч ягы да бар иде. Әмма, төптәнрәк уйлап карагач, Айдаров риза булмады. Ул әле һаман да фронтка китүдән өметен өзми иде. Дөресен әйткәндә, «Ижминвод»ка кайтып төшү белән, аның әүвәлге өмете тагын яңарды, чөнки ул учетка Пәнҗәр хәрби комиссариатына керде. Биредә аның авыру тарихын белмиләр, ныгытып тырышса, райком секретаре Шәяхмәт Айдаров та булышса, аның фронтка китеп баруы да ихтимал...

Башы-аягы белән госпиталь эшенә чумган Нурия аны онытты. Солтан өйдә үзе, берүзе. Аның хәзер бердәнбер хыялы — ничек кенә булса да фронтка эләгү.

Шулай бер көнне, Нуриясе госпитальгә китеп, балалар яслегә озатылгач, ул — япа-ялгызы — тирән уйга чумып, өстәл янында озак кына утырып торды. Ныклы бер карарга килеп, кулына каләм алды. Шәяхмәт Айдаровка, туганы Айдаровка түгел, райком секретаре Айдаровка хат язып җибәрде. Үтенече бер генә — аны фронтка җибәрүдә булышсын.

Хатны Нуриясенә күрсәтмичә, җайлы вакытын туры китереп, почтага илтеп биргәч, соң дәрәҗәдә сабырсызланып, җавап көтә башлады. Әйтерсең, аның бөтен тормышы әнә шул хатка, абыйсы Шәяхмәтнең аның үтенеченә ничек каравына бәйле.

Өйдә генә утырырга сабырлыгы җитмәсә, ул госпиталь ихатасына бара, елга буйларын әйләнә, кояшта утырган, күләгәле палаткаларда йоклаган солдатларны күргән саен, күңеле алгысый, ул аларны хәзер үзенә, җанына бик якын итеп тоя. Ул — алар арасында хәзер.

Төшендә ул үзен фронтта итеп, атакага барган солдатлар арасында итеп күрде. Кара-кучкыл төтен баскан кырлар өстеннән танклар бара, танклар артыннан, алга иелә төшеп, винтовкаларын «наперевес» тоткан солдатлар чаба. Юк, чапмый, иңгә-иңне терәп, стена булып бара...

Уянгач та әле ул моның төш кенә булуына ышанмыйча, ышанырга теләмичә, йөнтәс куркрәгән кулы белән уып, үз уйларына бирелеп утырды.

Бер атна узды, төш күргәненә, хат җибәргәненә ун көн узды — Шәяхмәт абыйсыннан хәбәр юк. Сабырсызланып, госпиталь ихатасына чыккан иде, майор Рәхимовны очратты.

— Айдаров, менә бик шәп булды, без бит сине эзлибез,— диде Рәхимов.

— Ни булды, Мисбах Гатауллович?

— Райком секретаре Айдаров килде, сине таптыра.

— Кайда соң ул?! — дип, үзе дә сизмәстән, ашкынып әйтеп ташлады Солтан.

Аның шундый ашкынулы чагын әллә бер дә күрмәгәнгә, Рәхимов сәерсенеп карап торды, аннары сабыр гына әйтте:

— Ул әле госпиталь белән таныша, беркая да китмә, хәзер мин аңа хәбәр итәм.

Бер сәгать уздымы икән, артыктырмы,— һәрхәлдә, Солтанга озак, түзеп булмас дәрәҗәдә озак тоелды,— ниһаять, абзыйсы Шәяхмәт госпитальдән чыкты.

Койма буенда арлы-бирле йөренеп торган Солтанны күрүгә, адымнарын кызулатып, аның янына килеп җитте, кул кысышып күреште, кулын җибәрмәгән хәлдә, башын янтайтып, энесенә сынаулы караш ташлады, аның чыраеннан канәгать калдымы, шайтан белсен, шактый ук күтәренке тавыш белән:

— Так, так. Шулай дисең алайса? Яхшы! Әйдә, сезгә кайтыйк. Шунда сөйләшеп бетерербез. Ерак торасызмы моннан? — диде.

— Ерак түгел. Ике квартал гына. Нурия дә өйдә юк...— дип, үзенә хас булмаганча, ашыгып, бер сулышта әйтеп ташлады Солтан.

Шәяхмәт Айдаровның чаларып бетә язган мыегы, тагын да олыгайган, ябыккан бите-чырае бер генә мизгелгә балкып алды. Энесе Солтанның, бала-чага сыман, гомердә булмаганча ашыгуы, хатыныннан яшертен эш эшләве сәерсендерде бугай аны. Шундук җитдиләнде, аермачык итеп, өздереп әйтте:

— Нурия ханымны күрдем. Госпитальдә. Майор Рәхимов канәгать аның эшеннән,— диде Шәяхмәт абыйсы.

Үзләре яшәгән бер катлы агач йорт янына кайтып җиткәч, җил капканы ачып кергән чакта, Шәяхмәт Айдаров, бер генә мизгелгә туктальп, йортны күздән кичерде, аннары Солтанның җилкәсенә кулын салып әйтте:

— Сөйләшү ике арада калырга тиеш. Мин бирегә синең өчен килдем,— диде. Чырае тагын да җитдиләнде, какча битендә яңак төерләре биешеп алды.— Инде өйгә керик. Сөйләшик.

Өйдәге зур тимер карават, балалар караваты, өстәл-урындыклар — һәммә кешегә таныш, гап-гади шушы җиһазлар никтер күзгә ташланалар, нәкъ менә шулар бүген Шәяхмәт Айдаровны дулкынландыралар иде.

— Кил әле, энем, утырыйк әле,— диде ул. Самавырга ут салып йөргән энесен үз янына чакырып китерде.

Солтан, самавыр торбасын морҗа төнлегенә турылагач, абыйсы каршысына, өстәл буена килеп утырды.

— Сәламәтлегең ничек? — диде Шәяхмәт, туп-туры, төбәп, чамадан

артыграк төбәп энесенә карады.— Юк, син күзеңне яшермә. Син миңа дөресен әйт. Исән-саумы син?

— Зарланмыйм,— диде Солтан, никтер кызарынып.

Шәяхмәт бармакларын аралаштырып, ике кулы белән иягенә таянды, мыегын чәйнәштереп торды — гасабилана иде.

— Яхшы. Исән-сау дип исәплик сине. Ләкин без әйткән белән генә түгел бит. Военкоматта комиссия узасың бар. Авыруың хакында хәрби билетыңа язылган.

— Ул бит моннан бер ел элек язылган иде.

— Моннан бер ел. Бер ел элек. Әйт әле, бер дә яшермичә әйт: хроническии үпкә авыруы белән син фронтка барып нишли аласың? Анда бит мылтык ата белү белән генә эш бетми. Анда эшләргә кирәк. Ат урынына! Окоп казырга, землянкалар ясарга, блиндажлар. Суык кар өстендә ятарга. Походларда йөзәр чакрым җәяү йөрергә! Пушкалар тартып барырга, грузовикларны этәргә. Ихтимал, йокысыз төннәр үткәрергә дә кирәк булыр. Синең сәламәтлегең, дөресрәге — ярымсәламәтлегең аларны күтәрерме соң?

— Мин барысына да... әзер...

— Алайсам, фикеремне әйтеп бетерим. Нигә син бу авыр көннәрдә ил өчен файдалы эшне именно фронтта гына эшләп була дип уйлыйсың?

— Тылда файда китерүчеләр миннән башка да җитәрлек. Мин моны ышанып әйтәм. Ихлас! Әйтик, менә син. Коммунист-җитәкче. Фронтны икмәк белән, ит-май белән тәэмин итүче. Тылдагы сәламәт климатны, ныклыкны саклаучы.

— Ә син?

— Минем хәл, абзыйкаем, башкачарак бит. Миңа ышанып тапшырмыйлар.

— Нәрсәне?

— Коллективны. Иген үстерүне. Ахыр килеп — тылның ныклыгын саклауны. Сугышта кешеләр өсләренә ут ала алалар. Таранга баралар. Дошман амбразурасын күкрәкләре белән каплыйлар. Ә мин биредә нәрсә эшли алам? Мин биредә нинди кыю адым ясый алам?

Солтан аяк өсте басарга, нык һәм усал итеп: «Мин бит партиядән чыгарылган кеше. Мин илгә тугрылыкны, халыкка тугрылыгымны, ут эчендә генә, дошман белән бугазга-бугаз килгәндә генә исбатлый алам»,— димәкче иде. Шәяхмәт, аның уйларын сизгәндәй, алданрак күтәрелеп өлгерде. Зур гәүдәсе, күңелендәге ныклы иманы, тырпайган мыегы, кысылган иреннәре белән ул энесенең каршысына басты.

— Сиңа госпитальдә эш тәкъдим иттеләрме?

— Иттеләр.

— Ә син?

— Мин нәрсә... Амбар ачу, амбар ябу, азык үлчәп бирү — минем эшмени ул? Аны бит теләсә нинди кортка, гарип-гораба ир-ат та булдыра ала.

— Ә синең эш нәрсә?

— Минем тормыштагы максатымны, абзый, син бик яхшы беләсең. Мин — җир баласы. Гражданнар сугышыннан кайткач, мин авыл агаеның ямьле яшәвен теләдем. Җирдә хуҗалык итүне фән кушканча башкармакчы идем. Мин ул хыялыма, максатыма ирешә алмадым. Илгә яраксыз, файдасыз бер кеше булып калдым...

Шәяхмәт Айдаровка энесенең теләге, нияте никадәр чын икәнен белү кирәк иде. Кара-каршы утырып сөйләшкәннән соң аның шиге калмады. Ул ашкына. Җаны аның гаделлек тели. Ул хәзер теләсә нинди адымга да әзер. Аны тотып калу, кирегә үгетләү бернинди дә нәтиҗә бирмәячәк.

— Чәең кайнаганмы? — дип, ул энесенә кинәттән көтелмәгән сорау бирде.

— Кайнаган. Ә нигә? — диде Солтан аптырап.

— Алып кил. Берәр чынаяк чәй эчик тә, мин кузгалыйм.

Солтан самавырны табынга китереп куйды. Такта чәйгә кура җиләге

яфрагын кушып, чәй ясады. Уе — абыйсын сыйлауда түгел, абыйсының нәтиҗә итеп әйткән соңгы сүзен ишетү иде. Шуны әле һаман да ишетә алмаганга аның ирене турсайган, сөмсере коелган иде.

Шәяхмәт моны сизде. Авызын пешерә-пешерә, кайнар чәй эчте. Солтан кисеп куйган ипи сыныгына да, чәй тәлинкәсенә салган атланмайга да кагылмады. Һәр телем ипинең санаулы икәнен ул белә. Чәен эчеп бетергәч, аяк өсте күтәрелде. Аңардан бик җитди сүз көтеп төбәлгән энесенә үзеп кенә әйтте:

— Сине сугышка алмаслар. Хезмәт фронтына алулары мөмкин. Күрәм — җаның ярсый. Омтылышын бихисап. Сине тотып калу мөмкин түгел хәзер. Военком белән сөйләшермен. Калганын шуннан хәбәр итәрләр. Энесен үзенә тартып китереп кочаклады. Күеныңа сыендырып, бер тын торгач, җибәрде, кырт кына борылып, ишеккә таба атлады. Ишек бавына тотынгач, тагын берничә сүз әйтүне кирәк тапты: — Җаның чиста синең. Социализм җәмгыяте кешесе син. Исәнлектә күрешергә язсын! Сау бул, энем. Озата чыкма.

Солтан ялгыз өйдә җанын айкаган тойгылары белән япа-ялгызы торып калды.

## VIII

Урман шаулый.

Илнең урманнары шаулый.

Кояш баешы ягында, Смоленск, Брянск буйларында, Белоруссиядә урманнар шаулый.

Куе кара урманнарга яшеренгән партизаннар дошманның гаскәр төягән эшелоннарын тау астына тәгәрәтәләр, штабларын яндыралар, корал складларын, аэродромнарын шартлаталар. Халык уллары дошманнан үч ала — гитлерчыларның борын төбендә әллә ниткән могҗизалар ясап, йөрәгенә шом салып, мина өстендәге кебек тота, кан калтырап торырга, кылган явызлыклары өчен үкенергә мәҗбүр итә. Үкенмәгәннәрен дөмектерә — кара күмергә әйләндерә.

Урман шаулый.

Илнең урманнары шаулый.

Ерак Себердән, тайгалардан фронтка агач килә, бүрәнә килә, снаряд ящиклары килә, фронтны тыл белән тоташтырган паровозларга ягулык килә.


Урман шаулый.

Илнең урманнары совет гаскәрләренә көч биреп, дошманның йөрәгенә курку салып шаулый.

Казанда чакта, «Ижминвод»та чакта ул турыда Солтан Айдаровның ничектер уйлаганы юк иде. Урман образы, аның авазлары, аның җанны ашкындырып шаулаган тавышы күңеленә килми иде. Инде менә хезмәт армиясенә алынып, өскә солдат гимнастеркасы, башка пилотка, аякка авыр солдат ботинкалары киеп алгач, үзенә тапшырылган взвод белән, атлы өч олау һәм бер трактор белән көн дә саен Илләт урманына утын кисәргә, хәрәкәттәге Армиягә булышырга чыга башлагач, Солтанның күңелендә үзеннән-үзе урман образы, урман шавы пәйда булды.

Күңелдәге образ теге заманнарда, гражданнар сугышы чорында, Азинның Тимер дивизиясендә сугышып йөргән, урманнарда төн үткәргән чаклар белән тоташты. Урманның яңа образы Зартугай янындагы Ужил урманы, Бояр урманы, Кама ярындагы Алабуга урманнары белән дә кушылып, аның күңелен бөтенләе белән биләп алдылар.

Ул ерак урманнарны уйлый башлады. Аның күңелендә сугыш гарасатлары, ил урманнары шауларга кереште. Әнә шул тойгылар аның былтыргы җәен, хезмәт армиясенә алынганнан соңгы тормышын аеруча мәгънәле итте. Хәзер инде ул үзен ил язмышыннан читкә алып ташланган



А. Тимергалиңа рәсеме.

итеп сизми, ил белән бергә, халык белән бергә итеп тоя — әнә шул күтәренке, ашкындыргыч халәте көн дә саен урманга үз взводы белән чыгарга, беләкләре талганчы юан наратларны пычкы белән кисәргә, атлы олаулар белән аланнарга бүрәнә чыгарып, эрдәнәләп өйгәннән соң да, ару-талудан зарланмаслык көч бирә.

Хәер, аңа көч биргән башка сәбәпләр дә бар. Сугыш чоры авырлыкларын үз җилкәсендә татып, исән-имин гаиләсенә кайтса, ул хатынының һәм балаларының күзенә туры карый алачак. Ул ил-көн алдында җиргә карап йөрмәячәк. Хәзергә аның эше көйле бара. Бер взводта аңа берьюлы өч якташы туры килде. Сарсак Умгадан — Гаврила, кайчан карама, төрепкә төтәтеп, үз алдына гына карап йөрүче җирән сакаллы удмурт; Салагыштан — Шәмгун — ат җене кагылган, зур авызлы, сакалмыексыз татар; Пәнҗәрдән — Константин Павлов — тегермәнче, татарчаны су урынына эчә торган урыс.

Айдаровның Зартугайныкы икәнен белгәч, взвод командиры икәнен дә белгәч, якташлары аны шундук эзләп таптылар: әледән-әле йомыш белән киләләр, туган яклардан хәбәр-хәтер юкмы дип сорашалар, күңелләренә дәва эзлиләр иде.

Бу өч якташны һөнәрле булулары да берләштерә иде бугай. Салагышның Шәмгун Солтан килгәндә үк бирелә иде инде — ат белән урман ташый иде. Хәзер дә шул эшендә. Атын карый белү, олауга утынны тиз һәм нык итеп төйи белү ягыннан биредә аңа чыккан берәү дә юк. Ялга туктаган сәгатьләрдә ул колхозның ат абзарында эшләгән чакларын, тыныч заманнарны сагынып искә ала. Кырыкмыш тайга беренче мәртәбә атланган яки камыт киерткән чакларны сөйләгәндә, күзләре урыныннан куба, очкынлана, йөнтәс кашлары югары сикерә. Константин да, Гаврила да, Айдаров үзе дә урман аланына аның олавында киләләр, аның олавында казармаларга кайталар. Юлда сүз күп сөйләнелә, сүз аларны якынайта, күңелгә утырган юшкыннарын чистарта. Шәмгун үзләренең взводындагы яшь, тәҗрибәсез олаучыларны да күздән ычкындырмый. Атның муенына камыт сукмаганмы, арбаның тәҗе баулары дөрес тартылганмы, атлар вакытында ашатыламы — һәммәсен тикшереп тора. Солтан өчен болар бик мөһим, служба тәртип ярата, тәртип бозылдымы, көт тә тор — җан тынычлыгың югала. Константин — затлы һөнәр иясе, столяр. Взводтагы утыз кешенең пычкысын ул кайрый, балталарын ул үткен итеп тота, агачның кай якка авачагын, пычкыны ничегрәк тартсаң җиңел булачагын ул билгели; Гаврила яшь юкәдән туйра алырга, бау ишәргә оста, камыт сүтелсә — ул тегә, ыңгырчак ватылса, ул төзәтә. Кыскасы — якташлар бер-берсеннән бик уңдылар.

Шулай да Айдаров сизеп йөри, өч якташ арасында Константин Иванович Павлов взвод командирын аеруча үз итә. Аның гаилә хәлләрен, балаларын теләбрәк сораша, кат-кат сораша.

Казармада, йокларга ятыр алдыннан, ул аның янына килмичә калмый. Беренче көннәрне Айдаров моны ничектер уңайсызланыбрак, ялагайлану кебегрәк кабул иткән иде, командирга ярарга тырышуы, үз мәнфәгатен кайгыртуы түгелме, дип шикләнә дә башлаган иде, торабара тынычланды, ямьсез уйларыннан кире кайтты. Павловның ул берәүгә дә әйтмәгән, әмма үзе белән сөйләшергә-бүлешергә теләгән сере барлыгын сизеп алды.

Павлов эшкә төгәл йөри, чүп-чар сүз белән вакыт уздырмый, килү белән, игәвен алып, балтагамы, пычкыгамы тотына, аларны урманчылар сокланырлык итеп кайрый. Ләкин ул моңсу, күзләре аның сагышлы. Имән түмәркәсенә утырып, пычкы кайраган чакта, аның колагына урман күгәрченнәренең гөрләгәне, ялгыз гына түгел, парлашып гөрләгәне ишетелә башлый; пычкысын бер читкә куеп, ул күгәрченнәр гөрләвен тыңлап тора; аның күз алдына Зартугай авылы, ике катлы агач йорт, ак халат кигән сепаратчы хатын Хәнифә килеп баса...

— Константин Иванович! — дигән тавышка сискәнеп башын күтәр-

сә, каршысында, ирен чите беләнрәк елмаеп, взводный басып тора имеш.

— Константин Иванович, ник моңайдың? — ди Айдаров. Җавапны да көтмәстән, йомышын әйтә: — Икенче отделениедә эзлиләр сине. Кая төшеп югалды бу безнең тегерманче урыс? — диләр. Бар инде, тилмертмә, янннарына барып кил, арбаларының тәҗесе өзелгән, пычкыларын да кайрыйсы бар бугай.

Константин Иванович ашыкмый гына урыныннан тора, игәүләр һәм башка төр эш коралларын салган бәләкәй фанер чемоданын кулына тотып, икенче отделение урманчылары эшләгән якка таба китеп бара. Айдаров аның зур гәүдәсе белән бөкрәя төшеп, адымнарын зур-зур алдырып, тигез атлап баруын күздән югалганчы карап кала...

Ихтимал, Айдаров взводындагы урманчылардан Павлов уйчанлыгы, сагышларын кешегә әйтмичә сагышлана белүе белән аерылып тора торгандыр. Айдаров рәхмәтле аңа. Хезмәт яратучы, бар кешене дә бердәй тигез үз күрүче бу ир-егет взводтагы ныклыкны, көйлелекне саклап алып бара. Сагышлану дигәннән, башкалар да сагышлана. Солдатлар сугыш беткәнне, безнең җиңгәнне көтәләр. Һәр көн иртән шул уй белән йокыларыннан уяналар, тиз-тиз киенәләр, күңелне биздереп бетергән, кургаш ядрәдәй тере борай боткасын, тешкә ябыша торган чи ипине һәм тозлы балыкны ашыйлар; команда белән атларын җигәләр; күңелне баскан тәбәнәк күк астында, офыктагы каралҗым болыт өемнәренә караштыргалап юлга чыгалар. Болытлар куера, күк йөзе тәбәнәкләнә, сибәләп-төтәп, вак яңгыр ява башлый. Тирә-якны аксыл томан сара. Урман андый чакта тоташ дымнан тора төсле: өс киемнәре юешләнеп авырая, җилкәне баса, юеш тәнне әчеттерә; наратлар арасында биек булып үскән абага үләне тезгә тикле чолгаган обмотканы, чалбарны юешләп бетерә, урманчыларны алмаш-тилмәш учак ягарга, юеш киемнәрне, утка якынрак торып, киптерергә мәҗбүр итә. Юкса аларны казармада ничек киптереп бетерәсең. Мич ягылмагач, анда киптерер урын да юк.

Ике атна буе гел шулай булды, юешлек җанга тиеп торды.

Бүген — кояш. Арбага егетләрчә бер житезлек белән сикереп менеп утырган Константин Иванович шатлыклы сөйләнә:

— Якташлар, кояш килде! Сиздегезме — кояш?! Яңгыр юк, яңгыр — вәссәлам! Томан юк, томан — вәссәлам! Юешлекләр бетте и вәссәлам! Вәссәлам дә вәссәлам — җиңгәчәнә бир сәлам! — ди ул чамадан тыш татарчалатып. Олаудагылар аның мәзәк сүзләреннән, үзләре сөйләшкәнчә гади генә итеп сөйләмәвеннән рәхәтләнеп көләләр. Көләргә хут бар, дөньяны балкытып кояш чыккан. Озак еллар татар авылларында тегерманче булып торган Константин, җай чыгудан файдаланып, мин әле болай гына сөйләшәмме татарчаны дигәндәй, тагын сөйләп китә: — Иех, малайлар, Кама буйларында да кояштыр инде. Валлаһи-билләһи, кояш балкыйдыр. Зартугай инешендә казлар йөзәдер, куласада тегермән суы шаулыйдыр, җиңгиләр көянтә-чиләкләрен күтәреп, суга барырга чыкканнардыр. Синеңчә ничек, взводный, кояшмы хәзер Пәнҗәр якларында?

— Непременно кояш! — ди Айдаров, үзе Константинның кояштай балкыган йөзеннән, мутланып, бер яккарак авыштырып кигән пилоткасыннан күзен алмый. «Непременно» сүзен ул Павловның күңеле булсынга кыстыра. Бу сүз, аның уенча, взводныйның кәефе бик шәп икәнне әйтеп торырга тиеш. — Н е п р е м е н н о бездә кояш. Безнең хәләл җефетләр н е п р е м е н н о безне уйлап утыра. Безнең белән бергә чакта булган дәгъваларын, талашларын сагынып искә төшерә.

Олаудагылар дөнья яңгыратып көләләр.

Урман башлана. Агачларның яшел ябалдашлары арасыннан каен утыны әрдәнәләре агарып күренә. Зур бер салам эскерте хәтле итеп өйгән нарат бүрәнәләре күзгә чалынып кала. Болар барысы — Айдаров взводының эше. Әле никадәрлесен вагоннарга төяп, көнбатышка, фронтка озаттылар.

Тагын ун-унбиш минуттан бүген эшлисе диләнкегә житәләр. Урманчылар олаудан төшә, шаулап фикер алыша. Берничә урында шаулап учаклар кабына. Дежурныйлар корымлы чиләкләрне, тоткалы казаннарны таганга, чәй кайнатырга куялар.

Айдаров урман авазларына, тирә-як тып-тын чагында, җил-мазар булмаганда да шаулаудан туктамаган кара урманга, биек наратларга, күмәк ритм белән чыжылдый башлаган пычкыларга, отделение командирларының команда авазларына колак салгалап, взводын барларга чыга.

Күкрәп торган урман, күмәк эш дәртенә бирелгән солдатлар, наратларның бөдрә ябалдашларын зөбәрҗәттәй балкытып, кыеклап сузылган кояш нуры — болар һәммәсе аның җанын кузгата, ашкындыра.

«Юк, мин бирегә килеп ялгышмадым, мин, ниһаять, бу авыр елларда халык белән бергә»,— дигән эчке горур тавыш, күкрәкне киңәйтә торган гайрәтле, җиңүле кайнар бер тойгы аны бөтенләе белән биләп ала.

Ул агачтан-агачка килә. Тамга салынган наратларны барлый.

Аның җиңелчә башы әйләнә.

Алда — урманчылар. Ул утырып йөри торган олауның солдатлары. Константин Павлов та анда. Ул бүген пычкы кайрамый, ул җилкенепжилкенеп урман кисә. Солтан алар янына килеп җитмәкче. Ләкин күкрәк турысында нәрсәдер чәнчи, барырга ирек бирми. Узар, артык дулкынлану ярамагандыр. Ләкин күкрәктәге чәнчү узмый, зурая, киңәя, бөтен гәүдәсенә җәелә. Аякларның хәлен ала. Аланга чыгарга, кешеләр күргәнче ятып торырга кирәк.

Аяклар атламый. Ул нарат кәүсәсенә сөялә.

Ниндидер тавышлар ишетә. Башын күтәрә. Күк йөзе әйләнә. Ямьяшел ябалдашлы нарат аңа таба килә. Ул үзе гүя нарат белән кочаклашырга теләгәндәй, кәүсәдән кубып, ачыклыкка таба атлый. Тавышлар көчәя. Каршысына йөгереп килгән Константинны күрә. Соңгы тапкыр күрә.

Шул ук мизгелдә ыңгырашу ишетә. Башына чүкеч бәләнме, нәрсәбеләндер тондырганны тоя. Тупыйк бер доңгырдау — аннары дөнья тына, тавышлар бетә — ул кояшның алтын нурларыннан балкыган бер аланга таба йөзеп китә...

... Иртәгесен урманда ике яңа кабер калкып чыга. Агач пирамидага йолдыз уеп, кызыл буяуга буйыйлар, хезмәт фронтында һәлак булганнарның исемнәрен язып куялар.

| |
|---|
| СОЛТАН САДЫЙК УЛЫ АЙДАРОВ |
| КОНСТАНТИН ИВАНОВИЧ ПАВЛОВ |

Тагын бер көннән кап-карадан киенгән бер хатын, кулларын кушырып, кабер ягасында утыра. Иреннәре әкрен генә кыймылдыйлар: «Кайларга ашкындың син, бәгырькәем?»

## IX

Шактый ук кырыс чырайлы, артыгы белән таләпчән, бәйләнүчән Зәйтүнә апаларында соңгы ике ай ярымын үткәреп, Казандагы рус мәктәбендә сигезенче классны тәмамлап, Шәфика «Ижминвод»ка кайтып төште.

Нурияләр гаиләсе өчен бу — болытларны ярып чыккан кояш төсле булды. Нурия сеңлесен көтә, тәкатьсез булып көтә иде. Солтанының Иләт урманындагы фаҗигале үлеменнән соң Шәфика аның өчен бердәнбер туганы, күңел юанычы гына түгел, әйтергә мөмкин, таяныр талы да булып калды.

Бер кулына сары фанер чемоданын, икенче кулына җәйге җиләнен тоткан, буйга үсеп җиткән зифа кызны, кара толымлы, көйрәп торган кара күзле Шәфиканы госпиталь капкасы төбендә очраткач, Нурия тетрәп китте.

Апалы-сеңелле елап күрештеләр.

Нурия Шәфикага җизнәсенең үлемен язган иде. Белеп кайткан иде, ничекләр күрешәсен күз алдына китереп, йөрәкләре өшеп кайткан иде Шәфика. Икәүләп елагач, бушанып калдылар. Тормыш дигән усал каенананың җәберләүләренә бирешмәс өчен күңелне нык тотарга, апалы-сеңелле кулга-кул тотынышып барырга кирәк булыр.

Шәфикага госпитальдә эш табылмады. Дөресрәге — озак вакытлар ут эчендә, дары төтеннәре эчендә йөреп, снарядлар ярылудан, үтерешсуешларны күрүдән җаннары каткан солдатлар арасында Нурия сеңлесен — үсмер кызны асрарга теләмәде. Аны Зартугайга илтеп куярга кирәк дип тапты.

Садыя Сафина моны хуп күрде. Ул Шәфикага, аның сигезенчене тәмамлавы хөрмәтенә, үзенә кечерәк булып калган, әмма әле төсе-мазары уңмаган зәңгәр ефәк күлмәген бүләк итте. Кара чәчле, кара тут йөзле Шәфикага зәңгәр бик килешми иде, караңгы яшел яки чия төсендәге күлмәк әйбәтрәк булган булыр иде, ләкин — ни хәл итмәк кирәк! — сайланып торыр замана түгел. Шәфика күлмәкне бик сөенеп, рәхмәт әйтеп алды. Зартугайда кешелеккә генә киярмен дип, фанер чемоданына салып куйды.

Зартугай, болай турыдан исәпләгәндә, «Ижминвод»ка ун чакрымнар чамасы. Ат белән барсаң, урманнар аша, әйләнгеч юллардан, Кама иделе буйларыннан йөри торгач, ихтимал, егерме чакрымнарга тула торгандыр. Госпиталь начальнигыннан ат соравы мөмкин түгел, чөнки Зартугайга барып кайтуны бер көн эчендә башкарып чыгып булмый. Ә сугыш вакытында кем инде сиңа госпиталь карамагындагы атны ике көнгә биреп торсын!

Ни дә булса уйлап чыгарырга маһир кеше Садыя Сафина. Зартугайга Иж буйлап барырга киңәш итте. Госпитальнең дүрт-биш көймәсе бар, алар әлегә буш торалар, хәл җыеп өлгермәгән сугышчыларга көймәдә йөрергә рөхсәт ителми иде әле.

Майор Рәхимовтан Зартугайга барырга, Дәүләтовтан бер көймәне алырга рөхсәт сорадылар. Дәүләтов әллә ни ялындырмады, ә менә Рәхимов башын кашып, байтак кына икеләнеп торды. Госпитальдә әле эшләр көйләнеп кенә килә, врачларның эш урыннарында булулары хәерле иде.

Ничек булса булды, юлга чыгарга ризалык алынды, һәм безнең сәяхәтчеләребез Иж буендагы юан бер имәнгә чылбыр белән бәйләп куелган көймәне чишеп алдылар.

Садыя, Кырымда бер-ике ел яшәгәнлектән, диңгездә көймә белән дә йөргән, руль тота белә икән. Ул койрыкка утырды, Нурия белән Шәфика ипләп кенә ишәргә булдылар.

Нурия алдан ук гозерен әйтте:

— Ашыкмабыз, яме, Садыя. Кызу ишәргә җегәр юк безнең,— диде.

Әкрен барасы килми иде Садыяның. Көймәгә кереп утыру белән үк, ул Фазылы белән Кара диңгездә сәйран кылып йөргәннәрен, Фазылының кояшта янган таза-көчле беләкләрен күз алдына китерде. Җаны ашкыну белән тулды.

Елга уртасына кереп җитү белән, ул Нурияне бәләкәй ишкәк белән койрыкка утыртты, үзе төп ишкәккә килеп ябышты.

— Кара аны, малакай, койрыкны шәп тот, яр башындагы каеннарга бәрдерә күрмә, мин кызу ишәрмен,— диде.

Ишкәкле көймәне алып бару ансат эш түгел, бигрәк тә хатын-кызга. Әмма елганың урта бер җиренә чыгып, зәп-зәңгәр күк астында калгач, июль кояшы алтын тәңкәләрен дулкыннар өстенә сибеп ташлаганны күреп, яр буендагы болыннарда, тау итәкләрендә йөгерешкән балаларга,

тал төпләрендә җим эзләп чумган үрдәкләргә, көтү-көтү булып йөзгән казларга карап бара торгач, җан әллә нинди бер моңсулык белән, сагыш белән тула, йөрәк ашкынып тибә, беләкләрдә көч арткандай була — тыныч еллардагы тигез гаилә тормышы, бәхетле чаклар искә төшеп, үзәкләр өзелеп китә. Кайчандыр гап-гади булып, гадәти булып тоелган ул көннәр, ярабби, алтын көннәр булган икән бит алар, инде хәзер сагынып сөйләргә калдыларммыни?

Нурия сагыш томаны каплаган күзләре белән Шәфикага карап бара. Шәфика үз җаена ишә дә ишә, Садыя апасы белән тигез тота ишкәкне — уф алла, арыдым, дими, ял итик, дими. Чандыр гына беләкләре белән ишкәкне шундый пөхтә каерып ала, ишкәктән тавышсыз диярлек коелган су кояш нурында салават күпере төсләренә кереп җемелди. Кызыйның җәптәшлегенә Садыя апасы да исе китеп бара. Югыйсә бит ул үзе тыныч елларда Кара диңгездә өйрәнде ишкәк ишәргә, ә менә бу балакайны, гомере буена да диңгез күрмәгән авыл кызын көймә йөртергә кем өйрәткән?!

Көндезге уннар тирәсендә Зартугай турысына барып җиттеләр.

Яр буенда бала-чага мәж килә иде. Алар зур бер көймәне ишкәк белән ишеп килгән апайларга сәерсенеп карап тора башладылар. Алар сугыш заманы хатыннарының ат җиккәнен, үгез белән печән ташыганын көн саен күреп торалар, сыер җигеп, җир сөрүләр дә алар өчен ят бер нәрсә түгел. Ә менә Иж чаклы Иждан көймә белән килгән апаларны күргәннәре юк иде әле.

— Әй, энекәшләр! Килегез әле, көймәне яр буена чыгарышырга булышыгыз! — дип кычкырды Садыя. Ул, утырган җиреннән күтәрелә төшеп, малайларга кул болгады.

Энекәшләр яр астына сикерделәр. Чалбар балакларын сызганып, чыр-чу килеп, шапыр-шопыр су эченә килеп керделәр. Садыя ыргыткан тимер чылбырга дәррәү килеп тотындылар.

Инде сөйрәп китәләр дип кенә торганда, арадан берсе кычкырып җибәрде:

— Шәфика апа!

Ул да түгел, икенчесе аваз салды:

— Нурия апа!

— Ә нигә син кычкырмыйсың, энем? Минем исемем Садыя! — дип малайларны көлеп җибәрергә мәҗбүр итте Садыя апалары.

Малайлар көймә тартырга кирәклеген онытгылар, чылбырны суга ташлап, көймәгә ябырылдылар. Ямаулы иске чалбарының балакларын сызганып куйган Мәхмүт, майкадан гына Әхмәт, кара бәрхет түбәтәйле, ләкин күлмәксез бер малай — өч кара чутыр — көймәгә кереп тулды.

Китте исәнләшү, китте буталыш!

Нурия ташбашларны кысып-кысып кочаклады. Алар аның энеләре иде, Габбас төсе иде. Солтанның үлеменнән соң аеруча кадерле, газиз булып калган балалар иде. Тулышып җиткән күңелен түгеп җибәрмәс өчен:

— Балакайларым! Көймәне ярга чыгарып куйыйк инде, әйдәгез,— дип, малайларның вазифаларын исләренә төшерде.

Садыя, Шәфика, Нурия, үзе, кара чутырлар, черәшә-черәшә, көймәне ярга, коры җиргә чыгарып куйдылар. Иж буеннан Зартугайга тикле шактый бар иде әле. Түбәтәйле малайны Мөхәммәтша абзыйларга ат алып килергә йөгерттеләр.

Туган — туган шул инде: Мәхмүт белән Әхмәт шундук Шәфика апаларына сарылдылар. Алар икесе дә үскәннәр, Шәфика апаларын куып җитә язганнар. Битләре кояшта янган, чәчләре кояштан уңган — колаклары гына тырпаеп тора! Алардан кояш исе, болыннар исе, тагын әллә ниткән җанга ятышлы хуш исләр килә иде. Алар, каладан кайткан апаларының әле бер ягына, әле икенче ягына чыгып, авыл яңалыкларын сөйлиләр, яз кошларыдай чебердәшәләр иде.

Озак та тормый, арык кына бер алашаны сиртмә арбага җиккән Мөхәммәтша абзый, мунчала дилбегәсен баш өстендә болгый-болгый, яр буена килеп тә җитте.

Аның бөкрәйгән аркасын, ямьшәйгән киез эшләпәсен, дилбегә тоткан зур кара кулларын күргә, Нуриянең күңеле тулды. Үксеп елап җибәрмәс өчен ул иренен тешләде.

Мөхәммәтша абзый бер генә мизгел сүзсез калып, инде тәмам агарып беткән сакалын сыйпады, аннары Нуриянең тетрәнгән иңбашларына кулын куеп:

— Чү, килен, чү! Бер син генә түгел, ил белән бит. Күрәсен күрми, гүргә кереп булмый...— дип юата башлады.

Ничаклы олы, ничаклы сабыр булырга тырышса да, үзе дә түзмәде, күзләре дымланды, ихтыярсыз агып киткән күз яшьләре чал сакал-мыегы эченә тула башладылар. Каршыда тетрәнеп, сулкылдап басып торган Нурия Солтанның үлемен чынга әйләндерде дә куйды.

Мөхәммәтша абзый, аңына килеп, кул аркасы белән сакал-мыегын сөртте, җебеп киткән борынын тарткалады, үзен кулга алып, Садыя белән килеп күреште.

Шәфика да килде, оялып кына Мөхәммәтша абзыйсына кулының очын гына сузды.

Мөхәммәтша абзый үзе белән казык, балта, бау алып килгән икән, казыгын каты җиргә, тау өстенә кагып, көймәне, дулкын алып китмәсен өчен, әнә шул казыкка бәйләп куйгач, кунаклар белән малайларны төяп, кайтыр юлга кузгалды.

Фәтхениса җиңги кунакларны тыенкы гына каршылады. Солтанның үлгән хәбәрен ишеткән иде.

Чәй янында үлем-җитем хакында иркенләбрәк сөйләштеләр.

— Сугыш Зартугайның һәммәкәй йортына да кереп чыкты, килен,— диде Мөхәммәтша абзый.— Инде унҗиде кешенең үлгән хәбәре килде. Милиционер Нажия үз теләге белән, доброволь булып киткәние, хат җибәргән: фронтка барып җиттем, зениткам белән фашист козгыннарын кырам, пощада юк аларга, актык тамчы каным калганчы, мин аларны кырачак и һәм дә җир йөзеннән ул дуңгыз танауларны себереп түгәчәк, дигән. Йөрәкле бит ул! Йөрәкле дә, башсыз да! Әйттеме — эшли инде ул аны, һәлак булып-нитеп куймаса, күр дә тор — герой булып кайтыр. Су буе Мортазаның улы Зиннурҗан сугыштан кантужин булып, саңгырауланып кайтты. Җитмәсә тагын — аягында сөяк туберкулезы икән. Аның врач кешене бик тә күрәсе килер инде. Вакытыгыз бик тыгыз икәнен дә беләм, Нурия, килен, әммәдәки Мортаза карт белән Зиннурҗанны күрми китү килешмәс, ник дибәйтеп әйтсәң, алар бит әле сезгә этиең Габбас ягыннан чыбык очы гына булса да туган да тиешле...

Менә шундый хәлләр икән.

Дүрт-биш минут эчендә Мөхәммәтша абзый хәбәрләрнең зурысын, кирәклесен табынга чыгарып аударды. Ул шундый ашыгып сөйли, әйтерсең, кемдер аны артыннан куып тора, әйтер сүзен әйттереп бетермичә, каядыр алып китәргә җыена иде.

Мөхәммәтша абзыйның күңеле булсын дип, башта Зиннурҗанга бардылар. Алар килеп кергәндә, авыру-бичаракай чаршау артындагы агач караватта хәлсезләнеп ята иде. Маңгайга таба киңәеп киткән калку яңаклы, җир төсле соры битен бөрчек-бөрчек тир каплаган, гыжылдап сулыш ала иде.

— Зиннурзан улым, менә бырач апаларың килгән, исәнләс,— диде тел очы белән сакауланып сөйләшә торган Мортаза карт.

Авыру хәлсез генә күзен ачып карады, хәлсез генә баш какты.

— Асамый менә, бер дә генә асамый. Асаса, музыт, эрәтләнеп тә китәрие. Асамый,— диде карт, өзгәләнеп.

Бер үк сүзне кат-кат әйтеп тора башлагач, болай да хәл эчендә яткан Зиннурҗанның ачуы чыкты бугай, чуар кызыл мендәр өстендә яткан башы калтыранып алды:

— Горасын да шулай дисең син, эти. Ашарга нәрсәң бар соң? Көне буе сөт эчеп кенә дә торып булмый бит. Ә-ә-ә-әәй! Кычыткан ашыгыз да туйдырды инде,— диде.

Бераз сөйләшеп утырдылар.

Зиннурҗанның тавышы, бүлмә артыннан ишетелгән кебек, саңгырау булып чыга иде. Авыру алдында артык кычкырып сөйләшүне яхшысынмыйча, Нурия Мортаза картны ишегалдына алып чыкты. Нәрсә кирәген, һәм авыруга ничек ярдәм итә алачагын аермачык итеп, үзе әйтте:

— Син, Мортаза абзый, үзең ат караучы булгач, «Ижминвод»ка ат белән килеп, дару алып китү кыен булмас. Мин синең артыңнан күп итеп хлористый кальций эремәсе, бәйләргә мамык белән бинт, марля биреп җибәрермен.

## X

Алар, авылны урап, өйгә кайтканда, Шәфика әниләренә киткән иде инде. Фәтхениса җиңги Нурия белән Садыяга урынны келәткә җәйде. Биредә хәзер, тыныч еллардагы төсле, ашлык исе, он исе борынны кытыкламый, буралар бушап калган иде.

Авыл тын. Су буенда бакалар сайрый. И кайгысыз җан ияләре! Алар өчен сугыш та, үлем уены да юк. Көндезләрен зәңгәр күктән кояш карап торса, кичкә тикле буадагы сулар җылынып өлгерсә, сайрыйлар да сайрыйлар алар. Ә менә адәм баласы...

Нуриянең җырчы Солтаны юк. Әле күптәнмени ул аны Гөлмәрьямнәң көнләшеп, кайнар яшь түккән иде. Ник кирәк булган инде елап йөрүләр? Теләсә кем белән биесен иде аның Солтаны, тик исән генә булсын иде. Исән булсын иде балаларының этисе! Авыруына да, бүтәннәр белән уйнап-көлеп сөйләшүенә дә — барысына да түзәр иде. Исән булсын иде аның җырчы кошы...

Келәт эче бөркүләнеп киткәнгә Нурия, барып, ишекне ачты. Келәт янында арба тора, арбада яңа чапкан печән, әнә шул яшел печәннең хуш исе, кичке дым белән кушылып, келәткә дә килеп керде. Печән исләрен иснәп, бакалар сайравын, тегермән буасы ягыннан ишетелгән су шаулавын тыңлап ята торгач, күңелләрендә тыныч заманнарның истәлекләре яңарды, күрсенү булып, тышка бәреп чыкты:

— Нуриякәем, бигрәкләр дә суга төшкән кук югалды бит Солтан абыебыз. Бигрәкләр дә үкенечле булды. Аны бит бераү дә трудармиягә көчләп җибәрмәде. Авыру иде бит, билетына язылган иде. Үз аягы белән барып, үзе эзләп тапты үлемен...— диде Садыя үкенечле, җанны телә торган тавыш белән.— Ичмасам, ахирәткәем, син дә үгетли белмәдең. Әйбәтләп әйтсәң, бәлкем, сүзеңне тыңлаган булыр иде...

— Юк,— диде Нурия, бераз гына тын яткач.— Бу дөнья кешесе түгел иде бит Солтан абыең. Үлем аның өчен куркыныч түгел иде. Дөнья малы аны кызыктырмады. Идея кешесе иде бит. Ул бит беркайчан да үзе өчен яшәмәде. Беләсеңме, Садыя, минем игътибар иткәнем бар: Толстой геройлары үләр алдыннан нииндидер бер югары минутлар кичерәләр. Солтан да, мөгаен, үлгән минутларында бәхетле булгандыр...

— Ни сөйлисең син, Нурия Аббасовна? Үлем бәхет булса, һәркем ана атлыгып торыр иде. Исән кешенең соң кайчан якты дөньядан туйганы бар?

— Аңламыйсың син, Садыя. Аңлап җиткермисең. Ул бит үләм дип китмәде. Ул бит фронтка булышам дип китте. Урман кисәм, корал ташучы паровозларга ягулык әзерлим, снаряд ящикларына материал бирәм дип язды бит ул хатларында. Бер ай эчендә дүрт хат язып өлгерде. Берсеннән-берсе оптимистиграк иде бит аның хатлары.— Беркавым сүзсез ятты, хатлары күз алдына килде бугай. Тавышы ныгуын көткәндер, бәлки. Дәвам иттерде сүзен: — Беләсеңме, элек, бергә яшәгән чакта, кырыс иде ул, әллә нинди төрпә иде, минем белән дә, Шәфика белән дә

кашны-башны җимереп сөйләшә торган иде. Син әйткән әнә шул трудармиясенә киткәч кенә, күңеле урынына утырды: мине сагынуларын, балаларны сагынуларын әйтеп язды. И Садыя, кайчагында янәшәбездә еллар буе яшәгән кешенең кем икәнен аңлап җиткермибез. Аны югалткач кына дөнья бәясе кеше булганлыгына төшенәбез...

— Шулай инде анысы. Янымда чакта ирем Фазыл миңа чүп тә түгел иде. Инде менә хәзер тиешенчә назламаганмындыр кебек тоела. Үзеңә мәгълүм, сигез ай хәбәрсез торды — утлар йоттым. Госпитальдән хаты килгәч, сөенүләремне белсәң! Ну кайтса, кадерен белер идем дим. Юк, кайтмый. Тагын ут эченә барып керә. Кайтыр микән ул, кайтмас микән?

— Насыйп булса, кайтыр. Киткән бер кешегә үләргә димәгән. Монарчы сине бәхет читләтеп узмый иде бит әле.

— Бәхетсез түгел идем мин, Нуриякәем. Яратышып өйләнешкән идек без. Ирләр беренче бала малай булсын дип шаша. Минеке әйтте, кыз булсын, диде. Без аны курчак төсле итеп киендерербез. Ул без күргән михнәтләрне күрмәс, диде. Күрмәгән кая! Әле бит менә өч яше тула инде — әтисен күргәне юк...

Беренче әтәчләр кычкыра башлаганда гына йоклап киттеләр.

Аларны Фәтхениса җиңги кереп уятты.

— Торыгыз, килендәшләр! Коймагым өлгерде.

Бизәкле ак яулыгын артка чөеп бәйләгән, күлмәген бөрмәгә кыстырып куйган, тула оек өстеннән сап-сары чабата кигән Фәтхениса җиңги кыстый-кыстый чәй эчертте. Мөхәммәтша абзый чәй янына кермәде, нәрсәдер майтарып, лапаста йөрде.

— Кайнагай нишләп чәй эчәргә керми? — дип сорады Нурия.

— Аның, җаным, үз акылы үзе белән. Берәр төрле уй-вәсвәсә кергәндер әле башына.

Чыннан да, шулай булып чыкты.

Кунаклар чәй эчеп, коймак белән сыйланып, табын яныннан кузгалган чагында гына, түгәрәкләп кырган чал сакалын сыйпаштырып, Мөхәммәтша абзый килеп керде.

Бүген аның хәрәкәтләре төгәл, йөзе җитди.

— Нурия килен, Садыя кодача, мин сезне озатып куярга булдым әле. Заманаларның болгавыр чагы. Дөньяның кеме генә юк. Ике яшь чибәр катынны ялгыз көймәгә утыртып җибәрү ярап бетмәс, дидем.

Фәтхениса җиңги бу урында үз сүзен китереп кыстыруны кирәк дип тапты:

— Мутланып маташуыңны куй син, карт боргыч. Сүзеңнең чатыботы юк. Сөйләсәң, җилем кыстырмый гына сөйлә, яме.— Кунакларга таба борылды, сер сөйләгән сыман, тавышын әкренәйтте: — Бик көйрәк җан. Төне буе йокламады. Инде менә күкәй сала алмаган тавык кебек кытаклап йөри: ат белән илтеп куярыем, көймәләре кала, көймә белән җибәрерием, икәү генә кайтып җитә алырлармы, ди. Килгәндә алар, ни дисәң дә, өчәү ие, ди. Менә шул. Мөхәммәтша абзагыз сезне озатып куяр.

Юлга әзерләнүләр тиз булды.

Күчтәначкә дигән ике дистә күкәйне Фәтхениса җиңги иске кәгазьләргә берәм-берәм төреп куйган иде.

Шафика, менә сезгә әни күчтәнәч җибәрде дип, бер кадак атланмай китерде.

— Юк, сеңлем, майны ала алмыйбыз.— диде Нурия ихлас күңелдән.— Сез үзегез дә бик күп. Хәзер инде, синең белән исәпләгәч, биш кашык булдыгыз. Ала алмыйбыз, сеңлем, үпкәләмә.

Шафика, Казанда апасы янагына суккандагы төсле, иренен тешләде. Күзеннән эре яшь бөртеге мөлдерәп тамды.

— Нәрсә булды, балам? — диде Нурия, каушап.

— Әни... аны бит... адарынган булган...

— Нәрсә дип адарынган?

— Чишмәбай этинең хәбәре килсә... хәбәре килсә...

— Чишмәбай исәнмени? Каян белдегез? Матурым, ускәнем, тынычлан, бәгырем! — Нурия, килеп, сеңлесен кочаклады, яшьле күзләреннән үпте.— Исәнмени этиегез?

Шәфика тынычлана төште. Күзләрен ике куллап сөртте, күз яшен яңаклары буйлап сылады. Аннары ашыгып, әйтеп бетерергә вакыт тимәс дигән төсле, төеләтөелә сөйләп алып китте:

— Чишмәбай эти исән. Мин кайтасы көнне хаты килгән. Фронтта дигән. Башта ниндидер аерым батальонда булган. Шагыйрь Фатыйх Кәрим белән бергә туры килдек, окопларда бергә ятабыз дигән...

Нурия сеңлесен кысып-кысып кочаклады, аркасыннан какты. Иң якын, иң кадерле кешеләренең исәнлек хәбәрен алу — башка сыймаслык, күңел тетрәтерлек хәл иде.

Аларның тулып ташыган хисләренә Мөхәммәтша абзый белән Садыя да килеп кушылгач, өй эче буталыш белән тулды. Ныклык, салмак-сабырлык ычкынды. Китәсе барын да оныттылар.

Шәфиканың яңа хәбәре әле ул гына түгел икән. Шатлык өянәге бераз кимеп, күңелләр әкрен-әкрен үз урынына утыргач, апасы Нурия белән саубуллашкан чакта:

— Мин, апам, ике айлык педагогик курсларга барырга булдым. Быелдан ук миңа алтынчы-җиденче классларда рус телен, рус әдәбиятын укытырга кушалар. Салагыш мәктәбендә шундый урын буш икән, укытучысын сугышка алганнар,— диде.

— Бик авыр бурыч йөкләгәннәр икән үзеңә, сеңлем. Бик авыр,— диде Нурия, аның хәленә кереп.— Курыкма, яме. Батыр бул. Минемчә, син аны булдырырсың. Әйбәт беләсең бит син әдәбиятны. Казанда чакта урысчаны да әйбәт өйрәндең. Тәртипле, тырыш бала бит син...

Нуриянең тагын күңеле йомшады, сеңлесенең уңышына сөенүдән күзләре дымланды. Апа кеше, елаклыгыннан оялып, башын читкә борды.

Аерылышу шул хәтле дә авыр булыр дип кем уйлаган?!

Моңарчы хәсрәт-кайгысын берничек тә белдермәгән Фәтхениса җиңги дә, китүчеләр елаша башлагач, күңеле тулганны тойды. Аның да бит Әхнәфе — бердәнбере ут эчендә. Аңардан бит инде өч ай чамасы хәбәр юк. Исән микән, сау микән, кайларда йөри икән? Иж ярына җитеп, юлчылар көймәгә утыра башлагач, аның да ныклыгы бетте, күз яшен күрсәтмәс өчен, ул битен алъяпкыч белән каплады.

— Вәт тибәнә!— диде Мөхәммәтша абзый.— Йә, кем инде кунакны бер чиләк су коеп озата? Сөрт, әнисе, күзенне сөрт,— диде. Аннары Садыяга таба борылып, кешечә, ягымлы итеп аңлатып бирде: — син, кодача, гаеп итмә безне. Әхнәфебездән хәбәр булмаганга җылый җиңгәгез. Бу хәлләрне Нурия белә...

Мөхәммәтша абзый бик хәтәр кызулый башлады — юл кешесенең юлда булганы хәерле. Ул нык киенеп чыккан: өстендә — юл кожаны, аягында дегет белән майланган күн итек, башында Ижау заводында эшләгәндә юнәткән күн картузын батырып кигән, иңбашына ишкәкләрне күтәргән.

Көймәгә ул башта Нурия белән Садыяны кертеп утыртты, каяндыр чабышып килеп чыккан өч кара чутырны — Әхмәтне, Мәхмүтне, аларның иптәшен, көшегез, көш! дип кулларын селтәп куып җибәрде, көймәне этә-этә, күн итекләре белән бераз су ерып керде дә, сикереп, көймәгә менде. Ишкәк беркетә торган тимерләрне сумкасына салып алып килгән тарантас мае белән майлады.

— Майласаң, ишкәк җиңел йөри, шыгырдамый,— дип, кыска гына аңлатты.— Аллага тапшырдык! — дип, ике кулына төкереп, ныгытып торып ишеп җибәрде.

Көймә әллә ни арада елга уртасына килеп чыкты. Ир-ат кулының нәрсә икәнен аңлаган Нурия белән Садыя бер-берсенә карашып куйдылар...

## XI

Сугыш афәтенең авырлыгы, мөгаен, барлык авылларга да тигез төшкәндер. Һәлак булганнар да, хәбәрсез югалганнар да, газиз ирләрен көтеп ала алмаган тол хатыннар да бер генә авылда да булмый калмагандыр. Өчпочмаклы, кара кайгылы хатлар авыл кешеләренең җанын бик күп җәрәхәтләде.

Монысы шулай. Әмма һәр авылның түккән күз яше — үзенчә, өзелеп сагынган кешеләре дә үзгә, үзләренеке...

Шәфика моңы, туган якларына кайтып, балалар укыта башлагач, үз күзе белән күрде, үз йөрәге белән аңлады.

Зартугайда Шәфиканың үги этисен — Чишмәбайны сагындылар. Ул салган амбарлар, ул корып калдырган су ындырлары, Аксагыз таулары итәгенә ул алты почмаклап, чарлаклап салган йорт — һәммәсе күз алдында иде шул. Әнә шундый алтын куллы кешенең суга төшкән төсле кинәт югалуы фаҗига иде. Сугышның икенче елында Чишмәбайдан килгән хат Зартугайны дер селкетте. Хәнифә өчен түгел, аның бер оя балалары өчен генә түгел, авыл өстенә төшкән кара тапның алып ташланганы өчен дә сөенделәр. Язын ераклардан очып кайткан кошлар төсле сөенечле бу хәбәр артыннан тагын да сөенечлерәк яңа бер хәбәрнең киләчәгенә ышанып яшәделәр. Чишмәбай төсле булдыклы, батыр йөрәкле кешенең, исән-имин булса, башкалардан аерылып чыгачагын алар белә иде.

Чыннан да, шулай булды.

Тагын ике айдан Каюм Хисмәев авылдашларының өметен аклаган хат җибәрде: ул, Сталинград өчен барган аяусыз сугышларда катнашып, медаль белән бүләкләнгән. Моңа Зартугайларның җаны канат какты. Бу көннәрдә тик Бүре Бадул гына караңгы чырай белән йөрде. Чишмәбайның башын ашадым дигән иде, гөманы расланмады — Чишмәбай исән, алла сакласын, кайтып килүе. Бүре нәселеннән үч ала башлавы ихтимал. Икенчедән, аның олы улы Тәхәвинең госпитальдән үле хәбәре килде. Бу исә моңарчы җиргә нык басып йөргән Гыйбадулланың җегәрен алды, үз эченә йомылырга мәҗбүр итте. Өстәвенә — интендантлык эшенә урнашуын зур бер вакыйга итеп язган Җиһангирының да, энесе Нух Галләмнең дә ярты ел инде хәбәр-хәтерләре юк.

Халык моны белә, халык моны үз бизмәненә салып үлчи — җил — агач башыннан, кайгы адәм башыннан йөри.

Салагыш урта мәктәбендә укыта башлагач, Шәфика бу авылда икенче бер кешене сагынганнарын төшенде. Мәктәп директоры, физика-математика укытучысы Зәйни Моратовны.

Заманында бер мең йортлы, дүрт-биш мәхәлләле булган, яңа-яңа, яртылаш калган, гражданнар сугышы чорында канлы вакыйгаларны башыннан кичергән авылда, базарлы һәм урта мәктәпле Салагышта 1942 елның ахырларына инде утыздан артык йортның хуҗасы сугышта үлеп калганлыгы билгеле булды. Солдат хатыннары кара мөһерле хатларны сандык төпләренә салып саклыйлар, төннәрен, сабыйлары йокыга талгач, ирләренең киемнәрен сандыктан алып карыйлар, үксеп җибәрмәс өчен тешләрен кысып, тавышсыз гына елыйлар, әмма ирләренең исән түгеллегенә ышанмыйлар иде әле.

Шәфика Бану Хамматоваларда фатирда тора, Зартугайга ял көннәрендә генә кайтып килә иде. Ул бер төнне Бану апасының һәммә кеше йоклап беткәч, төнге сәгать берләрдә җылы урыныннан торып, бер караватта тезелешеп йоклаган дүрт баласының йокысын бүлмәс өчен, аяк очларына гына басып, олы якка чыгуын, сукыр лампаны яндырып, зур агач сандыкны ачуын күрде. Йөрәге кысылып, укытучысы һәм мәктәп директорының ни эшләгәнен күзәтә башлады.

Сандыктан өчпочмаклы хатны алды Бану апасы, аны сүтеп, иреннәрен тавышсыз гына кыймылдатып, озаклап укыды, кире урынына

салып куйды. Утны сүндерде, почмак якка чыкты. Ятты — йокыга китә алмыйча борсаланды.

Шәфика аның елаганлыгын аңлады. Бану апасы белән алар икесе бер ястыкта йоклыйлар иде. Бану апасының иңнәре дерелди, үксеп җибәрмәс өчен, ул юрган читен тешләгән иде.

Әмма ул кайгысын урамга чыгармады.

Икенче көнне таң белән торды, сыерын кертеп, җылы су эчерде, бозавына имезде. Балаларын уятып, тамакларын туйдырып мәктәпкә җибәрде. Үзе дә килде мәктәпкә, нык тавыш белән, җитди чырай белән боерыкларын бирде. Мәктәп тормышы өчен ул җаваплы иде. Сугышка киткән Зәйни Моратов урынына аны директор итеп куйганнар иде.

Авыл халкы Бану Хамматованы ике яклап сынады. Беренчедән, элекке директор, ягъни Зәйни Моратов авыл өчен авторитет, беркем ирешә алмас абруй булган. Моратовны Салагыш сугышка елап озаткан. Бану Хамматова андый югарылыкка күтәрелә алырмы? Икенчедән, ни дисәң дә ир-ат — ир-ат инде ул, хуҗалык дилбегәсен кулга нык чорнап тота. Бану Хамматова нишләр менә? Дүрт бала. Иренең үлгән хәбәре килде. Җитәрме аның ныклыгы, әллә ул сыгылып төшәрме?

Салагышлар белән бергә, бу хакта яшь укытучы Шәфика Уразаева да уйламый булдыра алмады. Чөнки ул Моратовның нинди кеше икәнен ишетеп кенә түгел, күреп тә белә иде бит. Салагышка күчкәнче Зәйни Моратович Зартугай җидееллык мәктәбендә физика-математика укытты. Мәктәпнең җитәкчесе булды. Кара костюмнан килер иде мәктәпкә, чытыр ак күлмәктән, галстуктан. Көн саен шулай. Киемсалымын пөхтә йөртү ягыннан ул барлык Зартугайга үрнәк иде. Мәктәпкә бер генә кайчан да соңга калмас, хәтта беренче дәресе юк чагында да башка укытучылардан берәр сәгатькә алданрак килеп җитәр иде. Шулай бервакыт, Зартугай мәктәбенең бишенче сыйныфында укыган чагында, Шәфика аның мәктәп мичен ягучы ике апа белән сөйләшеп торганын күрде. Йомшак кына итеп сөйләшә, хәлләрен сораша...

Икенче мәртәбә ул аны өч елдан соң очратты. Зартугайда түгел, Салагыш мәктәбендә. Ике айлык педагогик курслардан соң, кулына роно приказын тотып килгән булачак яшь укытучыны Зәйни Моратович өстәл яныннан торып аягүрә каршылады. Хәлен сорашты. Иренмичә сорашты, белергә теләп. Кайда тора? Әнисе Хәнифә ни хәлдә? Үги әтисенең хәбәре юкмы? Әхмәт белән Мәхмүт сабакларын ничек укыйлар? Шамил үсәме? Нурия апасы белән Солтан абыйсы исән-саулармы?

Гаҗәпләндергән иде аны Зәйни Моратович. Өч елдан соң да алар күзләсендәге бер генә кешене дә онытмавы белән гаҗәпләндергән иде. Үзеннән унбиш яшькә олы шушы кеше белән икесенең арасында нинидер күңел уртаклыгы сизеп, атна буе дулкынланып йөргән иде. Ләкин Зәйни Моратовичның директорлык заманында ул ун гына көн эләгеп калды. Тик шул ун көн дә аңа Зәйни Моратовичның буй җитмәс биек, югары кеше икәнен аңлап калырга җиткән иде.

Инде менә ул фронтта. Аның хакында хәзер Бану апасы сөйли.

Кышкы озын кичләрдә, сукыр лампа яктысында җылы оекбаш, бияләй ише нәрсәләр бәйләп утырган чакларда яшь укытучы Шәфика Уразаева белән солдат хатыны Бану Хамматова бер-берсенә якынаеп киттеләр, эч серләрен бүлешә торган булдылар. Сер дигәннән, күбрәк Бану апасы сөйли. Шәфика тыңлый, аның үзенең әле кемгәдер сөйләрлек сере җыелмаган.

Сугышка кадәрле яшәп калган ун еллык гаилә тормышында ике малай, ике кыз тапкан Бану Хамматова. Инде шуларны карый-бага, балалар укыта, директор булып тора. Гаязының үле хәбәре килде — ышанмый, хет үтер — ышана алмый. Ничек яшәсен ул Гаязыдан башка, «Сезнең әтиегез юк, сез ятим» — дип, балаларына ничек әйтә алсын!

Сүзне ул, әлбәттә, ире белән яшәгән бәхетле көннәреннән башлап җибәрә. Уза ун минут — Зәйни Моратовка кайтып төшә.

— ...менә без әйтәбез, бу кешенең эше күп, бу кешенең эше юк, дибез. Беләсеңме, Шәфика, аңлыйсыңмы, үскәнем, кешенең эше күп яки аз булуы — фәкать үзеннән, әйе, үзеннән, җаным, бары тик үзеннән генә. Мәктәпкә төп-төгәл сигездә килеп, төп-төгәл дүрттә китүчеләр бар. Ләкин шундый аккуратный укытучы үзен мәктәп бинасында гына укытучы итеп сизә. Мәктәп бусагасын атлап чыктымы — ул педагог түгел. Онытә! Әллә син моны авыл халкы сизми дип беләсеңме? Сизә, үзенә әйтми, исәнләшер-исәнләшмәс кенә узып китә. Ә менә Зәйнинең авторитеты зур иде. Ак сакаллы карт та, сигез яшьлек сабый да аңа киңәшче итеп, олы итеп карый. Ни өчен? Кеше булганга. Халыкның хәленә керә белгәнгә.

Әле утыз өченче елларны, безнең бер генә балабыз туган мәлне. Зәйни «Фордзон» тракторларын өйрәнү түгәрәге ачты. Зартугайда эшләгән чагында. Сәерсенеп карадылар. Тапкан эш! Мазутка батып, кичнең кич буе. Шулай дип карады халык башта. Укытучылар да кул селтәде. Ләкин йөрәклесе табылды — корым-сөремнән курыкмый торганы. И китте, китте, мин сиңайтим, эшләр хутка. Трактор өйрәнгән укытучылар физикадан яхшырак укыта. Белеп укыта, яратып укыта. Зәйни тегеләрне җыелыш саен күтәрә, район киңәшмәләрендә сөйли. Китте боларның даны Пәнҗәргә, китте Казанга! Минем Гаязым да женләнде трактор белән. Икәү бергә безгә кайталар, бәхәсләшәләр — колаклар тона. Кычкыруын Гаяз күбрәк кычкыра, Зәйни сабыр. Әле егерме ике яшендә генә булса да, акылы күп. Бер урында таптанганны бер дә яратмый иде. Язын колхоздан ун гектар җир бүлеп бирделәр, үзләре сорап алды, алмаш-тилмәш сөрәләр минем Гаязым белән. Ике төн эчендә сөреп ташладылар, бер көн эчендә бодай чәчтеләр. Бодай теге аю шалканы кебек, котырып үсте. Ел килеше бик матур булган иде шул. Көзен мәктәп тирәсенә алмагачы, чия, карлыган утыртып чыкты. Биология укытучысы да, мәктәп каравылчысы да, мич ягучы да булышты. Зартугай малайларын эшкә тартты Зәйни. Матур итеп, күңелләр ашкынырлык итеп оештырды эшне. Бер почмакта гармун уйныйлар, бер почмакта биниләр, бер почмакта аш пешерәләр. Өмә. Карале син моны, хитрыйны, халыкның нинди матур гадәтләрен мәктәп янына китерә бит, әй!

Мәктәпкә килү бәйрәмгә әйләнде. Бу, җаным Шәфика, әгәр бик беләсең килсә, минем тәмамы җанымны билап алды. Борынга егетләр исе кергән чак. Мин Гаяз белән иләс-миләс. Зәйнине күрү күңелле, тик ул миңа почмакта капчык белән сугылган адәм шикелле тоела. Хәзер мин аны аңлыйм. Бәялим мин аны — хәзерге акылым белән. Ул чагында төпле егет кирәк. Йорт тоткасы. Әгәрже ягыннан килгән егетне сайладым — Гаязны. Аның көчле беләкләренә тотынып, тынычрәхәт яшисе килә. Менә шулай, Шәфика, шулай, үскәнем, яшьлекнең аның үз исәрлеге үзе белән! Хәзерге акылым булса, гафу ит мине. Зәйнигә чыккан булыр идем. Гаепләмә мине, яме, акыл бирәсе урынга, олы башы белән җүләр сатып утыра дип уйлама. Сагынулар сөйләтә, матурым, сугышка кадәрге матур заманнар...

Берара сүзсез утыргач, алсуланган бит алмаларын кулы белән баскалап, Бану апасы әйтеп куя:

— Беләсеңме, Шәфика, мин сине роноддан приказ тотып килгән көнне үк яраттым. Шуңа күрә үзебездә торырга чакырдым да. Исеңдәме ул көн?

— Исемдә, Бану апа. Сез әле мине коридорда очратып: «Кайсы класска укырга керәсең?» — дип тә сораган идегез.

Бану апасы, авызын кулы белән каплап, гөлдерәп кенә бер көлеп ала. Сукыр лампа филтәсенең күмерләнгән өлешен пычак сырты белән кырып төшерә — өйгә сасы керосин исе тарала.

— Их, тәрәзәне ачасы иде дә, өй суынып,— дип уфтана.— Зартугайның Гыйбадулла абзый кызы, амбарчы Нисаны әйтәм, беркөн Са-

лагыш базарында очрап, җиделе лампа куыгы бирермен дип ышандырган иде, шуңа барып кайтыргамы соң? Нишләргә дә аптыраган бу сукыр лампа белән. Иртән торгач, борынга тулган корымны юып бетерер хәл юк бит! — дип, ул бәйли торган оекбашы өстенә иелә. Нәрсәдер уйлый, чамалый, тарткалап карый. Менә ул башын күтәрә, Шәфиканың күкрәк өстендә яткан авыр кара толымнарына сокланып карап тора.— Беләсеңме, Шәфика, миңа синең максималист булың да ошый. Яшь чагында мин үзем дә турыдан ярып барырга ярата идем. Кешеләр минем өчен йә яхшы, йә начар, урталар бар дип белми идем. Шулай булгач, табигый, мин аларны йә яратам, йә яратмыйм. Гаяз белән Зәйни дөньяга алай карамаганнар ахрысы. Алар кешедән беренче нәүбәттә яхшылык орлыгын эзләгәннәр, тапканнар шуны — кешеләрнең һәммәсен үз артларыннан ияртеп алып китә алганнар. Алар — минем өчен икесе дә бик кадерле кешеләр. Сандыгымнан Гаязымның хатларын алып укыйм, фронттан язган хатларын, күңелем тула, күз яшьләре аша Зәйнине, аның буен-сынын, елмаеп басып торуларын, кара тутлы йөзен, бәләкәй кара мыегын күз алдына китерәм...

Бану апасы кинәт, һич тә көтмәгәндә, Шәфиканы гаҗәпкә калдырып, моңлы-сагышлы истәлекләреннән аерыла, фани дөньяның гап-гади эшләренә, борчулы мәшәкатьләренә керешеп китә:

— Әйдә, Шәфика, булмаса, йомышларыбызны йомышлап керик тә, ишекләребезне бикләп, йокларга ятыйк.

Ишегалдында аларны кышның зәмһәрир суыгы каршы ала. Баш өстендә кап-кара күк йөзе, анда, утлы очкындай, йолдызлар чекерәеп яна; бер-берсенә сыенырга теләп җемелдәшәләр, күз кысышалар, сыена алмыйча, суыктан калтыраналар. Яртылаш тулган ай күгелҗем-соргылт томан боҗрасы эчендә интегә. Кайдадыр авыл очында этләр өрә, сыкылы суык аларның тавышын да йота, тоныкландыра; сугыш еллары кышының салкыннарыннан күшеккән сарыклар йөткерenә, бурабзардан сыерның авыр гына мышнаганы ишетелә.

Шушы салкын төндә көнбатыш тарафларда Шәфиканың үги әтисе, Әхнәф абыйсы, укытучы Зәйни абый, фашистларны җибәрмәс өчен, салкын окопларда яталар. Гаяз абыйның инде үлгән хәбәре килгән, Бану апа ул хәбәргә ышанмый, димәк, ул да окопта бүген...

— Сыерның бозаулар вакыты да җитеп килә, саграк булырга кирәк,— ди Бану апасы.

Күкрәк тутырып, саф һава алгач, алар өйгә керәләр. Йокларга әзерләнәләр.

Итәгенә челтәр тоткан эчке күлмәктән, йомры гәүдәле Бану апасы, аяк очларына гына басып, почмак яктагы сәкедә йоклаган балаларын барлап килә, аннары беренче булып мамык юрган астына чума. Көне буе мәктәптә эше, колхозда агитаторлык эше, фронтовикларга җылы киемнәр әзерләү эше белән арып беткән буыннарының сулкылдавына бирелеп ята, аның янына тал чыбыктай нәфис, юка гәүдәле Шәфика килеп сыена.

Бану Хамматова «тал чыбыгы»на ярым пышылдап дәшә:

— Йарабби, минем дә бар иде бит шундый чакларым. Кая китте алар? Бетерде инде, сугыш бетерде аларны...

Шәфика, директор апасының моңсу тавышын тыңлап, беркавым сүзсез ята. Директор апасы йоклый алмый әле. Тагын сугышка кадәрге рәхәт заманнарга әйләнеп кайта.

— ...утыз тугызынчы елны Зәйни Моратов өйләнде. Бу хәзер йорт-җирен булдыра инде, кала суккан төсле итеп капка-койма корыр, алмагачы утыртыр, авылда бер дигән итеп яшәр дип торганда, Зәйниебез «сәяхәтче» журнал уйлап чыгарды. Балалар, өченче сыйныфтан алып югары сыйныфларга кадәр, һәммәсе директор янында. Кулларында — карандаш, буяу пумаласы: эшләгән эшләрен язалар, рәсем төшерәләр. Күпме сыерчык оясы куелган, күпме куян үстерелгән, күпме карлыган

утыртылган — берсен бер калдырмый язалар. Язар нәрсә күп: язын кырау төшәсен белгәч, ике төн буе тирес яндырып, җиләк-җимеш бакчасын саклап калдылар. Көзен кып-кызыл булып беренче алмалар пеште. Бит саен алмагач рәсеме. Ул гынамы?! Бит саен шигырь, хикәя. Шаштылар ул елны шигырь белән! Әллә яхшы ул шигырь, әллә бер тиенгә дә тормый — язалар, журнал битенә күчерәләр, бергәләп сөенәләр...

— Бакча утыртып йөргәннәрне беләм мин, анысы мин өченче сыйныфта укыганда булды,— диде Шәфика,— шигырь язып йөргәннәрен хәтерләмим.

— Каян хәтерлисең, син инде ул чакта Казанда, Нурия апаңнарда яши идең, аннары... болары бит Зартугайда түгел, Моратов Салагыш мәктәбенә директор булып килгәч эшләнде...

— Ә-ә-әәә,— диде Шәфика сузып кына.

— Син күрми калдың шул аларын. И, җаным Шәфика, белсәң иде менә, күрсәң иде, журнал китте Зартугайга, Чекалдага, Кырынды, Кадыбаш, Исәнбай, Яуморза мәктәпләренә. Пәнҗәр төбәген йөреп чыкты да, Әгерҗегә юл алды. Казанда Мәгариф халык комиссары ишеткән моны — шуннан соң безнең «сәяхәтче» журналны республика буйлап йөртә башладылар. Журнал «балаладЫ» — шундыйны барлык мәктәпләр дә булдырырга керештe. «Мәгариф» журналында, «Пионер каләме»ндә, «Яшь ленинчы» газетасында безнең балаларның шигырьләре, рәсемнәре, эшләнгән эшләре хакында хәбәрләр атна саен басылып торды. Шаулады безнең мәктәп!

1940 елны Моратов Зәйнине Мәскәүгә Бөтенсоюз укытучылар конференциясенә озатып җибәрдек...

## XII

Декабрьнең унҗиденче числосында Почта-Хәерҗамал Бану апасына телеграмма китереп тоттырды. Агарынып алды кәгазьне Бану апасы — Гаязның яңа хәбәре түгелме? Каударланып ачты, каударланып укыды, лып итеп караватка утырды.

Салагышның кайгы-хәсрәтен уртаклашырга күнегеп җиткән Почта-Хәерҗамал яулык өстеннән киеп куйган колакчын бүрекне арткарак чигерде:

— Үлем-җитем юктыр бит, дилектыр?

— Үлем-җитем юк, Хәерҗамалттәй. Юк үлем! — дип, үзе дә сизмәстән, кычкырып әйтеп ташлады Бану Хамматова.

— Әллә берәрсе кайтамы, малакай?!

— Кайта, Хәерҗамалттәй, кайта!

— Кем кайта, дилектыр, миңа да әйт инде?

— Нигә сорап торасың аны, Хәерҗамалттәй, телеграмм үз кулыңда иде бит, укымадыңмыни?

Почта-Хәерҗамалның хәтере калды:

— Син бит, Хамматова Бану, бик аңлы кеше, мин бит урысчаны сукыр бер тиеннек тә белмим. Ничек итеп укыйм ди инде мин аны шулай булгачыннан?..— Ул, бүреген басып киеп, кулына тоткан чыбыркысын селти-селти, аты янына китәргә дип кузгалды, тик шул чагында тагын нидер исенә төшеп, кире борылды: — Син, дилектыр, әйтәсең килсә — әйт, әйтәсең килмәсә — әйтмә, ә мин әйтәсем булгач, әйтәм: пуштыдан мине кисәтеп җибәрделәр, сәгате-минуты белән илтеп бир штубыты, соңга калып куя күрмәсен диделәр.

Бану телеграммага тагын күз салды.

«Урал поезды Әгерже станциясыннан 18 декабрьдә көндезге унике-ләрдә узачак биш минут туктап торуы ихтимал килергә тырыш Зәйни Моратов»

Бану Хамматова Шәфиканы килеп кочаклады, каушаудан ни әйтергә дә белми, колхоз идарәсенә чыгып йөгерде.

Тагын ике сәгатьтән ул үрәчәле чанага күк бияне җигеп кайтты. Шәфиканы тиктомалга ашыктырырга тотынды:

— Мин бит сиңа әйттем. Әзерләнә тор, дидем. Нишләп җәелеп утырасың син, кондырлы кодача кебек?

Юлда әллә ни күп сөйләшмәделәр.— суык иде. Толыпка төренеп барырга туры килде. Толыптан башны чыгарып сөйләшергә керештеңме, каш-керфекләргә сыкы утыра, толып якасы да агарып бетә иде. Өч-дүрт сәгать баргач, Кырынды авылында — Гаяз Хамматовның сугышка кадәрле үк килеп урнашкан бер кардәше Нурми картларда чәй эчеп чыктылар. Нурми — баш түбәсендә бер бөртек тә чәче калмый коелып беткән өлкән укытучы — сүзгә саран булып чыкты. Бану Хамматовадан ире Гаязны сораганнан соң, тегесе икеле-микелерәк җавап биргәннән соң, бүтән төпченмәде. Авылның тынлыгы, кар көртләре эченнән очлаеп күренгән йорт түбәләре, морҗалардан күтәрелгән аксыл төтен, урамны тутырган салам көле исе — болар барысы безнең юлчыларда моңсу тойгылар уятты.

Әгерҗеҗә житәргә җиде-сигез чакрымнар кала, күз бәйләнде, әйләнә-тирәгә эңгер инде, озакламый караңгы да төште. Алда Ижбубый авылының саргылтым тонык утлары күренде.

— Менә, Шәфика, карап кал, этиең Габбас мулла заманында шушы авылның атаклы мәдрәсәсендә укыган булган. Бу мәдрәсәдән чыккан кешеләрнең даны илгә таралган,— диде Бану апасы, ике катлы агач йорт яныннан узганда.

Төнне Ижбубыйда үткәрергә булдылар.

Бану йоклый алмады. Әле алмаш-тилмәш өргән эт тавышларына, әле мич буенда печән күшәгән бозауга колак салып, йокылы-уяулы васвасәләнеп ятты. Сугыш елларында бу якларда күбәйгән бүреләр турында, сугыш афәтеннән качып, Тугызбуй тирәләренә килгән пошилар турында уйлады. Черем итеп киткән чакларында шаулап килгән һәм туктамый узып киткән поездны күреп саташты...

Таң алдыннан йокыга куерган булган иде, ишектән мул булып кергән салкын аны туңып-дерелдәп уянырга мәҗбүр итте. Чаршау читен ачып караса — өйгә сыер керткәннәр, алдына пар бөркеп торган кабыклы бәрәңге салып, бозавын имезергә кушканнар.

Сыер җилененә дөбердәтеп төртә-төртә, койрыгын селки-селки, әнисен имгән аклы-каралы бозау аның тагын сугышка кадәрге тыныч-рәхәт заманнарын һәм... Әгерҗе станцасыннан узачак Зәйни Моратовны исенә төшерде.

Ул торып утырды. Чайрап йоклап яткан Шәфиканы уятты. Җылы урыныннан куба алмыйча, күзләрен уып, киерелеп яткан үсмер кызга ул байтак вакыт үтә дә якын итеп, хәтта кызганып карап торды. Бигрәкләр дә яшь шул, гамьсез-ваемсыз гына яшәр чаклары бит әле...

Тимер юл станцасына иртәнге уннар тирәсендә килеп җиттеләр. Урал поезды килергә ике сәгать вакыт бар иде әле. Атны каядыр куярга, поездның үз вакытында киләме-юкмы икәнен белешергә кирәк иде.

Суыктан шинель якасын күтәреп, муенын шуның эченә яшереп, йөгерә-атлый килгән бөкшәйгән бер карттан атны кая бәйләргә мөмкин икәнен сорадылар.

Поезд сәгать ярымга алданрак килде. Башта аның ерактан тонык кына итеп аваз салганы ишетелде. Ул да түгел, вагон саен автоматлы, каеры тунлы солдатлар баскан «товарняк» станцага тулы хутына килеп керде дә, тизлеген киметмичә, кара төтен бөрки-бөрки, пошкыра-пошкыра чаба бирде; аңа ияреп чапкан халыкны үртәгәндәй, станца читенә диярлек чыгып, ачы тавышлар белән шыгырдап туктады.

Поезд чапкан уңайга Бану зур бер кызыл вагонның ачык капкасына өелгән солдатлар арасыннан Зәйни Моратовны таный алмаган иде. Инде менә җиргә сикергән ак тунлы, маңгаена кызыл йолдыз кадаган ак бүрекле, мыеклы командирда Зәйни чалымнарын күргән-

дәй булгач, җаны тетрәп китте, һәм ул, абына-сөртенә аңа ташланды.
Калганы саташулы төш кебек кенә булды. Әллә күрештеләр, әллә күрешмәделәр. Вакыт шундый да аз, әйтер сүзләр шундый да күп, әмма ике елдан артып киткән сугыш кешеләрне чамасыз кырыс, чамасыз олы, чамасыз тыенкы иткән иде.

Ниндидер бик житди, шул ук вакытта бик тә ягымлы сүзләр әйтеп, Зәйни Бануның кулына бер төенчек тоттырды, күкрәгенә кысып, иреннәреннән үпте һәм ашыгып, шул ук вакытта аерылырга да теләмичә (дымлы кара күзләрендә үкенү чагылып узды), инде дөбердәшеп кузгала башлаган вагоннарга таба йөгерде.

Ул вагонга сикереп менгән чакта гына Бану аңына килде:

— Исән йөреп, исән кайт! — дип кычкырырга өлгерде.

Поезд ачы итеп сызгырта-сызгырта, кара төтенен бөрки-бөрки, станца будкалары артында күздән югалды. Аның соңгы сәламе, гудок тавышы бик тонык булып ерактан гына килеп житте.

Бер чакрым араны берни сөйләшмичә, очрашу тойгыларыннан айный алмыйча, атны атлатып кына кайттылар. Әллә педагоглык сабырлыгы, әллә хәвефле хәбәр белүдән курку төенчеккә кагылырга кушмый иде.

Беренче булып Шәфика — дөньяда бер сабыр кыз — сабырсызлана башлады. Шуннан соң Бану апасы да түземлеген җуйды. Калтыранган куллары белән ул төенчекне чиште, калтыранган куллары белән, дүрткә бөкләнгән хат-кәгазьне алып, күзенә якын ук китерде, укый башлады:

«Гыйлембану! Син минем бу хатымны укыган чагында, безнең поезд инде ерак киткән булыр. Мин синең газапларыңны күрмәм. Тик... шуны бел... мин гел... мин гел... синең яныңда...» — дип, бүтән укый алмыйча, сыгылып төште.

Хатның калган ягын Шәфика күз йөртеп укып бетерде. Анда Гаяз Хамматовның, гитлерчыларга каршы аяусыз сугышып, батырларча һәлак булуы әйтелгән. «Мин аны Сталинградтагы Мамай курганына үз кулым белән күмдем».— дигән иде Зәйни Моратов.

Кул кисәге хәтле бу хатны солдат хатыны Бану сугышлар беткәннән соң да әле кат-кат укыр. Ул чагында инде үскән, зурайган балаларына укытыр. Бу хат Хамматлар нәселенең илне фашистлардан саклап калганлыгын яңа буыннарга хәбәр итеп торыр; башка батырлар белән бергә, Гаяз Хамматов каберенә чәчәк салырлар.

Ә менә бу минутта Зәйни Моратов тапшырып киткән хат, учак көлендә сүнгән күмер кебек, Бануның соңгы өметен сүндереп ташлады.

## Унберенче башлам

### I

«Ижминвод» госпиталенең көннәр җылы, табигатьнең матур чагында гына эшләячәген Нурия Уразаева алдан ук белеп килде. Шулай да көне җитеп, көзге җилләр сары яфракларны җир өстеннән куып йөртә башлагач, терелгән соңгы авырулар, госпиталь персоналын кочаклап һәм рәхмәт сүзләрен әйтеп саубуллашкач, инде ияләнеп җиткән Иж тугайларыннан китеп бару шактый ук күңелсез булды.

Нуриягә сайлау өчен ике төрле мөмкинлек куелды: йә ул майор Рәхимов белән бергә Арча госпиталенә китә, яки язга тикле Пәнҗәрнең берәр авылында врач булып эшләп тора да, май башында янә үз урынына әйләнеп кайта.

Уразаева чишеп булмый торган авыр төен алдында торып калды. Арчага китеп барыр иде, анда гадәти госпиталь түгел, дошман гаскәрләреннән әсир итеп алынган тоткыннар госпитале; авылга барыр иде — кеше өстендә, мал-туар арасында ике баласы белән яшәү авырыксындыра.

Шулай да ул кышын берәр авылда эшләп торып, язын тагын «Ижминводка» кайтырга булды. Аның өчен иң яхшысы, әлбәттә, Зартугай булыр иде. Анда шактый ук зур медпункт бар. Анда — Мөхәммәтша каенагай, Фәтхениса җиңги, анда — Шәфика, авыру Зиннурҗан.

«Шәяхмәт Айдаровка әйтеп карарга кирәк. Бәлки ул безгә үзенең авторитеты белән Зартугайдан урын табып бирә алыр»,— дип фикер йөртте Нурия һәм шул хакта Мөхәммәтша каенагаена хат язып җибәрде.

Туган җанлыклы каенагай, Нуриядән хат алу белән, бер көн кичекмәстән, чарасына кереште. Нәкъ шул көннәрне Зартугайның участок врачын, яшь бер кызны, фронтка алганнар иде. Шул урынны ычкындырмаска кирәк. Кемдә торасы дип кайгырасы түгел, өй болын чаклы, алар анда нибарысы икәү — Фәтхениса да үзе.

Ләкин Шәяхмәт аны кочак җәеп каршыламады. Дөньяда алны-артны уйлап карау, замана җилләре белән исәпләшү дигән нәрсә дә бар. Адәм баласы, олыгайган саен, саграк эш итә, упкынга баштүбән ташланырга ашыкмый.

Үзен ничектер салкынрак кабул иткән Шәяхмәткә «туп-турыдан туп пашул» була торган Мөхәммәтша абзый, эшче кешегә хас усаллыгы белән кинәт бик хәтәр ябырылды:

— Син нәрсәдән куркасың? Ни өчен син үз шәүләңнән үзең дер калтырап торасың?! Партиядән чыгарылган дип исәпләнелгән Солтан хәзер якты дөньяда юк! Трудармиядә ил өчен җанын фида кылган Солтан гына бар. Киленебез ике ел буе хәрби госпитальләрдә яралылар дәвалый. Ә мин, җитмешкә җитеп килә торган карт, атлар дирбиясен гөл кебек итеп тотам. Әгәр син Нурияне Зартугайга урнаштыруны семьячылык дип карыйсың икән — напрасны! Ник дип әйткәндә, син аны эвакуация белән кайтса да, урнаштырмый хәлең булмасые. Инде килеп, күңелдәгесен әйттереп бетерәсең килә икән, әйтәм, хәтерең калыр дип тормыйм: теге заманнарда сиңа Шаукымлы Шәяхмәт дип юкка кушамат такканнар. Шикләнүчән Шәяхмәт дип әйтәселәре калган. Беләсеңме, иптәш партионный секретарь, жир йөзендә йөз ел куян йөрәкле булып яшәгәнче, бер ел арслан йөрәкле булып яшәвең әйбәтрәк.

Шәяхмәт бусарынып чыкты. Фронт мәшәкате, урман кистерү, задание икмәген тапшыртып бетерү, сугышчыларга җылы киемнәр әзерләү хәстәре белән мие дүнгән секретарьның какшаган нервылары кинәт биреште — озынча какча битенә кызыл таплар бәреп чыкты, иреннәре калтыранды. Монысы да бит аның Айдарлар нәселеннән иде, гаепсезгә гаеп итүне күтәрә алмый иде бу нәсел.

Каршысында юл кожаныннан, күн итектән һәм күн картуздан басып торган чал сакаллы абзыйсына яннан кырын күз салгалап, телефон «колагын» борырга тотынды. «Кызыл Зартугай» председателенә шалтыратты — өйдә юк, колхозчыларны Ужил урманына озатырга киткән; авыл советына шалтыратты — Мәрдән Мурзинга, анысы күршетирә авылларда җылы кием җыеп йөри; инде бердәнбер юл — партоешма секретаре Каһармановны эзләтеп таптыру иде, ләкин аңа таянуны ул аеруча уңайсыз бер нәрсә дип карый, чөнки Нуриянең әтисе Габбас мулланы раскулачивать итәргә беренче булып килгән кеше ул; ничек дип карый бит әле ул синең киңәшеңне? Өстән басым ясау дип, Габбас мулла кызын җайлы урынга урнаштыру дип бәяләсә? Бәхете — Каһарманов та өйдә түгел, егерме бишенче елгыларны Татвоенкоматка илтә киткән булып чыкты.

Тирләп киткән маңгаен кулъяулыгы белән сөртеп, аның алдында әле һаман усал судья булып басып торган Мөхәммәтша абзыйга төбәлде: күрдеңме, янәсе, дөнья син дигәнчә генә түгел, дөнья үз җае белән бара, бу сиңа сугыш заманы.

Ниһаять, ул саргылт төк баскан ияген учлап утыра торгач, Пәнжәрнең сәламәтлек саклау бүлегенә шалтыратырга булды:

— Иптәш Харитонов, берәр авылга участок врачы кирәк түгелме?

— Зартугайга дип әйт, Зартугайга,— дип, куллары белән ишарәләр ясый башлады хәйләсез Мөхәммәтша абзый.

Райком секретаре аңа әйләнеп тә карамады.

— Кайда? Кайда? Аһ, Зартугайдамыни? Яхшы, иптәш Харитонов. Нәрсә? Минем кандидатура? «Ижминвод» госпиталеннән вакытлыча авылда эшләп торырдай белгеч бар. Кулдан ычкындырмаска иде. Квартир ягымы? Анысын колхоз карар. Уразаева. Так точно — медицина фәннәре кандидаты. Әлбәттә. Бик дөрес әйтәсез, башка чакта төшкә дә керә торган түгел.

Менә шулай килеп чыкты эшләр. Нуриянең язмышы тагын башка борылыш алды. Мөхәммәтша абзый аны ике баласы һәм төенчек-чемоданнары белән «Ижминвод»тан атка төяп алып кайтты. Җылы кулдан Фәтхенисасына тапшырды.

— Менә, энисе, килендәшең. Савыт-сабалары, бала-чагалары белән. Барыбыз бергә рәхәтләнеп бер чүкердәшеп кыш чыгыйк әле. Безгә генә гомер буе туганнардан аерым яшәргә димәгән!

Сугыш заманы Нурияне ваемчан булырга, берьюлы бернichә эшне эшләп куярга өйрәткән иде. Ул, Казанга барып, иң әүвәл үзенә кирәкле эш кораллары алып кайтты, остазы Майскийны да күрде.

Александр Николаевич салкын һәм буш кабинетында күзге пальтодан бөкшәеп утыра иде. Нуриянең кулын үз кулыннан җибәрмичә, аның чыраена, яктырып-чаткыланып торган күзләренә карады, шәкертенең тәмам сәламәтләнеп җиткән булуына ышангач, үгет-нәсихәтен әйтте: бүтән чирләмәскә, аяктан егылганчы чапмаска, китаплар укуны, чит тел өйрәнүне онытмаска, тагын әллә нәрсәләр, тагын әллә нәрсәләр...

Нурия борчыла башлады. Майский Солтанның үлемен ишеткәнме — юкмы? Ишетмәгән булса, аны әйтеп, кайгыга салыргамы? Бер генә мизгел икеләнеп алгач, шулай да әйтүне кирәк тапты.

Профессор аһ итте. Үзе тәрбияләп үстергән галимәнең кайгысына ихтирам йөзеннән аяк өсте басты, башын иеп, байтак вакыт сүзсез торды.

Аннары ул каударлана башлады. Ничә еллар саклап торган запас инструментларын да, әҗәл даруына дип саклаган даруларын да биреп җибәрде. Нурия аңа үзе кулдан бәйләгән калын һәм бик йомшак йон свитер бүләк итте. Картлач тагын каушады, тагын каударланды, бүләккә каршы бүләк эзләп тинтерәп бетте...

Йорт кирәк-яракларын да онытырга ярамый иде. Мөхәммәтша каенагайларының самавыры тузган, ә Зәйтүнә-мөгаллимәнең ак самавыры тик тора; артык яткан кофтадыр, күлмәктер ише нәрсәләрне дә алырга кирәк — балаларга да, Шәфикага да ярап куяр. Тегү машинасын да аласы булыр. Машина машина инде ул — сине ачлык-ялангачлыктан коткара ала.

Янында бернинди ярдәмчесе булмаса да, шул әйберләрне поезд белән алып кайтып җиткерә алды Нурия. Хәер, «җиткерә алды» дип әйтү генә ансат. Зартугайга түгел, Әгерже станцасына хәтле генә алып кайтып җиткерә алды. Аннан көчкә иншалла белән олау тапты. Кич кырын, бар булганын ат арбасына салып, кайтырга чыктылар. Октябрь башлары иде инде бу. Көн җилләп тора, кара-кучкыл авыр болытлар түбәннән генә агылалар; ачык кырга чыгу белән җил көчәйде, әллә кар булмаганга, ул шундый үзәкләргә үтеп исә, Казаннан алып чыккан одеалны төенчектән чишеп алып, бөркәнеп утырырга туры килде. Бер мәртәбә озаклап авырган Нурия үпкәсенә салкын тидерүдән, балаларын бөтенләй ятим калдырудан бик курка иде.

## II

Зартугай медпунктында врач Уразаева килгәнче фельдшер хезмәтен бик тә каты бәгырьле, аягы аксак булу сәбәпле сугышка китми калган

Миртимер Курамшин башкарган. Председательгә ярашу өчен ул авыруларның хәленә керми, урман кисәселәре килмәгәнгә, теләсә нинди чир уйлап табалар дип, хатын-кызлар өстеннән гел әләкләп торган. Көнетөне кырда, Пәнҗәр юлларында, урман кисүдә азап чиккән солдаткаларның ул тәмам гайрәтен чигереп бетергән.

— Үлсәк үләрбез, әммәдәки ул кара йөрәккә, имансыз кавемгә бармабыз,— дигәннәр Зартугай хатын-кызлары.

Нурия, килеп урнашу белән, эшләүнең авыр булачагын аңлап алды. Бердән, сугыш вакыты булу сәбәпле, организмга кирәкле азык җитми, икенчедән, татар авылларында гомер буе камыр ризыгы ашаганга, халыкның байтак өлеше медпунктка эч авыртудан зарланып киләләр иде.

Председатель Миңнуллага бик озак аңлатып, врач Уразаева Пәнҗәрдән егерме тонна кәбестә кайтартты. Аны ничек итеп тозларга кирәклеген өйрәтте, үз кулы белән эшләп күрсәтте.

Врачлык эшен өр-яңа ысул белән башлау Уразаевага булган игътибарны арттырды.

Ашказаннары тәмам эштән чыкканнарга, гастриттан интеккәннәргә тиешле даруларын язып бирде, кайберләрен Пәнҗәр больницасына илттерде. Язвадан интеккән өч хатынны еракка китеп урман кисүдән, ягъни коры-сары ашап йөрүдән коткарып калды.

Ошамады болар Миңнуллага. Аңардан бит кем чирле, кем сәламәт дип сорамыйлар. Урман сорыйлар, азык-төлек сорыйлар. Сугыш чорында ашказаны бозылмаган кем генә бар икән? Аларның һәркайсысын урман кисүдән бушата башласаң, кем бара урман заготовкасына? Кем китә Илләткә?

Врач Уразаева беренче көннән председатель Батыршинның бавырына таш булып утырды. Әмма Уразаеваның аңарда эше юк, ул врач, ул авыруны дәваларга, хәлен җиңеләйтергә тиеш. Сугыш чорының киң таралган тагын бер чире — балаларны баскан корчаңгы белән дә көрәшергә кирәк иде әле. Курамшин корчаңгыны бетерү өчен бармак та селкетмәгән, әниләре исә борынгыдан килә торган «халык медицинасын» кулланганнар — балаларының бармак араларына казан төбе корымы сөрткәннәр.

Барлык аналарны, әби-сәбиләрне, үсмерләрне колхоз клубына җыеп аңлаткач, корчаңгыга каршы кирәкле даруларны табып, бала-чаганы ике көн эчендә медпункт аша үткәргәч, яңа килгән «дуктырның» дәрәҗәсе бермә-бер артты.

Уразаеваның абруй артты. Курамшинныкы җимерелде.

Әгәр Уразаева амбарчы Нисага якты йөз күрсәтмәсә, аны урман кисү кебек эшләрдән коткарып калмаса, фельдшерның якты көннәре караңгыга әйләнәчәк, ул чагында аның Бадулларга, Нисаларга кирәге калмаячак.

— Бүрене бүректә чакта буарга кирәк,— диде Миртимер.— Йоклап ятма, Нисакаем, бар, кылын тарт, теләсә нинди хакка сатып ал «яңа себеркене».

Амбарчы Ниса — Бүре Бадулның олы кызы — ашлык амбарына сугышның беренче елында ук оялап алган иде. Ул эшен шул хәтле дә оста алып бара, үзе урлый, үзе юллый иде — бәйләнеп тә карадылар, ничәмә-ничә мәртәбә ревизия дә ясаттылар, өстеннән берни дә чыкмый.

Бүре Бадулның унбишләп умартасы бар. Өстәвенә ул — колхоз умарталыгында инде ничә еллар баш умартачы. Балның ачысы да, төчесе дә өзелми Бадуллар табынынннан. Ә байлык кешегә дәрәҗәсен аңларлык көч бирә, тавышны бөердән чыгарып сөйләттерә. Авыл кибетенә аракы-сырец кайтса, башкалар аны бер чирек ала, Бадул берәр пот сыешлы өч шешә белән алып куя. Кирәге чыгар. Кемнәрне екмаган хәмер, кемнәрне юашландырмаган.

Гыйбадулла картның ишле гаиләсеннән олы улы Тәхәви генә, аңы-

моны абайлап өлгергәнче, ут авызына барып керде. Керде дә, һәлак тә булды. Җиһангиры интендантлык хезмәтендә. Шириязданына унҗиде, Мифтахына унбиш, Мәхмүзәсенә унбер, Харисына тугыз яшь. Булдыклы хатын, Бадулның Җамалы елның елында дип әйтерлек бер баланы тупырдатып таба да тора.

Бервакытны урман каравылчысы, бик әйбәт кәефләнеп алгач:

— Гыйбадулла абзый, ничек соң синең семьяң шулхәтле ишәйде әле? — дип беркатлыланып сорау биргән иде, Гыйбадулла абзаң кеткет көлеп кенә куйды:

— Үзем дә аптыраган, иптәш кем... Катынның күлмәк итәгенә генә кагылып китәм — шалт бер бала!

Әнә шул «итәккә кагылганнан гына» туган балалар шундый тере, булдыклы, эш яратучан — язга чыгу белән, Бояр урманыннан каен себеркесе, юкә кайрысы ташый башлыйлар; чокыр-чакырлардагы, таллык араларындагы печәнне чалгы белән чабып, урак белән урып, кул белән йолкып өйгә ташыйлар, киптерәләр, печәнлеккә өя бaралар. Каен җиләге пештеме, чикләвек өлгердеме — Бадулныкылар тагын урманда.

Балта эшенә кулы ята торган Бадул малайларның һәркайсына кул арбасы ясап бирде. Кышкылыкка бәләкәй чана әмәлләде. Малайлар бәләкәй арба белән болын ягыннан печән, урман ягыннан коры ботак ташыйлар; әбәд чиләге белән карлыган, шомырт, кура җиләге алып кайтып эвакуация маржаларыннан кием-салым юнәтәләр. Күңел көр малайларның, берсеннән-берсе уздырып, ярышып эшлиләр.

Сугышның беренче елында ук Бадулныкыларның даны Зартугайга гына түгел, тирә-күрше авылларга да таралды. Яши белеп яшәүдә аларны уздырган беркем юк.

Бадулныкылар уйлап табарга да оста булып чыкты. Ике яшьлек үгез асрап, аны тәртә арасына керттеләр. Көне-төне урман ташыйлар. Үзләренә генә түгел, күршеләргә дә. Салагышка да илтеп саталар. Үгезнең файдасы тимәгән җир юк. Печән өстендә урманнан йөгейөге белән алып кайта башладылар печәнне. Шириyздан чаба, Мифтах чаба, унбер яшьлек Мәхмүзә дә чаба, тугыз яшьлек Харис тырма белән җыя һәм апасын, авыз ерып котыртып тора:

— Чап, әйдә, чап! Дәртең сүрелсен бераз, авыгың басылсын!

Каян ишеткән диген имансыз малай «дәрт» дигән, «авык» дигән сүзләрне?! Хәер, авыл малае шәһәр малаеннан иртәрәк өлгерә, алты яшендә инде ул дөньяның яратылышын, нәни балаларны нинди коедан алганнарны белә. Аккошлар алып килде дип тә, диңгез дулкыннары алып килде дип тә алдый алмыйсың аны.

Авыл малае ун яшендә ат җигәргә өйрәнә, унике яшендә сука сукалый; иртән әтисе җигә торган атны инешкә алып төшеп сугару, төннәрен урманда ат саклаулар — һәммәсе аның өстендә. Авыл малае — кече яшеннән әтисенең уң кулы.

Олыраклар, аулак өйгә йөри башлаган егет-җилән малайларга кызлар белән ничек танышырга, танышканнан соң нишләргә һәм әнә шул «нишләүнең» дөньядагы барлык рәхәтләрдән дә рәхәтрәк икәнен аңлатырга тырышалар. Озын сүзнең кыскасы — алда торган хыялларын малайларга сөйләп, күңел юаталар.

Шулай булгач, тугыз яшьлек Харисның апасын үртәп рәхәт табуы бер дә гаҗәп түгел. Аның бит инде ничәмә-ничә мәртәбә болынга төшкәне, олырак малайларның кырыкмыш тайга атланып шыбын тарттырганнарын күргәне булды.

Андый чакта солдат хатыннары, бикләнеп яткан тойгы-дәртләренә чыдаша алмыйча, малайларны ат өстеннән тартып төшерәләр дә, җыйнаулашып, көлешә-көлешә, мәкәшен карыйлар. Малай башта гарьләнә, елый, аннары үзе дә үсмер кызларның күкрәкләрен учы белән умырып тотып, кычкырып елатырлык дәрәҗәдә әрсезләнә.

Абыйлары Шириyздан, Мифтах белән бергәләп, Харис кичке уен-

нарга чыга; Хәнифә түтинең Мәхмүте белән бергә, гармун күтәреп йөри; тик шунысы күңелсез — Харисны кызлар үртиләр генә, ә Мәхмүтне «наныем, үскәнем, йәле, өздереп җибәр әле гармуныңны!»— дип кочаклап, үбеп, җанына тиеп бетәләр. Их, Харис гармунны Мәхмүт төсле уйный белсәме?! И-ии җүләр, белер иде ул кадерен, атаманлык итеп карар иде ул! Ә хәзер аңа — тьфү! — кемнең кемне яратканын, кемнең кемне яратмаганын күзәтеп, әрсез малайлар белән симәнке ярып, аулак өйдән куып чыгарсалар, шул йортның түбәсенә таш атып йөрергә генә кала.

Аулак өйләрнең түбәсенә таш ата-ата, кызларны үрти-үрти, егетләрдән кыйнала-кыйнала, кеше була авыл малае.

Озакламый Харис та кеше булачак. Ул да яңа кием, кич чыгарлык яңа ботинка, кара кепка, ак күлмәк һәм кара чалбар таләп итәчәк әтиләреннән. Яшел түбәле, аркылы-торкылы кызыл тасма үткәрелгән түгәрәк бүрек, мех якалы пальто киеп җибәрсәң, сарык йонынннан бәйләгән ап-ак шарфны җилкә аркылы салсаң — кулга гармун тотарга, авызга папирос кабарга гына кала.

Әнә нәрсәләр белән хыяллана авыл малае.

Әйе, Бадулныкылар сугыш вакытында ачлыкның, ялангачлыкның, салкын өйләрдә калтырап утыруның нәрсә икәнен дә белмәделәр. Дөньяның артына тибеп, үзләренә кирәген умырып алып, районнан килгән түрә-караның авыш ягына салам кыстырып, салам сыймаган җирдә, мичкәдән бал коеп, күкрәп яшәделәр.

Бу аларны күтәрде. Бу аларның Нисаларына колхоз амбарында үз амбарындагы кебек йөрергә юл ачты.

Зартугай хатыннары сугыш башыннан бирле урман кисәргә дүртәр-бишәр мәртәбә барып кайттылар инде, глубинкадан бәләкәй чана белән симәнә ашлыгы ташыдылар. Нисаның андый эшләрне уена да керткәне юк. Ни өчен дисәң — аның сакчысы, аны урман кисүдән, симәнә ашлыгы ташудан йолып кала торган Курамшины бар.

Менә хәзер Зартугай медпунктына мөдир булып Уразаева килде. Каты себерә диләр яңа себеркене. Ләкин Бадулныкыларны паникага төшерү ансат эш түгел. Җае табылыр, бу дөньяга берәр төрле кармакка капмаган балык юк. Чуртан булып чуртан каба кармакка!

Урман кисәр өчен Мари якларына бригадалар туплый башлагач, фронттан аягын өздереп кайткан агач аяк Гайрәтулла низаг чыгарды. Бик сабыр, бозау кебек юаш булганга, аңардан андый хәлне көтмәгәннәр иде. Дөресен генә әйткәндә, халык моңа бик гаҗәпсенде, Гайрәтулланың исеме ул көннәрдә телдән төшмәде.

Аның беркайчан да җыелыш-мазарга килгәне юк иде. Колхоз идарәсенә дә ул елына бер генә мәртәбә, анда да килми калырга мөмкин булмаган очракта гына сугыла иде.

Күрәчәк күмер ашатыр ди — бу юлы килде. Урман кисәргә китүчеләрне клубка җыеп, эш тәртибен әйтә башлауга, агач аягын шакылдатып килеп керде. Клубтагылар, башларын борып, Гайрәтуллага карадылар. Кемдер «пырх» итеп көлеп җибәрде. Пәрәмәч! Гайрәтулла килгән түгелме? Җүнлелеккә булсын! Сугышлар бетәргә язсын!

Әмма дә ләкин авыз еру, елмаю, төртмәле сүз әйтү шуның белән бетте. Гайрәтулла арттагы эскәмияләрнең берсенә чүмәшеп, йокымсырап утыра башлады. Инде аны онытып та баралар иде, инде әйтәсе сүз әйтелеп, биреләсе боерыклар бирелеп, таралышырга ук торалар иде, тагын агач аякның шакылдатып идәнгә басканы ишетелде. Баксаң-күрсәң, агач аяк Гайрәтулла, басынкы бозау, Батыршинның үгетнәсихәтләрен шыпырт кына тыңлап, маегына урап барган икән.

— Персидәтел Миңнулла! — дип кычкырып җибәрде ул.— халыкны таратырга ашыкмый тор әле.

— Тагын нәрсә булды инде? — дип, Миңнулла канәгатьсез тавыш белән мыгырданып куйды.— Соңга калдың, Гайрәтулла абзый, тыңлап утырырга кирәк иде. Мәсьәлә ачык, таралабыз.

— Я-а-аак, мәсьәлә ачык түгел, мәсьәлә ябык. Укы списокны, яңа баштан укы,— дип, карлыккан тавыш белән сөрән салды Гайрәтулла.

Җыелышта буталыш китте.

— Укы. Рас кеше тели икән, укы! — дип кычкырдылар төрле яктан.

— Укы, кәнишне! Фронтовикларны санга сугарга вакыт!

— Ярар, укы,— диде Миңнулла янына утырган авыл советы башлыгы Мәрдән Мурзин.

Миңнулла, ризасызлыктан кызарып-бүртенеп, урман кисәргә китәргә тиешле утыз биш солдатканың исемлеген, һәр исемгә тукталып, ашыкмыйча гына укып чыгарга мәҗбүр булды. Ул укып бетерүгә, Гайрәтулла янә дә аяк өсте калыкты, янә дә бөтен клубка оран салды:

— Персидәтел Миңнулла! Партийный түрә Каһарманов Иматетдин, и шулай ук силсәвит башлыгы Мурзин Мәрдәнша! Әйтегез әле, кешеме сез, түгелме? Нәрсә карыйсыз сез, тукмак башлар? Амбарны талыйлар бит. Бүре Бадулның ачкүз Нисалары талый бит амбарны. Ни өчен минем бүсер зәхмәтле Тәгъзимәм урман кисәргә барырга тиеш тә, Бүре Гыйбадулласының амбар талап симергән бүре авызлы Нисасы бармаска тиеш? Нисмиеш правы! Барсын! Мин әйтәм, Бадул бүксәсе дә барсын! Әйтегез, катыннар, кайда монда гаделлек? Их, сез, түрәләр, Бүре тәренең бер чүмеч әче балына сатылган малакасусный түрәләр! Мин сезнең берегездән дә курыкмыйм и куркачак та түгел! Мин сезнең маңгаегызга винтовка түтәсе белән бәргән төсле итеп әйтәм, әгәренки сез настаяшный камунистлар икән, сатылырга тиеш түгел. Нисмиеш правы!

Менә шулай диде бозау кебек басынкы Гайрәтулла.

Һәм шушы хәлдән соң колхоз җыелышына беркайчан да аяк басмады. Иллә мәгәр аның бөтен клубны яңгыратып кызмача баштан әйткән сүзләре Зартугайлар өчен канатлы сүз булып калды. Тукмак баш! Хатын-кызлар аны үз җайларына «кабак баш» дип әйттеләр. Чөнки «тукмак баш» дигәне нинди-дер кирәкмәгән бер сүзне искә төшерә иде.

### III

Авылны дер селкетеп яшәгән Бадулныкылар фронтовик Гайрәтуллага куеннан йодрык төйнәп куйдылар. Заманында тегермәнче Чишмәбайны төнәтә алгангадыр, алар Гайрәтулланы да акылга утыртабыз, дип ышандылар. Моның өчен Нисаның урман кисәргә яраксыз булуы турында врачтан белешмә генә алырга кирәк иде.

Ниса январьның чатлама суык бер көнендә, Гайрәтулла оран салганнан соң озак та тормастан, Зартугайның медпунктына килеп керде. Өстендә — ямау өстенә ямау салган фуфайка, аягында — ирләр сөйри торган олтанлы зур итек, башына гына күпереп торган ырымбур шәле бөркәнгән иде. Кулына ул хуҗалык сумкасы тоткан, чырае ачы миләш капкан төсле чытык, бәбәкләре генә, мин барысын да булдыра алам дигән төсле, тишеп, әрсезләнеп карый иде.

Врач Уразаева аны, башка авыруларны ничек кабул итсә, шулай тыныч кына кабул итте.

Врач Уразаеваның уң кулы булырга тиешле кеше — фельдшер Курамшин да шушында иде.

Ниса карасына кабынып керде, әмма көн-ай кебек җәелеп, төче телләнеп сүз башлады:

— Авылыбызның иң чибәр кызы Гөл-Нурия бик зур укымышлы булып кайткан дигәннәрие. Сез буласызмыни инде ул? Сөбханалла, бик күркәм, бик затлы кеше икәнсез. Күрешик әле,— дип ике кулын сузды. Каты иде кулы — Нурия моны сизми кала алмады. Ә Ниса, фельдшер Курамшин ягына әйләнеп тә бакмастан, шундук тагын үз

сүзенә кереште: — Халык сездән канәгать, Нурия апа. Әнинең бик күптәннән адарынып куйган бер тәпән балы барые, Габбас абзый исән чагында тәки бирә алмадым шуны, бар әле, кызым, илтеп кайт әле Нурия апаңа, диде, амәнәт җан саклар, диде, алып куегыз шуны, Нурия апа. Еллар авыр, чәйгә салып эчим дисәң, ни шикәре, ни кәнфите юк. Бездән булсын яхшылык. Кыш буена җитәр бу сезгә. Нәкъ ун кило бал монда, үзем үлчәдем...

Нисаның иреннәре ачылды, бүлмәне балкытып, алдагы ике алтын теше күренеп китте.

Врач Уразаева җавап бирергә ашыкмады.

Аның күңеленнән яшен тизлегендә менә нинди уй узды:

«Алай икән, Курамшин заманында эшләгән этлекләрегезне дәвам итәргә җыенасыз икән. Миңа Курамшин алдында ришвәт-взятка биреп, аннары бик әйбәтләп таш капчыкка тыкмакчы буласыз икән. Юк, Ниса-күсе, мин сезнең андый капкынга кабарга үсмер кыз түгел. Шөкер, дөньяның төрлесен күрдем мин...»

Шулай да чыраена караңгылык чыгармады врач Уразаева. Табигать мул итеп биргән артистлык сәләтен эшкә җикте:

— Туктагыз әле, сеңлем. Без бит әле, гөлкәем, сезнең белән танышмадык та түгелме? Мин соң белмәгән-күрмәгән кешедән ничек итеп күчтәнәч алыйм, ди. Кем сез, каян сез?

— И дуктыр, нишләп белмәгән кеше булыйм ди инде мин? Гыйбадулла кызы Ниса лабаса мин! Әнә Курамшин абый мине килеп эшли башлау белән танып алды.

Курамшин, инде иллеләрне узып киткән, табактай зур, җәенке бите бурлаттай янып торган ир, титаклап урыныннан торды, Ниса ягына күз атып алды, кыюрак бул, янәсе.

— Фамилиягез? — диде врач Уразаева.

— Әти ягыннан дисәгез — Гыйбадуллина, аерылган ирем ягыннан — Исрафилова.

Әле һаман кулында хуҗалык сумкасын тотып торган Нисага ул:

— Кайсысын языйк? — диде.

Башка чакта кирәкле кешесе белән, ягъни Миртимер Курамшин белән бик тиз уртак тел таба алган амбарчы хатын бүген эшләрнең, майланмаган арба кебек, бик авырдан баруына кәефе китеп, тирләп чыкты; кулына тоткан сумкасын идәнгә куеп, мамык шәлен чишеп җибәрде. Җубалгы чәче бүселеп чыкты, телгә бик оста булса да, чәчен тарамаган иде Ниса; күрәсең, ансат кына үтеп китәр, белешмәне бал белән баллайдырып, бик тиз алырмын дип исәп тоткан, ахрысы.

— Утырыгыз, Гыйбадуллина-Исрафилова,— диде медпункт мөдире.

Ниса утырды. Фуфайкасының төймәләрен ычкындырды.

— Фу-уу, эссе сездә.

— Эссерәк шул,— диде врач Уразаева, гафу үтенгән сыман.— Ләкин суык булса да читен. Көне буе авыруларны суыкта тотып булмый. Чишенегез. Менә элгечкә элеп куегыз фуфайкагызны. Китерегез...

— Юк, юк, рәхмәт. Кул-аягым исән минем, үзем дә элә алам — дип Ниса элгечкә үрелде. Инде кырыкны узып киткән бу хатынның әле һаман буй-сыны матур, күкрәкләре дә тулышып торалар, өстенә кигән яшел йон күлмәге дә үзенә ятышлы иде.

«Йа хода! Ничекләр кимсетә кеше үзен! Нигә кирәк аңа кырык ямаулы фуфайка? Маскировка өченме?» — дип уйлап алырга өлгерде врач Уразаева. Ул пациентын өстәл янына, каршысына утыртып, төпченеп сораша башлады:

— Кай төшегез авырта? Нәрсәдән зарланасыз?

Врачлар тарафыннан бирелә торган гап-гади сораулар иде бу. Әмма Ниса Гыйбадуллина-Исрафилова кып-кызыл булып кызарды, комач булып кабынган табак битенең уртасына ук посып утырган почык борынына кагылып алды:

— Ир-ат тыңлап торганда, сөйләргә уңайсызланам мин. Курамшин абый чыгып торсын,— диде Ниса, җилкәләрен уйнатып.

— Гафу итегез, Миртимер иптәш, авыруның теләген үтәми булмый. Сезгә минем дә бер үтенечем бар: чыккан чагында әнә шул сумканы да баскыч төбенә куя китегез әле, пожалысты,— диде медпункт мөдире.

— Аны бит миңа түгел, сезгә китерделәр.

— Беләм. Ләкин минем бал ашаганым юк. Ашказанымның кислотасы аз. Бал кислотаны арттырмый, киметә генә. Бал миңа зарарлы!

— Ә май? — диде Ниса ашыгып.

— Май да ярамый. Ит тә. Борчылмагыз минем өчен, колхоз биргән паек та җитә минем гаиләмә. Миртимер, сумканы баскыч төбенә чыгарып куярга оныта күрмәгез. Зинһар дип әйтәм. Ниса ханым аны кайткан чакта алып китәр.

— Кагылма! Якын да килмә! Берәрсе алып китсә... базарда балның килосы йөз таңкә тора,— дип, ихтыярсыздан, кайнарлык белән ычкындырып ташлады амбарчы хатын.

— Авылдашларыгыз хакында алай начар уйлавыгыз ошамый миңа, Ниса ханым, ошамый,— диде врач Уразаева, аннары тавышын күтәрә төшеп әйтте: — Курамшин! Йә сез сумканы хәзер үк урам якка чыгарып куясыз, йә мин сезнең икегезне дә куып чыгарам!

Үз гомерендә хатын-кызның боерык рәвешендә әйткәнен ишетмәгән Курамшин каушады, бер-ике мәртәбә баскан урынында титаклап алгач, бәхәсләшеп тормастан, сумканы күтәреп, чыгып китү ягын карады.

— Йәгез, тыңлыйм,— диде врач Уразаева, фельдшер чыгып киткәч.

Ниса кулларын угалап утырды, иртәдән бирле уйлап йөргән авыруын тәфсилләп сөйли башлады:

— Чирем минем бик сәер, дуктыр. Көзән җыера мине. Бигрәк тә иртәнге якта, аннары кичләрен. Көзән дигән каһәр суккан чир зәхмәте аяк башларыннан тотына, ботларым буйлап үрмәләп, корсагыма менә, корсагым белән ботым тирәсендә бик озак азаплап йөргәч, аркама үрмәли, күкрәгемә кагыла, аннары муеныма менеп, буа башлый. Соңга табарак битемә, ирennәремә, борыныма килә, азактан баш миемә керә дә, мунча сыерчыгы кебек, чыр-чыр чырылдап тора.

— Ничә ел җыера инде сезне көзән?

Ниса көтелмәгән сораудан аптырабрак калды.

— Ничә ел дип?.. Бәлки, мин аны баштарак... ни... белми йөргәнмендер... Сизә башлавым... сугыш чыкканнан бирле...— дип, тотлыга-тотлыга сөйли башлады.

Хәл җыйгач, кыюлана төште.

— Бик авыр хәлләрдә калдыра ул мине, дуктыр. Кеше-кара барында егылып киткәннәрем дә бар. Итәкләрем дә ачылып китә, күлмәк изүемне ертам — сулыш җитми...

— Көзән җыеру эсседән буламы, суыктанмы?

— Эсседән... юк, юк, суыктан.

— Төгәлрәк әйтегез — эсседәнме, суыктанмы?

— Суыктан,— диде Ниса, урман кискән чагында суык булуын абайлап өлгерде.— Суыктан була минем көзән җыеруым.

— Гафу итегез, Ниса ханым. Сез амбарда көннең көн буе суыкта ничек эшли аласыз соң? Анда бит ягылмый торгандыр?

— Ягылмый шул,— диде Ниса, ялганы тотылганга кәефе китеп.— Сез мине азапламагыз инде, Нурия апа, урман эшенә ярамый дип әйтеп, ыспырафкы язып бирегез дә — эше беткән. Мин бит, үзегезгә мәгълүм, амбар тулы икмәкне теләсә кемгә ышанып калдыра алмыйм. Ачкычларны биреп. Халык усаллашты, берсен берсе күрәлми. Бер кило он өчен бугаз чәйнәргә әзер тора. Тамак — тәмуг дип, юкка гына әйтмәгәннәрдер инде аны.

— Дөрес әйтәсез. Ашау яклары кыен. Ләкин мин сезгә белешмә бирә алмыйм. Чөнки сезнең бер авыруыгыз да юк, симулянтлык зәхмәтен искә алмаганда. Янып торган таза кеше сез, Ниса ханым. Ышанмасагыз, көзгедән карагыз, чыраегыз тук, сезнең ише йомры бичәләрне руслар, «кровь с молоком»,— диләр. Әйе, хет упкәләгез, хет үпкәләмәгез, мин сезгә белешмә бирә алмыйм. Әмма сез әйтәсез, амбарны мин чит-ят кеше кулына калдыра алмыйм, мин материальный җаваплы дисез. Мин моның белән килешәм. Сезне урман кисәргә җибәрү-җибәрмәү мәсьәләсен ни җитте кеше хәл итә алмый. Колхоз идарәсе үзе хәл итсен,— диде.

Ниса Гыйбадуллина-Исрафилова бөтенләй югалып калды. Бердән, аңа белешмә эләкмәде. Икенчедән, ул яңа килгән, үзе җүнләп белмәгән кешегә бал сыламакчы булып хурлыкка калды. Өченчедән, ул төнозын уйлап яткан «чырлый торган» чир-зәхмәтне медпункт мөдире ялганга чыгарды. Әле монысына да түзәргә булыр иде, ул аны ихтирам итеп сөйләште, кешечә ягымлы мөгамәләдә булды, урманга бармый кала алуның чын дөрес юлын да әйтеп бирде.

— Рәхмәт сезгә, Нурия апа, күземне ачтыгыз,— диде Ниса ырымбур кәҗәләре мамыгыннан бәйләнгән, күпереп торган йомшак шәлен башына япты.— Барам кәнсәләргә! Әйтәм ныгытып! Өстемдә шул чаклы ашлык була торып, аларның мине Иллэт урманына җибәрергә хакы юк.

Ул, ник килгәненә үкенгән кеше төсле, шыпырт кына чыгып китте. Ләкин бу әле үкенү түгел, бу әле тактиканы гына үзгәртү, «дуктыр»ның күзен буу гына иде.

Бүре Бадул кызы хурлыкка калуын берәүгә дә әйтмәде, япа-ялгызы амбарында бикләнеп елады да, кышкы буранлы төндә Миртимер Курамшинны өенә чакырып, башта аны бик һәйбәтләп ачы бал белән, каклаган каз ите белән сыйлады: булып узган күңелсезлекләренең күңелдәге юшкынын юып ташларга теләгәндәй, төне буе аксак фельдшер белән типтерде, таң алдыннан тегенең кыска бармаклы кулына ябышып әйтте:

— Әгәр дә мәгәр шул мулла сөрхәнтәен Зартугайдан кудыра алмасаң, минем өемнең бусагасын оныт. Аңладыңмы? Синең ишеләр әнә трудармиядә чери. Ә син? Май кебек җылы өйдә утырасын. Башкаларның түшенә дә керми торган чибәр катын белән төн үткәрәсең. Аңладыңмы, җанкисәгем?

Аңладым,— дип мыгырданды Курамшин. Бу әрсез тол бичәнең тавышын бөердән чыгарып сөйләшүе аның җанына кагылган иде.

Ләкин ул сөекле сөяге кушкан этлекне эшләми дә кала алмый, юкса таш астыннан чыккан явыз хатын аның үзенә этлек эшләячәк. Бүренекеләр диләр аны! Сүзен аяк астына салып таптата торган нәсел түгел.

Курамшин бер атна чамасы врач Уразаевага нинди яла ягарга икәнен уйлап, баш ватып йөрде. Таба алмады. Аның саен Нисаның ачуы кабара, Миртимерне ул җылы куенында асравы белән табалый, тагын да сузып килсә, урыныннан кудырту белән яный, чөнки эвакуацияләнеп килүчеләр арасында аны алмаштырырлык кызлар бар, урын буш булмаганлыктан гына әле төрле эшләрдә эшләп йөриләр иде.

Врач Уразаеваның һәм партоешма секретаре Каһармановның таләбе буенча колхозда гомуми җыелыш җыйдылар, анда Зартугай кешеләренең сәламәтлеге хакында медпункт мөдире белдерү ясады. Булган хәлне генә сөйләп калмады Уразаева, нәрсәләр эшләргә кирәген дә күрсәтеп бирде. Ул, мәсәлән, Курамшин кебек әрсез адәмнәрнең җылы урынга оялауларын, халыкның сәламәтлеген кайгыртмауларын, үзләренең шәхси тормышларын гына кайгыртуларын ачыктан-ачык сөйләде. Әллә ничек менә шунда аның артистлык сәләте тагын өскә калкып чыкты. Ул колхозда кайберәүләрнең ничек итеп үзләренә чир уйлап

чыгаруларын ялган җибәрде. Чир-зәхмәтнең аяк бармакларыннан башлап, бот аша, корсак аша баш миенә тикле менеп җитүен, чымырдыйчымырдый менүен галәмәт тә мәзәк итеп, Нисаның сөйләү рәвешләрен китереп, нәкъ ул әйтә торган сүзләр белән сөйләде. Халык аны, комик артистны тыңлагандай, көлә-көлә, кул чаба-чаба тыңлады. Нурия симулянтның кем икәнен әйтмәсә дә, ярты зал моны төшенгән иде инде.

Шулай да халык арасыннан, төгәл исемен белергә теләп, кычкырып утыручылар да булды:

— Кем ул симулянт? Исемен әйт, дуктыр! Исемен әйт!

Врач Уразаева җитдиләнде. Чыраена ирләрчә нык тәвәккәллек чыкты.

— Хәзергә әйтми торам, иптәшләр. Шул хәл кабатланса, әйтермен. Минем сезгә зур үтенечем бар, зинһар дип әйтәм, медпункт хезмәткәрләрен юк-бар чир-зәхмәтләр уйлап чыгарып интектермәгез. Ялган белешмәләр сорап килмәгез. Мин моны ни өчен әйтәм? Безгә әле фронттагылардан үрнәк алырга кирәк. Сталинград ут эчендә. Гәзитләрне укып барсагыз, белә торгансыздыр, таш өстендә таш калмады бит анда. Сталинградта кем сугыша — барысы да герой. Сталинградка кем булыша — барысы да герой. Менә алгы рәттә унике-унөч яшьлек малайлар утыра. Пәнҗәр элеваторына алар көзге суык яңгырларда, кышкы бураннарда Сталинград олаулары илтәләр. Аларның берсенең дә, мине бу эштән коткарыгыз дип килгәннәре юк. Чир-зәхмәтләр дә уйлап чыгарганнары юк. Сталинград сугышчыларын да, аларга икмәк әзерләүче энекәшләрне дә халык онытмас.

Нурия боларны бик ихластан, күптән җанында җыелып йөргәнгә, кабынып китеп сөйләгән иде, ул сүзләр халыкка шулхәтле дә тәэсир итәр дип башына да китермәгән иде. Зал тып-тын калып тыңлады аны. Өлкәнрәк апалар арасында яулык чите белән күзләрен сөрткәләп утыручылар да табылды.

Аның сүзләреннән аерыча дулкынланган, ачу-гайрәтләре бугазларына менеп җиткән ике кеше бар иде. Миртимер һәм Ниса!

«Ничава, без сине дә герой ясарбыз. Ходай кушса, урам уртасына бала-чагаларың белән чыгарып ташларбыз! — дип зәһәрләнеп уйлады амбарчы Ниса.— Сине якларга инде хәерче Садыйк малае юк. Түрәләрнең түләме кечкенә, бәгырьләре каты».

Шул ук кичне ул янә дә Курамшинга ябырылды.

Урын өстендә бер кат эчке күлмәктән яткан килеш, булдыксыз фельдшерның чәчен йолкый-йолкый әйтте:

— Менә бу көнҗәлә чәч астында баш та булырга тиеш! Баш эчендә сыек кына булса да ми дә бардыр бит? Әй син һаман тиле-миле Майттыпыра шикелле йөрисең! Оят! Сине эт итеп сүгәләр, бөтен халык алдында мине рисвай итәләр. Ә син, аңгыра алабай, колагыңны шәлперәйтеп тыңлап утырасың. Бел аны, тагын бер генә көнгә сузасың икән, тагын бер генә мәртәбә мине шул салам сыйраклы мулла сөрхәнтәеннән мыскыл иттерәсең икән, кудыртам! Икегезне дә! Көлегезне күккә очырам! Районда минем сезне генә кудыртырлык танышларым бар. Матри, филшер, өшегән кишер, йә ул, йә мин. Ашык! Югыйсә, ышмуткаларыңны төяп, аксак аягыңны сөйрәп, башка авылга сыпырырга туры килмәгәе...

Шуннан да арыга сузарга ярамый иде Курамшинга, сузса — ахыры катастрофа булачак. Ул тагын өч көннән мәкерле планын корып бетерде һәм, врач Уразаеваны авыл хатыннарына яшерен аборт ясауда гаепләп, Пәнҗәргә, тиешле оешмаларга жалоба язып җибәрде.

«Кызыл Зартугай»га прокурор ярдәмчесе килеп төште. Үзе белән врач-гинеколог та алып килгән иде.

Авыл халкы, шомланып, ни буласын көтте.

Медпунктның ишеген эчтән бикләп, врач Уразаевадан сорау алдылар.

Врач-гинеколог — өстенә яшькелт төстәге пөхтә костюм, аягына җыйнак киез итек кигән, күксел күзләрендә ниндидер моң саклана торган яшь һәм сөйкемле хатын Мария Пушкарева — исәнләшү белән үк, Уразаевада өмет уятты. Аның каруы прокурор ярдәмчесе Әюповның — таушалган костюмлы, йолкыш кыяфәтле, сул кулын марля белән муенына аскан ир уртасы кешенең күңеленә нәрсәләр төяп килгәнлеге билгесез иде. Врач-психолог буларак, Нурия аның ябык йолкыш чыраендагы бер нәрсәгә игътибар итми кала алмады — күзләре бәләкәй, әмма елтырашып торалар, бер генә нәрсәне дә ычкындырмыйлар. Халык андый кешене «очлы күз» ди.

Пушкарева, прокурор ярдәмчесенең кушуы буенча, медпункт мөдире өстеннән язылган жалобаны укып чыкты. Чыраена ул бернинди усаллык та, хәлгә керү кебек юашлык та чыгармады. Аның үз-үзен тотышы, бөтен кыяфәте намуслы-гадел кеше икәнлеген, кайдадыр читтә, зур бер шәһәрдә белем алганлыгын, әдәп кагыйдәләренә ия булганлыгын әйтеп тора иде. Гадәттә, андый кешеләр белән уртак тел табу ансат була.

Ул жалоба кәгазен укып бетергәч, Әюпов энә очы төсле үткен, елтыравык күзләре белән медпункт мөдиренә төбәлде. Юристларга хас сынау-эксперимент идеме бу, хода белсен, ләкин аның ул усал карашы Нурияне каушата алмады. Күрәсең, коллегасы булган Пушкаревада ул үзенә кирәкле ныклы таяныч күрә иде ахрысы.

Сынау-тикшерү минутлары узгач, Уразаеваның аксыл чыраена аз гына кызыллык йөгерүен, әмма аның тамчы бөртек тә каушамавын күргәч, прокурор ярдәмчесе, вакытны сузмас өчен, медпункт мөдиренә сораулар бирә башлады:

— Врач Уразаева, сез биредә язылганнарны раслыйсызмы? Тылган алымнар белән, яшерен рәвештә хатыннарга аборт ясавыгыз хакында нәрсә әйтә аласыз?

Нурия аяк өсте торып басты. Менә шунда аның битенә шаулап кан йөгерде, чигә тамырлары сулкылдап суга башлады. Ул кан басымының бик кинәт күтәрелеп китүен аңлады, аңын җуймас борын әйтер сүзен әйтеп калырга ашыкты:

— Болар һәммәсе — ялган. Чеп-чи ялган! Уйдырма! Чакырыгыз солдаткаларны. Берәм-берәм сорап чыгыгыз. Әйтерләр. Әйтми калмаслар.

— Чакырырга туры килә,— диде прокурор ярдәмчесе битараф салкын тавыш белән. Әмма күзләре һаман очлы, һаман елтырый иде.

Шаһит итеп чакырылган беренче кеше — Гыйбадулла Ядкаровның олы улы Тәхәвинең тол калган хатыны, дүрт бала анасы, өстенә мамык сырма, башына ирләр бүреге, аягына олтанлы дәү киез итек кигән Мөслимә — башта сорауны аңламады; йокысызлыктан, дүрт баланы багып, эш эшләп алҗыганнан кызарып чепиләнгән күзләрен ачалак-йомалак китереп аптырап торды; аңлап алгач, зинадан бала төшерүне беренче нәүбәттә врач Уразаевага яла ягу дип түгел, үзенә — дүрт бала анасына, солдат хатынына яла ягу дип аңлады, теле тотлыкты, тез буыннарының хәле китте, гарьлегеннән акырып елап, бер сүз дә әйтмичә, ишеккә таба юнәлде.

Пушкарева кинәт каушады — йөзе көл кебек булды. Ул үзен бу минутларда ниндидер бик зур бер гаделсезлек, хәтта җинаять эшләгән кебек итеп тойды.

— Бәлки, кирәкмидер, иптәш Әюпов? Без бит солдаткаларны рәнҗетәбез,— диде ул әкрен генә.

Закон сакчысының җавабы коры һәм кискен булды:

— Без, Мария Степановна, сентиментальщина белән шөгыльләнергә килмәдек. Җитди задание үтәргә килдек. Дәвам итәбез,— диде.

Икенче хатынны чакырдылар.

Мәскәүдән 1941 елның көзендә үк эвакуацияләнеп килгән, үгез җигеп, авылның башка хатыннары белән Пәнҗәр элеваторына ашлык ташучы Евдокия Ивановна — кырык яшьләрендәге нык-усал холыклы,

үзенә беркайчан да тел-теш тидертми, кирәк икән ирләрчә сүгенеп тә җибәрә торган солдатка, колакчын бүректән, каеры туннан, кулына чыбыркы тотып килеп керде дә, ишек төбендә киез итекләрен бер-берсенә бәреп, карны койгач, туп-туры прокурор ярдәмчесенең каршысына килеп басты.

Ул инде монда ни буласын ишетеп кергән, нишләргә икәнен хәл иткән иде.

Прокурор ярдәмчесенең соравына җавап биреп тормады ул, чыбыркы сабын кулына чытырдатып кыскан хәлдә, үзе Әюповка ябырылды:

— Ник килдең син безгә? Тәртип урнаштырыргамы? Әллә фронтны туендыручыларны мыскыл итәргәме? Катыннардан көләргә килдеңме? Булмас! Барып чыкмас синең мәкерле планнарың! Барып чыкмас!

Әюпов, бәхетсезлегенәдер, аны закон сакчысына тел тидерүдә гаепли башлаган иде, Евдокия Ивановна чыбыркыны бүлмәдә мылтык аткан тавышлар чыгарып шартлатты да, күзен кан баскан сыердай үкереп, тегенең өстенә китте:

— Кемне куркытасың син, закон капчыгы?! Кемне? Фронттагы ирләре өчен өчәр смена эшләгән солдаткаларнымы? Нигә син моңарчы амбар талаучы күселәрне тикшермәдең? Ялган белешмәләр биреп, илне алдап яткан Курамшиннарны ник килеп тикшермәдең?! Алар синең авызыңны бал белән сылап куйдылармыни? Оятсыз! Бушбугаз! Без сиңа моны шулай гына калдырыр дип белдеңме?! — Ул, чыбыркысын баш өстенә күтәреп, прокурор ярдәмчесенә селтәнергә итте.

Эшләрнең зурга китүеннән курыккан Пушкарева, алар арасына кереп, эшне җайламакчы иде, тегесе аны бер кулы белән читкә генә селтәп атты да, ишекне аягы белән тибеп ачып, урамга кычкырды:

— Катыннар, нәрсә карап утырасыз йоклап? Безне мыскыл итәләр бит! Безнең намусыбызда тукыналар бит!

Нурия Уразаева калган ягын төштә кебек кенә хәтерли.

Төбенә кадәр ачып куелган ишектән, салкын буы белән аралашып, хатыннар кереп тулды, медпункттагы шкафларны, өстәлләрне аударып, алар отыры эчкәрәк тыгызландылар. Прокурор ярдәмчесе Әюпов — төсе көл кебек булган, күзләре тагын да ныграк елтырый башлаган Әюпов — өстәл өстенә менеп китәргә, ничек кирәк алай үзен тукмалудан саклап калырга мәҗбүр булды.

Солдаткалар, тамаклары карлыкканчы кычкырып, акырып-янап, күз яше белән елап аргач, ачык ишектән урамга ташып чыктылар; ярсулары кимемәгән иде әле — йөзләре ут кебек яна, рәнҗешләре бик зур иде. Гөнаһ шомлыгы түгел диген, нәкъ шул чагында, эшләрнең нәрсә белән беткәнен белергә теләп, урамның урта бер җиреннән, титаклый-титаклый, Курамшин килә иде.

Хатыннар, умарта күче төсле кара бер йомгак булып, аның өстенә киттеләр — урам уртасында, бала-чаганың күз алдында, үзләренә яла яккан фельдшерны гәүдәсен җыя алмаслык итеп кыйнап ташладылар.

## IV

Эшләр зурга китте.

Зартугайга Шәяхмәт Айдаров, прокурор, җаваплы урыннарда эшләгән тагын берничә кеше килеп төште.

Булган хәлләргә бәя бирергә кирәк иде.

Айдаров, партоешма җитәкчесе белән киңәшеп алгач, «Кызыл Зартугай»ның гомуми җыелышын җыюны кирәк дип тапты. Нияте — халыкны тынычландыру, тагын да зурракка җибәрмәү иде.

Җыелышны кичке җидегә билгеләделәр. Әмма бишләр тирәсендә үк инде клуб яны халык белән тулды. Председатель Миңнулла — төсе

качкан, ашыгудан бүрегенең алдын артка әйләндереп кигән Миңнулла — Айдаровка килеп әйтте: «Хәлләр яман, халык ярсына, хәзер үк башламасак, бер-бер хәлнең чыгуын көт тә тор», — диде.

Айдаровның бодай саламы төсле сары мыегы кыймылдашты, ул ачуын тешләре арасыннан кысып чыгарды:

— Болар бар да синнән, Батыршин. Синең мәгънәсезлегеңнән. Җыен каракны, гаделсезне куеныңа оялатудан! Колхозда тәртип урнаштыра белмәвеңнән! — диде. — Ки бүрегеңне рәтләп. Онытма, иртәгә фронтка китәргә гаризаң язылган булсын. Синең белән күп азапландык — җитәр!

Җыелышны вакытыннан алда башларга мәҗбүр булдылар.

Айдаров, ике-өч урында унлы лампа белән яктыртылган ярымкараңгы озын залны, тыгызланып тулган халыкны — күбесе ир-ат бүреге кигән хатыннарны — күздән кичергәч, борчылып сүз башлады:

— Иптәшләр, мәсьәлә бик житди. Кичә сезнең колхозда килеп чыккан гадәттән тыш хәлнең сәбәпләрен ачыкларга дип җыелдык. Кем беренче булып сүз ала?

— Нәрсәсен ачыклыйсың аның? Болай да билгеле! — дип кычкырды ачы тавыш. Хатын-кыз тавышы.

Аңа башкалары ялганып китте:

— Кирәкми булдыксыз җитәкчеләр!

— Солдаткаларны мыскыл итәсез!

— Не позволим!

— Әйттең сүз: карга карганың күзен чукымый!

— Туктагыз! Җәмәгать, җәмәгать!

Клубта шундый тавыш купты: ата — ананы, ана баланы аңламас хәлгә килде.

Ат дугасына тага торган зур бакыр кыңгырауны шалтырата-шалтырата арып беткәч, Каһарманов бугаз ярып кычкырды:

— Иптәшләр! Катыннар! Болай бит үзебезгә генә начар эшлибез. Күпме шауласак та файдасыз. Файдасыз, аңлыйсызмы, файдасыз!

Зал әкренләп тынды. Ләкин сөйләргә чыгучы табылмады.

— Фронтовиклар бармы? — диде Айдаров, аяк өсте басып.

Халык арасыннан Гайрәтулланың озын буе калыкты.

Зал дәррәү көлеп җибәрде. Үз гомерендә бер мәртәбә кызмача килеп, аның җыелышта нинди сүзләр белән сүгенеп киткәнен халык онытмаган иде әле.

— Нәрсә ат урынына кешнисез? — диде Гайрәтулла. — Бик рәхәтмени безнең хәлебез? Авызыбызга су кабып утырабызмыни?! Районнан олавы белән килгән нәчәлстуага безне акылга утырту әмәлләрен эзләү әллә бик рәхәт дип беләсезме?

— Тәкъдимегезне әйтегез, иптәш фронтовик, — дип, Айдаров янә дә аягүрә басты.

— Тәкъдим минем бер генә: суык судан тотмыйк без балыкны! Кайда гаепле кешеләр? Бүре Гыйбадулланың Нисасы кайда — амбар талап симергән күсе? Авантюрист, ялачы Курамшин кайда? Чыгарып бастырыгыз аларны халык алдына. Күрсәтегез ул җинаятьчеләрне прокурорга. Менә шуннан соң без әйтер сүзебезне үзеп әйтербез.

— Правильно! — дип залны ярып җибәрде баягы ачы тавыш. Башлар шул якка борылды. Зартугайга эвакуация белән килгән Евдокия Ивановна, бүреген башыннан йолкып алып, халык өстеннән күтәрелеп, нидер әйтмәкче була, әмма аны тавышлар тагын күмеп киткән иде.

— Бирегә килегез! — дип кычкырды Каһарманов.

Евдокия Ивановна, халыкны ярып, юл уңаенда кычкыра-кычкыра сәхнәгә таба килә башлады. Ләкин ул сәхнә алдына аеруча күп булып өелгән үсмерләрне берничек тә аралап чыга алмады.

— Шуннан гына сөйләгез, — диде Айдаров.

Евдокия Ивановна тирләп-кызарып чыккан иде. Кайры тунының якасын чишеп җибәрде:

— Без бүген, солдаткалар, Курамшинны да, амбарчыны да таба алмабыз. Курамшинны без гомер буе онытмаслык итеп кыйнадык. Булдыксыз Батыршинның, куркак Батыршинның аңа чара күргәнен көтеп ятмадык. Амбар күсесе Ниса Гыйбадуллина биредә юк, күрәсең, ярыкка кереп поскан. Укыгыз безгә тикшерү комиссиясенең актын: дөньяда гаделлек бармы әле, әллә инде ул беткәнме — без шуннан белербез.

Зал тып-тын калды. Ике метрлы буе белән бер кырыйда стенага сөялеп торган Әфләтун картның гыжлап сулыш алганы ишетелә башлады.

— Үзең укы актны, — диде Айдаров партоешма секретарена.

Каһарманов тамак кыргалап алды, алгарак чыкты, — утка якынрак килде. Тоныграк тавыш белән укырга тотынды:

*Пәнҗәр районы прокуратурасына «Кызыл Зартугай» колхозы медпункты фельдшеры М. Курамшиннан килгән жалобаны тикшерү турында.*

*1943 елның 17 мартында район прокуратурасына медпункт мөдире, медицина фәннәре кандидаты, врач Н. А. Уразаеваның яшерен рәвештә кайбер хатыннарга аборт ясавы турында жалоба кергән иде. Исемнәре атап күрсәтелгән хатыннардан — ире сугышта һәлак булган Бәдига Сәлимовадан, ире сугышта һәлак булган Мөслимә Гыйбадуллинадан, эвакуация белән Ленинградтан күчкән Евдокия Ивановна Самойловадан сорау алу, врач Уразаевадан сорау алу жалобада күрсәтелгән фактларны расламады. Язылганнар яла булып чыкты. Солдаткалар өстенә һәм намуслы врач Н. А. Уразаева өстенә ягылган яла 1943 елның 17 мартында «Кызыл Зартугай» колхозында колхозчы хатын-кызларның бунтын китереп чыгарды.*

*Тикшерү нәтиҗәсендә түбәндәгеләр ачыкланды:*

*Врач Н. А. Уразаева «Кызыл Зартугай» колхозына медпункт мөдире булып килгәннән соң, халыкка медицина хезмәте күрсәтү яхшырган. Авырулар төгәл хисапка алынган. Медпункт фельдшеры М. Курамшинның тап-таза, сәламәт кешеләргә, урман кисәргә бармас өчен, ялган белешмәләр бирүе бетерелгән, димәк, ришвәт алу юлы да киселгән. Фельдшер Курамшинның яла ягуы врач Уразаевага гына карамый, асылда бу фронтны азык-төлек белән тәэмин итеп килгән хатын-кызларыбызга да яла ягу булып чыга. Гражданин М. Курамшинның ришвәтчелеге, намуслы колхозчыларга һәм врач Уразаевага яла ягуы җинаятьчеләр кодексына керә. Моның белән районның прокуратурасы шөгыльләнергә тиеш.*

*Тикшерү комиссиясе тагын бер хәлгә басым ясауны кирәк дип таба: М. Курамшинның җинаятьләренә амбарчы Н. Гыйбадуллина булышкан. Колхозчылар мәнфәгатен үз вакытында кайгырта белмәгән колхоз җитәкчеләре дә булышлык иткәннәр.*

Акт укылып беткәч, халык бик каты кул чапты.

Мәсьәлә тулысынча ачык, җыелышның карарын гына кабул итәргә дип торганда, тынлыктан файдаланып, Әфләтун карт клуб стенасыннан купты:

— Җәмәгать! Бүре Гыйбадулласын ник әйтмәгәннәр? Бүре Гыйбадулласын җәзасыз калдырсагыз, рәнҗим. Кул аркам белән битемне сыпырып бәддога кылам. Ул, мөртәт, минем улымны гарип ясады... — дип сөйләп китте.

Җыелыш карары кыска булды:

*1. «Кызыл Зартугай» колхозы медпункты фельдшеры М. Курамшинны намуслы колхозчыларга яла якканы, ришвәт алганы өчен хезмәт вазифасыннан азат итәргә. Эшен прокуратурага тапшырырга.*

*2. «Кызыл Зартугай» колхозы амбарчысы Н. Гыйбадуллина-Исрафилованы, үз тирәсенә намуссыз кешеләрне ияләштергәне, фельдшер М. Курамшинны яла ягарга котыртканы өчен, эшеннән алырга.*

*3. «Кызыл Зартугай» колхозы председателе М. Батыршинга, авыл советы председателе М. Мурзинга, сәяси гаделсезлек күрсәткәннәре, шуның белән намуссыз элементларга юл ачканнары өчен, каты шелтә белдерергә.*

Жыелыштан күңелсез таралдылар.

Айдаров үзен чәй эчеп чыгарга бик тә кыстаган Имам Каһармановка өзеп кенә әйтте:

— Юк, Иматметдин, кирә алмыйм. Бу күңелсезлекләрнең тамыры беренче чиратта сиңа барып тоташа. Син — авылда беренче кеше, партоешма житәкчесе, нәрсә карап яттың? Борын астында әнә бит нәрсәләр эшләп яталар икән. Әзерлән. Сиңа бу хакта райком бюросында хисап бирергә туры килер, — диде.

Пәнжәргә ул шактый ук күңелсез уйлар белән кайтты. Әмма аның намусына тими торган бер хәл бар. Врач Уразаева — аның энесе Солтанның хатыны Нурия — әлеге ситуациядә югары булып калды. Әгәр Курамшин эшләгән җинаятькә — ришвәт алуга юл куйса, ни хәл итәр иде.

Иртәгесен, райкомга эшкә килгәч, секретарь кыз аңа берничә хат кертте. Арадан берсен сайлап алып:

— Шәяхмәт Айдарович, менә монысына бүген үк җавап бирүгезне үтенделәр. Телефоннан. Казан Наркомздравыннан шалтыраттылар, — диде.

Айдаров Татарстан Сәламәтлек саклау халык комиссариатыннан килгән хатны бик җентекләп укып чыкты.

*Иптәш Айдаров! Сезнең районда («Кызыл Зартугай» колхозында) вакытлыча, кышкы айларда, д-р Уразаева Н. А. эшли. Ул медицина фәннәре кандидаты, тәҗрибәле гистолог. Бөек Ватан сугышы башланганнан бирле хәрби госпитальләрдә намус белән эшләп килә. Аңа кулыгыздан килгән барлык ярдәмне күрсәтсәгез иде. Май аена тикле ул Сезнең районда эшләп торсын, аннары без аны мобилизация белән тагын хәрби госпитальгә кайтарырбыз.*

## V

Колхоздагы иң яхшы атлар, сайланып, сугышка алынгач, заданиегә икмәкне һәм урман ташу өчен җигү атлары җитмәгәндә, колхозчыларның сыерларын тәртә арасына китереп керткәч, Бүре Бадулның да күз карасы кебек саклап үстергән өч яшьлек үгезен алдылар.

Сугыш заманының законнары усал, колхоз башлыклары белән дәгъвалашып торып булмый — алар артында бит аның прокуроры бар, судьясы бар. Кайчандыр ул тыныч карый торган бу кешеләр аны шикшөбһәгә, хәвефкә сала башладылар. Ул таш капчыкка яптырган, инде дөмекте дип уйлаган Чишмәбай әнә фронттан хат җибәреп ята. Алла сакласын, ул башсызның әллә ниткән батырлыклар эшләп, герой булып, Зартугайга кайтып төшүе дә ихтимал. Дапруслаган чакта, кем белә, аның өстеннән жалуны Гыйбадулла Ядкаров язганны әйтмәгәннәр дисеңме? Әнә бит жалуны яза белми язган Курамшин нишләде? Прокурор авызына барып керде.

Бүре Бадулның күңелен корт кимерә башлаган чак җитте.

Ләкин Гыйбадулла абзаң кайгыны калынайтып күрергә гадәтләнмәгән. Аның эше — тик ятмау. Гамәл. Эш. Тырышлык. Менә нәрсә кешене кеше итә. Үгезне бирде ул колхозга. Ай-һай лабаса, әрәм китте үгезем, дип сөйләнеп йөрмәде. Еллар буе чылбырда утырган йөнтәс эте Пиратны бәләкәй чанага җиктереп, малайларына Ужил урманыннан утын ташыта башлады. Ул арада күрше авылдан килеп кергән урам алабаен — бозау чаклы сары этне иялләндереп, этләрне бәләкәй арбага парлап җигәр өчен дирбия әзерләде.

Малайлар мәктәптән кайткач, урманга элдерәләр. Этләр белән! Корыган наратмы, имәнме — аларга гел очрап тора. Тураклыйлар да алып кайталар.

Урман каравылчысыннан курыкмый Бадул: җәен умарталыкта, кышын өендә ачыган бал өзелми. Адәм баласының авызын ябарга күпме кирәк соң?!

Бу араларда аның күңеле бигрәк тә почмакланып йөри әле. Интендант хезмәтендәге Җиһангирның, ниһаять, хаты килде: яраланып, госпитальгә кергән. Казанга кайтарулары да ихтимал дигән.

Өченче улы Ширияздан белән Пәнҗәр базарына утын сатарга барып кайтты. Ат караучы Мортазадан председательгә белгертмичә генә ат алган иде. Дуга биеклеге итеп төялгән утынны казылмадан алып чыга алмыйча азапланганда, Ширияздан җилкә белән бер генә этеп җибәрде — ала да китә ат. Малайның монысы да таза булып чыкты бит әле болай булгач. Әйе, малайлар шәп, үзенә тарткан, тик ул хакта тиктомалга кычкырып йөрергә ярамас, алла сакласын, яше җитмәс борын сугышка алып куюлары да бар.

Базардан улына Бадул зәңгәр түбәле, мех белән камаган түгәрәк бүрек алды, мех якалы постау пальто алды. Шомырт кара язгы йоннан киез итек бастырды — йөрсен әле малай этәч булып!



Шириязданны кеше күзенә чекерәеп карерлек итеп киендерүнең икенче сәбәбе дә бар иде. Амбарчы Нисаны, фельдшер Курамшин белән буталганы, намуслы кешеләргә яла ягарга котыртканы өчен (суд тикшерүендә шуны әйтеп барды!) амбардан кудылар. Әнә шул куучыларга үч итеп киендерә улын Гыйбадулла карт. Сөенмәсеннәр. Канат какмасыннар. Бүре нәселе бетте, түбән тәгәрәде, дип уйламасыннар! Хәер, кызы да аның амбардан куылгач та, борын салындырып йөрмәде, кул кушырып утырмады. Күршеләрендәге Хәмиткә — бала чактан ук шар суккан чагында бер күзе шар тиюдән йомык калган, әмма холкыфигыле нык, үзен кимсетелгәннәр рәтендә санамый торган егеткә кияүгә чыкты. Хәмит тыныч елларда үзенә кәләш таба алмаган иде, кырык яшенә тикле буйдак булып йөргән иде. Менә хәзер ул, сугыш елларында, Пәнҗәр районы буенча налог агенты булып алган, әллә элекке елларны кызларның аны санга сукмауларының каруын кайтарырга теләп, әллә башка сәбәпләр аркасында, налогларын түләп өлгермәгән авыл кешеләре, бигрәк тә үз авылы Зартугай кешеләре белән аеруча кансыз кылана иде. Иш ишен таба, ди. Менә шушы кансыз кешегә кияүгә чыкты Бүре Бадулның Нисасы. Авыл советына, Зартугай урамнары буйлап «подручкым» барып, язылып кайттылар. Законча булсын! Күрсеннәр Зартугай хатыннары эштән куылган Нисаның төшеп калган кеше түгеллеген!

Аның белән генә бетмәде әле. Ниса тегү машинасы сатып алып, бөтен Зартугайны күлмәктер, алъяпкычтыр ише нәрсәләр белән тәэмин итеп тора башлады. Ә үзе — бәйләнмәсеннәр өчен, авыл мәктәбенә мич ягучы булып керде. Төннәрен мич яга, көндезләрен машина келтерәтә. Китте Нисаның эшләр хутка!

Ниса Гыйбадуллина булдыклылыгы, җәптәшлеге белән тагын халык теленә керде.

— Болар, җаным, җир астына төшсәләр дә, караңгы базларда таш күмере чапсалар да, кая гына барсалар да, хур буласы түгел. Болар, җаным, таш астыннан чыккан, — диде халык.

Хак иде халыкның сүзе. Яшәргә дип туган, умырып, сугышып яши иде Бүре нәселе.

Ләкин кайчагында «таш астыннан чыккан» адәмнәргә дә баш бирергә туры килгән чаклар була.

Апрель ахырларында Ниса белән налог агенты арасында низаг чыкты. Ниса үзенең Хәмитен Исәнбайда ниндидер бер солдатка белән бутала дип ишетеп кайтты.

Ишетте — гауга чыгарды.

Ни өчен әле ул, Зартугайның булдыклыдан да булдыклы бичәсе, шушы сукыр-букыр адәмнән мыскыл иттереп торырга тиеш? Ни өчен әле ул кырыкка кадәр хатын чырае күрмәгән кылыйдан үзен җәберлә-

тергә тиеш? Юк, мәкашле сукыр. Бүренекеләр өстеннән көләр адәм дөньяга тумаган әле и тумаячак та!

Хатын-кыз ваклыгына түзә торган кеше иде Хәмит. Аларның үз йортларында да биш кыз арасында, бер әби һәм бер әни арасында үл бердәнбер ир бала иде. Апаларының-сеңелләренең талаш-ызгышларын аз ишетмәде ул. Гомумән, Хәмит дөнья ваклыкларына кул селтәргә гадәтләнгән, үз юлы белән, үз дигәнчә йөрергә күнеккән иде. Ләкин Ниса, аның законлы хатыны, вак игәү белән игәүләгән төсле, тешкә тия торган вак сүзләрен тезепме-тезә! Чирек сәгатенә түзде Хәмит, сүз әйтмәде. Ярты сәгатенә түзде, Бүре Нисасының туктарга бер дә нияте күренми. Ниһаять, Хәмитнең сабыры төкәнде, тавышны күтәрмичә генә әйтте:

— Җитәр, җанкисәгем, тукта, калганын иртәгә сөйләрсең, — диде.

Туктамый гына бит каһәр төшкере Ниса! Хәмит аяк тибеп кычкырды:

— Җитте диләр сиңа, юеш танау! Нәрсә монда улап утырасың, ач бүре төсле?!

Әнә шул «ач бүре», ягъни этиләренең кушаматы тешенә тиде Ниcаның. Китте бу шуннан усаллашып, китте, мин сиңайтим — түз генә. Бетле хәерче дә, халыкны талаучы да, килмешәк тә — берсе дә калмады. Азагын — бума чире дип, псих дип тәмамлады. Юк икән әле, тәмамламаган икән, гыжылдап берничә мәртәбә сулыш алгач:

— Печтерелгән кәҗә тәкәсе! — дип кычкырды.

Хәмитнең сабыр төбе төкәнгән иде. Ул башта Нисаны, өстенә атланып, кара көйдергәнче тукмады, тегесе һаман әшәке телләнүен туктатмагач, чәченнән сөйрәп, өй астына ыргытты — өстен ача алмаслык итеп, кадаклап куйды.

Үзе налогларын җыяр өчен күрше авылларга чыгып китте. «Өчдүрт көн караңгы базда ятсаң, җефәк төсле йомшак булырсың, атаман булуыңны онытырсың»; — дип фикер йөртте ул.

Бүре нәселеме тәүбәгә килүче?! Ике көн тырмашты Ниса идән астында, тырнакларын каерып, канатып бетереп, балчыкны казып, урам якка килеп чыкты.

Бүре Бадулның малайлары җизнине гафу итмәделәр. Күрше авыллардан налог җыеп кайткан чагында сагалап торып, өстенә капчык бөркәделәр — күн итек белән тибә-тибә акыртып, кара канга батырып кыйнадылар. Ерак түгел генә бер күпер астына илтеп ташладылар.

Хәмитнең кыйналуы хакында сүз күп булды. Берәүләр әйтте, бандитлар акчасын талаган икән, диде. Икенчеләре яңа бер уйдырма уйлап чыгарды, сугыштан ялга кайтучы солдат аны хатыны белән тоткан икән, диде. Хәмит үзе Бадулныкылардан шикләнде — ләкин тәгаен күрмәгәч, аларга кагыла алмады.

Ул гомерлек гарип булып, аягын сөйри торган булып калды.

Җәзасызлык кешене азындыра, үз күз алдында дәрәҗәсен күтәрә. Бадулныкылар сугыш елларында кырдан икмәк урладылар, урманнан утын ташыдылар, колхоз басуларыннан клевер, торна борчагы чабып алып кайттылар; умарталыктан рөхсәтсез бал алдылар, эскертләрдән ташыган саламны әйткән дә юк; инде бер дә урлар нәрсә калмагач, Пәнҗәрнең бер урман күленнән ике йөк мунчала урлап, кыш буе бау ишеп чыктылар.

Аларга берничә мәртәбә тентү керде, ләкин беркайда да урланган малны таба алмадылар. Ник дисәң — Бадул лапас түренә бик зур һәм бик тирән итеп баз казыган, шуны кирпеч белән өйләгән, аның капкачын лапас коймасының кырыена ук куеп, утын әрдәнәсе белән каплаган иде. Бадул үз гомерендә тик бер генә мәртәбә тотылды. Хәер, моны тотылды дип, авыз тутырып әйтү бигүк дөрес булмас. Азагы бик тә серле булып калган, сере беркайчан да ачылмаячак нәрсәгә тап булдылар Бадулныкылар.

1943 елның маенда, Сталинградтагы бөек җиңүдән соң, колхозларга тагын, берән-сәрән генә булса да, тракторлар килә, тыныч заманнардагы тормышны хәтерләтеп, Ужил урманы артыннан тракторларның тоныкгерелтесе ишетелә башлаган иде.

Бадул, Ширияздны белән Мифтахын ияртеп, кап-караңгы бер төнне, коеп яңгыр явып торган чакта, кыр станыннан берәр потлы өч шешә белән керосин урлап кайтты. Тентү-мазар керә торган булса, тапмасыннар өчен, потлы шешәләрне бәрәңге бакчасы башына, җиргә күмделәр. Кышкы озын төннәрдә керосин бик тә кирәк булачак.

Күмделәр, бүтән исләренә дә кертмичә яшәделәр.

Бер заманны, ашка бәрәңге алырга чыккан Җамал җиңги бик аптырап әйтте:

— Әтисе, карале, сиңайтим, бәрәңге алганыем ашка салырга, гел дә менә керәчин исе аңкып тора. Нигә шулай ул, ә? Салыйммы соң моны, юкмы?

Бадул бакча башына ташланды. Күмелгән потлы шешәләрне иплән кенә актарып карады — өчесе тиң челпәрәмә килеп ватылган, керосин ярты бакчага тикле агып төшкән иде.

Берәү дә белмәде моның серен.

Әти кеше дә, малайлар да моны гаиләдәге хатын-кыздан яшерделәр. Әмма Бадулныкылар керәчинле бәрәңге ашый икән дигән сүз ул елны авылга таралды.

Бадулныкылар — «керәчинле» бәрәңге ашамадылар, чөнки аны ашау мөмкин түгел иде. Алар ярты бакчаның бәрәңгесен казып алып, төнлә Бүре чокырына илтеп күмделәр генә. Элек бу чокыр Үләксә базы дип йөртелә иде. Күтәрәмгә калган берничә ат үлеп, шунда чыгарып ташлагач, анда сугыш чорында ишәеп киткән бүреләр ияләште — караңгы төшәр-төшмәс алар өерләре белән шунда җыелалар, йөрәккә шом салып, улаша башлый торганнар иде. Шуннан үзгәрде Үләксә базының исеме, Бүре чокыры булып китте.

Шешәләрнең ватылу сере бик тә гади иде.

Моны налог агенты Хәмит эшләгән иде. Үзенең гарип булып калуын Бадулныкылардан күргәнгә күрә, ул айлар буе Бадулныкылардан үч алу уе белән яшәде. Һәм менә җае чыкты. Коеп яуган яңгырдан соң арка-җилкәсенең, аякларының сызлый башлавын тоеп, ул үзләренең шомырт бакчасына аз гына булса да сызлау басылмасмы дип чыкты. Әрле-бирле йөреп торды. Бер заманны, яңгыр туктагач, арба шыгырдаган тавышка үзләренең бакчасыннан башын тыгып караса, ни күрсен — Бүре Бадул, ике малае белән бергәләп, арбага утырып кайтып килә.

«Бүреләр аудан кайта, — дигән уй яшен тизлеге белән күңеленнән узды. — Карап карыйк, бу юлы нәрсә эләктердегез икән?»

Нисага өйләнеп яшәп калган берничә ай эчендә Бүренекеләрнең бик сак кылануларын сизеп өлгергән иде Хәмит. Алар Хәмиткә, кияүләре булса да, нәрсә урлаганнарын күрсәтмиләр, хәтта кызмача чакта да серне чишмиләр иде. Ләкин аларның караңгы эш белән йөрүләрен Хәмит сизенә, чөнки ул үзе дә бигүк чиста куллы егет түгел иде.

Шул төнне Хәмит, Бүренекеләрдән дә саграк булып, аларның нәрсә алып кайтканнарын күзәтте. Бадул үзе, ике малае, кулларына зур һәм авыр нәрсәләрдер күтәреп, бакча ягына таба киттеләр. Аларның бакча башы Хәмитләрнең бакчасына ук диярлек терәлеп тора, шунлыктан шомырт арасында посып утырган кешегә төнге авазлар аермачык ишетелә иде.

— Ширияздан, Мифтах! Иплэбрәк кыланыгыз! Шешәне төшереп вата күрмәгез. Керосин исе бөтен авылга җәелер, — ди Бадул тавышы.

«Әһә, кыр станыннан керосин урлап кайтканнар. Хәзер шуны бакча башына күмәргә йөриләр, — дип уйлады Хәмит. — Ярый, ярый, күмегез. Бик тә шәп итеп күмегез. Без аны нишләтергә икәнен белербез».

Бакчада кеше тавышлары тынгач, Хәмит өйләренә кереп, лом алып чыкты; йөрәге дөпелдәп типкән хәлдә, тагын да авыраебрак киткән

гарип аякларын көч-хәл белән сөйрәп, киртә арасыннан Бадуллар бакчасына керде. Өч җирдә казык агарып күренә иде. Шунда барды — дөбердәтеп ломны җиргә тыкты, тонык кына шешә ватылган тавыш ишетелде.

Калган икесен дә шулай эшләде. Авылга бернинди дә керосин исе таралмады. Шешәләр шактый тирәнгә күмелгән, керосин акса, бакча башыннан түбәнгә таба көпшәк җирдән бәрәңге тутәлләре арасына гына агачак иде.

Хәмит кергән юлдан кире чыкты. Куркудан аяклары бөтенләй тотмый башлагач, җирдән шуышып барып, үз бакчаларына, шомырт арасына кайтып егылды; хәл җыя алмыйча, чигәләренең сулкылдавын тыңлап, бик озак ятты...

## VI

1943 елның җәендә Бадулныкыларны тетрәткән тагын ике вакыйга булды. Гыйбадулла Ядкаровның өченче малае Ширияздан Салагыш мәктәбендә тугызынчы класста укый иде. Математиканы ул су кебек эчә, әмма әдәбият, рус теле аңа бик авырдан бирелә иде.

Көтмәгәндә ул әдәбият укытучысы Шәфика Уразаева белән дуслашып китте. Мәктәп дирекциясе Мирхәйдәр Фәйзинең «Ак калфак» драмасын укытучылар көче белән сәхнәгә куярга, спектакльдән килгән акчаны фронтовик балаларына җылы киемнәр алырга тотарга булдылар. Хәмдия ролена Шәфика туры килә дип таптылар. Энҗеле яшел бәрхет калфакны Шәфиканың шомырт кара ике толымлы башына ак ефәк яулык белән бергә беркетеп куйганнар иде — аһ иттеләр. Коеп куйган бер сылу! Ул сызылып киткән кара кашлар, ул туры борын, ул түгәрәк сөйкемле йөз — йа хода, этисе исән булып бер күрсә, акылыннан язар иде. Тәмам җиткән, тәмам пешеп чыккан кыз икән ич бу! Иннек-мазар сөртмичә дә уттай янып торган иреннәр аның кара-туткыллы ягымлы битен тагын да балкытып җибәрә, инде аңар үлеп тә гашыйк булган Бакыйны, яшь көтүчене табарга кирәк. Юк кына бит Бакый роленә ир-ат. Унсигездән узганнар барысы да фронтта. Нишләргә? Укытучылар арасыннан бу рольгә кеше табу мөмкин булмаганга күрә, югары класс балалары арасыннан эзләргә карештеләр. Дөрес, бу педагогия кагыйдәләренә туры килми, иллә мәгәр бүтән чара юк иде.

Җыелып сөйләшкән чагында берничә кешенең, хәтта унлап үсмер егетнең исеме телгә алынды — берсе дә яраклы түгел. Бүе булса, чырае юк, чырае булса — ике сүзне оештырып әйтә алмый. Өченчесенең бүе да бар, телгә дә бик оста, әмма моңы юк, җыр дигән затлы нәрсә егеттән ерак йөри, музыкантлар әйтмешли, колагына аю баскан.

Озаклап эзли торгач, төскә-биткә дә, буйга-сынга да туры килә торган үсмер егет булып Ширияздан табылды — Бадул малае. Музыка укытучысы, мәктәптә бердәнбер баянчы Рәбига апа җырлатып карады Шириязданны — койган да куйган. Искиткеч моңлы бәрхет тавыш.

Репетицияләр башланды. Сизеп тора Шәфика: аның суфлердан соң кабатлап әйткән һәрбер сүзен Ширияздан чынга ала да кызлар кебек кызара. Бу хәл укытучы кешене бик кыен хәлгә кигереп куйды. Тагын биш көннән соң, парлап, дуэт белән җырлау өлешенә күчкәч, репетицияне тыңларга килгән мәктәп директоры Бану апа, татар әдәбияты укытучысы Камәр апа, тагын берничә укытучы хатын, барысы да солдаткалар, бу ике яшь кешенең моңланып, өзелеп-өзелеп җырлауларын тыңлап утыра торгач, мышкылдап елап җибәрмәсеннәрме?! Сугышка кадәрге ямьле чакларны, егет сөеп, гашыйк булып йөргән заманнарын искә төшерделәр ахрысы. Кайларда йөри икән хәзер аларның газиз кешеләре?

Олылар күңеле бер тулыр да бетәр. Ә менә яшьләр... яшьләр нишләсен?

Бадул малае инде хәзер Шәфиканы репетицияләрдә генә түгел, мәктәп коридорларында гына түгел, мәктәптән соң вакытта да, кичке уеннарда да күрергә тели башлады. Егетебез күкрәк турысында нәрсәләрдер бик әкрен, әмма өзлексез рәвештә сулкылдап торуын сизде. Никтер җырлыйсы килә, җырлый-җырлый, тауларга менәсе, таулардан йөгереп төшәсе, Иж ярларыннан тирән чоңгылларга сикерәсе, тирә-якка суны чәчрәтеп, дулкыннар җәелдереп, шаулап йөзәсе килә иде.

Өйдәгеләр белән сөйләшәсе килми. Үч иткәндәй, әтисе аңа гел эш куша, йомыш куша, шөпшә кебек колак төбендә һаман аның тавышы; шул дорфа калын тавышны, шул гүләүне ишетмәс өчен әллә нәрсәләр бирер иде Ширияздан!

Урманга утынга баруны, мал астын җыештыруны, ишегалдын себерүне дә онытты егетебез. Юк, мондый кыланыш ошамый Гыйбадулла абзаңа, үтер, суй — ошамый. Ул хәвефтә: әллә егет кисәгенең борынына кызлар исе кергәнме?

Бүре Бадул улының театр куярга җыенганлыгын белгәч, күңеленнән генә сөенеп тә куйган иде югыйсә: туктале, җыен этлекне, бар булган усаллыкны безгә генә такмасыннар! Ийе! Чыгып бер клубта балкып керсен әле аның Шириязданы!

Ул да түгел, Гыйбадулла картның колагына улының Габбас мулла кызы белән бергә уйнаячагы, бергәләп җыру җырлаячагы килеп ишетелде. Гыйшык турындагы нәмәстәкәй, имеш. Монысын инде Гыйбадулла Ядкаров бер дә кулай тапмады. Кем белә, бәлкем, алар анда кеше күз алдында үбешеп тә торырлар. Юк, җанкисәкләрем, монысына инде ул юл куя алмый. Монысы чиктән ашкан! Габбас мулла кызы булганы өчен түгел, Хәнифә кызы булганы өчен. Теге чакта бит ул, мәгънәсез катын, Бадулны бөтен Зартугайга рисвай итте. Ә үзе нишләде диген? Көнлекче Хисмәй малае Каюмга алмаштырды аны. Бөтен авылны күкрәтеп торган Бүре Бадулны ата зимагур Чишмәбайга алыштырды бит. Чишмәбайдан үчен алды Бадул, иллә мәгәр аның әле Хәнифәгә булган үче бетмәгән икән.

Гыйбадулла картның бүре табигате өскә калкып чыкты. Кичен, сөтле умач чөмереп утырганда, ул Шириязданга әйтә куйды:

— Карале, малай актыгы! Син Хәнифә кызы белән чуала дигән сүз йөри. Дөресме шул? Туп-туры әйт, мин моңа риза-бәхил түгел!

Ширияздан, ашый торган җиреннән сискәнеп китеп, башын күтәрде, кашыгын өстәлгә куеп, ишегалдына чыгып китте.

Кичен, репетиция вакытында, ул бик моңсу иде, чырае бер дә яктырмады. Спектакльне әзерләүче Рабига апалары:

— Ширияздан, үскәнем, син авырыйсың мәллә? Авызыннан чыккан сүзең ишетелми, гел ботка пешереп торасың, — диде.

Үзенең башка малайлардан көчлерәк булуын, атаманлыгын сизеп йөри торган Шириязданны бу сүзләр икенче мәртәбә рәнҗеттеләр. Күпне күргән күркәм кеше булса, ирен чите белән генә елмаеп куяр, яки, әйе шул, кәефем юграк, дияр иде дә бетерер иде, унҗиде яшьлек үсмергә, өстәвенә Уразаева Шәфикага бер атна эчендә мөеннан гашыйк булган егеткә андый тәҗрибә, андый басынкылык каян килсен! Суфлер әйткән сүзләрне ул йә ишетми, йә бозып әйтә башлады.

Ул көннәрне репетициянең рәте-башы булмады. Рәбига апалары, бүгенгә җитеп торыр дип әйтүгә, Ширияздан сумкасын алырга дип сәхнә артына ташланды; бәхетсезгә вакытсыз дигәндәй, кемдер аның сумкасын башка җиргә күчереп куйган, сәхнә артындагы иске-москыны актарып, сумкасын эзләп тапканчы шактый вакыт узды, ниһаять, табып алып, тар аралыктан чыгып килгәндә, ярым караңгыда ул Шәфика белән очрашты. Каушады Ширияздан — узып та китә алмый, уздырып та җибәрә алмый. Кыюсыз бер мизгелдән соң зиһене ачылып:

— Шәфика... — дип дәште.

— Нәрсә бар? — диде укытучы кыз.

— Бүген кич клубка чыгасыңмы?

— Клубка? Ник?
— Мин сине озатып та куяр идем.
— Син нәрсә, Гыйбадуллин?
— Нигә, ярамыймыни?

Шәфика бүтән сүз әйтмәде. Аның менә шушы минутта чыгып китәчәген, инде бүтән беркайчан да сүз кузгатмаячагын аңлап, Ширияздан сүзен әйтеп калырга ашыкты, кабаланып, очрашуга чакырды.

— Кит юлдан. Кеше күрер. Зартугайда очрашырбыз.
— Ә кайтмасаң?
— Карале, егетме син, түгелме? Әйттем бит, кайтырмын дип.

Яшьлектән дә күбрәк ялгышкан, яшьлектән дә күбрәк үкенечләр җибәргән вакыт юктыр.

Ширияздан, кызый хәйләли, миннән котылмакчы була дип уйлап, аның юлына аркылы төште, аны өзелеп яратканын исбатлар өчен, ике кулыннан берьюлы тотып алып, үбәргә үрелде.

Күзләре зураеп киткән укытучы, куркынып:

— Җибәр диләр сиңа! — дип янаулы тавыш белән пышылдады. Баянчы Рәбига апасының, яки мәктәп директоры Бану апасының менә-менә килеп керүе мөмкин иде.

Ширияздан башын җуйган, күзенә ак-кара күренми, әгәр ул хыялында иң сөекле бер зат итеп күргән Уразаева Шәфиканы ычкындырса, гомергә югалтыр төсле тоя иде. Янында гына басып торган укытучы кызны, аның җылы йомшак кулын ул берничек тә ычкындырырга теләми, тик күпме генә этләшсә дә, ул аны үбә алмады. Шәфика башын чайкый, иреннәренә үрелергә ирек бирми иде. Ширияздан, малайлыктан узып, егет икәнен дә онытып, ирлек хисенә бирелде — бер кулы белән Шәфиканы үзенә кысып китерде, икенчесе белән күкрәгенә үрелде.

Шәфика үзәк бәгыреннән чыккан зәгыйфь тавыш белән әкрен генә ыңгырашып куйды, кинәт артка каерылды да, Шириязданның яңагына чалтыратты:

— Нәрсә, теләсә кем ябышырга, әллә син аны ишек тоткасы дип беләңме? — һәм алдына-артына карамый чыгып китте.

Әле һаман аңына килеп өлгермәгән, саташулы томан эчендә йөзгән Ширияздан баскан урынында катып калды.

Репетицияләргә ул бүтән килмәде. Мәктәпкә йөрүдән дә туктады. Оят иде аңа, әйтеп бетергесез оят иде! Хәзер ул әтисе ни кушса, шуны үти, урманнан этләр җигеп, утын ташый, караңгы бер төнне урман күленнән урлап алып кайткан мунчаладан бау ишә; кичләрен аулак өйләргә бара, үсмер кызлар җыелган җирләргә бик теләп катнаша, әрсез авыл егетләре кебек, кызларның артына шапылдатып суга, түшләренә үрелеп кычкырта, — боларның барысын ул тәкәббер укытучы Шәфика Уразаевага үч итеп эшли; әмма күкрәгендә бер хис — җанын сызлатып, моңайтып торган, өзлексез үкендергән бер хис яши, һәм ул аны берничек тә җиңә алмый иде.

Малаеның шундый эшлекле, хезмәт яратучан булып китүенә Бүре Бадул куанып бетә алмый, аның аулак өйләргә чыгуын да хуплый — шөкер, ул үзе дә аз йөрмәде аулак өйләрдә; булдыра икән, йөрсен, күрсен кызларны, кызлар аны күрсен, дөньяның яратылышын өйрәнә башларга да бик вакыт.

«Минемчә булды, улым Ширияздан минем юлдан бара», — дигән уй Бүре Бадулны бик мавыктырган, күзен сукырайткан иде. Ул әле Шириязданының нинди әкәмәтләр ясаячагын, хәзергә әле җае гына чыкмый торуын белми иде.

Шириязданга, баксаң-күрсәң, язмыш Бүре Бадулның төшенә дә кермәгән, керә дә алмый торган бер вакыйга әзерләп куйган икән.

Гыйбадулла Ядкаров улы Ширияздан өчен тынычланып, җәй буе урмандагы колхоз умарталыгында эшләде. Җәйне ул быел аеруча кәтеп алган иде. Ник дигәндә, арка-җилкәләре дә сызлаштырып тора, нәр-

сагадер эче поша, урман һавасы, каккүк моңнары, урман күгәрченнәре гөрләве житми иде бугай аңа. Шифалы үләннәр, дөньяны жемелдәвек йолдызлар белән каплап, басып үз канаты астында тотып торган урман төне житми иде бугай.

Бал ачыта торган буш мичкәне сиртмәле жиңел арбага бау белән бәйләп, ел саен жигеп йөри торган Күк биягә тәңкәле йөгән, чуклы шлеяләрен кидертеп, Казан тау жыенына киткәндәй китеп барды Бүре Бадул.

Үзе белән ул Мифтахны, Мәхмүзәне, Харисны, чылбырда торып усалланган Пиратны алды. Балалар аңа чүннек йортын жыештырырга булыштылар, урман аланнарыннан печән чаптылар.

Өйдә ир-ат затыннан төп кеше булып Ширияздан гына торып калды. Ул колхоз эшенә йөри, шунлыктан умарталыкка бара алмый иде.

Жәйнең матур айларында алны-артны белми эшләгән егетебез, август керүгә үзендә ниндидер үшәнлек сизде, берән-сәрән саргая башлаган агачлар аның күңеленә моң салды һәм ул көннәрдән беркөнне, абзардан тирес чыгарырга дип алган сәнәген ыргытып, ишегалды чирәменә сузылды.

Рәхәт иде болай ятуы. Янда тавыклар жырлап йөри, үрдәкләр ава-түнә капка астыннан кайтып керделәр. Үрдәк әйткән ди: өй түбәсе такта әле, саламга калдырганчы тырышам әле, дип әйткән ди.

Ширияздан шуларны уйлап бетерергә дә өлгермәде, аның янында гына чүпләнеп йөргән бер ак тавык, зур кызыл суалчанны йотты да, канатларын кагынып, капкага чаклы йөгереп барды, көтмәгәндә һавага күтәрелде, ә дигәнче койманың теге ягында юк булды.

Ширияздан, нишләгәненә хисап биреп бетерә алмастан, сикереп торып, капкага ташланды — озын яшел сарафанлы, яланаяклы чегән кызы тавыкны култык астына кыстырып, болынга, су буена таба чаба.

Ширияздан тик шунда гына чегән кызының тавыкны суалчанлы кармак белән эләктергәнен абайлап алды.

Юк, тавыкны ычкындырырга ярамый.

Әллә ниткән эчке бер инстинкт аңа көч-гайрәт бирде һәм ул, авылдагы иң оста чабышчы, күз ачып йомганчы чегән кызының су буена барасы юлына аркылы төште. Бу дөрес иде. Әгәр ул Иж буена чегәннәр таборына барып житсә, тавыкны түгел, үзеңне дә таба алмассың.

Кызый шундук юнәлешен үзгәртте, болынга таба түгел, авылның басу капкасына таба элдертте. Әллә таборга юлы киселгәнгә, әллә юри Шириязданны котыртыпмы, ул элек чапканыннан күп өлеш тизрәк чаба, аркасында озын кара толымнары атынгалап бара да кояшта янган матур аякларының табан аслары гына жемелдәп-жемелдәп кала иде.

Шириязданда йөгерешчеләр дәрте кузгалды — аңа икенче сулыш килде, һәм ул яшь, сылу, матур аяклы чегән кызы белән узышудан үзенә рәхәтлек таба башлады.

Аның әле бернечә көн элек кенә жанын сыкратып торган тойгы... узышу, якынлык тойгысы белән аралашты. Аралашып кына калмады, аның хәзер чегән кызын куып житәсе, аны беләкләреннән тотып аласы, аның күзләренә карыйсы килде.

Кыз басу капкасын чыккач та туры юлдан чапмады, уңга борылды, якында гына көнбагыш басуы бар иде. Чегән кызы көнбагыш арасына йомылды. Ул кереп киткән урында, көнбагыш сабаклары берберсенә бәрелешеп чыңлап калдылар; һавага, кояш нурларыннан жемелдәп, күңелдә әллә ниткән тойгылар уятып, алтын-сары тузан күтәрелде.

Ширияздан да көнбагыш арасына бәреп керде һәм шул мизгелдә үк ак тавыкның кытаклап һавага күтәрелгәнен, аннары көнбагышлар арасында юкка чыкканын, ә сылу чегән кызының, авызын ачкан көйгә еш-еш сулыш алып, үзен көтеп торганын күрде.

Йөрәгенең дөпелдәп тасырдавын тойган хәлдә, ул көнбагыш сабакларын аударып, чегән кызы янына барып житте, аның көйрәп торган зур кара күзләрендә хәтәр очкыннар кабынуын, нинди нияте барлыгын сизде, ләкин каушамады, курыкмады, дөресрәге — аның каушарга да, ул хакта уйларга да вакыты булмады, сихерләнгән төсле, дөньясын онытып, йотылып, аңа карады, чегән кызының көчле матур беләкләре аны муеныннан кочаклап алдылар һәм үзе өстенә аудардылар.

Ауган чакта чегән кызының изүләре чишелеп китте, кояшта янган шалкандай тыгыз имиләре килеп чыкты. Ширяздан шашынып, кайнарланып, аның күперенке алсу иреннәренә сөлектәй ябышты, мәхәббәт мәсьәләсендә тәҗрибәсез икәнен раслап, мыштырдый, гыжлап, авыр итеп сулыш ала башлады. Көтелмәгән хәлләрдән аның йөрәгенә каплан иде...

Егет бер мизгелдә аңын җуйган иде; аңына килгәндә, чегән кызы, кулларын таратып ташлап, җирдә ята, сарафаны ачылган, бурлаттай янган кара-туткыллы битендә, кара бөдрә чәчләрендә көнбагышның алтын-сары таҗлары җемелди иде.

Шул көннән башлап, Бүре Бадулның уртанчы малае юкка чыкты. Күрше авыл кешеләре, Бадулны якыннан белгәннәр, бер татар малаеның чегәннәр арбасында гитарага җырлап барганын әйттеләр.

Шуннан башка хәбәр-хәтер булмады.

Бүре Бадул, нигә мин аны теге чакта ачуландым икән, нигә үз иркенә куймадым икән дип, бик озак үкенеп йөрде.

## VII

Инде урнашкан урыннары шактый ук уңайлы булса да, инде туганнары Мөхәммәтша абзыйлары йортында матур гына яшәп ятсалар да, инде Зартугай халкы врач Уразаевага тәмам ияләнеп, аны үз итеп бетерсә дә, бирeдән китми булмый.

Татарстанның Сәламәтлек саклау халык комиссариатыннан һәм Республика хәрби комиссариатыннан куйган ике шартның берсенә — йә «Ижминвод» госпиталенә, йә Арчадагы хәрби әсирләр госпиталенә китәргә кирәк иде.

Нурия бу юлы Арчаны сайлады.

Арча, ни генә димә, Казанга якын, аңа Казан — Арча поезды белән ике-өч сәгатьтә килеп житеп була. Димәк, остазы Александр Николаевич Майский белән тизрәк, ешрак очрашырга да җай чыгачак. Ә ул очрашулар Нуриянең докторлык диссертациясе өчен көн кебек кирәк нәрсә. Профессор аның Зартугайдан киңәш сорап язган хатын алган, бик җылы итеп хат язып җибәргән: Арчага кайтуың хәерлерәк булыр, дигән.

Нурияне Арчага тартканы тагын шул — Мисбах Гатауллович Рәхимовны Арча госпиталенә күчерәләр. Нык һәм каты куллы булса да, ул — гадел кеше, кемнең кем икәнен бик тиз танып ала торган, кул астында эшләгәннәрнең кадерен белә торган кеше.

Арча беренче күргән мәлгә Нуриядә бик тә күңелсез тойгы калдырды. Ташлы тауга менеп чумашкан, авыл дисәң — авыл түгел, кала дисәң — таш йортлары юк дип әйтерлек; агач та сирәк; биредә «Ижминвод»тан, Зартугайдан соң ниндидер котсызлык, салкынлык җанны өшетә; бәлки, ул алай да түгелдер, тегендә ни дисәң дә, үз кешеләрең, үз авыруларың, үз яралыларың иде, монда — дошман солдатлары, безнекеләр әсир иткән дошман офицерлары...

Бәлки, юл мәшәкатьләре бик ваткандыр, Арчага килеп, аерым квартирага урнашып, балаларны бакчага биргәч, госпиталь начальнигы Мисбах Рәхимовның һәм аның белән инде ярты елдан артык бергә эшләгән Садыя ахирәтенең якты йөзен күреп, җылы һәм якты өендә

чүкердәшеп кенә бер чәй дә эчеп алгач, Нуриянең җанына җылылык иңде, хәзер инде аңа ялангач тау башындагы Арча да бигүк котсыз күренми башлады.

Тау башыннан тимер юл станцасына шактый матур манзара ачыла — Себер ягыннан килгән поездларның төтен бөрки-бөрки узганнары күренә, тонык кына булып гудок тавышлары ишетелә; язгы ташулардан соң тегермән буасын буганнар — Казан елгасы тулып тора; анда каз-үрдәкләр йөзә, елга тугаендагы болынлыкларда сыер-сарык көтүләре йөри; тормыш, кайдадыр туплар гөрселдәвенә, авыл-калалар яныуына карамастан, гел дә үз җае белән бара.

Һәм ул шулай булырга тиеш тә.

Кешелек җәмгыяте тарихында нинди генә өермәләр булмаган, илләр өстеннән нинди генә яулар узмаган, калалар һәм авыллар, мәчетләр һәм чиркәүләр җир белән тигезләнмәгән — шулай да тормыш сүнмәгән; кайнар кояш астында үләннәр яшәргән, җилләр болытларны тибрәткән, болытлар шифалы яңгырларны яудырганнар, елгалар тулып ташыган, тегермән ташлары он тарткан, элекке авыллар килеп утырган — тормыш тагын үзенең мәңгелек юлын дәвам иттергән.

Хәзер дә шулай булыр. Әнә бит Идел каласыннан нинди куанычлы хәбәрләр килде: безнекеләр легендар каланың һәр йорты өчен, һәр карыш җире өчен кайнар каннарын агызып, көнне-көнгә, төнне-төнгә ялгап сугышлар.

* * *

Озак та үтми, газетада басылган, радиода сөйләнгән сүзләрне раслап, Арча госпиталенә Сталинградта әсир төшкәннәр кайта башлады. Нинди генә милләт кешеләре юк анда — немец, итальян, чех, мадьяр...

Фашистларның концлагерындагы вәхшилеккә капма-каршы буларак, гуманизмның бездә нинди икәнен күрсәтү шарты беләндер инде, тоткыннарны кирәкле рационда ашаталар, җылыда тоталар, ял көннәрендә музыкантларына, җырчыларына тоткыннар алдында чыгышлар ясарга да мөмкинлек тудыралар.

Бу эш госпитальнең начмеды Наимә Байтирәковага тапшырылган. Чит ил кешеләре безнең үз халкыбызның музыкасы белән дә танышсын, безне кыргыйларга санап йөргәннәрнең күзе мангаена менсен әле дип, Наимә ханым врач Уразаевага Казаннан сугышка кадәрге запасларыннан пластинкалар да алып килергә кушты. Әсир төшкән итальян докторы Франзини «Урман кызы»н неаполитан җырларына охшатып, безнекеләр ишетмәгән сокланғыч тавыш белән җырлый башлады.

Лабораториядә фрицлар канын тикшереп утыру гаять моңсу күренеш булганга күрә, врач Уразаева, Казандагы галимнәр-дуслары белән киңәшеп, сугыш чыгу сәбәпле туктап калган фәнни эшен дә дәвам иттерергә булды. Дистрофия белән килүчеләрнең нерв очлары ниндирәк икәнне дә тикшерергә нияте бар иде Уразаеваның, әмма Александр Николаевич әйтте: ул эш белән шөгыльләнмә, капиталистлар моны дөрес аңламаслар, син, Нуруся, үзең өчен кирәкле медицина әдәбияты укы, немецлар белән күбрәк сөйләшергә, немец телен практик рәвештә отып калырга тырыш диде.

Шунлыктан Нурия, госпитальдә кизү торган чакларда, дистрофиклар белән сөйләшкән чакларда, аларны журналга теркәгән чакларда, тәрҗемәче белән түгел, үзләре белән немецча сөйләшергә тырышты.

Баштарак әсирләр моңа гаҗәпләнебрәк карыйлар иде, тора-бара иялашә төштеләр, доктор Уразаевага авыруларын гына түгел, Герман илендә кемнәре торып калган — балаларын, хатыннарын, туганнарын сөйли башладылар.

Немец врачы Шульц доктор Уразаеваның беренче ярдәмчесе булып китте.

Врач Шульц баштарак, әлбәттә, сүзсез иде. Ул врач Уразаева әйткән анализларны ясый, ни политика, ни сугыш мәсьәләләренә катнашми, әмма үз акылы үзе белән икәне әллә каян күренеп тора. Госпитальдә әсирләр кия торган күксел-соргылт халатны да ул пөхтә итеп кия, төз басып, салмак атлап йөри, күрәсең, хәрби муштра мәктәбен дә үз вакытында бик төгәл үтеп чыккан булса кирәк.

Немец докторының ачылып сөйләшкән беренче сүзе шул булды:

— Фрау Уразаева, сезнең ничә балагыз бар? — дип сорады ул.

— Икәү,— диде Нурия.— Доктор Шульц, ул нигә сезне кызыксындыра? — дип, үзе дә сорау бирде.

— Сез — галим кеше. Балагыз да күп түгел икән. Нигә шулай бик арзанлы киемнәр киеп йөрисез? Врачларга сездә шулай аз түлиләрмени?

Нурия баштарак бу сорауны әдәпсезлек дибрәк кабул иткән иде, доктор Шульцның безнең ил турында, безнең халык турында көннән-көн күбрәк белергә теләге барлыгын сизеп алгач, бу сорауның гади бер кызыксыну гына түгеллеген белгәч, чын дөресен әйтеп бирде.

— Социализм илендә бер күч өстен сыйныфлар мәнфәгате өчен яшәмиләр. Бездә һәркемнең матур киенергә, әйбәт квартираларда торырга хакы бар. Ә хәзергә без Гитлер көчләп таккан сугышны җиңәргә, Европа халыкларына азатлык алып килергә тиешбез. Безнең яңа система бик яшь әле, аңа каршы унсигезенче елны барлык империалистлар Антанта корып сугышты, сез безгә баштан-аяк коралланган гаскәр белән басып кердегез. Бөек революция алдыннан безне хәлсезләндердегез. Без промышленностьны, авыл хуҗалыгын аякка бастырып җиткерергә өлгермәдек. Гитлер безгә хыянәтчел төстә сугыш башлады. Йә, әйтегез, Шульц, шулай булгач, безнең матур киенергә, үз-үзебезне кайгыртырга вакыт булдымы?

Докторның нечкә иреннәре кысылган, күзе ярым йомык иде — ул дәшмәде.

Икенче көнне дә дәшмәде ул. Өченче көнне дә. Хәтта дүртенче көнне дә. Килә. Әсир халатын салып, больница халатын кия, ак халат, ак калфак килешә аңа, йөзенә нур кертә, әсирхәленнән чыгара. Күрәсең, ул моны үзе дә сизә иде бугай, лабораториягә керү белән, соры халатын акка алыштырырга ашыга иде.

Ак халатлы Шульц көне буе врач Уразаевага булыша — әсирләрнең кан анализларын ясаша. Ләкин инде бүтән ачылып сөйләшми. Эшен генә җиренә җиткереп, бик төгәл башкара.

* * *

Бер ай шулай бик җитди узды.

Икенче ай башында Шульц яктырып килде. Йөзе дә алсу, күзләре дә түбән карамый. Килгәч тә соры халатын акка алмаштырды, калфагын көяз итеп киеп куйды. Шуннан соң ашыкмый гына соры халатының кесәсеннән газетага төргән кечерәк бер нәрсә чыгарды.

Тураеп басты, әздереп кенә әйтте:

— Фрау доктор, мин сезнең балаларыгызга бүләк алып килдем. Бәлки сезгә әсирләр белән мөнәсәбәттә булырга рөхсәт итми торганнардыр. Түбәнчелек белән гафу үтенеп, минем шул кечкенә генә бүләгемне алуыгызны сорар идем.

Врач Уразаева бер мәлгә икеләнде. Ярыймы соң аңа әсир доктор белән дуслык мөгамәләсендә булу? Ул аңа берәр төрле этлек уйлап килмәгәнме? Алай дияр идең — йөзе бик якты.

Ни булса ул булыр дип, врач Уразаева әсир докторның төргәген алды. Рәхмәт әйтергә ашыкмады. Сүтте төргәкне. Аның эченнән немец халкының атаклы әкиятчеләре — бертуган Гриммнар уйлап тапкан ике гном килеп чыкты.

— Моны сез каян алдыгыз, доктор Шульц?

— Үзем ясадым. Агачтан юнып. Минем пәкем дә, башка коралларым да юк. Әсирләргә бит андый кораллар бирелми. Мин моны пыяла кисәге белән кырып ясадым. Алыгыз, фрау Уразаева.— Ул Нуриягә якынрак килде, нелә төште, әкрен һәм серле тавыш белән пышылдады: — Гитлер капут!

Нурия гномнарны алды, озаклап карады. Курчаклар бик матур, балалар моңа сөенәчәкләр. Рәхмәт әйтте. Курчак өчен булудан бигрәк, әсир докторның икенче бер илгә, социализм иленә, аның докторына булган ихтирамы, якты мөнәсәбәте өчен әйтте рәхмәтне.

Ул да немец докторына таба нелә төште:

— Әйе. Гитлерның муены астына киләчәк. Инде моңа шикләнмәскә мөмкин,— диде. Ләкин ул моны немец докторыннан аермалы буларак, пышылдап түгел, кычкырып, нык ышанып әйтте.

Доктор Шульцның фрау Уразаевага әйтәсе сүзе бетмәгән икән әле. Гафу үтенеп, ул тагын сүз башлады:

— Мин инде сездә бер ел буе әсирлектә. Сталинград эпопеясын күрдем. Сезнең илнең гадел сугыш, азатлык сугышы алып барганлыгына ышандым. Сез әйткән тигез хокуклылык турында да күп уйладым. Әйе, фрау доктор, күп уйладым. Тигезлек бар җирдә дә әйбәт түгел дип уйлыйм мин. Сезнең илнең армиясендә югары чиннар белән солдатларның тигез яшәве миңа ошамый. Администрациядә дә начальник начальник булырга, буйсынучы буйсынучы булырга тиеш. Демократия идарә ителә торган булса гына прогресска илтә. Җитәкчеләр белән буйсынучылар арасында дистанция булмаса, сезнең ил какшаячак. Гитлер капут! — дип, бу юлы кычкырып әйтеп очлады ул үзенең сүзен.

## VIII

1944 елның Яңа ел бәйрәмен Арча госпиталендә чын чыршы куеп, зур итеп үткәрергә булдылар. Майор Рәхимов «Үрнәк» совхозы янындагы калын кара урманга ике йөк машинасы җибәрергә приказ бирде. Бер чыршыны совет хезмәткәрләре өчен Кызыл почмакка куярга, икенчесен әсирләр өчен ишегалдына, госпитальнең эчке зонасына урнаштырып бизәргә әмер ителде.

Көтелмәгән бер хәл приказны җимерә язды. Госпитальдә эшләгән шоферларның берсе — Сталинград сугышларында күкрәге яраланып кайткан, инде хәрби хезмәткә яраксыз дип табылган Айзатулла Сабиров, авызыннан ут чәчеп сөйләшә торган күксел күзле мишәр, чыршы алып кайтуга теше-тырнагы белән каршы төште. Госпиталь начальнигы алдында ук, тартынып-нитеп тормастан, җитмеш җиде катлы итеп сүгенеп ташлады:

— Фашистларга елка алып кайтыргамы? Мин ул мәләвеннәрнең иманнарын, кабер такталарын... Ул ерткычларга, Европаны шакал тавышы белән тутырган кабахәтләргә Тукай урманыннан чыршы апкайтып куяргамы?! Тотсыннар!

Майор Рәхимовның чәчләре үрә торды.

— Ни сөйлисең син, Сабиров? Бездә фашист концлагере түгел. Бездә госпиталь. Аңлыйсыңмы, госпиталь! Үчне солдаттан түгел, Гитлердан алырга кирәк. Бүгенге көн белән генә яшәргә ярамый, водитель. Я-ра-мый! Бетәр сугыш, әсирләрне алмашырга тотынырбыз. Безнең пленныйлар кайтып ни сөйләр дә, немецлар кайтып ни сөйләр? Нигә без фашистлардан үрнәк алырга тиеш? Нигә? Бездә, иптәш Сабиров, бер немецлар гына да түгел бит. Бар немецы, бар венгры, бар итальяны, бар мадьяры, шулай булгач, водитель Айзатулла, авызны без чамалабрак ачыйк, яме? Беребез дә илгә басып кергән килмешәкләрне яраткannан түгел, гуманистик максатлардан чыгып эш йөртәбез. Ә син,

иптәш Сабиров, дөньяда Маркс булганны, Тельман булганны онытып җибәрәсең. Германиядә эшчеләр сыйныфы барлыгын да онытма син.

— Онытма да онытма, имеш! Мин, иптәш майор, йөрәгем эргәсендә немец снарядының ярчыгын йөрткәнемне онытмыйм. Чөнки ул онытырга ирек бирми. Вот! Буран булса да, томан булса да, сызлый күкрәгем. Мин кермәдем немец йортына басып, немец минем йортыма басып керде. Юк, госпиталь начальнигы, аркама өч көпшәле мылтык терәсәң дә, Арча тавы башына бастырып атып үтерәбез дисәң дә барасым юк! Категорически бармыйм. Гитлерчы мародерларга чыршы алкайтып йөрсәм, мин кем булам?! Алар миңа пушка төбәсеннәр, ә мин...— дип, ярсуыннан кызарынып-бүртенеп, буыла-буыла, гыжлый-гыжлый кычкырынды Айзатулла.

Майор Рәхимов тәмле тел белән аңламаган шоферга куркытып-янап аңлатырга исәп тотып карады.

— Слушай, водитель Сабиров, миңа бит сине эштән чыгару хакында приказ язарга туры киләчәк,— диде ул, каш астыннан карап.

— Яз, майор! Берне түгел, унны яз. Симулянт диген, корткыч диген, адәм тәганәсе диген, бармыйм дигәч, бармыйм!

Госпиталь начальнигы эшләрнең катлауланып киткәнен, сугыштан кайткан Сабировны берни белән дә куркытып булмаячагын төшенде. Төптән уйлап караганда, ул хаклы. Немец баскыннарының безгә эшләгән палачлыгын ничәмә-ничә буын совет кешеләре онытып бетерә алмаячак әле. Ләкин чыршыны алып кайтырга кирәк. Совет кешеләренең зур бәйрәме, җиңү бәйрәме якынлашканны аңлатырга кирәк немецка.

Киеренкелектән тирләп чыккан майор, маңгаен учы белән угалап, Айзатуллага икенче яктан якын килеп карарга ниятләнде.

— Ярый, фронтовик иптәш, мин синең җаныңны аңладым. Әсирләргә дигән чыршыны Фәйзи Булатов алып кайта. Аның сугышта булганы юк. Фашист снарядыннан яраланганы да юк.

— Ә мин нишлим? — диде Айзатулла аптырап.

— Син чыршыны үзебезнең персоналга — совет хезмәткәрләренә алып кайтырсың.

— Һы! Ә мин фашистларга кемнең чыршысын куйганны каян белермен?

— Чыршыңа балта белән тамга салып куярсың.

Ләкин Айзатулланың күңелендә утырып торган канлы төер шундый зур, бармаска хакы барлыгын аңлау шундый көчле иде, ул тешен кысып кына риза булды һәм мыгырданып китеп барды.

Майор аны, кул изәп, кабат чакырып алды. Ул кабат гасабилана башлаган шоферга Арча район советыннан чыршы кисәргә алган рөхсәт кәгазен тоттырды:

— Фәйзи Булатовка мин әйткәннәрне аңлатырсың,— диде.

Айзатулла кырт борылып чыгып китте. Майор тәрәзә аша аның йөк машинасын каты үкертеп китеп барганын машина чаттан борылып, күздән югалганчы карап торды.

...Арча күпере төбендә шоферларны өстенә толып кигән Садыя Сафина көтә иде. Яңа ел алдыннан аның Фазылыннан хат килде. Ул госпитальдә яткан (өченче мәртәбә!), озакламый аны чыгарачаклар, гаиләсе янында булырга рөхсәт итәчәкләр. Сикерә-сикерә биерлек сөенеч иде бу Садыя өчен. Әмма шул ук мизгелдә аның күңелен икенче бер тойгы яндырып узды. Фазыл кайтыр, күрешү кайнар булыр. Ә Нурия? Аның бит Солтаны юк. Ул инде еласаң да, чәчләреңне йолкысаң да, кайтмаячак. Шуларны уйлагач, тәне эсселе-суыклы булып китте.

Нииндидер бер яхшылык эшлисе иде бит Нуриягә. Аның яралы йөрәгенә нииндидер дәва табасы иде. Майор Рәхимовның врачларны җыеп, үз ниятен әйтеп бирүе булды, Садыя күңеленә салып та куйды: «Мин дә барам. Бәләкәй чыршы алып кайтам. Нурия балаларына да, үземнең Гөлфирәмә дә менә дигән булыр!»

...Башы-аягы белән кереп чумардай зур толыпның итәкләрен җирдән сөйрәтеп, ике метр озынлыгындагы ямь-яшел чыршы күтәреп кайтып кергән Садыйны балалар «Урра!» кычкырып каршыладылар. Сөенечләреннән нишләргә дә белмичә, сикерештеләр, чыршының ылысларын тотып-тотып карадылар.

Бүлмәгә таралган ылыс исен рәхәтләнеп исни-исни, балаларны көчхәл белән тынычландырып, табын янына утыртты. Утырдылар балалар, тик ашаулары ашау булмады, аннан-моннан гына капкалап, ашап бетермәгән ипи сыныкларын кулларына тотып, табын яныннан ычкындылар. Чыршы янында булу алар өчен дөньядагы иң зур могҗиза иде.

Нурия әле госпитальдән кайтмаган. Садыя чыршыга эләргә дигән уенчыкларны балаларның үзләреннән ясатты. Ул аларга ак кәгазьдән кайчы белән түгәрәкләр кистерде, кызылга, сарыга, яшелгә буятты. Аннары Садыя китаплардан куян, төлке, бүре, аю рәсемнәрен кисеп алды. Кар бөртекләрен ясаган чакта балалар әсәренде, чөнки Садыя кәгазьне катлы-катлы итеп бөкли дә, кайчы белән бер генә урыннан кисә, кәгазьне җәеп җибәргәч, зур, матур кар бөртеге килеп чыга иде.

Нурия госпитальдән төнге уннар тирәсендә генә кайтты.

Түр башында балкып утырган чыршыны күргәч, ул телсез калды.

— Әнекәйгенәем! Әнекәйгенәем! — дип, ахирәте Садыяны килеп кочаклады.— Бу синең эшеңдер инде, тиктормас? Каян башыңа килде бу? Кем алып кайтып бирде бу гүзәл чыршыны?

— Әни! Әни! Уенчыкларны без ясадык.— дип ду килде Сания белән Рафаэль.

— Нурия апа, мин дә ясадым, мин дә ясадым! — дип килеп җитте Гөлфирә.

Кызларның чәч түбәләрендә зәңгәр бантик балкый иде, үзләре бәйрәм шатлыгыннан, моңарчы күрелмәгән сөенечтән алсуланганнар, курчаклар төсле матурлар иде.

— Тегендә ни хәлләр соң, госпитальдә? — дип сорады Садыя.

— И Садыя җаным, әкәмәт анда. Сөйләп бетерерлек түгел. Пленныйлар ишегалды уртасында балкып утырган чыршыны күргәч, башта әсәренделәр, гөж килделәр. Мисбах Гатауллович безнең гаскәрләрнең фронттагы уңышларын сөйли башлагач, тып-тын булдылар. Майор аларны Яңа ел белән котлап бетерүе булды, чыршыда гөлт итеп утлар кабынды. Беләсеңме, Садыя, Арчаның тимер юл станцасы безгә, чыршы бәйрәме өчен, өстәмә рәвештә махсус ут бирде бит...

— Йараббым, тизрәк бетсен иде сугыш, бетсен иде, бетсен иде,— дип такмаклап тезеп китте Садыя.

Бераздан чыршы янында уеннар башланды. Саниякәй, Гөлфирәкәй, Рафаэль, күршеләрдән кергән өч малай, чыршы тирәли әйләнеп, балалар бакчасында һәм мәктәптә откан җырларын җырладылар.

Эчкәреге бүлмәдән өстенә тун, аягына зур киез итек киеп чыккан Кыш бабай нәниләргә, кәгазь капчыкларга салып, өйдә пешергән печенье-прәннек, алдан ук хәстәрләп куйган кәгазьле конфет өләште. Балалардан берәм-берәм шигырь сөйләтте, җырлатты.

— Бәйрәм булгач бәйрәм булсын, уен-көлке, җыр-биюләр тулып торсын! — диде Кыш бабай гөбедән чыккан төсле калын тавыш белән.

Балалар көлештеләр. Кыш бабайның Садыя апалары икәнен алар аңлап алганнар иде инде.

Бәйрәм олыларга күчте. Нурия «Тамчылы гөл» җырын җырлады. Җырлаган чакта күзеннән яшь мөлдерәп тамды. Балалар нигә аның күзеннән яшь тамганны аңламадылар. Чөнки алар «Тамчылы гөл»нең Солтан Айдаров мәҗлес саен җырлый торган җыр икәнен белмиләр иде шул.

Бәйрәмнең тоташ күз яшенә әйләнү куркынычы бар иде. Садыя башына кара бәрхет түбәтәй, иренең зәңгәр сатин күлмәген, кара чалбарын киеп чыкты, Нуриягә өчкеллләп ак яулык бәйләтте. Икәүләп «Эпи-

пә»гә биеделәр. Балалар «егет»нең кып-кызыл чөгендер борыныннан, аякларын ат кебек як-якка атып, сикереп-сикереп биюеннән рәхәтләнеп, эчләре катканчы көлделәр.

Сания белән Рафаэль чыршы тирәсендә җырлап күрсәттеләр. Садыя апалары бик дулкынланды:

— Нуриякәем, кызың бигрәкләр дә матур җырлый, шушы яшеннән, ә?! Сугыш беткәч тә музыка мәктәбенә йөртерсең, яме,— диде.

Нурия, ярар дип, баш какты.

Ул, чыршы төбенә чүгәләп, балалар белән бергә, алар ясап элгән кәгазь уенчыкларны берәм-берәм тотып карап чыкты; карый торгач, түзмәде, күз яше белән елап җибәрде.

Гөлфирәкәй, Нурия апасын кызганып, муеныннан кочаклады. Сания аңардан көнләште, Гөлфирәнең кулын каерып алырга кереште. Сугышып киттеләр. Садыя аларны көч-хәл белән аерды.

Нурия, елагач, бушанып калды. Сания белән Гөлфирәнең икесен ике тезенә утыртты да, иркәләп, моңлы итеп әкрен генә көйләде:

Үчти-үчти, син, балам,
Сине йокларга салам,
Синең йокыңны саклап,
Үзем янында калам...

Бу юлы Садыяның күңеле тулды. Нуриянең балалары әтиләрен беркайчан да күрмәячәк бит инде.

Нурия җырлаудан туктады. Балалар аны әйләндереп алып, тагын үз уеннарына керештеләр.

Садыя тавышсыз-тынсыз калган ахирәтенә игътибар итте. Нурия башын күкрәгенә салып, йоклап киткән иде.

«Арыды, мескенкәем. Уен эшмени — өч ел буена яралылар бага. Ә үзенең йөрәгендә төзәлеп бетмәгән яра...» — дип Садыя күңеле нечкәреп уйлады.

## IX

Яз һәм җәй айлары Арча госпиталендә зур борчулар, мәшәкатьләр белән узды.

Әсирләр арасында көтмәгән бер киеренкелек башланды.

Бу хәл беренче мәлгә госпиталь персоналын — конвойны, врачларны, техник хезмәткәрләрне аптырашта калдырды.

Ул хакта майор Рәхимовка да, начмед Байтирәковага да хәбәр иттеләр. Тәртип сагында җанын аямый торган усал холыклы начмед бик гади һәм бик төгәл бәя бирде:

— Җиңү көне якыная. Сталинградтан кайткан әсирләр, Курск дугасында плен төшкән немецлар фронттагы үзгәрешне бирегә китереп торалар. Менә шул, немец йоклый алмый интегә, сугыш кайчан бетәр дә, пленныйларны кайчан алмаша башларлар икән дип борсалана,— диде ул, иреннәрен кысып.— Гитлерчылар хәзер фюрерларының тизрәк дөмегүен телиләр, безгә басып кергән көннәрен ләгънәтлиләр.

...Нурия лабораториянең ишегалдына караган тәрәзәсе буенда көндәлек эшен башкара — анализ нәтиҗәләрен карый.

Күк йөзен соры болыт каплаган. Күрәсең, җил дә бардыр; яшь каеннар өзлексез чайкала, бәргәләнә. Күңелсез урамда, ямьсез, шулай да урамга чыгасы, хәсрәтләрне таратасы килә.

Доктор Шульц, кулына тоткан пробиркасын киштәгә куеп, Нуриягә дәшә:

— Фрау Уразаева, сезнең башлыклар сизәме, тоткыннар арасында җанлану башланды бит? Нерв системалары чамадан тыш киеренке аларның хәзер. Ә нерв киеренкелеге пленныйларның яралгы хәлендә генә булган кайбер чирләрен көчәйтәчәк. Процедураны бермә-бер арттырырга кирәк булачак.

— Мин аны беләм,— ди Уразаева, урамнан күзен алмыйча.
Урамнан хәрби киемле берәү атлый.
«Кемнендер бәхетлесе исән-сау кайтып килә»,— дип уйлый Нурия.
Шуны уйлап бетерүе була, дежур солдатның ишеккә башын тыгып кычкырган тавышы ишетелә:
— Доктор Уразаева! Сезне комендатурага чакыралар.
— Ник? — ди Нурия, эштән бүленәсе килмичә.
— Лейтенант Айдаров күрергә тели сезне,— ди дежур солдат.
Нуриянең башы әйләнеп китә.
— Нинди Айдаров? Әллә ходаем...
— Зонаның теге ягына чыгыгыз. Ул сезне урамда көтә.
Нурия, нәрсә дип уйларга да белмичә, урамга чыга.
Өстенә өр-яңа яшькелт френч, галифе чалбар, йолдызлы биек фуражка, хром итек кигән, погонында өч йолдыз балкып торган япь-яшь, тап-таза ир-атны Нурия башта танымый тора, таныгач, кулларын җәеп кычкырып җибәрә:
— Әхнәф, син түгелме, балакаем?!
Нурия, шаулап-сөенеп һәм елап күрешкәннән соң, гүя, белеп бетерә алмый калам дип курыккандай, ашыгып-кабаланып, каенишенең хәлләрен сораша башлады. Ул да түгел:
— Карасана! Нигә дип әле без урамда торабыз? Өйгә кайтыйк. Тукта, Әхнәф, беркая да китмә, шушында гына тор, яме,— дип, үзе зона эченә кереп китте, аннан рөхсәт алып, янә дә Әхнәф янына килеп чыкты.
Балалар бакчада, Садыя госпитальдә, икәүдән-икәү генә, чәй янында барлык хәлләрне иркенләп сөйләшергә була.
Өч ел буена пехотада булып, рота командирына хәтле күтәрелгән Әхнәф Айдаров окоплар казыган, блиндажларда яткан, атакага барган. Аңардагы ныклыкка, хәрби форманы пөхтә йөртә белүенә игътибар итте апасы. Әхнәфкә, ничәмә еллар фронтта, ут эчендә булган кешегә, ирләрчә таза чырай кергән, аның үз-үзен тотышында, сөйләшүендә чаялык, шул ук вакытта тыныч тормышны, туганнарын өзелеп сагынуы сизелеп тора.
Сугышка ул үсмер егет булып киткән иде. Олы чырай кергән. Тукта, ул бөтенләе белән Солтанга, абыйсына охшап бара түгелме? Керпе энәләре төсле каты соры чәч, зәп-зәңгәр күзләр... Хәтта өске ирене белән борын арасының беркемдә булмаганча киңлеге дә Солтанны хәтерләтә.
Нуриянең күзләрен сагыш томаны басты. Әхнәф моны сизде.
— Апа, абыйны ник хезмәт армиясенә җибәрдең? Авыру иде бит. Бармаса да, беркем аңа гаеп тага алмаган булыр иде,— диде.
Нурия озак кына сүзсез утырды. Аңа менә ничә мәртәбәләр инде шушы каһәр суккан сорауга җавап бирергә туры килә.
— И, энем...— диде бераздан. Аның аңлатырлык та, җавап бирерлек тә хәле юк иде.
Әхнәф авыр итеп бер көрсенде.
— Син, Әхнәф, Казан аркылы кайткансыңдыр инде. Әкълимәне күрдеңме? Ул ни хәлдә?
— Юк, күрә алмадым, апа. Ул яктан мин гел дә бәхетсез икәнмен. Казанга кайтсам, әйтәләр: врач Әкълимә Айдарованы фронтка алдылар. Сез аның белән фронтта гына очраша аласыз диләр.
Нурия башын селкеп торды, үкенеч белдермәде.
— Кайгырма, энем. Хәтерендәме, сугышка киткән чакта, 1941 елны, хатынымны күрә алмый китәм дип утлар йотып йөргән идең. Мин сиңа әйткән идем, насыйп булса кавышырсыз, дигән идем. Күңелемнән уйладым ул чакта: бәлкем, исән-аман йөреп кайтыргадыр, күрешә алмый китүе хәерлегәдер дидем...
— Әле минем унҗиде көн вакытым бар. Иң әүвәл әти белән әнине

күреп килим. Исәндер бит алар?— диде Әхнәф.— Зартугайга кайтып килергә өлгерәм әле.

— Исән-саулар. Бер кышны Зартугайда үткәрдем, медпункт мөдире булып. Аларда тордым. Сине бик тә сагына инде әнкәң. Өзелә инде, өзелә,— диде Нурия.

Озаклап Зартугайны сөйләштеләр.

Аннары фронт хәлләренә керешеп киттеләр.

— Безнең сугышчыларның күңеле бик күтәренке, апа. Фашисттан кәҗә кәлҗемәсе ясыйбыз дип ясканып торалар. Ләкин ул кәлҗемә кыйбатка төшәчәк әле. Беләсеңме, апа, дошман явыз, мәкерле. Инде барыр җире калмаган бит, алай да сугышсыз гына бирелми. Тәмам сукырайган, үз төтененә үзе тончыккан сурәттә дә һаман котырына: авылларны яндыра, заводларны шартлата, халыкны, хәрби эштә булмаган халыкны суя, кисә, үтерә, әсирлеккә алып китә.

Нурия самавырын яңартты.

— Безнең яклардан берәүне дә очратмадыңмы?

Әхнәф тагын бер мәртәбә авыр итеп көрсенде дә берничә ай күңелендә йөрткән серен әйтеп бирде:

— Хисмәев Каюм абый... теге кем... авылдагы кушаматы белән әйткәндә...

Күзләре зураеп киткән Нурия алга сөрлекте:

— Нәрсә булды? Үлмәгәндер бит Чишмәбай?

Бүлмәдә кабер тынлыгы урнашты. Әхнәф бик озак сүзсез утырды.

— Әллә ярамаган эш эшләдеме?

Әхнәф иренен очлайтып торды, апасының отыры сабырсызлана баруын күреп, ипләп кенә, ерактан уратып сөйли башлады:

— Сугыш зур, тормыш тагын да зуррак икән ул, апа. Кем уйлаган менә пехотада, меңләгән, ун меңләгән кеше арасында Зартугайның ике кешесе очрашыр дип?

— Җанымны талама, әйт: исәнме Чишмәбай?

— Аз гына сабыр ит, апа. Хикмәтле нәрсә сөйлим мин сиңа. Исәнме Чишмәбай, юкмы — үзең шуннан аңларсың.

— Тыңлыйм, сөйләп бетер.

— Фронтта Чишмәбай белән Нух Галләм очрашалар.

— Солтан абыеңа яла яккан Нух Галләм түгелдер бит?

— Нәкъ үзе.

— Китсәнә! Ул да фронтка эләккәнмени?

— Эләккән. Теләмәсә дә эләккән.

— Гафу ит сабырсызлыгым өчен, сөйләп бетер.

— Оборонада ятабыз шулай. Бик каты һөҗүмнән соң, дошман безне көн буе дөмбәсләгәннән соң, позиция бирмичә, нык ятабыз. Минем взводка бер солдатны китерәләр. Трибуналга җибәрәсе солдатны. Карагач, артыма егылып китә яздым — Чишмәбай. Танып алдым, сорыйм, ни булды, мәйтәм. Сорама, энем, булды инде ди. Юк, мәйтәм, дөресен әйт, юкса миннән авылга кайткач сорарлар. Әйтте. Сөйләп бирде ни булганын. Дошман белән кара-каршы атышкан чагында, Нух Галләм алга килеп чыга да әйтә тегеңә: ат ди. Баштарак Чишмәбай аптырый, аңламый — кая атарга? Караса — Нух Галләм беләгенә ике кирпеч ипи бәйләгән, шуңа атарга кушуы икән. Чишмәбай башлы адәм иде бит — аңлап ала моның ниятен. Янәсе, пуля ипи буханкалары аша чыккан чагында, дары исе ипидә торып кала, юрамалый, фронттан котылыр өчен атканны белмиләр. Дошман пулясы тигән дип уйлыйлар. Шул рәвешле Нух Галләм башта госпитальгә эләкмәкче, госпитальдән ансат кына Казанга кайтып китмәкче. Ә Чишмәбай — гадел кеше, моның явыз ниятен белеп алуы була, тота да Нух Галләмнең маңгаена чәпи пуляны. Кадалып кына барып төшә Нух Галләм. Ыңгырашырга да өлгерми, шундук җан бирә.

— Ай аллам... ай аллам...— диде Нурия, башын тотып.— Котылырмы инде ул аннан?

— Котылырмы ул аннан, юкмы — бер хода гына белә...

— Һе... менә син, һе... Язмыш агач башыннан йөрми, адәм башыннан йөри, дип юкка гына әйтмәгәннәр икән. Нух Галләм дә үлемен тапкан икән. Кемнән диген әле? Солтан абыең гына бу көннәрне күрмичә үлде. Һе...— диде теш казналары кысылып килгән Нурия.

Аның күз алдына ике кешелек сак астында трибуналга китеп барган Чишмәбай һәм җирдә, кан эчендә яткан Нух Галләм килеп басты.

## X

*Хөрмәтлебез Нурия Аббасовна!*

*Профессор Голосов, фронттан Сталинградка кайтып, медицина институтына кафедра мөдире булып урнашты. Ул безне, Казан гистологларын, Идел буендагы һәм Уралдагы барлык гистологлар белән бергә, фәнни конференциягә чакыра. Уразаеваны да алып килегез, юкса үпкәләрмен, дигән. Сезгә, Нурусҗ, димәк. Арча госпиталендәге эшләрегез нинди генә тыгыз булмасын, юлга җыенырга туры киләчәк. Илебез өчен кадерле булган кешене, Николай Григорьевичны, рәнҗетергә хакыбыз юк. Аның егерме яшьлек бердәнбер улы Саша Сталинград өчен барган сугышларда танк эчендә янып үлде.*

*Җавап көтәм. Килми калмассыз дип ышанам.*

*Сезгә рөхсәтне Сәламәтлек саклау министрлыгыннан һәм Хәрби комиссариаттан үзем юллыйм.*

*Сезне ихтирам итүче — профессор Майский.*

*20 сентябрь — 1944 ел.*

Хатны Садыя почта ящигыннан алып кереп биргән иде.

Менә хәзер ул ахирәтенең хатны укып бетергәнен, хатның аңа ничек тәэсир иткәнен көтеп утыра.

Күз читләренә җилпәзә җыерчыклар яткан, сугыш елларының билгесе булып ирен кырыйларына калын гына ике сызык утырган, әмма әле һаман мөлаемлыгын югалтмаган Нурия бу минутларда аның өчен иң гали кеше иде.

Ул Сталинградка бара. Хәрабәләр эчендә яткан калага. Ул аны хәзергә ишетеп кенә белә. Күргәч, йөрәгең бозылмасмы? Әнә бит хәзер үк, легендар каланы күрмәс борын ук, анда бару хакындагы хатны уку белән үк ничек каушады. Җүнлелеккә булыр микән андый каушаутетрәнүләр?..

Садыя тамак кыргалады. Нуриянең алсуга капкан йөзенә янә дә бер мәртәбә күз сирпеде.

— Барасыңмы?

Ахирәт дустының кинәт төбәлеп карап торуыннан һәм көтелмәгәнчә йомшак итеп, аның өчен борчылып сорап куюыннан Нурия уңайсызланды.

— Нишлим икән соң? Балаларны кайда калдырырмын? Әгәр барсам дип әйтүем?..

— И җүләркәем! Бала дигән була. Шундый остазларың олылап чакырып торалар икән, бармый калалармыни?! Балаларың кая китсен, үзем карап торырмын. Кайгырма, җил-яңгыр да тидермәм мин аларга.

...Юлда коллегалары белән әңгәмә корып, пароход палубасында шактый ук тыныч килгән профессор Майский, Сталинград панорамасы офыкта калыккач, кинәт алга сөрлекте:

— Атакай гынам! Шәһәр калмаган бит монда!..

Картның тавышы шундый да шомлы иде ки, гөр килеп сөйләшеп барган врачлар кинәт тынып калдылар.

Алар каршысына күз күреме җирдә Идел ярлары буйлап сузыл-

ган хәрабәләр өеме калыкты. Бөек елга ярында алтмыш чакрымга сузылган яшел һәм төзек каладан бернәрсә дә калмаган иде.

Ярга чыгып, элек урам булган урыннардан уза башлагач, алар җан өшеткеч күренешләргә тап булдылар. Бер генә кабыргасы исән калган дүрт катлы кирпеч йортның стенасында штукатуркасы купкан урыннарда кызыл кирпечләр канлы яралар сыман күренә, аста — көл өеме арасында — урталай ярылган кара рояль аякларын өскә күтәреп ята; адым саен — хәрабә, адым саен кара күмер, тырпаеп калган морҗа. Стеналары җимерелгән йортларның да тәрәзә уентыклары кабер авызы кебек ыржаеп тора; урам чатларында трамвайларның үләксәләре ауный — пуля аларның калаен иләк кебек итеп чәрдәкләп бетергән...

Ярабби, бу хәтле ватык-җимеректән арынганчы, боларны янә дә сугышка кадәрге рәвешенә китергәнче тагын бер мәртәбә сугыш утын кичеп чыккан хәтле гаҗәп чигәсе бар икән әле.

Сугышның аяусыз корбанын — шәһәр чаклы шәһәрнең аяк астында аунап ятуын күрү һәммәсен дә өнсез калдырды. Өсләренә траур ябынгандай, башларын аска иеп, сүзсез атладылар.

Казан делегациясен каршы алган врач-капитан, көр тавыш белән исәнләшеп, хәлләрен сорашкач, аларны үзе белән алып китте. Бераздан аларга шактый ук өметле күренешләр дә очрый башлады. Шәһәрнең югары очына урнашкан атаклы Трактор заводы, хәрабәләр арасында үзенә оя корып, инде эшли дә башлаган. Урамнарны урыны-урыны белән көлдән арчыганнар. Анда трамвайлар йөри.

Гаҗәп хәл: әллә дөньядагы иң шәфкатьле кешеләр — врачлар әзерли торган урын булганга, мединститут бинасы исән калган. Аңарда үз тәртибе белән укулар бара. Тик әле студентлар якындагы авылларга бәрәңге алырга киткәнлектән, тулай торак бөтенләе белән диярлек буш иде.

Кунаклар шунда урнаштылар.

Профессор Голосов та шунда яшәп ята икән. Казан делегациясен ул үзәк өзгеч дәрәҗәдә дулкынланып каршы алды, берничә секунд сүзен әйтә алмыйча, тотлыгып торды.

— М-менә... Александр Николаевич... минем улымны да үтерделәр. Хатыным больницада ята, Сашаның һәлакәтеннән соң аякка баса алганы юк...— диде хәлсез тавыш белән.

Майский аны күкрәгенә кысып, баласы кебек итеп юатты.

Делегация тып-тын басып торды.

Голосов үзгәргән: Казанда чакта сакалсыз иде, сакал үстергән, куе җирән төстәге көрәк сакалга буй-буй чал йөгергән, зур туры борыны яныннан тирән бураз налар сузылган. Кайчандыр озын төз гәүдәле, балкып торган зәңгәр күзле интеллигент егет бөкрәя төшкән, ябыккан, кыскасы — вакытсыз картайган иде.

Хатын-кызлардан ул беренче булып Уразаеваны күреп алды. Аның белән күрешеп, битеннән өч мәртәбә үпкәннән соң, саран гына елмайды:

— Минем авыр көннәремдә якын итеп килгәнегез өчен бик зур рәхмәт, Нурия Аббасовна. Кайгыгызны ишеттем. Түзәбез инде. Түзми кая барасың...— диде.

Нуриянең күңеленә Голосов Казанда бергә эшләгән заманнардагы кебек үк якын булып, бу юлы тагын да мөлаемрак булып урнашты.

Конференцияне иртәгесен ачтылар. Председательлек итүче Голосов эшне күтәренке рухта башлап җибәрде. Бүген аның чыраена күз салган кешеләр, бу бит күптән түгел генә авыр кайгы кичергән дип әйтерлек түгел иде. Күрәсең, өч елдан артык фронт шартларында яшәү, чамасыз күп үлемнәрне, янгыннарны, яралыларны күрү, үз кулы белән йөзләгән операция ясау аны кирәк чагында сабыр да, батыр рухлы да булырга өйрәткәндер...

Конференцияне тыныч еллардагы кебек, озакка сузып, җәелеп үткәрмәделәр. Сугыш заманы кыскалыкны, төгәллекне таләп итә иде.

Голосовның утырышны ачкандагы бик төгәл сүзеннән һәм галимнәрнең җыйнак чыгышларыннан Нурия бер нәрсәне аңлады: гистологлар эшли торган өлкә, нерв җепселләре белән бәйле булу сәбәпле, ил күзен төбәп алардан ярдәм көтә. Таушалган нервларны үз урынына утыртканчы, сугыш яраларын дәвалап төзәткәнче, ай-һай, күп вакыт кирәк булачак әле.

Димәк, гистологларга сугышка кадәрге елларга караганда да күбрәк эшләргә, көне-төне, ару-талуны белми эшләргә, невропатологларның, хирургларның, терапевтларның нәтиҗәле эше өчен алдан юл ярып барырга кирәк булачак. Дәвалауның яңа ысулларын, препаратларның эффектны күбрәк бирә торганнарын уйлап табу өчен, күрәсең, беренче чиратта нерв күзәнәкләрен, нерв системасының эшен яхшы белергә кирәк. Бу өлкәдә ике кала — легендар Сталинград белән тыл каласы Казан аеруча күп эшләргә, дуслыкның, кулга-кул тотынып эшләүнең үрнәген күрсәтергә тиешләр.

Нурия, конференциядә ишеткәннәрне күңеленнән үткәреп, үзалдына уйланып утырды. Әле кайдадыр туплар шартлый, калалар җимерелә, яралылар ыңгыраша, ә биредә, дошманга җимергеч ударны ясап, үзе көл өеме булып калган Сталинградта, инде җиңү көннәреннән соң булачак тыныч тормышны кайгырталар. Менә боларны доктор Генрих Шульц башына сыйдыра алмас иде, мөгаен...

Голосов куйган, Майский, Терегулов, Иванов, Имамбаевлар яклаган тезис: с у г ы ш т а н  с о ң  с ы н ы к  к ү ң е л л ә р н е  д ә в а л а у  м ә с ь ә л ә с е бөтен зурлыгы белән врачларның күз алдына килеп басты.

Ул хактагы сүзнең дошманга тез чүкмәгән, аның кояшын баеткан Сталинградта әйтелүен, моның сәяси һәм әхлакый әһәмиятен алар бик нык төшенделәр.

Кичен, конференция ябылгач, Голосов галимнәрне үзенең лабораториясенә чәй эчәргә чакырды. Әйе, бу чын мәгънәсендә чәй мәҗлесе, мәй мәҗлесе түгел иде. Әкрен генә сөйләшеп утырдылар. Сугыш заманының авырлыкларын тешләрен кысып үткәргән кырыс холыклы, нык ихтыярлы кешеләр һәр көнне безнең гаскәрләрнең яңа калаларны азат итүләренә, инде илебез чикләрен узып, Европага килеп чыгуларына сөенәләр, тыныч көннәрдә, тыныч шартларда башкарачак эшләрен күңелләреннән барлыйлар иде.

Кемдер җыр башлап җибәрде:

Вьется в тесной печурке огонь,
На поленьях смола, как слеза.
И поет мне в землянке гармонь
Про улыбку твою и глаза.
О тебе мне шептали кусты
В белоснежных кустах под Москвой.
Я хочу, чтобы слышала ты,
Как тоскует мой голос живой...

Хатын-кызларның пәрәвез җебедәй нечкә, нәфис авазлары һаман өскә, һаман югарыга күтәрелә; ирләрнең калын, бәрхеттәй йомшак моңнары, ул нәфислекне саклап, озата бара, сөйгән ярларның еракта, үлемнән нибары дүрт кенә адымда булуы үзәкләрне өзә; солдат окопларыннан тылдагы калаларга, авылларга хәтле кайтып җиткән җыр бирегә җыелган кешеләрнең алгы көндә дә дус булырга, күмәк көч булып тупланырга, ил язмышын бергәләп күтәрешергә ант итешүләре кебек яңгырый иде.

*Икенче китап тәмам.*

*1980—1985.*

*Казан — Переделкино — Казан.*

# Рәшит Гәрәй

## Ник яшерим

Уйнап кына яшәрмен, дип,
Килгән идем дөньяга.
Әллә үзем болганамын,
Әллә дөнья болгана.

Тау-тау дулкыннарын кайчак
Китереп бәрә иңнәргә.
Ник яшерим, бөтенесен
Көчем җитми җиңәргә.

Кемгә хаҗәт, бирешмим, дип
Үз-үземне мактавым.
Булмыймыни кәтмәгәндә
Сыгылып төшкән чакларым?

Ә дөньяга нәрсә аңа,
Кычкырып көлә генә:
— Тормышта син уйнап түгел,
Көрәшеп яшә менә.

Җимереп яшә заманның
Иң кырыс киртәләрен.
Кичләрең болытлы булса,
Аязыр иртәләрең.

Күңел күзең зәңгәрләнер,
Кояшың чыгар балкып.
...Нинди тылсымлы сүзләр бу,
Торгыза мине тартып.

Кабат аягүрә басам,
Офыкка теким күзем.
Туган җирем, бу бит синең
Үз итеп әйткән сүзең.

Бу дөньяда сыкранмыйча
Яшәүләргә җитәме?
...Ишелгән яр өстендә дә
Кошлар сайрый бит әле.

---

РӘШИТ ГӘРӘЙ *(1931) — шагыйрь, «Җырчы камышлар», «Тальян гармун», «Синдә калам» һ. б. шигырь китаплары авторы, Татарстанның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

## Кыюлык бир, җырым

Буең кыска булгач, кирәге юк
Бәхәсләшеп-нитеп торуның:
Колоннада һаман әүвәлгечә
Арткы рәттә минем урыным.

Яшерен-батырын түгел, кайчагында
Туры килә шактый авырга:
Әзер түгелмен мин дуслар белән
Бер аякка атлап барырга.

Ялгыштырган саен адымымны,
Маңгаемнан бәреп тир чыга.
Охшатамын шунда үземне мин
Хәлдән таеп барган юлчыга.

Алдагылар тамак кырып куя,
Үртәләдер миңа алар да.
Кыюлык бир, җырым, күтәрелеп
Күзләренә туры карарга.

Гозерләнеп сорыйм, мондый чакта
Кыен хәлдә мине калдырма:
Тыгыз шеренгалар аша уз да
Канат җилпе сафлар алдында.

Арткы рәткә баскан өчен генә
Урыным соң нишләп буш булсын!
Дусларымның уртак җырларына
Минем тавышым да кушылсын.

## Утыз өч чакыру кәгазе

Илемнең гел шулай хәвефле
Булырмы таңнары, кичләре?—
Тынгандыр, дисәк тә сугышның
Туктарга юк әле исәбе.

Кан эчеп симергән аждаһа
Яткан да кешелек юлына,—
Иң таза ирләрне үзенә
Йөзәрләп, меңәрләп суыра.

Июньдә, июльдә агылды,
Юк иде авылымның кемнәре?!
Калганнар ашыкты басуга —
Борчакның өлгергән көннәре.

Санадым, утыз өч чалгычы
Тын гына тезелде бер рәткә.
Җир буйлап сузылган фронтның
Бер очы тоташкан йөрәккә.

Әйтерсең, фронт ул башлана
Авылның тузанлы юлыннан.
Һәм уза бәләкәй урманлы,
Чишмәле басулар турыннан.

Әнә ич барысы шул якка
Текәлде, турайтып билләрен...
Авылдан ашыккан җайдакның
Беләләр ни өчен килгәнен.

Утыз өч чакыру кәгазе...
Кирәкми бүтәнне юрарга...
Берсе дә өлгерә алмады
Башлаган покосын чыгарга.

Кайгымны яшермим дигәндәй,
Кояш та болытка күмелгән.
Утыз өч чалгычы берьюлы
Кузгалды басулар түреннән.

Бер көнгә утыз өч... Зар елап
Соңгы кат чыңлады чалгылар.
Киттеләр... Олы юл чатында
Арышлар боегып калдылар.

Тормышың намусың кулында,
Гомереңне ил гомеренә ялгыйсы.
Изге яу кырыннан әйләнеп
Кайтмады утыз өч чалгычы.

Утыз өч сугышчы... Туган җир
Онытмас аларның берсен дә.
...Моңнары мәңгегә тирбәлер
Покослы басулар өстендә.

## Язлар җитте менә...

Чәчләремә ап-ак бәсләр кунды
Салкын төннәрендә кышларның.
Ә мин юләр, язлар житкәч алар
Эрер әле, диеп ышандым.

Кеше күңелендә һаман шулай
Өмет яши, өмет сүрелми.
Язлар җитте менә... Ә чәчемә
Кунган бәсләр һаман эреми.

## Йолдызлар санадым төшемдә

Йолдызлар санадым төшемдә,
Калдырмый санадым берсен дә.
Арадан иң якты дигәнен
Кадарга теләдем түшеңә.

Күз генә кысты да сүнде ул
Үрелеп алырга дигәндә.
Ә калган йолдызлар, әйтерсең,
Мыскыллап көлделәр: «И бәндә...

Буйларың җитәрлек түгел шул,
Күр менә, без нинди биектә!
Беркемгә буйсынмый йөзәбез
Иге юк, чиге юк киңлектә.

Ымсынып, кызыгып карыйсың —
Талларга, тауларга басып та.
Сабыр ит, син безне сөйгәнең
Түшенә кадарга ашыкма».

...Төштәге йолдызлар нәрсә ул,
Өнендә яктырып янмаса.
Тормышым юлында син үзең
Иң якты йолдызым лабаса.

Йолдызлар биек бит, димә син,
Уйлама, оныт ул турыда:
Рөхсәтем юк сиңа бу җирдә
Йолдыздан түбәнрәк булырга.

## Көзге яфраклар

Уйланып барам тын гына
Урман юлыннан атлап.
Юлда сап-сары яфраклар,
Үтәсем килми таптап.

Әйтерсең, сагыш-моңнары
Урала хисләремә.
Сагаеп кына сүз кушам
Иелеп өсләренә:

— Ничек курыкмадыгыз сез
Яңгырлардан, салкыннан,
Ник,— димен,— иярмәдегез
Очар кошлар артыннан?

Кар астында кышлаулары
Түгелдер бик үк уңай...
Кыштырдап шунда яфраклар
Җавап кайтара бугай:

— Саубуллашып, каңгылдашып
Казлар очкан чакларда,
Җилләр очырмакчы булды
Безне ерак якларга.

Ә без менә сүз куешып
Каршы тордык җилләргә.
Җиргә төшеп түшәлдек тә...
Калдык туган илләрдә.

## Бик бәхетсез кеше булыр идем

Юк, дуслар, мин көнче малай түгел,
Мактансам да була ул яктан.
Кеше бәхете минем күңелемдә
Матур хисләр генә уяткан.

Кеше бәхетен күреп шатланганда
Үз бәхетем калган бер читтә.
Әйтә идем: «Шушы гадәтемне
Саклый алсам иде ничек тә».

Әллә нишләп китте әле күңелем,
Ят бер аваз чыңлый аңымда.
Көнчелеккә хас бер хис уянды
Басуларда йөргән чагында.

Сабан көйләүләрем искә төште,
Күз алдыма килде үткәннәр.
Ерак сузылып киткән буразнаны
Ник мин түгел, сыза бүтәннәр?

Маһирлыгым юкмы җир сөрергә?..
Бәхәсләшик, әйдә, алдасам.
Бик бәхетсез кеше булыр идем
Шундый уйлар белән янмасам.

## Тауларым да иңгән

Шул ук сукмак... Шул ук чишмә...
Шул ук ярлар бит болар.
Ә арырак нинди вак-вак
Үрләр калкып чыктылар?

Андый үрләр юк иде ич
Без бәләкәй чагында.
Сорау белән юлдашыма
Текәләм мин тагын да.

Ә ул әйтә:— Ансын инде
Үзләреннән сорарсың.
...Күптән белгән тауларым ич,
Ник танымый торам соң?

Әнә ич үзем тирбәлгән
Сиртмәле миләшләрем.
Ник киттем ташлап, ник киттем,
Тотмыйча киңәшләрен.

Алар да утыра боегып,
Үксез балалар кебек.
Таулар кичерәя диеп
Уйламый идем әлек.

Заман җиле аларга да
Төрле яклап искән шул.
Таулар да иңгән... Таулар да
Картаялар икән шул.

# Рәдиф Гатауллин

## ТУЛПАР АТНЫҢ ТОЯК ҖИЛЕ

●

Ничек уйланмыйсың?
Тере затың,
Кеше дигән атың булсын да —
Һәр күзәнәгең — уй, ә ул уйда
Дөнья булып атом тулсын да?

Тамырыңда һәр тибешең сорый:
— Яшәү асылын син таптыңмы?!
Әйләнә Җир — һәм һәр әйләнеше
Үлчи, саный синең вакытыңны...

Уза гомер... Галәм белән тоташ
Һәрбер көне, хәтта мизгеле...
Ничек уйланмыйсың? Шул киңлектән
Эзләрләрме синең эзеңне?

Нәтиҗәләр кирәк...
(Тәҗрибәләр
Чоры үткән...) Кайда ахыры?!

Лампада май кебек кими мәллә,
Я артамы кеше акылы?...

Акыл арта микән?! Хәвеф арта,
Кыл өстендә бу Җир язмышы...
Ничек уйланмыйсың? Афәт килеп,
Харап итсәк аны ялгышып?..

Без галәмдә — бөртек.
Ләкин нинди?
Гади тузанмы, я алтынмы?
Барыбер, син алтын Яшәү өчен
Җаваплы бит, Адәм акылы...

Уйның торган түгел, уйлый торган
Атом белән җаның тулсын да,
Уйланмассыңмыни?
Тере затың,
Кеше дигән атың булсын да!

---

РӘДИФ ГАТАУЛЛИН *(1941) — шагыйрь, «Гөлләр су сорый», «Ирләр булыйк», «Чакыру» һ. б. татар һәм рус телләрендә уннан артык шигырь китабы авторы. Татарстанның атказанган культура хезмәткәре. Казанда яши.*

Кемдер, Хыял, бүгенгеңне мактый,
Ә мин синең горур яшьлек яклы!—
Көчле иде бит ул, югары...
Мин дә бурычлыдыр аңа:
Рухны
Әйдәп, биеккә ул чыгарды...
Яңа күтәрелеш дип танылган
Алтмышынчы еллар Хыялын —
Сине — яшьлек аша сагынсыннар...
Тугры аңа минем уйларым...
Илдә күпме үзгәрешләр, җырда —
Тулпар иде безнең, ирекле...
Еллар аша килә тояк җиле,—
Юкса вакыт сабыр ир итте...
Яну, ярсу түгел элекке:
Бәйгеләргә ашкынган чак үтте!
Кемнәрнеңдер һаман күрәсе
Килә безнең җилеп узганнарны...
Ә кемнеңдер килә: «...Үшәнләнде
Күптән алар, күр!— дип көләсе.—
Узган дан хакында бәхәсләшеп,
Яши алар хәзер»,— диясе...
Аяусыз шул вакыт!
Тулпар түгел,
Бездә, бәлки, чынлап йөк аты?!
...Яшьлегеңне сагынам — шул елларга
Килик, Хыял, тагын бер кайтып?!
Яңа йөрәкләрне биеклеккә
Кемнең омтылышы чыгарыр?!
Кабатланмасмыни андый яшьлек?!
Күңелдә ул...
Сүнмәс чыраг ул!

Җир — гаҗәеп...
Балкый кеше аңы,
Йолдызларга хәтта юл алып;
Якты нурга охшаш гомерләр бар,
Кешеләргә охшаш — хыялы...
Гомерләр бар — җирне шашып сөйгән.
Һәр карышын — туфрак, чирәмен
Сөю тылсымында яшәртүче,
Илһам итеп хезмәт, тир тәмен.
Күпме гомер — кешеләргә шатлык,
Үкенечле түгел үтсә дә:
Ул җыр булып һәм нур булып калган,
Җыр, нурны чор биек күтәрә —
Чын мәхәббәт белән сугара ил...
Дөнья әнә шулай бара күк...
Матур кебек... Ә соң каян анда
Яман таплар?
                    Каян каралык?

Бар бит шундый җаннар:
Бар шөгыле

Кара ягу аклык, сафлыкка.
Үч һәм мәкер белән сузылалар
Дошман күреп, кемгә?— шатлыкка.
Акылыма барып җитми — күрәм:
Агу җыя алар гөлдән дә...
Югарылык өчен
Дошман күреп
Өстериләр җырны түбәнгә,
Яла, мәкер белән аулап аны...
Балга дегет сала — болгата,
Матурлыкка кушыла алмый, шуңа
Ачуыннан яши ырлап ла...
Нинди ялгыш белән яралган ул,
Нинди ләгънәт узган каныннан?—
Туганда ук гүя, әмер булып,
Изгелеккә ишек ябылган!
Тик каралык, явызлыктан әгәр
Гөлләр үссә? Алар кем өчен?

...Дөнья камил кебек...
Тик кешеләр
Аңлый белсен, дибез, бер-берсен!
Уртак максат өчен яши белсен,
Балкыр сөю — уртак бәрәкәт...
Тик ул кояш түгел мәллә,
Нурын
Тигез сипми мәллә мәхәббәт?!
Яхшылыктан мәхрүм, без белмәгән
Ниндидер көч җирдә бар төсле —
Каралыкны сөйгән явыз бер көч,
Кара күрәлмидер ак төсне...

Кем гаепле моңа!
Синме, акыл?!
Нидән сәбәп?
Ә ул — бар төсле...

●

«Үпкәнеңнән бирле»... Тукай сүзе
Күңелемдә иде...

Сагынганда сине, әнкәй, хәзер
Мин дә шулай димме?!
Ә бит үбәлмәдем, соңгы юлга
Озатканда сине,
Тартындым мин — кырык яшьлек улың!
Инде кабатлыймын:
— Киткәнеңнән бирле...

Синең җаның күккә ашкан сәгать
Гомеремне дә кыл урталай бүлде,—
Элеккечә була алмам хәзер:
Үзгәртте ул мине!
Элеккечә ярата алмам кебек
Кешеләрне:
Нидер ирек бирми
Киткәнеңнән бирле!

Әнкәй!
Дөнья иминлеге гомер буе
Күңелеңдә иде.
Иң изге ул догаң миндә бүген —
Гүяки син васыять итеп бирдең:
— Сакла, диден, Җирне!
...Киләчәккә алып барыр — хәзер
Шул яшәтер мине:
Дәвам итәр йөрәк синең уйны —
Киткәнеңнән бирле...

Беләм:
Җир хәстәре кучкән маңгаема
Беренче кат мине
Үпкәнеңнән бирле!

●

Әтисезлек... Юк, ятимлек димим:
Безне кеше иткән әнкәмнең
Рәнҗер рухы...
Читләмәде Бәхет —
Язмышыма рәхмәт әйтәмен...

Ләкин бүген сәер бер хис миндә:
Ятим хыял һәм моң... бар бугай...
Көчле, матур, бәлки,
Ләкин боек:
Түрдә түгел урыны,
Тар бугай...
Бәргәләнә очар өчен, гүя,
Тели биеклеккә ашарга;
«Син — үксез бит...» дигән тойгы
Бирми
Горур булып күкрәп яшәргә...
Нидер югалткан да, читләтелгән,
Аерганнар Бәхет-әнкәсеннән,
Тумыштан ук, гүя, ятимә,
Төшенке бер рух яшеренгән аңа,
Кимсенүле хис бер, хатирә...
Башкалардан, юк, ким түгел:
Тигез
Яратылышында...
Тормышта
Бер каһәрме төшеп арыналмый
Гүяки, бер фаталь каргыштан.
Сәбәп нидә? Кайчан ялгышкан?!

...Тарих! Дәвамында — бер сынса да,
Югалса да, терәк-Ватанын
Кабат табып күтәрелә алган
Хыял, моңнар азмы?
Көн саен
Калка алар барлык кыйтгаларда
Язмышына каршы, мөгаен?!—
Тулы хокук даулый алар үзенә,
Бәхет яулый һаман...

Әнкәем,
Ятим моңлы түгел җырым, рәхмәт!
Бар дөньяга хасмы бу мәрхәмәт?!
Юкка мәллә уем,
әйткәнем?!

●

«Кайт, и нәфсе мотмәиннәм!...»[1]
Рухым,
Кайтчы син дә тизрәк —
чынлыкка —
төп «тәңре»ңә!

Кире кайткан кебек
Шау-шудан соң гамьле Тынлыкка —
Бабайларның туфрагына кайт син:
Гөнаһ сарган тәнне,
тезләнеп,
Өр-яңадан яңарырга кайтар,
Ачылырга, соң кат үзгәреп...

Кайт чынлыкка!
Туфрагыннан башка
Кем соң уңган, булган канәгать?!
Зур бәхеттер — китсәң, кайта алу,
Кайтыр урының булу — сәгадәт...
Бөек шагыйрь васыятеннән чынлык
Бәлки шулдыр? Туфрак-тәңресе
Яңарышка гүя чакыра җанны,
Ишетәлсәң аның әмерен син:
Чакыра ул гомер чишмәсенә,
Артта — диңгез, давыл, сәясәт,
Болганган хис... Әмма алда — пакьлек.
Изге, таза, рухи сәяхәт!
...Соң булганчы, аңла хакыйкатьне,
Рухым!
«Тәңре»ң — Олы Гамьгә кайт!

## Язмыш-каләм

Әллә саба җиле,
Әллә сәлам иде —
Синнән килде иртән:
Боекмаска кушкан,
Онытмаска кушкан
Сүзең килеп җиткән!

Илһам теләүче хат,
Азрак көнләүче хат,
Ялкын тулы мәгәр,
Гади генә сүзләр,
Әмма синең хисләр —
Күңелеңнән хәбәр!

---

[1] Кайт, и нәфсе мотмәиннәм — кайт, и тынычлык тапкан күңелем. Г. Тукайның «Васыятем» шигыреннән.

Жырда кылларымның
Ерак яңгыравын
Күптән көтәсең, яр!
— Язмыш каләмнәре,—
Дисең,— безгә дә әле
Тиңсез бәхет язар!

Сагынудан безнең
Уртак бәхетебезнең
Моңы шундый яңгырар!—
Язмыш каләм үзе
Безгә язар сүзен
Шул моңнарда табар...

И, яр, теләктә кал!

## Яшәү җыры

(СУРӘТ)

Бөтен гәүдәң рәхәтлектә талган —
Оеп калган... Чәчләр таралган
Тузгып, тетрәнүле күкрәкләргә —
Алар хәлсез, читкә караган,
Оялгандай... Каян яралган
Бу халәтең? Ләззәт булып синнән
Дулкынмы узган? Әллә нур яуган —
Авырайткан бөтен вөҗүдеңне,—
Бәхет мизгеленнән ни калган?!

Бу хәлеңдә син тәхеттә кебек,
Куллар әнә төшеп салынган...
Аякларың көчсез, хәрәкәтсез...
Тик елмаю йөзгә язылган:
Җиңелү, юк татлы җиңү төсе!
Сүзләр кая китеп югалган
Наз кичерешеңдә?— ...Күзләр исә
Ярым йомык... Рухың юл алган
Бәлки күккә? Теләкләрдән азат
Тәнең, арган... әллә армаган?!—
...Хавабыздан мирас халәт бәлки,
Мәгълүм Данаядай сурәт бәлки?—
«Алтын яңгырдан соң хәл алган...»

Хава-әнкә! Чынлап та син Адәм
Кабыргасыннанмы яралган?!—
Без бит синнән... Синнән — матурлыктан
Яратылган! Яшәү, җан алган!
Син һәр гүзәл җенес-оныгыңда
Кабатланасыңдыр яңадан?!

Бөек мизгел! Әлмисактан күпме
Җаннар синнән бәхет табалган,—
Син һаман шул: гади һәм илаһи!—
Яшәү җыры... Ә кем язалган
Сиңа — мәхәббәткә лаек сүзләр?
Мин дә гаҗиз...
Мин дә — табалмам.

Миргазиян Юныс

# ТАҢДА БОСФОР АША

ПОВЕСТЬ



Мин һаман «Вега»ны саклыйм. «Чолман» диңгездә. Бер тәүлек җилкәнле корабта, ике көн китапханәдә утырам. Вакыт уза. Китап дөньясында яшим. Шул арада җиргә яз килгән. Көләч көньяк язы. Ак акация чәчәк аткан. Шәһәр урамнарына чиләкләп исле май сибеп киткәннәр диярсең. Хуш истән, язның тылсымлы һавасыннан баш әйләнә. Яз сулышы йөрәк тибүен ешайта. Һәр яңа яз безне яңадан тудыра. Яздан соң син икенче кеше. Яз — табигатьнең зур бүләге. Яз — кышкы суыкларга, кояшсыз яшәүгә түзгән өчен бирелгән бүләк. Яз сине балачак куанычларыңа кайтара.

Кала язын Караяр язы белән чагыштырып карыйм. Монда бөтенләй икенче яз. Дөрес, яз килгәч, монда да һава көннән-көн җылына, кояш көннән-көн яктыра тора. Монда да язгы нурлар йөрәктә астыртын ашкыну, ямансулык уята. Монда да яз, безнең Караярдагы шикелле, тау битләрен кардан әрчеми. Боз кузгалу, ташу китү дә юк монда. Кичләрен җылы яктан кайткан каргалар инеш буе өянкеләрендә базар ясап шаулашмыйлар. Тагын бер-ике көн үтә. Кинәт яңа, яшел күлмәк киеп, шатланып утырган агачлар очрый. Әле мартта гына дулкын тавышы зәһәр, кыргый иде. Хәзер алар йомшак, моңлы яңгырый. Аның таш йортларны, таш җәйгән урамнарны үзгәртергә көче җитми. Икенче карауда шәһәр язы, акыл утырткан җәйгә әйләнеп, кырлар, яланнар турында кайгырта башлый.

Авыл язы башка төрле. Ул чын, табигый яз. Авыл язы кар эрүдән башлана. Беркөнне тау битенә төс керә башлавын күреп гаҗәпләнәсең. Тиздән авыл артындагы урман кардан арынып, күкшел төскә буялган була. Кинәт моңа кадәр бары тик алтынчы «А» классында укучы гына булган бер нечкә сыйрак күзеңә гел икенче яктан ташлана. Элек ул синең белән пионерлар слетында янәшә утырган бер җан иясе генә иде. Моңа кадәр ул кыз шәүлә генә иде. Баксаң, аның битләрендә сипкел бар, ул сипкелләр аңа килешә. Ә иреннәре? Ә керфекләре? Бүген син аның дөньяда барлыгын һәм кызлар затыннан булуын тәнең һәм җаның белән сизә башлыйсың. Ярларга бәрелеп, ташу ага. Боз китә. Төннәрен ташу тавышына кушылып, тальян гармун елый. Һәм көннәрдән беркөн-

---

Ахыры. Башы 1 нче санда.

не зәңгәр һавада тирбәнә-тирбәнә сайраучы тургай авазын ишетеп аласың. Бу инде чын, вәсвәсәле, сине мәхәббәтнең татлы газабына дучар итәчәк авыл язы. Яз — авыл фасылы. Кала аны имгәтә, буйсындыра гына.

Ак сәрби бары тик агач кына бит. Җирдә үскән гади бер куак. Аның чәчәк атуы нинди кодрәт белән синең йөрәгеңә тәэсир ясый? Ак акация чәчәк ата башлау белән, йөрәк ашкыныбрак тибә, күңел нечкәрә, тойгылар сизгерләнә. Акация исе кинәт минем житкән егет икәнлегемне белгертте. Култык астыма гармун кыстырып, клубка барасы килү үзәгемә тиеп, бәгыремне ачыттырып узды. Мин бит армиягә киткәнче гармунчы идем. Диңгез хезмәтендә авыл моңыннан оялу гармунны оныттырды. Их, онытулар... Үзем гаепле, җәзасын да үзем кичерәм. Гармун уйнау тукталгач, җан чукракланды, күңел теле сакаулана башлады. Гармунсыз, сизәм, хисләр коргаксый. Кулга гармун алып уйный башларга батырлык җитми — мин бит үз көйләремне, авыл көйләрен генә беләм. Адәм баласы йөрәк теләгәнгә колак салып яшәргә тиеш. Җан теләгәннән баш тарту кешелекне кимәтә, ярлылата.

Кинәт яшьлекнең вакытлы гына булуын, картаюның бусага артында сине көтеп торуын ниндидер аяныч белән тоя башлыйсың.

Башымны күтәреп, югарыга карыйм. Кишәнке-кишәнке кайнап торга: ак чәчәкләр арасыннан саф зәңгәрлек чагыла. Елмаясы килү белән елыйсы килү бергә. Газаплы тойгы. Әйтерсең, моңа кадәр минем чәчәк күргәнем булмаган. Безнең Караярның кырлары, яланнары чәчәкләргә күмелеп ята иде.

* * *

Тагын бер атна китеп югалды. Кадрлар бүлегендә мине башка инспекторга беркеттеләр. Хәлемне ул да, каботаж инспекторы Зеленковский да белми. «Чолман» диңгездә. Әллә мәрҗән атауларына, иртәнге бриз җиле белән пышылдап сөйләшүче пальмаларга кул селтәп, Караярыма кайтып китәргә инде? Диңгезгә дә кул селтәргә, кесәмдәге дипломга төкерергә, сабанга тотынырга, үлгәнче сабан тоткасын ычкындырмый яшәргә кирәк. Буразна туры, аның юнәлеше изге, — ул икмәккә, иминлеккә китерә. Колхоз эшенә әзерлек зур. Кесәмдә — авиация һәм диңгез штурманы дипломы. Читтән торып пединститутка керсәм, бәлки, бишенче классларда география укытырга да рөхсәт итәрләр. Безнең Караяр укытучылары — ким дигәндә профессор. Укытучы — шәхес, рухи остаз безнең авылда.

Капитан Курбатов «Вега»га килми башлады. Аны диңгез инспекциясенә капитан-наставник итеп куйганнар икән дип ишеттем. Үзен күргән юк әле. Үкенеп йөрим — ул мине чакырды. Барасым калган икән. Капитанны күрәсем килү, аның белән серләшәсе, уйларымны бүлешәсе килү туктаусыз газаплый.

Аерылып булырмы икән диңгездән? Авыр булачак. Диңгез минем сөйгән ярыма, кардәшемә, туган җиремә әверелде диярлек. Син, диңгез, нинди кодрәт белән минем күкрәгемә кереп урнаша алдың? Син мине туган-үскән җирләремә нигә җибәрмисең?

Бу юлы комитет секретаре ачуын яшерә алмады:

— Без бит бу мәсьәләне хәл иткән идек инде. — Каш җимерек, секретарь нәфрәт белән телефон трубкасына үрелде. Номер җыйгач, ул трубканы колагыннан аерды, әйтерсең андагы бюрократизм телефон аша секретарьның битенә бәрелә иде.

— Лутченко? Птушкин бу. Сез ни сәбәпле Рахманкуловны «Чолман»га кайтармыйсыз? Капитан? Дөрес, экипажны ул сайлый, ул җыя. Әйе, әйе, ул җавап бирә. Хәтереңдә тот, Лутченко: җыелыш карарын, кызганычка каршы, капитан да үзгәртә алмый. Җыелыш чыгарган карарны, иптәш Лутченко, бары тик җыелыш кына үзгәртә ала. Юк, демагогия

бетте. «Чолман» сәяхәттән кайтуга, приказ Рахманкуловның кулында булырга тиеш. Урнаштырмыйсыз икән, без синең белән партком секретаре кабинетында очрашачакбыз.

Мин, секретарьга күтәрелеп карарга оялып, бер тын басып тордым да, чыгып, кадрлар бүлегенә йөгердем.

— Ну, Рахманкулов, гаугачы икәнсең син, — дип каршы алды инспектор Лутченко. — Акыллы кеше безнең белән конфликтка керми. «Кадры решают все» — син шуны да белмисең икән. Элек «Чолман»га милиция белән дә урнаштырып булмый иде, кораб Италиягә йөри башлагач, ябырылып торалар.

— Виза күптән ачык, сез мине нигә каботажда тотасыз? Кайда ул дөреслек?

— Дөреслек? Ничек сөйләшә! Билгеләмәгез, алмыйм дип, капитан радиограмма җибәргән. Ул синең кем икәнлегеңне аңлап җиткергән, күрәсең. Әләкчене беркайда да яратмыйлар.

— Ул мине каян белә? Мин бит аның белән эшләмәдем, — дидем мин һәм кинәт аңлап алдым: Лохмачев!..

— Ярый. — Лутченко өстәл тартмасыннан кәгазь тартып чыгарды. — Өч көннән «Чолман» Одессага кайта. Өч көн эчендә документларыңны өлгертә алсаң, пароход синеке. Дикъкать белән тыңла: алты фоторәсем, дипломыңның өч копиясе, матрос булып эшләвең турында порт капиганы биргән белешмә. Әгәр шул кәгазьләрне ике көн эчендә өлгертә алсаң, чит ил паспорты кесәңдә булыр. Менә бу кәгазьне җентекләп карап чык. Андагы таләпләрнең һәр пунктын сүзсез үтәп барачакмын дип кул куй, — инспектор өстәл аша типография шрифты белән басылган кәгазь сузды.

«...Мин, Фәлән Фәләнович, чит илләрдә йөргәндә...» укып чыктым. Тизрәк кул куйдым. Кәгазьне кире инспекторга суздым. Әйе. Яр буенда үскән пальмаларның иртәнге бриз җиле белән серләшүен күбрәк палубадан тыңларга туры киләчәк.

— Рахманкулов, синең Советлар Союзы гражданины дигән почетлы исемгә тап төшермәвеңә ышанам. Котлыйм. Калганнары — мин әйткәнчә. Онытма, ике көн калды.

* * *

Бу көнне мин бөтенләй башка кеше идем. Бар нәрсә икенче: ихтирамым, җаваплылык, уяулык, абруй. Чит илләрдә йөрергә рөхсәт алган кеше... Чагыштырырга мисал табып булмый.

Тукта! Нинди икән ул чит илгә йөрүче диңгезчеләр паспорты?

Таможня мәйданын кыйгачлап үттем дә скверга кердем. Як-якта көмеш тирәкләр утыра. Тирәкләр шаһит — мин чит илләргә йөрүче моряк. Әнә, мин утырган җирдән ярты метр ераклыкта тирәк яфрагы тузанда аунап ята. Өске ягы балавызланган шикелле булып ялтырый. Аскы ягы аксыл, бәрхетләнеп тора. Минем «загранморяк» булуыма шушы яфрак, Одессаның зәңгәр күге, юлда җим чүпләп йөргән күгәрченнәр шаһит. Паспортымны кесәмнән алдым. Буяу һәм кургаш исе килеп тора. Чия көрән тышлы. Тышлыкка «Паспорт моряка» һәм инглизчә «Симанс паспорт» дип алтын хәрефләр белән язылган. Тышлыкны ачтым. Алтын белән баскан дәүләт гербы һәм кагыйдә:

1. Диңгезче паспорты чит илләргә йөри торган совет корабында эшләүче Советлар Союзы гражданына бирелә.

2. Паспортның хуҗасына, әгәр ул судовой рольгә теркәлгән булса, корабка утырып, СССРдан чыгарга һәм СССРга кире кайтып керергә рөхсәт ителә...

«...Бу паспортны күрсәтүче Рахманкулов Габдрахман Бәкерович...»

Паспортка хәтта минем буемның ничә сантиметр икәнлеге, күзлә-

ремнең коңгырт булуы, тәнемдә һәм кыяфәтемдә «особая приметалар» юк икәнлегенә кадәр язылып куелган. Мине чиктән тыш тетрәндергән нәрсә — фоторәсем белән янәшә баш бармагымның эзе булуы. Моның бөек, искиткеч житди документ булуына минем шигем юк. Башка очракта бармак эзен таләп итмәсләр иде.

Мактану, билгеле, начар гадәт. Ә минем һәр очраган кешегә паспортымны күрсәтәсем, аны авырлыклар белән, озак көтеп алуымны сөйләп, эчемне бушатасым килә иде. Авылдашларыма, Сахалиндагы дусларыма, Мәскәү университеты студентларына — барысына да күрсәтеп, шуларның һәммәсе алдында мактанасым килә иде.

Тагын көн туды. Бу көнне «Чолман» пароходына өченче штурман итеп билгеләнү приказы кулымда иде. Приказны дүрткә бөкләп, түш кесәмә салдым. «Чолман»ның кайтканын көтә башладым.

* * *

Трапка кадәр шактый ара. Йөз-йөз илле адым чамасы. Чемоданымны жиргә куеп, бер тын хәл жыйдым.

«Чолман». Траптан өскә менәм. Авылыма кайткач, капка аша ишегалдына кергәндәге тойгы. Күз алдымда кызыл томан. Туган нигезенә кайту — балачакның зәңгәрсу бәхетенә кабат чумуга тиң. Мин үзем эшләгән корабка кайтам — бусы хыялга кайту. Ә хыял — шул ук балачак. «Чолман» пароходы да миңа елмая, килүемә сөенә иде.

Ниһаять, трапның соңгы басмасы. Палуба...

— Рахманкулов, синме бу? Албанец! — Деримедведь яныма килеп, касыгыма төртте. — Хәл белергә генәме, әллә эшләргәме?

— Син, жилкуар, капитанның өченче ярдәмчесе алдында үзеңне ничек тотасың? Смирно! — дип кычкырдым. Уенын-чынын кушып шаярту сүлпәнрәк чыкты. Тәкәббер командирлар әтәчләнүе онытылган.

— Тар балаклы чалбар киеп жибәргән. Әллә мореходканы бетереп тә ташладың? — Деримедведь арткарак чигенеп, бер тын карап торды да кычкырып жибәрде. — Белоштан. Чык әле, күр, кем килгән безгә?

Ишектән Белоштан атылып чыкты. Өстендә хатын-кыз сурәте төшкән зәңгәр нейлон күлмәк, башында озын козыреклы жокей картузы.

— Бон джорно, синьор. Коме стаи, мио каро?[1] — итальян телен белүе шуның белән чикләнде булса кирәк, ул русчага күчте. — Бу илдә халык ничегрәк яши? Уңышлар ничек?

— Кайларда булдыгыз? Ниләр күрдегез? — дидем мин Белоштанның кулын кысып. — Танырлык та түгел. Италия сезне үзгәрткән. Итальянча сөйләшә башлагансыз. Ничек өйрәнеп өлгердең? Лохмачев корабтамы?

— Өенә кайтып китте, — диде Деримедведь. — Төштән соң килергә тиеш.

— Ә капитан?

— Ул пароходта. Син аңарга күренергә ашыкма әле, — диде Белоштан кинәт пышылдап сөйләшүгә күчеп.— Ул бит «Чолман»га килгәнче «Чистяков» пароходында эшләгән, ишеткәнсеңдер бит?

— Ишетмичә! Анда минем дустым Феликс Каминский өченче штурман иде.

— Хәзер алар Лохмачев белән бер тәртәгә жигелделәр. Хәзер «Чолман»да күп нәрсә үзгәрде. Марс планетасында яшәү бар — кешеләр юк, — диде Деримедведь, катлаулы кинаягә күчеп.— Мин бит вахтада. Вахтада торганда, сөйләшергә ярамый. Кич белән очрашырбыз. Югалма, яме.

Корылма эченә кердем, ике еллык гомерем калган жиргә. Йортым

---

[1] «Хәерле көн. Ничек яшисең, кадерлем?» дигәнрәк мәгънәдә.

иде бу корылма. Эш һәм яшәү урыным. Тансык булып китте. Тансык һәм куркыныч. Сагындым мин «Чолман»ны. Авылымны сагынган шикелле.

Күмер ташыганда, корабны тузан каплый иде. Антрацит валчыклары, олтанга ябышып, коридорга керә иде. Диңгезгә чыккач, юа идек. Портта кораб тагын пычрана иде.

Пароход чистарган. Тузан юк. Ләкин пөхтәлеген югалткан. Спардекка домино уйнар өчен өстәл ясап куйганнар. Тупас. Такталарын шомартып та азапланмаганнар. Өстәл янындагы эскәмияләрнең аяклары чалыш. Тәмәке төпчеге ташлар өчен тимер мичкә утыртканнар. Мичкә астына такта кыстырырга кирәк иде. Агач палубага мичкәдән агып төшкән тутык сеңәчәк. Аны берничек тә бетереп булмый. Юк, капитан Курбатов агач палубага тимер мичкә утыртырга рөхсәт итмәс иде. Боцман Шахсуарзадә юклыгы да адым саен сизелеп тора.

Мин, авыл малае, яшьли эшләп үскән. Болай диңгезчелек күп яктан авыл хуҗалыгын хәтерләтә. Җилкәнле кораблар чорында матрос булып авыл егетләре эшләгәннәр. Шунлыктан авыл хуҗалыгының күп кенә ысуллары диңгезчелеккә сеңеп калган. Менә мин тагын «Чолман»га кайттым. Тырышырга туры килер. Эшемнән капитан да, Лохмачев та гаеп таба алмаслык итеп. Бердәнбер дөрес юл — тырышып эшләү. Ә нигә куркырга? Мин Деркач белән Лохмачевка ялланмаган. Кораб — дәүләтнеке. Бездә социализм кануннары хөкем итә. Демократия. Дөреслек. Дуслык. Бездә җәберләү, кимсетү законы юк.

Газаплы авыр уйлар килгән чакта мин уң як шлюпка астындагы ком тартмасына чыгып утыра идем. Шунда барып утырдым. Акваториядә буксирлар кайнаша. Кран «Чолман» алып кайткан йөкне бушата. «Чолман»ны портта торган башка кораблар белән чагыштырам. Картаясың, дустым. Йончу күренәсең. «Курбатов чорында син башка идең. Ник болай боектың?» — дип сорап карыйм. Кораб дәшми. Дәшмәсә дә, аңлыйм. Син капитан Курбатовны сагынасың. Бригас, Шахсуарзадә дә юк бит инчмасам. Авыр булыр безгә. Ләкин... Курыкма, бирешмәбез. Алда безне юллар, ераклыклар көтә.

* * *

Лохмачев килде.

Үтешли өлкән штурман Деримедведьны шелтәләп өлгерде. Кайбер начальниклар үзләренең начальник икәнлекләрен шелтә аша белгертәләр. Шыгырдый торган туфли янымнан узды. Виктор Филимонович мине күрмәде. Аңа күрмәү отышлырак иде.

Өлкән штурманның каютага керүен, чишенүен, көзгегә карап, бер тын сокланып торуын көттем. Көзге каршында утырганда хатын-кыз үзенә соклана. Ирләр исә көзге каршында: «Менә мин кем! Фәлән Фәләновичка үземнең кем икәнлегемне күрсәтим әле. Белсен минем кем икәнлегемне», — дигән сүзсез роль башкаралар.

Көзгегә карарга Лохмачевка ирек бирдем. Эш кәефенә керергә тагын биш минут өстәдем. Тәвәккәлләп, ишек кактым.

— Кем ул анда?

Элек бу кешенең тавышы башка иде. Ярашуга, буйсынуга көйләнгән ялагайлар тавышы иде. Өлкән штурманның тавышы буйсындыруга көйләнгән.

— Исәнмесез, — дидем мин, кулларымны кая куярга белмичә.

Лохмачев каушады. Ул мине көтмәгән икән.

— Рахманкулов бит әле сез, әйеме? — Өлкән штурманның битенә сыек елмаю чыкты. — Эшләр ничек?

— Әйбәт. Зарланырлык түгел.

Өстендә ак униформа. Тукымасы гына да ни тора. Шундый ак,

тыгыз, шома. Ука тасмалы җиңнәр. Лайка күннән теккән штиблет. Аяк киеме белән пардан эшләнгән ак перчаткалар диванда ята. Кайсы ил тегүчеләре тырышкан безнең Лохмачевны патша малае итеп киендерү өчен? Дөрес, тырышулары бушка китмәгән. Русның «встречают по одежде, провожают по уму» дигән әйтеме бар. Әлек, чыннан да, акылына карап озата торган булганнардыр. Без стресс заманында яшибез. Кешенең акыллымы, түгелме икәнлеген ачыкларга вакыт җитми. Шуңлыктан киемгә карап каршыларга да, озатырга да туры килә. Килешә безнең Лохмачевка кием. Һәм ул үзен киеменә лаеклы тота белә. Ак униформага өстәп, дулкынланып торган аксыл сары чәч, зәңгәр күзләр һәм алсу алма битләр. Суперменнар токымыннан безнең Лохмачев! Табигать бабай ялгышмый. Табигать Лохмачевка тышкы матурлык биргән. Әчкесе, күрәсең, башкаларга эләккән. Башкача ничек аңлатасың?

— Хәл белергә кердегез, Рахманкулов, әйеме? — өлкән штурман суыткычтан кока-кола чыгарды да татлы итеп иснәде. «Төне йокысыз узган», — дип уйлап алдым.

— Мин корабыма кайттым, Виктор Филимонович. Менә приказ, — кадрлар бүлегеннән алган кәгазьне Лохмачевның өстәленә җәеп салдым.

— Тормыш шулай ул, Рахманкулов, — диде өлкән штурман, кәгазьгә күз дә салмыйча. — Мин сиңа бергә яшәргә тәкъдим итеп карадым. Солидно, ир-егетләрчә. Борын чөйдең. «Курбатов! Бригас! Ах-ох! Бөек диңгезчеләр! Мине яраталар! Үз итәләр!» Менә нәтиҗә — синең язмышың безнең кулда. Ялынып килгәнсең кебегрәк.

— Мин, Виктор Филимонович, сезгә ялынып килмәдем. Кораб дәүләтнеке. Сез дә, капитан да нинди зур, көчле булуыгызга карамастан, шул ук мин буйсынган Уставка, шул ук Конституциягә һәм хөкүмәт карарларына буйсынасыз. Мин сездән эш сорарга җыенмыйм. Мине шушы корабка капитан ярдәмчесе итеп билгеләделәр. Өстәвенә, мин экипажның комсомол секретаре.

Лохмачев тыныч кына кәгазьләр актара иде. Ул белә, шундук җавап бирсәң, эффект кими. Виктор Филимонович мин әйткән сүзләрнең суынуын, тәэсире кимүен көтә. Өлкән штурман мине оныткан булып кылана. Алдындагы кәгазьләрне мавыгып укый, уйлый, башына җитди хәлиткеч фикерләр килгәнен күрсәтер өчен, бармак белән чигәләрен сыпырып куя.

— Комсомол комитеты карарын без әһәмиятсез калдырмыйбыз. Шуңа карамастан, экипажны капитан үзе сайлый. Уставта шулай язылган. Штурманнар тулысынча капитан кулында. Аларның эшкә ярарлыкмы-түгелме икәнен бары тик ул гына белә. — Лохмачев китап киштәсеннән Устав алды. — Менә тыңлагыз. «Егерме тугызынчы бит, җитмеш өченче параграф». «Экипаж әгъзаларын капитан үзе сайлый». Дөрес, Григорий Григорьевич миңа да ышана. Мин тәкъдим иткәнгә каршы килми ул. Мин менә сезне алыргамы-юкмы дип баш ватып утырам. Язмышыгыз минем кулымда. Мин, Рахманкулов, сезне кызганам.

— Сез инде алай язмышка ук үрелмәгез, Виктор Филимонович. Алдыгызда приказ. Аны кадрлар бүлеге чыгарган. Приказ үтәлергә тиеш. Сез аны берничек тә үзгәртә алмыйсыз.

— Әйе, Рахманкулов, сез фәлсәфә куерта беләсез. Фәлсәфә буенча сезнең белән ярышып булмый. Ярышып булмый, Рахманкулов. Пароходка беренче килүегездә Курбатов сезне матрос итеп куйдымы соң? Исегездәме, ул чакта да приказ сезне матрос итеп билгеләү турында язылган иде бит.

— Ул чакта минем тәҗрибәм юк иде.

— Хәзер бармыни? Штурман булып син ничә ел эшләдең?

— Мин самолет йөрткән кеше. Бригас вахтасында штурманга

тиешле бар эшне башкарып карадым. Тәҗрибәсе юк дип, сез мине борып җибәрә алмыйсыз. Мин кораб йөртү буенча диңгез инспекциясенә экзамен тапшырдым.

«Чолман»да калуыма ышана идем мин.

Лохмачев тәмле итеп иснәнеп алды:

— Ярый, мин капитанга аңлатырга тырышырмын. Син бит минем дустым, әйеме?

Тешемне кыстым, бер сүз әйтмәдем. Лохмачевның капитанга нәрсә сөйлисен мин туксан процентка белә идем. Җир дә йотмый бит шушындый икейөзле, вөҗданы теләсә кайсы якка борыла торган бәндәне! Өстәвенә, ул Бригас урынында, шуның каютасында яши! Бар нәрсә Бригас заманындагыча: ишек, иллюминатор, рундук, өстәл. Бары тик стенада шәрә кыз сурәте төшкән календарь, яшел малахиттан ясалган уткабызгыч, каютага кергән кешене сокландырыр өчен, өстәлгә утыртып куелган. Һәм, шкафта хрусталь рюмкалар. Юк, тын алып булмый бу каютада. Йөрәк кысыла.

— Капитанның карары кайчан билгеле булыр? — дидем мин, үземне көчкә кулга алып.

Лохмачев сәгатенә карады:

— Кичке дүртләр тирәсендә. Бәлки иртәгә, бәлки бөтенләй билгеле булмас. Капитанның вакыты юк. Аның эше бик тыгыз. Бик җаваплы, бик тыгыз безнең эш. Чит илгә йөрибез бит.

Лохмачев мине озата чыкты. Хәтта кулымны кысты, хәтта күземә карап, ягымлы итеп елмайды. Ә минем, тешләремне кысудан, авызымнан кан саркып чыккан иде.

«Капитан Курбатов белән киңәшеп карарга кирәк. Ул нинди киңәш бирер икән?» — дип уйладым, причалга төшкәч, һәм, Василий Степановичны эзләп, пароходчылыкка киттем.

* * *

Мин кара дерматин белән тышланган авыр, мәһабәт ишекләр яныннан уза башладым. Болары пароходчылык начальнигының ярдәмчеләренеке. Беренче, икенче... ниһаять, бишенче ярдәмче. Дүртенче ярдәмче диңгезчелек буенча. Аның кабинетына янәшә капитан-наставниклар бүлмәсе. Ишек шакыргамы, рөхсәт сорап керергәме? Диңгез горефгадәтләре батып үлгән морякларның җаннары, язмышлары белән язылган. Алар — катгый. Шул турыда уйлап, икеләнеп торганнан соң, бүлмәгә уттем.

Идән уртасында — кеше биеклеге глобус. Киштәләрдә секстаннар, навигация приборлары. Түр почмакта өр-яңа радар. Стена буена тезелгән шкафларда — лоция, астрономик таблицалар, җилләр, агымнар, су күтәрелүе турында язылган күн тышлы калын-калын белешмәләр. Гадәттә, урындагы кешеләрнең кабинетлары үзара охшаш була. Капитан-наставниклар утырган бүлмә исә музейга, галимнәр кабинетына тартым иде.

— Нихәл, лачын? Нигә түрдән узмыйсың? — диде Курбатов, өстәл артыннан торып. — «Чолман»га билгеләр алдыннан безнең белән киңәштеләр. Мин шат. Син, лачын, экипажның абруен сакла инде.

— Василий Степанович, сез «Чолман»га кире кайтасызмы?

— Рөхсәт юк шул, лачын. Җибәрмиләр. Менә бит яңа эшкә билгеләделәр.

— Василий Степанович, сезне бик югары күтәргәннәр. Остаз, капитаннарның капитаны. Котлыйм. «Чолман» экипажы шатланыр инде.

— Аның нәрсәсенә шатланырлар икән? Яшьрәк чакта булса, чыннан да шатланыр идең. Көн саен гаиләм янына кайтып кунам — куанычы шул. Картлык көнендә ялгыз йокларга да була. Гомерем минем диңгездә узды. Я, лачын, сөйлә, ни йомыш?

— Василий Степанович, мине «Чолман»га штурман итеп алырга теләмиләр.

Курбатовның кашы җимерелде:

— Кем теләми, капитанмы, әллә Лохмачевмы?

— Әлеге Лохмачев, — дидем мин. — Капитан аңа каршы килмәячәк.

— «Чолман» бит хәзер минем карамакта. Әллә чакыртыйммы үзләрен? — Курбатов уйга калды. — Әллә ашыкмыйкмы? Бәлки, бер мәртәбә сиңа матрос булып кына рейска барып кайту да зыян итмәс? Киләсе кварталда дүрт яңа кораб алабыз. Венециядә төзелгән яңа рефрежератор-банановозга капитан итеп мин Бригасны тәкъдим итмәкче булам. Ул бит сине белә. Бергә вахтада тордыгыз. Әгәр сине «Чолман»га штурман итеп куйсалар, күчерүе кыен булыр. Бәлки, әлегә-чыннан да матрос булып кына эшләргә кирәктер?

Уйлап торасы юк иде. Курбатовның шәкерте Бригас белән мин яңадан дневальный булып, табак-савыт юып торырга да риза идем. Ихтирам иткән кешең кулы астында эшләү үзе бер бәхет.

— Андый корабка билгеләрләрме икән соң? Әле бит минем тәҗрибәм дә юк.

— Кандидатурасы үтсә, нишләп синнән Бригас баш тартсын? Вакыт бар. Әлегә «Чолман»да эшләп тор. Әйләнеп кайтуга, күз күрер. Уңышлар телим, лачын, — диде Курбатов, кулымны кысып.

Урамга чыккач кына исемә төште: рәхмәт әйтергә дә оныткanмын икән. Әйләнеп керергә уңайсыз иде. Тапшырылмаган рәхмәтемне күтәреп шәһәргә юнәлдем.

* * *

«Чолман»ны башка гаваньга күчергәннәр. Мин килгәндә, аның трюмнарына йөк төйи башлаганнар иде. Вахтада — Стовбуненко. Экипаж ярда. Дүрт кешелек кубрикта Белоштан төнге вахтадан соң ял итә. Шуның янына кереп, капитан килгәнен көтә башладым. Ярты сәгатьтән Деримедведь кайтты.

— Рахманкулов, — диде ул шатланып. — Тагын килгәнсең икән. Без сине алмадылар, борып кире җибәрделәр дип уйлаган идек. Дөрес булса, сине штурман итеп билгеләгәннәр дип сөйлиләр.

— Белмим. Кичә Лохмачев штурман итеп алмыйбыз диде.

Деримедведь, сумкасыннан бөтен бер сыер йөрәге чыгарып, өстәлгә куйды:

— Йөрәк ашаган кешене кызлар ярата дип сөйлиләр. Гастрономнан алдым, — диде ул пычак белән зур бер калҗа кисеп алып.

— Кызлар сыерныкын түгел, аларның үз йөрәкләрен ашаганны яраталар, — диде Белоштан мендәрдән башын күтәреп.

— Сез миңа рейс турында сөйләмәдегез бит әле. Генуядан соң Албаниянең Дуррес портына кергәнсез икән. Анда ниләр бар? Нәрсәләр күрдегез?

— Генуяның «Колбаса тыкрыгы» урамындагы теге түшәк эше белән тамак туйдыручы хатыннар җыелганы турында сөйләдем бит. Авызыңны ачып уяулыгыңны югалтсаң, күз ачып йомганчы бүлмәләренә сөйрәп кертәләр, — диде Белоштан.

— Син теге зират турында сөйлә, — диде Деримедведь. — Без бит Кампо Санто дигән зиратка экскурсиягә бардык. Зиратта Рязань өлкәсендә туып үскән Федор Полетаев атлы бер партизан күмелгән. Шуның каберенә чәчәкләр куйдык. Андагы матурлык — әҗәл килгәнен көтмичә, тере килеш кереп ятарлык.

— Габдрахманга зират нәрсә ул. Үлгәч, кая күмсәләр дә ярый. Барыбер череп бетәсең. Бер күмелгәч, кабердән чыгып, кипарислар

күләгәсенә ятып, барыбер ял итеп булмый. Син Габдрахманга итальян кызлары турында сөйлә. Без аларның кызларын да күрдек. Битләре шундый матур, тел-теш тидererлек түгел. Гәүдәләре дә җыйнак. Киенүләре турында сөйләп тә торасы юк, арзан тукымадан теккән кием булса да, модно киенәләр. Шул яклары яман — аяклары кыска. Дөрес, кайберләре биек үкчәле туфли кия. Аякларын озын күрсәтү өчен кияләр. Битләрен инде карап кына торырлык. Аяк кыска булу гына харап итә.

Бу турыда мин Италиядә булмасам да белә идем. Гадәттә, чит илгә барган кеше үзенең ишетеп белгәнен күреп кайта.

Ишек шакыдылар.

— Рахманкулов, капитан килә, — диде Стовбуненко. Бераздан өч тапкыр электр кыңгыравы чылтырады.

Һәм тынлык урнашты. Әйтерсең, каютада безнең сөйләшкәнне тыңлап торучы сизгер колак барлыкка килде.

Сул як бортка узып, Лохмачевның ишеген шакыдым.

Өлкән штурман килмәгән иде әле. Көтә башладым.

Төш вакыты җитте. Деримедведь мине ашханәгә чакырды. Баш тарттым. Сәгать икедә Лохмачев килде. Көтәргә кушып, каютасына кереп бикләнде. Вакыт үткән саен, көтү газаплырак була. Соңгы сәгатьтә мин тәмам гарык идем. Көтеп тору кешене мескенәйтә. Тәҗрибәле түрәләр кешенең ихтыяр көчен шушы юл белән сындыралар. Түзәр хәлем калмагач, Лохмачевның кисәтүенә кул селтәп, ишек шакыдым.

— Әйе.

Өлкән штурман диванда ята. Кулында иллюстрацияле журнал. Шуны карый. Мине күргәч, канәгатьләнеп елмайды.

— Бераз көт, Рахманкулов. Хәзер мин сине капитан янына алып керәм. Син аңа ошарсың дип уйлыйм. Ошамаган кешене Григорий Григорьевич алмый, борып җибәрә. Ә сине мин хәзерләп кертәм.

— Сез минем турыда капитан белән сөйләшкәнсездер бит инде?

— Мин сиңа әйтмәдеммени? Безнең өченче штурманыбыз бар. Сине без матрос итеп куя алабыз. Риза булсаң, билгеле. Көчләп түгел. «Чолман»да эшләргә теләүчеләр буа буарлык. Мин сине хәзер капитанга күрсәтәм. Син үзеңне акыллырак тот. Аңа ошарга тырыш. Язмышың хәл ителә. Аңладыңмы?

Без кергәндә, Деркач нидер язып утыра иде.

— Учти, комсомол секретаре, — диде ул коры гына. — Мин сине Лохмачев сораганга күрә матрос итеп алам. Тәртип бозсаң, начар эшләсәң, антимония куертсаң — «Чолман» пароходыннан китәргә туры киләчәк. Аңладыңмы?

— Матрос булып эшләргә син ризамы? — диде Лохмачев, минем ялына башлавымны, штурман итеп куюны соравымны көтеп.

— Миңа барыбер, — дидем мин, гамьсез күренергә тырышып.

Капитан белән өлкән штурман бер-берсенә карашып алдылар. Болай тиз, сатулашмыйча риза булуымны көтмәгәннәр иде бугай.

— Син... син, матрос булып эшләргә үзем теләп риза булдым дип, минем исемгә рапорт яз, — диде капитан шикләнүен яшерә алмыйча.

— Григорий Григорьевич, Рахманкуловны кайсы вахтага билгеләргә? — дип сорады Лохмачев. Алдан уйланган режиссураның бозылуы, ялвару сүзләренең әйтелмәве өлкән штурманның да кәефен бозган иде. Алар сизенделәр, ләкин минем болай тиз генә матрослыкка риза булуымны берничек тә аңлый алмыйлар иде.

— Билгеле, төнге вахтага, — диде капитан. — Лагуткин белән.

Бусы да мин теләгәнчә булды. Билгеле, иң авыры — төнге вахта, нульдән иртәнге дүрткә кадәр. Ләкин түзәрлек...

«...Горька и печальна наука дальних странствий...» — Бодлерның шигыре исемә төште. Алда — юл, яңа диңгезләр, ят илләр, чит ил портлары. Хыялымның тормышка аша башлавына ышанасым килми иде.

* * *

Швартов бауларын ярдагы пушкалардан ычкындырдылар. Мин шуларны сөйрим. Җырлыйсым, Караярга ишетелерлек итеп кычкырасым килә: «Бу дөньяда морадына ирешкән кеше булса — ул мин, Караяр Бәкеренең улы Габдрахман!»

Озатырга килүчеләр кул болгыйлар. Бала тавышы. Әтисенә кычкыра. Кемнеңдер хатыны причалда авызын учы белән кысып каплап, икенче кулы белән күз яшьләрен сөртә... Күперчектән капитанның тавышы ишетелә:

— Вира шприн!

Мин тагын Стовбуненконы алыштырдым. Ул ялга китте. Калдым. Бу юлы мин еракка, чит илләргә йөрүче беренче классны тәҗрибәле матрос. Кесәмдә штурман дипломы. Мөһер суккан гади бер кәгазь, ләкин ул миңа ышаныч бирә, абруйлы була башлавымны сизәргә ярдәм итә. Теге беренче тапкыр «Чолман»га утырып диңгезгә чыккан егет түгел инде мин. Ир-егет кулындагы иң көчле корал — тәҗрибә. Ул — миндә. Өстәвенә — корабта якын дусларым бар. Диңгез миңа таныш. Мин диңгезне яратам. Бусы — тагын бер ышанычлы терәк.

Без Африкага, Судан иленә барабыз. Анда капиталистик чынбарлык. Капиталистик чорналышта совет кешесен сагалап кына йөриләр ди. Миңа шулай аңлаттылар. Уяулыкны йомшарттың исә — провокация, шантаж.

Ярлар офык артында калды. Тирә-якта су. Иксез-чиксез, тоташ су. Кораб алга бара. Су шаулый. Өстә төпсез зәңгәр күк.

Кубрикка кереп чишендем, урыныма менеп яттым. Төн уртасында уятырга тиешләр. Деримедведь белән Белоштан вахтада. Аста су шаулый. Корабны курска кайтарганда, палуба астында рулевая машина дөбердәп ала. Рәхәтлек, куаныч, курку кайдан? Билгесез киләчәк. Мин бит үземнең киләчәгемә барам...

* * *

Баскан саен, аяк астында ком сызгыра. Кайнар, пыяла валчыгы шикелле эре ком. Комлыкка пальма урманы килеп терәлгән. Җылымса океан бризы яфракларны салмак кына кыштырдата. Кошлар сайрый. Ара-тирә бер ят җәнлек шомлы тавыш белән кычкырып ала. Агачтанагачка сикереп, уйнап йөргән вак маймыллар, нәрсәнедер бүлә алмыйча, үзара ызгышалар.

Күңел күтәренке. Аяк астындагы ком сызгыруын, кошлар сайравын, иртәнге бриз җиленең пальма яфраклары белән моңлы итеп серләшүен тыңлап, айлар, еллар буе туктамыйча алга барыр идем. Сирәк була торган җан рәхәтлеге. Саф шатлык һәм иң куанычлы чаклар китерә торган әчке канәгатьлек.

...Кулымда кызыл комач. Аны төреп култык астына кыстырганмын. Шушы лозунгны океан ягына каратып, яр буендагы ике биек пальма арасына тарттырып эләргә тиешмен. Эләргә яраклы агачлар әле һаман күренми. Миңа агачларның биеклеге, болытларга тиеп торганнары кирәк. Океанга таба чыгып, башкалардан аерылып торганнары.

Ниһаять, таптым. Су эченә керә язып үскән ике мәһабәт кокос пальмасы. Төзләр. Кырып ясаган орчык шикелле зифалар. Очларында үскән җилпәзә яфракларның һәрберсен юрган итеп ябынып ятарлык. Авыр булыр бу пальмаларга менүе. Агач төбенә күләгәгә ял итәргә утырдым. Аркамны пальма кәүсәсенә терәдем. Кайрыдагы кытыршылык күлмәк аша тәнне авырттыра.

Хәл җыйгач, комачны куеныма тыктым да агач башына үрмәләргә керештем. Ботак юк, тотынып булмый. Кайры учны, аякларны тырный.

Тын бетә, йөрәк тибә. Йөрәк тибүе аяк-кулларда, чигәдә, хәтта бармак очларында сизелеп тора. Туктап, тирә-якны күзәтәм. Мәрҗән атоллы икән бу. Атоллны боҗралап рифлар урап алган. Рифлар белән атауның ярлары арасында күлгә охшашлы тыныч зәңгәр лагуналар. Океаннан килгән тау-тау дулкыннар, лагуна эченә үтә алмыйча, рифларга бәрелеп ватыла, кире чигенә.

«...Миңе бит лозунг эләргә җибәрделәр. Элә алмасаң, корабка кайтма», — диделәр. Кайда соң безнең кораб? Әллә ул мине атауда калдырып киттеме? Курку эчемне суытып алды. Теге ят җәнлек һаман үкерә. Җил кузгалды. Океаннан килгән дулкыннар, риф барьеры аша сикереп, лагунага керә башладылар. Су башта яр чите комлыгын, әкренләп агачлыкны басты. Җил агачларны бөгә, дулкын өстенә яткыра башлады. Ярдәм сорап кычкырам — тавышым чыкмый. Су шаулый. Шашынып, давыл үкерә. Мин ябышкан пальманың тамырлары комлыктан суырылып чыга башлады. Ул, гөрселдәп, дулкын өстенә ауды. Миңа таба пальма буйлап елан шуып килә. Һаман якыная. Ут янып торган кызыл күзләр. Ике җәпле агулы тел маңгаема килеп тия язган. Чәбәләнәм, кычкырып карыйм — тавыш чыкмый...

— Тукта. Түшәмне тишәсең бит, — матрос Белоштан җилкәмнән тотып җилтерәтә иде. — Тор. Вахтага чыгар вакыт җитте.

Их, йокы! Дөньяда йокыдан да кыйммәтле нәрсә бар? Бар рәхәтлек, бар дөнья тигезлеге шул йокыда.

Йокы рәхәт, ә нигә шундый куркыныч нәрсәләр төшемә керә?

Торып киендем, рубкага юнәлдем.

Өлкән штурман вахтасы җитмәгән әле. Шуңа карамастан, ул рубкада. Капитан да монда. Штурвал янына килдем:

— Курс йөз туксан ике. Вахтаны тапшырдым, — диде Белоштан.

— Курс йөз туксан ике. Вахтаны алдым, — дидем мин.

Рубкага икенче штурман Лагуткин керде. Аның гигант гәүдәсенә монда кысынкы иде. Лагуткин ачулана белми. Якты дөнья тоташ яктылыктан тора дип ышанып яши торган кеше ул. Шунлыктанмы, битендә — даими елмаю.

«Чолман» Босфор бугазына якынлашып килә иде.

Босфор аша үткәндә, штурвалга иң оста рулевойны куялар. «Чолман»ның иң оста рулевое Виктор Барсуков иде. Аны чакырырга вакыт, капитан нигәдер ашыкмый. Мин корабны курста тотарга тырышам. Тырышуның чиктән тыш булуы комачаулый. Компас угын тиешле курска кайтарып куям, ул тагын кача, мин тагын кайтарам. Капитанның мине тирги башлавын көтәм. Үзем һаман: «Болар нигә Барсуковны чакырмыйлар икән?» — дип хафаланам. Руль миндә. Димәк, миңа ышаналар. Горурлык кабынып киткәнен сизәм. Дөрес, Деркач — каты бәгырьле кешегә охшаган. Ә бәлки? Бу кешенең яхшылыкларын эзләргә керешәм, аның уңай сыйфатларын табасым килә.

Рубкада рәхимсез каты киеренкелек. Штурманнар капитанның боерыгын көтәләр.

Босфор аша узганчы гына булса да капитан Курбатов безнең янда булсын иде. Ул бит, рубкага кергәч, берәр мәзәк сүз табып көлдерә. Шул сүздән соң атмосфера йомшара, киеренкелек юкка чыга, аңлашу, уртаклык барлыкка килә иде. Ярататлар иде Курбатовны. Ул безнең янда булганда, эшнең авыры, катлаулысы булмый иде. Хәзерге заман теле белән әйткәндә, проблема тудырмый иде ул.

Кичә мин Босфор турында лоцияне укыган идем. Бугаз эченә керер алдыннан туктарга ярамый. Монда якорь ташлар урын юк, су тирән. Агым ярга таба куа. Бердәнбер — дөрес юл — турыдан-туры Босфор эченә керә башлау иде.

— Дмитриев, пеленг.

Вахтада — Лагуткин. Пеленгны ул алырга тиеш иде.

— Ярга житәргә алты миль калды, — диде Дмитриев.

— Курс? — дип кычкырды капитан.

— Ике йөз алтмыш жиде, — дидем мин.

— Малый вперед! — диде капитан.

Лохмачев машина телеграфын «малый впередка» күчереп куйды. Алда безне каршы аласы лоцман көймәсенең уты күренде. Дмитриев белән Барсуков лоцманны каршы алырга палубага төшеп киттеләр.

— Стоп машина, — диде капитан һәм маңгай тирен сөртеп алды.

Лоцман көймәсе «Чолман»ның бортына тиеп кенә киткәндәй итте. Рубка ишегендә чандыр, озын буйлы төрек лоцманы күренде. Лоцман безнең Караяр кешесенә охшаган иде. Ул инглизчә исәнләште һәм корабның суда ничә метрга утырганын, тизлеген, машина көчен сорады.

Кораб өстендә йомшак Истанбул күге. Ярларны караңгылык каплаган. Яр буена тезелгән утлар, кораб борыла башлау белән чәчелеп китәләр дә, артка таба йөгереп узалар. Күз компас угында. Меңләгән, йөз мең данә төнге утларын бугазга текәп уйга калган тарихи кала әкрен генә артка шуыша, караңгылыкта калып, эри, югала тора. Мәчет манаралары төнлә дә күренеп торсын өчен прожектор уты белән яктыртып куйганнар. Куллар штурвалда. Калага карыйсым килә — ярамый.

Ниһаять ярдагы утлар, тылсымлы манаралар артта калды. Мәрмәр диңгезенә чыкканда, безне лоцман көтеп тора иде. Төрек лоцманы, саубуллашып, рубкадан чыгып китте.

Вахта алышынганда, таң беленеп килә иде инде. Төн арыган, күңелдә татлы канәгатьлек. Сәгать төнге дүрт. Йокының иң татлы чагы. Ашханәгә төшәсең. Машина бүлегеннән, икенче механик Русаковка ияреп, машинист Шмаков белән кочегар Емельянов менә. Экипаж йоклый. Планетаның көнчыгыш ярымшары йокыда.

Без ашарга утырабыз. Вахтада дүрт сәгать авыз йомык торган. Үзәкләргә тиеп сөйләшәсе, серләшәсе килә. Кайчакларда сәгать алты житкәнче гәпләшәсең. Ашап туйдык. Табак-савытны жыештырып, өстәлне сәрттек.

— Әйдә, кереп чыгыйк әле, — диде Лагуткин, үзенең каютасына күрсәтеп. Кубрикта артык тыгыз, вибрация көчле, бәлки минем диванда гына кунарсың?

— Мин бераз Мәрмәр диңгезен карыйм әле. Беренче күрүем бит, — дидем мин һәм спардекка чыктым.

Диңгездә балыкчы көймәләре. Алар күп. Көймә саен якты ут. Көймәдәге утларга кушылып, яшькелт яктылык белән диңгез суы балкый. Искиткеч матур күренеш. Балыкчылар ишкәгеннән тамган тамчылар йөзек кашындагы бриллианттай тылсымлы яктылык чагылдырып балкыйлар. Суда йөзгән балыклар артыннан яшькелт юл сузылып кала.

Кораб артында да яшелле-зәңгәрле утлы юл. Әйтерсең, күктәге йолдызлар диңгезгә су коенырга төшеп эрегәннәр. Кораб әкият дөньясында йөзеп бара шикелле. Шушы матурлыкны бер генә күрер өчен дә калган гомереңне икеләнмичә бирерлек иде. Үз иркеңнән диңгезне ничек ташлап булсын? Ул мине һаман үзенә тарта, сихерли, буйсындыра. Озакламый мин диңгезсез яши дә алмам шикелле.

Таң атканчы, кубрикка кермичә, диңгезнең фосфорланып януына карап утырдым.

* * *

Корабны ремонтка куяр алдыннан кочегар Сукач, диңгезчеләр телендә «Борис патша», расчет алып, Мурманскига балык тотарга ялланып киткән иде. Эшемне мин Сукачка тапшырырга тиеш идем. Ул табак-савыт юудан баш тартты. Кораб чит илгә йөри башлагач,

дневальный итеп Дмитрий Афанасьевич Галочкин дигән кешене куйдылар. Диңгезчеләр телендә аның кушаматы — «Тобик хуҗасы».

Озын кушамат озак яши алмый. Аны кыскарталар. «Тобик хуҗасы» бераздан «хуҗа»га әйләнде. Аңа элек тә Дмитрий Афанасьевич дип дәшкәннәре булмаган, күрәсең. Ул тиздән үзе дә «Хуҗа»га күнегеп китте.

— Хуҗа, кандейгә әйт, майны кысмасын.

— Хуҗа, бүген минем чират иде бит, ә сөякне дракон кимереп утыра.

«Тобик хуҗасы» эшкә сәгать иртәнге биштә тора. Камбузга керә, Тобик исемле этенә тәбә пешерә, колбаса кыздыра. Ашаткач, этен каютасына кертеп йокларга яткыра да эшкә керешә. Галочкин ишек тоткаларын, су краннарын, иллюминатор кысаларын яшел паста белән ышкып ялтырата. Ышкып шомартсаң, җиз алтыннан көчлерәк ялтырый. Ашханә залын, буфетны, кызыл почмакны Дмитрий Афанасьевич кичтән юып калдырган була, ул аларны иртән юеш чүпрәк белән тагын сөртеп чыга. Өстәлләргә ак эскәтер җәя, ресторандагыча кашык, чәнечке һәм пычак куя. Өстәл саен салфетка һәм чәчәк. Чәйне диңгезчеләр сигезенче яртыда эчәләр. Пешергән чәй озак торса, тәмен, хуш исен югалта. Хуҗаның чәе диңгезчеләр килергә биш минут кала пешерелгән була. Әгәр берәр матрос ун минутка соңга калып килсә, Дмитрий Афанасьевич аңа яңа чәй ясый.

Ашханәдә эшләгән чакта Галочкинның өстендә яңа юып крахмалга манган ак куртка, куенында күбәләк галстук, беләгендә ак сөлге. Дневальный ашханәгә керүченең һәрберсен елмаеп каршы ала, урынына кадәр озатып куя һәм торып китәр алдыннан: «Тамагың туйдымы? Әллә өстимме?» — дип сорый. Галочкинның соравы олылый, җанны рәхәтләндереп җибәрә. Без бит адәм балалары — җылы сүзгә һәрвакыт мохтаҗ яшибез. Әйбәт мөнәсәбәт безгә саф һава дәрәҗәсендә кирәк. Әни кискән икмәк телеменең ашханә өстәлендә яткан икмәктән тәмлерәк булуы бәхәссез. Дмитрий Афанасьевич кискән икмәк тә гаҗәп тәмле тоела. Сере — Хуҗаның тылсым беләгендә. Ул эшне куанып эшли. Табак-савыт юу, камбуздан аш ташу, идән себерү аңа начар эш тоелмый. Эш аны канәгатьләндерә: аның үзен дә, башкаларны да.

Мин дә бит бер елга якын дневальный булып эшләдем. Табак-савыт юу, идән себерү авыр тоела иде миңа. Кешеләргә кем булып эшләвемне сөйләргә ояла идем. Галочкинның эшен күргәч, мин аңладым: җир йөзендә яхшы һәм начар, абруйлы һәм абруйсыз эш юк. Эшнең бөеге — син яраткан эш. Нинди бөек, шифалы һәм илаһи көч икән ул ярату! Ул дөньяны матурлап, яшәүгә ямь биреп торган бөек тылсым.

Кичке чәйдән соң диңгезчеләр кино карарга җыелалар. Хуҗа, этен ияртеп, палубага чыга. Сул як шлюпка астында аның махсус урындыгы бар. Шунда барып утыргач, Дмитрий Афанасьевич Тобикны алдына ала, кочаклый. Эт хуҗаның битен, кулларын ялый. Хуҗа сөеклесенең тамак астын кашый, сыртын сыпыра. Алар бәхетле. Галочкин — буйдак. Тобикның да хуҗадан башка беркеме юк. Дөрес, ул башка диңгезчеләрне дә ярата. Ул аларны Хуҗага ихтирам күрсәткәнчә, аңа ягымлы булганы өчен ярата. Ялгыз ир һәм ялгыз эт. Алар икесе дә яратуга, назга мохтаҗ. Хуҗаның йөрәк җылысы тулысынча Тобикка эләгә, этнеке — Галочкинга. Уртак ярату аларның икесен дә бәхетле итә. Бай, зур һәм бөек ул бәхетле кеше.

Алар шулай, диңгезгә карап, төн урталарына кадәр утыралар. Тобикның исенә көчек чагы төшә булса кирәк. Ул ара-тирә шыңшып ала. Галочкинның да еш кына яшь чагы, авылда яшәгән чагы, җимерелгән беренче мәхәббәте исенә төшә. Дмитрий Афанасьевич ул турыда уйламаска тырыша. Корабта аны яраталар. Аның эте һәм яраткан эше бар.

Кайвакыт Галочкин белән Тобик янына диңгезчеләр җыела. Кем-

дер Тобикка конфет, кемдер казылык китерә. Кайберәүләр үзләренең кызыксынуларын алып киләләр. Диңгезчеләр Галочкиннан Лондон портында Тобикка камзул тектергәнен сөйләтәләр. Диңгез ләчтите башлана. Эт кешеләрнең сөйләшкәнен, күзләренә карап, дикъкать белән тыңлый. Кайвакыт ул койрыгын болгап куя. Әйтерсең, ул барысын аңлый, койрык болгавы — раслау билгесе. Тобик кешеләрне ярата. Ярату — шул ук аңлау бит ул. Аңлау — шул ук ярату, ихтирам итү.

— Тобик, исерек матрос пароходка ничек кайтып керә? — дип сорый кем дә булса. Эт әүмәк-тәүмәк килеп йөреп күрсәтә.

— Тобик, боцман Жак матросларны ничек сүгә?

Эт танавын өскә күтәрә, тешләрен ыржайта һәм ырылдарга тотына. Шундый усал һәм тәкәббер ул хәзер. Диңгезчеләр тәгәрәшеп көләләр.

— Капитан каршында боцман үзен ничек тота? — дип сорыйлар Тобиктан.

Тобик палубага ята һәм, койрыгын болгый-болгый шыңшып, безгә таба түше белән шуып килә. Диңгезчеләр көләләр. Боцман сүгенә:

— Туйган инде, Галочкин, синең корчаңгы көчегеңнән, ди ул. — Палубага тәрәт итеп йөри. Сиңа өч көн срок. Әгәр өч көн эчендә этеңә оя ясап, шунда бикләп тотмасаң, мин аны диңгезгә томырам.

Диңгезчеләр кабат рәхәтләнеп көләләр. Тобик — артист. Ул күрсәткән образ кораб тормышындагы хакыйкатьне тапкыр чагылдыра. Диңгезчеләр Тобик күрсәткән образ аша боцманның коллективка хыянәтен фаш итteләр. Алар шаяртып кына боцманнан «үч» алдылар. Егетләрнең күңелләре булды.

— Тобик, капитан ачулы чакта ничек сүгенә? — дип сорыйлар аулаграк минутларда. Эт арт аякларына басып башын күтәрә, күкрәген киерә һәм күзләрен акайта:

— Һау-һау-һау.

Нәкъ шул чакта:

— Капитан килә, — дип кычкыралар. Эт юкка чыга. Аны ни кадәр эзләсәң дә, таба алмыйсың.

Һәр экипажның үз риваяте, үзе чыгарган легендасы була. Шул легендалар арасында экипажның яратканы — эт хуҗасының Одессага кайткач ял итүе.

Сәяхәттән кайткач, Галочкин бер тәүлек ял сорап ала. Бу тәүлек аныкы. Ял көне Дмитрий Афанасьевичка диңгез юлында чәчелеп калган гомере, якынлашып килгән картлык һәм сугыш еллары авырлыгында үткән яшьлеге өчен дә яшәп калырга кирәк.

Хуҗа, Тобикны ияртеп, ярга чыга. Потемкин баскычыннан менә, Одессаның иң яхшы парикмахерскаясына керә. Эт иң оста мастер кулында. Тобикның йонын матурлап кыркалар, затлы шампунь белән юалар. Бу эшкә Галочкин илле сум түли. Чиратта — ресторан. Эт белән хуҗа Одессаның иң яхшы рестораны — «Лондонский»га керәләр. Дөрес, «Лондонский»ның залына эт белән керергә рөхсәт ителми. Галочкин белән Тобик — легендар шәхесләр. Алар һәм экстраординар шәхесләр өчен «в виде исключения» дигән канун бар. Шул канунга таянып кертәләр Галочкинны ресторанга.

Керәләр. Өстәл әзер. Эт почетлы урында. Башта этне сыйлыйлар. Балык уылдыгы, севрюга. Тобикның яраткан азыгы — каз бавыры. Эт ашап туя, өстәл астына кереп бөгәрләнеп ята. Бу көнне Дмитрий Афанасьевич җан өчен, күңел өчен яши. Аның җаны бүген җыр тели. Ресторан ябылганчы, оркестрны ул уйната. Оркестр егерменче елларда дан тоткан җырларны уйный. «Чубчик»ны Дмитрий Афанасьевич кат-кат уйнаттыра һәм, оркестрга кушылып, туйганчы елый. Бу көн — аныкы һәм Галочкин бу көнне арзанга ычкындырырга теләми.

Безнең чорда космоска ракета очырту да, атом төшен аерып алу да катлаулы түгел. Җир йөзендәге иң катлаулы нәрсә — адәм баласы, аның җаны, кичерешләре. Бу дөньяның иң катлаулы сере адәм

баласының бәхетле һәм бәхетсез булуы. Кеше дигән җан иясен без бөтенләй белмибез һәм киләчәктә дә тиз генә белә алачак түгелбез.

Корабка кайткач, Дмитрий Афанасьевич «үз көне» житкәнче, башын да күтәрмичә, тагын айлар буе эшли. Эткә тиешле рияссыз хисләр исраф булыр дип куркып, беркем белән дуслашмый. Бәлки, шул сәбәп аны буйдаклыкта яшәргә мәҗбүр итә торгандыр? Кем белә? Аның яшәвенең һәр сулышы эткә булган дуслыкны саклауга багышланган. Дуслыкка зыян китерер эшкә ул теше-тырнагы белән каршы. Без шуны гына беләбез.

Борынгылар тәкъдир дигән нәрсәгә ышанганнар. Дмитрий Афанасьевичның яшәве нилектән шулай икән? Галочкинның тормышын фән, дә фәлсәфә дә аңлата алмый. Адәм баласының кичерешләре — сер. Алар аның белән гүргә китәләр.

* * *

Су. Суның чиген таба алмыйча, күз арып туктый. Су офык читендәге зәңгәр күккә барып тоташкан. Офык артында тагын су. «Бәлки, без югында, туфан калкып, җир йөзе су астында калгандыр?» — дип шикләнеп куясың. Җирне, җир йөзендәге кешеләрне, җан ияләрен, үсемлекләрне күрәсе килү кинәт кабынып, бәгырьләргә тиеп китә. Өске палубага менәсең. Офык бераз киңәя төшә. Үрмәләп, мачтага менәсең — офык тагын да киңәя. Ә җир барыбер күренми. Һаман су. Су сахрасы. Мачтаның салкын тимер баганасын кочаклап утырганда, ачыш ясап куясың — җир шары чыннан да түгәрәк икән. Һәм горурлык уяна — җирнең түгәрәк булуын үз күзең белән күрдең... Син — Колумб, Магеллан.

Инде биш тәүлек кораб яныннан туктаусыз су ага. Яныбыздан атаулар, материклар узды. Ят кораблар туктаусыз узып тордылар. Суның да, уй-исәпләрнең дә чиге юк. Уйлар, күңел аша узганда, күкрәктә тынгысызлык калдырып китәләр. Сәяхәткә кузгалганнан бирле тоташ тынгысызлык. Ял юк, котылыр чара юк. Бүген дә тынгысызлык минем белән бергә уянды. Безнең вахта иртәнге биштән көндезге унбергә кадәр йоклый. Уяндым. Унбиш минуттан төшке аш, сәгать уникедә вахта башлана. Күлмәк кия башлаган идем, бер сәдәф өзелеп китте. Җеп эзләргә керештем. Деримедведь белән Белоштан өзелгән сәдәфне тимер чыбык белән генә эләктереп куялар. Энә белән эш итәргә мин армиядә күнектем. Җеп сорарга Анастасия Аристарховнаның каютасына юнәлдем.

Мин кергәндә, буфетчы хатын көзге каршында башына ак косынка бәйләп азаплана иде. Йомышымны әйткәч, өстәл тартмасын ачып, җеп эзләргә кереште. Һәм нәкъ шул мизгелдә ишек ачылып китте дә каютага атылып Лохмачев килеп керде.

— Аңлашылды, — диде ул майлы күзләрен бер миңа, бер Анастасия Аристарховнага төбәп. — Аңлашылды. Көпә-көндез, бикләнеп, шушы эш белән шөгыльләнәләр. Оят түгелме?

— Нинди эш ул, Виктор Филимонович? — буфетчица елый башлады. — Төннәрен бикләгән ишекне тартырга теләп бәйләнүегез җитмәгән, оятсыз, ялган яла ягудан да тартынмыйсыз икән.

— Мин әле дә каютагызны дубликат ачкыч белән ачып кердем. Каюта эчтән бикле иде, — диде Лохмачев чыгып китәр алдыннан.

Анастасия Аристарховна зарланырга тотынды:

— Белдем мин аның кабахәтлек эшләрен. Алдан белеп тордым. Әгәр төн кунарга кертмәсәң, визаңны яптырам ди. Яный, куркыта.

— Помполитка әйтергә кирәк, — дидем мин, аны юатырга тырышып. — Болай калдырырга ярамый. Хәзер мин үзем әйтәм. Ул әле моның белән генә чикләнеп калмас, тагын әллә ниләр эшләр.

— Әйтмәгез, Габдрахман, барыбер ышанмаслар. Лохмачев — капитанның иң якын дусты. Власть алар кулында. Помполит та берни эшли алмас. Алар помполитны да кысалар, диңгез эшен белмисең, катнашма дип куркыталар.

Кәеф кырылды. Ашханәгә кереп тормыйча, вахтага чыктым. Тынгысыз, теңкәгә тия торган вакчыл кайгылар җанны агулап тора иде. Ярты сәгатьтән мине капитан чакырды.

— Әллә берәр ярамаган эш эшләдеңме? — диде Лагуткин, тынгысызлана төшеп. Аңа сөйләп, эчне бушатырга, киңәш сорарга кирәк иде. Бу фикер соңга калып килде.

— Мөмкинме? — дидем мин, капитанның ишеген шакып.

— Мөмкин.

Помполит Чоломбитько да монда иде. Ул дәшмәде. Күтәрелеп карарга базмыйча, помполит күзен яшерде.

— Мин аның кем икәнлеген Босфорны үткәндә үк аңлап алдым, — диде капитан, помполитка төбәп. — Рульдә торуын онытып, гел Стамбулны күзәтте, гел шуңа карады. Төрек шәһәре сиңа нигә кирәк иде?

— Минем ул каланы беренче күрүем иде, — дидем мин, гаепнең асылын аңлый алмыйча.

— Ишеттеңме? — диде Деркач, помполитка борылып. — Ул менә нинди теләк белән «Чолман»га килгән. Күзәтер өчен. Кызыксыныр өчен. Башта кызыксына, аннан соң өйрәнә, соңрак, Босфорны үткән чакта — фьюить — суга сикерә дә, йөзеп, ярга чыга. Менә кемне пароходка утыртып йөрибез без, Афанасий Иванович.

— Мин сезгә фикеремне әйттем, Григорий Григорьевич. Ашыкмыйк, дидем. Буфетчицаның каютасында андый эш барлыгын белгәч, Лохмачев кемне дә булса шаһит итеп алып керергә тиеш иде. Бер өлкән штурман сүзеннән чыгып кына юридик яктан без аларны җавапка тарттыра алмыйбыз, — диде помполит.

— Шул ук хәл, — диде капитан, ачуыннан тәмам кызарып. — Син, помполит, диңгез спецификасын белмисең, бөлергә дә теләмисең. Синең йомшаклыгың аркасында экипажда тәрбия эше җимерелеп бара. Кисәтеп куям, әгәр тикшерә башласалар, сине эшеңнән чыгарачаклар, күрерсең.

— Бу турыда без аерым сөйләшербез, — диде Чоломбитько. — Рахманкулов мәсьәләсен хәл итәргә җыелдык без, шуны карыйк.

Эчемә җылы йөгерде. «Помполит Деркачның кем икәнлеген аңлаган, күрәсең. Ул мине якларга тиеш», — дип куанып куйдым.

— Рахманкулов, сез буфетчица янына нигә кергән идегез? — диде Чоломбитько.

— Җеп сорарга.

— Каютага кереп бикләнмичә генә сорап булмый идемени? — диде Лохмачев, зәңгәр күзләрен миңа төбәп.

— Мин, Виктор Филимонович, сезнең шикелле төн урталарында янап, куркытып, буфетчы каютасына һөҗүм ясамыйм, — дидем һәм шундук телемне тыя алмавыма үкенә башладым.

— Ишеттегезме? — диде Лохмачев, урыныннан сикереп торып. — Шулай әйтер дип, мин сезне алдан кисәтеп куйдым.

Йодрыгымны кысып йомарладым. Тырнаклар уч төбенә батып керделәр.

— Беренче тапкыр строгий выговор белән чикләнәм, — диде капитан. — Әгәр тагын каютага кереп, азынып йөрүеңне белсәм, Африкадан җәяү кайтарып җибәрәм.

Мин рөхсәт сорап чыгып киттем. Киңәшмә дәвам итеп калды.

Тирә-юньдә су һәм зәңгәр күк. Рәхәт тынычлык һәм пакь зәңгәрлек. Минем күкрәк эчендә мәңге төзәлмәслек җәрәхәт. «Нигә шушы кадәр борчылам мин? Лохмачев сүзенә кем ышаныр!» — дип, үз-үземне юатмакчы булам. Барсуков ышанмас. Лагуткин һәм Емельянов та бу

ялага ышанмаска тиешләр. Партоешма секретаре Черногорский белән сөйләшергә, аңа аңлатырга кирәк. Борчылырга ярамый... Юанырга тырышам. Булмый. Тынычлык бетте. Ничек кеше күзенә күренермен? Гайбәтне кем тикшереп тора? «Карл тун урлаганмы, әллә аның үзенең тунынмы урлаганнар — мескен Карл бәлагә юлыккан», — ди немец әйтеме. Мин дә хәзер шундый хәлдә.

* * *

Вахта алышынгач, мине помполит чакырды. Башта ул комсомол оешмасының эшләре турында сораштырды. Әкренләп, эшкә, ял итүгә һәм кемнәр белән дуслашып яшәвем турында кызыксына башлады. Аннары:

— Рахманкулов, минем дөресен беләсем килә, сез буфетчы каютасында нәрсә эшли идегез? — дип сорады.

— Лохмачевтан сорагыз. Ул белә, — дидем мин, ачуымны яшерә алмыйча.

— Юк, сез миңа тыныч кына сөйләп бирегез. Лохмачев кергәндә, сез нәрсә эшли идегез? — диде помполит.

— Лохмачев кергәндә, мин әнием белән бер яшьтәге Анастасия Аристарховнаның түшәгендә ята идем. Сезгә шушы сүз кирәкме? — дидем мин помполитка.

— Мин, Рахманкулов, конфликтны туктатырга телим. Коллективта ызгышып яшәргә ярамый, ә сез аңларга теләмисез. Мин тынычлык урнаштырырга юл эзлим, ә сез — кирегә таба.

— Афанасий Иванович, мин Лохмачев белән ике ел бергә эшләдем. Мин аның кем икәнлеген беләм. Каботажда эшләгәндә, ул мине капитан Курбатовка каршы котыртып йөрде. Ызгыш, бер-береңә бәла ягу, пычраклыклар булмаганда, Лохмачев тыныч яши алмый. Күрерсез киләчәктә ниләр булганын.

Помполит тәмәке кабызды. Бер тын, йотлыгып, төтен суырды.

— Без әллә нинди куркынычлар көтмик әле, Рахманкулов, — диде Чоломбитько. — Партия мине экипажда гаделлек һәм социалистик закон хөкем итсен өчен куйды. «Чолман»да коллектив начар түгел. Экипаж бердәм. Мөнәсәбәтләр җылы. Минемчә, сез юкка паникага биреләсез.

— Дөрес, Курбатов биргән тәрбия бетеп җитмәгән әле. Василий Степанович капитан булып торган заманда «Чолман»да эшләү үзе бер зур бәхет иде. Эш чиктән тыш авыр иде каботажда йөзгәндә. Курбатов белән Бригас җитәкчелегендә без авырлыкларны сизмәдек. Сез әле аңлап бетермисез, Афанасий Иванович, коллектив таркала башлады. Нindидер куркыныч, акылны тар-мар итә торган шикчеллек барлыкка килде. Без хәзер авыз ачып сүз әйтергә куркып, бер-беребездән шикләнеп йөрибез.

— Дөрес түгел, — диде помполит. Һәм мин аңладым: аның эшен тәнкыйтьли идем мин. Ул эшли башлагач, экипажның эше, коллективтагы атмосфера яхшырырга тиеш иде. Помполит тәмәке төпчеген көл савытына басып сытты, урыныннан торып, иллюминаторга карап килде. Кораб чайкала башлаган иде. Чоломбитько әле чайкалуга күнекмәгән иде. — Сез ялгышасыз. Пессимизмга бирелү бу. Мондый кәеф белән яшәргә ярамый. Мин сезгә рөхсәт итмим алай яшәргә.

—Аңлыйм мин сезне, Афанасий Иванович. Монда сезгә дә авыр. Устав буенча сез бит капитанга буйсынасыз. Тәрбия эше буенча сез җавап бирәсез. Экипаж аңлый, бу атмосферада тәрбия эшен алып баруы авыр сезгә.

— Сез мине аңларга теләмисез, Рахманкулов. Дөрес, капитан — единоначальник. Ул биргән приказны беркем үзгәртә алмый, хәтта ко-

мандирлар киңәшмәсе чыгарган карарны да үтәмичә, ул үзенчә эшли ала. Буржуаз системада капитанга берничек тә тәэсир итеп булмас иде. Без социалистик илдә, партия җитәкчелегендә яшибез. Корабта партоешма бар. Капитан — партия әгъзасы. Ул партоешма карарына тулысынча буйсына. Бу — безнең социалистик системаның өстенлеге. Димәк, аның ялгышлыкларын төзәтеп була. Киләчәктә шушы юл белән эш итәчәкбез. Бу турыда без партгруппорг Черногорский белән киңәштек. Ул да дөрес аңлый. Ә син пессимизмга бирелгәнсең. Без, комсомол секретаре, оптимист булырга тиеш. Давай, җиң сызганып эшли башлыйбыз. Килештекме?

— Килештек, — дидем мин һәм, рөхсәт сорап, чыгып киттем.

Бу кеше авырлыктан курыкмый иде. Мин шуны аңладым.

* * *

Гомеремдә беренче тапкыр Африка ярларын күрәм. Шушы көнгә кадәр китап сүзләре һәм географик карта аша гына чагылып торган ерак континент минем күз алдыма килеп басты. Яңа күренеш вак-төяк борчылуларны, көндәлек ыгы-зыгыны каплап китте.

Бу тойгы миңа электән үк таныш иде. Авиациядә очасы маршрутның һәр чакрымын алдан хисаплап, юнәлешен картага сызып куясың. Самолетның тизлеге, җил тәэсире, очкычның винт әйләнгән якка тайпылуына кадәр алдан хисаплап куелган. Приборлар дөрес күрсәтә. Һава торышы әйбәт: давыл да, томан һәм яшенле яңгыр да юк. Ә җан, нигәдер, тыныч түгел. Маршрут юлыннан дөрес бара алуыңа һәм аэродромга кире әйләнеп кайтуыңа беркайчан да тулысынча ышанып бетә алмыйсың. Заданиене үтәп, аэродромга әйләнеп кайткач кына акылыңа һәм эшне дөрес башкаруыңны аңлап куанасың. Диңгезчелектә дә шул ук кагыйдә хөкем итә.

Порт-Сәид күренгәч, Лагуткин мине кочаклап алды.

— Дрейфка күбрәк куйганмындыр дип хафаланган идем. Дөрес эшләгәнмен икән. Бер генә градуска да читкә тайпылмаганбыз. — Икенче штурман капитанга чылтыратты. — Порт-Сәид ачылды, Григорий Григорьевич...

Бераздан рубкага капитан килеп керде. Маңгаенда тирән җыерчыклар. Бу юлы мин аны кызганып куйдым. Шатлана белми иде бу кеше. Өстәвенә, башкаларның гаделлегенә, тугрылыгына ышана алмый иде ул. Аңа һәр кеше үз җаен караучы, үз файдасы өчен ялганларга, теләсә нинди әшәкелеккә әзер торучы булып күренә ахрысы.

— Каян белдең аның Порт-Сәид икәнлеген? — диде ул Лагуткинга.

— Ярлар нәкъ лоциядә күрсәтелгәнчә ачылды. Әнә, маяк та һәр ике секунд саен кабынып-сүнә. Тышкы рейдта каналга керергә чират торучы кораблар да күренә. Аннан соң, әнә теге гөмбәзле ак йорт Сүәеш каналы кампаниясенең идарәсе булырга тиеш, — диде икенче штурман.

— Булырга тиеш, — диде капитан ышанмыйча. — Әгәр ул башка порт булса? Яр сызыгы күренү белән, мине чакыр дип кисәтмәдеммени сине?!

Аңа капитан вазифасы чиктән тыш авыр иде, күрәсең. Табигать аңа зирәклек бирергә оныткан. Акыл бит ул кыенлыкларны җиңәргә юл күрсәтә, катлаулы мәсьәләләрне гадиләштерә, кулдашларың белән уртак тел табарга ярдәм итә. Капитан Деркачның күзаллавы һәрвакыт кыенлыкка килеп төртелә. Катлаулы мәсьәлә аңа йөз тапкыр катлаулырак күренә, үзенең ярдәмчеләренә ышанмаганлыктан, алар да капитанга тиешенчә ярдәм итә алмыйлар. Деркач — ялгыз.

Бер тын рубкада таптанып торганнан соң, капитан машина телеграфын «малый вперед»ка күчереп куйды. Машина бүлегендә реверс бир-

деләр. Корабның баруы әкренәйде. Лоцман көймәсенең кызыл уты пароходка якынлашып килә иде. Көймә «Чолман»га килеп сырышты.

— Нәрсә көтәсең каршы ал, — дип боерды капитан миңа. Мин, рульне Лагуткинга тапшырып, лоцманны каршы алырга аска төшеп киттем.

***

Каналга керү чиратында пассажир лайнерларын, супертанкерларны алга куйдылар. Кәрванга җыелган кырык ике кораб арасында «Чолман» утыз тугызынчы булып бара.

Порт-Саиднең йортлары, караңгыдан чыгып, кораб белән тигезләнә, аннан соң, артта калып, күздән югала. Каланы җылы, йомшак караңгылык томалаган. Утлар сүлпән яна. Кала эчендә серле шәүләләр кыймылдый. Алар пальма агачлары, челтәрле койма диварларга сырышканнар. Таш диварлар күренеп үтә. Челтәрле капкалар, мәчет манаралары, шуларның һәммәсеннән, муеннарын сузып, шул шәүлә карап кала. Урам фонареның тонык уты астында берничә кеше кулларын болгыйболгый сөйләшеп торалар. Алар да шәүлә рәвешендә генә чагылып китә. Як-якка карамаска тырышам. Күз алдымда — компас угы, кулым — штурвалда. Ят каладагы төнге тормышны тән һәм күңел сизә. Хәтта таш стеналар эчендә кайгы-хәсрәтләрен бүлешеп, иртәгесе көнне кайгыртып утыручы җир улы — гарәпләрне дә күңел күзе күреп бара.

Шәһәр артта калып югалды. Африка ягыннан искән төнге җил бала елаган тавыш алып килде. Исемә мәмлүкләр язмышы килеп төште. «Әллә шуларның туган җирләреннән мәхрүм калган җаннары үксиме?» — дип уйлап, тетрәнеп киттем.

Сулда — Азия, уңда — Африка. Европа диңгезләр артында калды. «Чолман» әкрен генә ике континент арасыннан бара. Минем туган авылым һаман ераклаша. Сагыну еракка киткәч тә сүнми икән. Ара озынайган саен, аерылу хисе һаман көчәя, тирәнәя. Сафка тезелеп барган кораблар арасында — безнең «Чолман», аның эчендә — Караяр малае Габдрахман Рахманкулов. Вахтаның соңгы минутлары. Арылган. Күк йөзендәге алсулык һаман киңәя. Офык читендә әллә нинди көрәнсу-шәмәхә төсләр кайнашып алды. Яңа көн туа. Барсуковны ияртеп, рубкага Лохмачев менде. Безне алыштырдылар.

Ашыйсы һәм йокы килүгә кул селтәп, өске палубага мендем. Уңда Нил суына тоташкан ерганак-канал фәллахларның бакчасын сугара. Соргылт саман йорт ышыгында балалар уйнап йөри. Качышлы уйныйлар. Гарәп балаларының уйнавында бернинди аерма, бернинди үзгәлек тапмыйм. Балалар — иң бөек, иң даһи интернационалистлар.

***

Сүәеш каналыннан чыгып, дүрт тәүлек йөзгәннән соң, офык читендә яр сызыгы күренде. Якынлашкан саен, коры җир ачыла. Инде яр буена тезелеп утырган ак йортларны, мәчет манараларын ерактагы ак сыртлы зәңгәр тауларны аерып була башлады. Яр белән таулар арасындагы яссы яшеллек — Африка саваннасы. Саваннада кайнозой эрасында яшәгән казылма җәнлекләргә охшашлы ялгыз агачлар.

Туган телебездә сокланырлык матур яңгыраган «әрәмә», «урман», «дала», «кылган» шикелле сүзләр күп. «Саванна» сүзе дә ничектер безнеңчә яңгырый иде. География дәресендә беренче тапкыр «саванна» сүзен ишеткәч, күз алдыма йомшак ак чәчләрен җилфердәтеп дулкынланган кылганлы дала килеп басты. Кылган дулкыны эчендә, сикерешеп, кыр кәҗәләре уйнап йөри, күктә — горур бөркетләр. Җилкаләренә озын

муенлы чүлмәк утырткан кызлар судан кайта. Шул сурәт әле һаман күз алдымда.

Без Судан иленең Судан исемле портына якынлашып киләбез. Порт, яңа гына судан чыгып, яр буена ял итәргә утырган каланы хәтерләтә. Шәһәр артында саванна башлана. Чын саванна башкарак булып чыкты. Аксыл төстәге киң, биек күк йөзе. Еракта биек таулар. Диңгез ярыннан башланып киткән яшел киңлек ерактагы тауларның итәгенә барып терәлгән. Африка җире без күреп күнеккән иген кырлары шикелле йончылмаган. Мондагы җир яшь һәм көр табигатьле. Саваннадан нефть даулап, аның җелеген, канын суырмаганнар. Бу җирдән бер-бер артлы канлы сугышлар да үтеп тормаган. Дөрес, монда да басып алулар, сугышлар булган, килмешәкләрнең дагалы итеге монда да җирле халыкның ирегең сыткан. Бәлки, саванна өстендә танклар йөрмәгәнгә ул шулай көр, яшь табигатьле күренә торгандыр?

Бер дуамал теләк күңелне кыбырсытып узды. Офык читендәге чал тауларга җиткәнче, үлән өстеннән яланаяк барасым килә иде. Үләннең иң куе җиренә чалкан ятып, «Каз канаты»н җырлыйсым килү бәгыремә бәрелде. Бу теләк, билгеле, беркайчан да чынга ашмаячак. Без — эш кешеләре. Эшне мин унбиш яшемдә иярләдем. Сугыш чоры безне иртә өлкәнәйтте. Шул ашыгып өлкәнәю аркасында балачак теләкләре гамәлгә ашып бетмичә һаман саклана,вәсвәсәли, күрәсең.

Су астында сагалап торган мәрҗән рифларын урап үтеп, ярга життек. Аврал уйнадылар. «Чолман»ны, юан арканнарга тарттырып, причалга бәйләдек. Мине кораб сакларга трап янына вахтага куйдылар. Минем белән бергә корабны Судан солдаты да саклый. Яшькелт кыска чалбар балагы эченнән кап-кара сыйраклар тырпаеп чыккан. Өстендә шул ук яшькелт тукымадан теккән озын тужурка. Башындагы киң читле кара йон эшләпәгә тәвә кошы каурые беркетеп куйганнар. Уенчык солдатка охшашлы булса да, сакчы шундый житди һәм тәкәббер. Янымнан узганда, солдат винтовкасын кысыбрак тота. Янындагы кеше белән сөйләшми, аралашмый тору искиткеч газаплы икән.

Төнге җылы җил саванна ягыннан әллә нинди сәер тавышлар алып килә. Шәһәрдә утлар җемелди. Кемдер өзек-өзек итеп әллә җырлый, әллә дога укый. Чит ил, ят континент. Мине хәйран калдырган нәрсә — монда да кояшның көнчыгыштан калкуы. Монда да өстә — күк йөзе, аста — җир. Монда да үлән җирдә үсә, болытлар күк йөзендә йөзәләр. Африкада яшәүчеләрнең дә бәхетле буласылары килә торгандыр? Алар да, күп кенә халыклар шикелле, ач-яланган калудан һәм сугыш чыгудан куркып яши торганнардыр?

Сәгать төнге дүрт җиткәч, кубрикка кереп, Белоштанны уяттым. Ул, мине алыштырып, вахтага басты.

***

Кичтән башланган йөк бушату караңгы төшкәч тә туктамады. Төн рәхимлерәк. Юеш кайнар һава парлы мунча һавасын хәтерләтә. Төнлә кояш тәнне көйдерми.

Дөбердәп, чыгыр әйләнә... Мачтага беркеткән йөк уклары трюм эченнән капчык бәйләмен сөйрәп, өскә күтәрәләр һәм причалга бушаталар. Мин трюм авызына килеп аска карадым. Мәйданчыкта ярымялангач кешеләр кайнаша. Йөкне капчыкка тутырып торалар, икенчеләре капчык авызын тегә, өченчеләре тулы капчыкларны парашют өстенә ташып өяләр. Парашют тулу белән, капчыкларны өскә күтәреп, причалга төшерәләр. Ярдагы грузчиклар капчыкларны машиналарга төйиләр.

Кубрикта ятканда ишеттем мин бу тавышны. Гаҗәп тәэсирле, эчке экспрессиягә сугарылган сүзләрне матәмле тавыш белән кычкырып

укыйлар. Йөк бушатучыларның Африка континенты эченнән килгән кыргый кабилә вәкилләре икәнен икенче штурманга агент сөйләде. Алар Европада яшәүчеләргә охшамаган иделәр. Кара агачтан кырып ясалган сын шикелле чандыр җыйнак гәүдә. Тән шома, щетка белән ышкып ялтыраткан кыйммәтле күн шикелле елкылдап тора. Тәндә бер чеметем май юк. Тәндә мускул, сеңер һәм сөяк. Битләр бизәкле. Һәр яңакка үткен пычак белән колак астыннан авыз турына кадәр өч тапкыр сыздырганнар. Яра төзәлгәч, чукрәеп торган өч җөй калган. Чәч куе, киезләнеп беткән тыгыз бөдрә. Куе, калын чәч башны искиткеч зур күрсәтә. Муен нечкә, озын. Йөк бушатучыларның башлары казыкка утыртып куйган түгәрәк чүмәләне хәтерләтә. Мондый чәчкә, билгеле, тарак кермидер. Бамбуктан ясалган бәйләм энәсенә охшашлы тарагычларны йөк бушатучылар чәчләренә кадап йөртәләр.

Кояш зенитка күтәрелгәч, эсселек күләгә җирдә илле өч градуска житте. Шушындый кайнарлыкта бөтенләй эшләп булырлык та түгел, тәмуг эсселеге. Тәнеңнән туктаусыз тир агып торганда житмеш килограммлы капчыкны парашютка ташып торып кара әле. Ярты сәгатьтән җаның чыгар. Кыргый кабилә вәкилләре җырлап эшлиләр. Җыр ырым сүзләренә һәм сихергә охшашлы.

Чал чәчле карт абориген башлап җибәрә дә, югары бер ноктага житкәч, кинәт туктата. Шушы мизгелдә җырны йөкчеләр эләктереп алалар. Авыр капчыклар, җыр ритмына буйсынып, һавада очып баралар, парашют өстенә яталар. Җыр сүнә. Чал чәчле карт тагын такмакларга тотына. Башкалар кушылу белән, кабат тукый. Пружинадай тыгыз ритм йөкчеләрнең хәрәкәтләре белән идарә итә, ул капчыкларны һавага күтәрә, очыртып, парашютка китереп сала. Йөкчеләрдәге көч, алардагы түземлек — боларның барысы да шушы җыр сихереннән. Җыр берләштерә, җыр оештыра, җыр эшне тәртипкә салып, көйләп тора. Бәлки бу җыр да түгелдер? Дога, ырым дип атасак, дөресрәк булыр иде. Бала чакта мин «Без Кронштадттан» дигән кино карадым. Шул фильмның бер эпизоды күз алдымда калган. Бер төркем кызыл матрослар һәм кызылгвардеецлар ак офицерлар һөҗүменә каршы торырга, аларны үткәрмәскә, җиңәргә тиешләр. Комиссар атака алдыннан хәрби оркестр чакыра. Оркестр марш уйнап җибәрү белән, яралы матрослар, хәлдән тaеп арыган кызылгвардеецлар, җәрәхәтле тәннәренең сызлаганын онытып, атакага кузгалалар.

Татар телендә «көй» тәртипкә салуны, оештыруны аңлата. Бәлки безнең борынгы бабаларыбыз да күмәк эшне, һөҗүмгә баруны җыр көе белән оештырганнардыр? Кайда ул көйләр? Без соңгы вакытта жаныбызны көнбатышта сәүдә өчен эшләнгән шлягерлар белән туклandырып тора башладык. Ят көй җанны канәгатьләндерә алмый.

Төш вакыты житкәч, мин тагын вахтага бастым. Кояш һаман рәхимсез пешерә иде. Күктә бер болыт әсәре юк. Эсселектән миләр кайный. Йөкчеләрнең һаман әле туктарга исәпләре юк иде. Аларның көйләре шактый озынайды, ритм салмаклана төште. Йөк бушатучылар арый башлаганнар иде. Көй йөкчеләрнең арыганын сизеп әкренәйде, шәфкатьлерәк яңгырый башлады. Йончып хәлдән тайган кешеләрнең җырлап эшләве шундый кызганыч иде. Көй инде кумый, өндәми, ул үгетли, егылмаска, туктамаска куша, үтенә, ялвара.

Трюмда эшләүче аборигеннарның телен белмим мин. Җырның аерым үз теле бар. Җир йөзендә яшәүче халыкларның уртак теле. Җыр — сүзсез, турыдан-туры тойгылар белән сөйләшә. Африка континентының иң караңгы почмакларыннан җыелган мәҗүсиләрнең җыры миңа тулысынча аңлашыла иде:

Авыр түгел, жиңел бу...
Жиңел итеп алып сал.
Авыр түгел жиңел бу.
Егылма. Түз. Бердәм бул...

Көйдә мәгънә нәкъ шушы иде. Кыргый кабилә вәкилләренең йөк төйи торган көчле краннары да, капчык күтәрә торган автокаралары да юк. Аларның эш коралы — көй. Аларга шул ярдәм итә.

Бәләкәй чагым исемә төште. Ул чорда бергә җыелып кич утыру гадәте яшн иде әле. Кич утырып җеп эрләгәндә орчык әйләнгән ритмга күрше хатыннары бәет, мөнәҗәт әйтәләр. Әллә нинди борынгы йола җырларын, ниндидер ырымлы такмаклар әйтәләр. Җыр аларны илһамландыра. Күңел иҗат эшенә керешә. Кич утыручы хатыннар, үзләре дә сизмәстән, яңа бәет, яңа мөнәҗәт тә чыгарып куялар. Безнең әтиләр буыны җыр, мөнәҗәт аша яшәү серен аңларга тырышкан. Тәэсирле бәеткә, мөнәҗәткә әверелеп, моң халыкка вөҗдан хөкемен тарата. Көндәлек җыр һәм моң аша халык җәмгыятьнең рухи дөньясына тоташкан иде.



***

Асфальт юл портка кереп туктаган иде. Тропик кояшы асфальтны эреткән. Баскан саен, юлда аяк эзе кала. Порттан чыккач, кабырчык исенә кояшта кызган җылы үлән исе кушылды.

Бинокльдән караганда, шәһәр читендә каплап куйган чүлмәккә охшашлы сәер корылмалар күренә иде. Шулар янына килеп туктадык. Кызыл балчыктан катырып ясалган һәм җиргә каплап куйган гигант сөт чүлмәкләре. Үрмәләп кенә керерлек тәбәнәк ишек, тәрәзәләр юк. Яктылык очлы түбә уртасындагы түгәрәк тишектән керә. Йортның төп вазифасы — адәм баласын эсселектән саклау. Шуңа күрә баш сыймаслык тишектән кергән яктылык та җиткән.

Адәм баласы нинди генә корылмалар салмый! Балалар бакчасы һәм төрмә, алачык һәм патшалар сарае, вигвам һәм көяз коттедж. Чүлмәк йортлардан соң русларның өйләренә охшашлы соры шифр түбәле кирпеч йортлар башланды. Нәкъ шушы күренеш тетрәндерде мине. Мин илленче еллар тәрбиясендә күзалларга өйрәнгән кеше. Чит илләр тоташ эшсезлек, забастовка һәм кризислардан укмашып оешкан булып күз алдына баса. Башка илләрдә бездәгегә охшашлы берни булмаска тиеш дип, шулкадәр тирән инанган булганмын, соргылт кирпечтән салган җәлпәк йортларның безнең ил йортларына охшашлы булуы искиткеч тетрәндерде.

Судан каласындагы эсселек Урта Азия чүлләрендә дә юк. Андагы эсселек коры — су парлары белән сугарылмаган. Монда кайнар пар катнаш юеш эсселек. Төкерек, җиргә төшкәнче, парга әйләнә. Бер тавыш, бернинди хәрәкәт юк. Әйтерсең, кояш нурлары тереклек дөньясын тоташ күмергә әйләндергән.

Шәһәр читендәге аерым йортларны үтеп эчкәрәк кердем. Тоташ урам башланды. Юл чатлыгына җитеп, сулга борылдык та әлсерәп торган зур кәҗәгә килеп юлыктык.

— Шайтан түгелме икән бу? — диде Барсуков һәм кәҗәне читтәнрәк урап узды.

— Әй, мур кыргыры, син нишләп чит илгә килдең? — диде Лагуткин шаяртасы итеп.

Тимер пароход, дөбердәп эшләп торган машиналар өстендә яшәү безне ялыктырган иде. Ак кәҗә балачакның саф куанычларын уятып җибәрде. Мал карау кешене рухи яктан баетып җибәрә. Сыер, ат, кәҗә асраучылар көн саен хайванның талымсызлыгын, аның эчкерсез, беркатлы гадилеген күреп торалар. Бәлки шуңа күрә хайван караучылар йомшак мөнәсәбәтле, талымсыз, сабыйларча мөлаем була торганнардыр?

Кәҗә күздән югалды. Каршыбызга баштанаяк ак тукымага төренгән бер хатын килеп чыкты. Озын, матур куллар канат рәвешендә як-якка җәелгән. Гәүдә төз, нәфис. Хәрәкәтләр төгәл, салмак. Тамаша күрсәтүче жонглерларның хәрәкәтләре шундый була. Хатынның баш

түбәсендә яшелчә, ал чәчәкләр төшкән бизәкле сандык иде. Өстәл зурлыгы сандык баш түбәсенә береккән.

— Егетләр, ул сандык ничек төшеп китми? — Барсуков хәйран калып туктады. Күзәтә башлады.

— Әйтерсең, кадаклап куйганнар, — дидем мин соклануымны яшерә алмыйча.

— Йөрүен карагыз. Аяклары җиргә дә тими шикелле. Әйтерсең, һавада очып бара, — диде Лагуткин.

Без, хәйран калып, карап торабыз. Хатын да безгә таба борылып карады, елмайды. Ә сандык һаман ябыштырган шикелле баш түбәсендә утыра. Судан хатыны, борылмага җитеп, күздән югалгач та, аның канат шикелле җәелгән куллары, җиңел сыны, байрак шикелле җилфердәп барган бөркәнчеге бик озак күз алдында торды.

Үзәккә якынлашкан саен, йортлар биегәя, ешая. Алар бер-берсенә терәлеп утыра башладылар. Һәр бинаның беренче катында кибет. Сатыласы товарларны, урамга чыгарып, тышкы як стенага, ишеккә элгәннәр, күп товарны тротуарларга тезеп куйганнар. Аяк киемнәре, күлмәк-чалбар, күн әйберләр аша атлап узабыз. Сәүдәгәрләр күләгәдә ашыкмыйча гына тәсбих тартып утыралар. Печән базары, «көфер почмагы» искә төшә. Сәүдәгәрләр күп. Адым саен кибет. Кибет саен сәүдәгәр. Аларның күбесе сатлык товарларын күтәреп йөриләр. Сатып алучы, урамда өелеп яткан товарлар белән кызыксынучы күзгә күренми. Сәүдәсез сәүдәгәрләр ничек яши, ничек тамак туйдыра икән дип сәерсенеп куясың.

Каршыбызга ике европалы килә. Ирле-хатынлы. Ире иллedән узган булса кирәк, хатын утызлар тирәсендә. Икесе дә кыска чалбардан, башларында бөке шлем. Плантаторлар! Бу ирнең кулына камчы тоттырып карыйм. Негрлардан шикәр камышы ташытучы надсмотрщик күз алдыма килә. Җыерчыкланып беткән кансыз бит, юка ирен, алга чыгып торган киң авыр ияк. Хәрәкәтендә, күз карашында корыч тәвәккәллек. Теләсә кемне буйсындыра, теләсә нинди шартларда теләсә кемнән үз кирәген ала торган прагматист бәндә.

Плантаторлардан соң яшел тукымага төренгән бер төркем хатыннар узды. Хатыннар имчәк балаларын янбашларына атландырып, чүпрәк белән билләренә бәйләп куйганнар. Баланың урыны уңайлы. Аналарга да җайлы. Аларның куллары буш, теләсә нинди эш башкарып була. Судан хатыннарының үзара көлешеп, эре-эре атлап барулары бала карау аларга бернинди мәшәкать китермәгәнне аңлата шикелле.

Яшелгә төренгән хатыннар юлларын дәвам иттеләр. Без тротуарда басып торган озын торыклы ак дөя янына җитеп туктадык. Дөянең сыртында тау хәтле йөк. Ике сәүдәгәр шул йөкне бушатып азаплана. Картон тартма эчендә Япониядә ясалган транзистор, радиоалгыч, магнитофоннар, электрон хисап приборлары. Нух пәйгамбәр чоры хайванына төяп, егерменче гасыр товарлары алып кайтканнар. Дөя үзе дөнья хәлләренә тулысынча битараф. Ул, күзен йома төшеп, әкрен генә күши. Битендә шундый тирән, шундый җитди уй-исәп. Йөк бушатучылар да ашыкмыйлар. Вакыт аларның артларыннан кумый.

Шәһәр үзәге дә артта калды. Тагын бер катлы тәбәнәк йортлар башланды. Киң бер мәйданга җиткәч, кая барырга белмичә, туктап калдык. Шушы мәйданнан чаткы рәвешендә тугыз урам башланып китә. Мәйдан уртасында ялгыз һәйкәл. Ак мәрмәрдән ясалган озын буйлы чандыр бәдәви ерактагы тауларга карап уйга чумган. Постамент ташына гарәп хәрефләре белән нәрсәдер язганнар. Безнең бабаларыбыз бу язуны шартлатып укырлар иде. Без онытkan гарәп хәрефләре эчендә гасырлар буе туплана килгән ата-баба мирасы калды...

Ерактагы тауларга карап барабыз. Йортлар сирәгәя башлады. Кояшка әлсерәп утырган тәбәнәк, ярлы кыяфәтле йортлар. Ниһаять, ачык саванна күренде.

Мондый үләнне минем Кырымдагы патша резиденциясе Ливадияда күргәнем бар иде. Саваннаның үләне кылганнан эре, камыштан ваграк. Таулар ягыннан искән кайнар җил үләнне кыштырдата. Шундый шомлы, тешкә тия торган тавыш. Киң офык, биек, чиста күк йөзе. Таушалмыйча сакланган яшь дөнья. Адашкан юлчы авазына охшашлы сәер тавыш яңгырап куя — кошмы, җәнлекме кычкыра. Бу җирдә тыныч иркенлектә уяна алмый йоклап яткан яшьлек көче барлыгын тоясың. Ерактагы күксел моңсу тауларда ниләр генә юктыр?

Саваннада югалып калган сирәк авылларда колонизаторларга тез чүгеп яшәүче кабиләләр торып аякларына басачаклар. Богаулар өзеләр. Җирле халыкның канын суыручылар никадәр көчле булмасыннар — хөкем котылгысыз. Аклану юк аларга. Аларны җәзага тартылу көтә. Мин шуңа ышанам.

Басып алучыларны җир һәм байлык кына канәгатьләндерми. Яулап алганда, алар күпләрнең канын койганнар. Буйсындыру дәверендә — тагын кан, тагын аһ-зар, күз яше. Хакыйкать хөкеменнән котылу өчен яулап алучылар җирле халыкны юкка чыгарып, канлы эзләрен яшерергә тырышалар. Шушы ният белән җирле халыктан сатлык җаннар табып, шуларны яллап, көрәшчеләрне юкка чыгаралар. Көрәшчесез калгач, буйсынган халыкның тарихы пычракка таптала, сөрсеп яткан үләнгә әйләнә. Культура, гореф-гадәт, тел бетерелә. Басып алучылар буйсынучыларга үз телләрен, үз гореф-гадәтләрен тагалар. Бу процесс җирле халыкны культурага ирештерү дип атала.

— Нәрсә ул офык читендә, күрәсезме? — диде Барсуков, горизонтка күрсәтеп. Ниндидер озын, гигант еланга охшашлы соргылт җәнлек әкрен генә тауларга таба шуыша иде.

— Кәрван бит бу, — диде Лагуткин, бераз карап торганнан соң.

Офык читендәге кәрванны мин дә аера башладым. Дөяләр, муеннарын алга сузып, салмак кына атлыйлар иде. Алар да юлда. Аларның да язмышлары безнеке шикелле. Алар да туган-үскән илләреннән читтә яшиләр. Кызгану хисе күңелемне ачыттырып узды. Безнең юлда йөргәнне күреп уйланучы, юлчылар язмышын аңлаучылар бармы икән?

Кәрван күздән югалгач, без кайту ягына борылдык. Бераздан кипкән күлгә охшашлы түгәрәк уйсулык төбеннән чыккан чишмә янына килеп туктадык. Гарәп кызлары чишмәдән су алалар. Нәрсә турындадыр мавыгып сөйләшәләр. Тавышлары шундый матур: әниемнең яшьрәк чагын, аның көйләп мөнәҗәт укуы исемә төште. Безне күргәч, кызлар нечкә муенлы чүлмәкләрен җилкәләренә утыртып, кузгалып киттеләр. Бернинди көчәнү күренми. Ниндидер сихерле көч кызларны эләктереп алган да җир өстеннән салмак кына очыртып алып бара.

— Ну-у-у-у, егетләр, — диде Лагуткин кызларның торналарга охшап, тезелеп баруларына сокланып.

Башка сүз таба алмадык. Ташып киткән тойгыларның түгелүеннән куркып, сөйләшүдән туктадык.

***

Кичке җиделәр тирәсендә йөк бушатылып бетәргә тиеш. Алда — Хәбәшстанның Массауа исемле порты. Массауадан без Җиддәгә сарык төяп илтергә тиешбез. Җиддә — Сәгуд Гарәбстаныныкы. Ул Мәккә каласыннан кырык кына чакрымда. Бер атнадан анда хаҗ кылу башлана.

— Сарыкның иңе һәм буе күпме була? — Володя Лагуткин корабның дүрт трюмына күпме сарык сыясын хисаплап йөри иде.

— Йөк төяү турындагы кулланмада юкмыни?

— Юк шул. Төзүчеләр корабка сарык төяп йөрү турында уйламаганнар.

— Сарыкның төрлесе була. Нинди токым, аларга ничә яшь икәнен күрсәтмәгәннәрме Массауа агентыннан килгән радиограммада?

— Юк, бу турыда бер сүз юк. Без килүгә уникe мең сарык әзерләп куябыз диелгән. Бар информация шул. Икенче, иң зур трюмга дүрт мең, беренче һәм өченче трюмнарга мең сыйса, калганнарын дүртенче трюмга һәм палубага урнаштырырга туры киләчәк. Шушы турыда баш ватам.

— Палубада кояшка чыдый алмаслар. Шторм башланса, аларны минут эчендә дулкын юып алып китәчәк, — дидем мин.

***

Иртәгә йөкне бушатып бетерергә тиешләр. Порт эчендә су коена торган бассейн бар иде. Аның тирәсендә җиләс верандалар. Буфетта кока-кола, ананас, апельсин суы саталар. Җимеш суын синең күз алдыңда сыгып, боз салып бирәләр, йоткан саен, тәнгә рәхәтлек агып керә. Без һәр кичне, шул бассейнга барып, су коендык. Ә бүген Суданның башкаласы Хартумнан килгән диңгез флоты министрлыгының вәкиле бассейнны җирле халыкны христиан диненә аударырга килгән миссионерлар төзегәнен әйтте. Чукындыру өчен төзелгән бассейнда су коенудан бердәм баш тарттык. Диңгездә су коенырга рөхсәт юк иде. Бүген капитанның кәефе булдымы — помполит җитәкчелегендә сай җирдә су керергә рөхсәт итте.

Диңгез суы утыз ике градус. Шуңа карамастан, һава белән чагыштырганда, су шактый салкын тоела. Дөрес, суда озаграк йөзсәң, мунча кергәндәге шикелле хәл беткәнен сизәсең.

Көн кичкә авышып килә. «Авышып килә» сүзе тропикта кояш иңүен дөрес сурәтли алмый. Монда кояш күк йөзеннән турыга төшә дә мизгел эчендә офыкка чума. Караңгы төшкәнче туйганчы коенып калырга ниятләп, диңгез ярына килдек тә суга чумдык.

Су асты дөньясы. Тирә-юньдә балыклар көтүе. Бәйрәм көнне тәти күлмәкләрен киеп урамга чыккан көяз кызларны хәтерләтәләр. Балыклар. Каян тапкан табигать мондый буяуларны? Сары, зәңгәр, яшел, кызыл балыклар. Безне күрү аларга сәер тоела. Килеп иснәнәләр. Тәнгә борыннарын төртеп, капшап карыйлар. Бигрәк тә вак балыклар әрсез. Эре балык читтән урап уза. Эре балыкларның хәрәкәтендә кешелек җәмгыятендә була торган тәкәбберлек, сиңа җирәнеп карау сизелә. Һәр балыкның үзенә күрә мөһим эше, башкарасы вазифасы бар шикелле; каядыр ашыга, соңга калудан куркып кабалана.

Сайлык артта калды. Мин тоташ мәрҗән рифын тәшкил иткән упкын буйлап йөзеп барам. Су төбен мәрҗән урманы каплаган. Кайнозой эрасында калып юкка чыккан эре яфраклы абагалар, кәкре ботаклы сәер агачлар. Әкияти җәнлекләргә, җен-пәриләргә, ниндидер куркыныч зур кошларга охшашлы мәрҗәннәр бар. Их, табигать! Күпме гасырлар синең кочагыңда, син биргәнне ашап, матурлыгың белән ләззәтләнеп яшәп тә, без синең сереңне аңлый алмаганбыз. Без бит синең кәррә кисәгең, синең гигант тәнеңдәге бер күзәнәк кенә. Без башка күзәнәкләр исән чагында гына исәнбез. Ә без, адәм балалары, табигатьне җимереп, үзебез теләгән матурлык төземәкче булабыз. Җир йөзендәге һәр тереклек, һәр җан иясе табигатькә ярашырга, яшәвен аның карамагына тапшырырга тырышып яши. Тик адәм баласы гына табигать белән ярыша, аның белән көрәшә. Бәлки, җир йөзендәге иң зур ялгышлык шушыдыр?

Нәрсәдер аягымны эләктереп алды. Акула! Лагуткин икән. Сайлык ягына ымлый. Ияреп киттем. Киң маңгайлы яшел балык ашыкмыйча гына мәрҗән ботакларын кимереп йөри. Әнә, елан балык — мурена су төбеннән шуышып бара. Канәфер чәчәгенә охшашлы чибәр актиния агымда салмак кына селкенә. Үтешли бер ахмак балык чәчәккә борынын тидерде дә кинәт тыпырчына башлады. Мескенкәйне көзән җыера. Ышан матурлыкка! Рухи матурлык та шулай күзгә ташланып торса

иде ул. Янымда попугай балыклар кыбырсынып йөри. Килеп, тәнемә борыннарын төртеп карыйлар. «Китегез, нәрсә кирәк сезгә?» — дип кычкырасым килә. Әллә минем монда йөзеп йөрүем турында акулага барып сөйләргә җыеналар инде? Әләкчедән куркам. Каян килә икән ул әләкчелек?

Әнә, диңгез төбендә өчпочмаклы шәлгә охшашлы скат йөзеп бара. Ләмдә ятканда ул соргылт көрән төстә, комда ятканда — саргылт. Камчыга охшашлы озын, электр тогы җибәрә торган койрык. Кыяларга диңгез керпеләре ябышкан. Иксез-чиксез балыклар көтүе. Бу җан ияләренең күбесен мин беренче тапкыр күрүем. Әнә, каләм бәйләменә охшашлы сәер нәрсә кыяга ябышып тора. Ул да бит җан иясе. Нәрсә ул?

Янымнан диңгез чуртаны — барракуда очып узды. Аның юлына очраган бер кечерәк балык юкка чыкты. Җан ияләренең тормышы нигә шулай икән? Берәү яшәсен өчен кемдер үләргә, юкка чыгарга тиеш. Бездә дә бит актиниягә охшашлы тыштан матур ялган чәчәк куаклары бар. Андый чәчәк безнең үзебезне чакмаса, аның матурлыгына сокланып йөрибез.

Кабыргама төрттеләр. Борылып карадым. Лагуткин ярга чыгарга ишарә ясый. Тирәнлектән соргылт шәүлә калкып чыкты да, тирәбездә әйләнеп йөреп, безгә якынлаша башлады. Икенче мизгелдә без ярда басып тора идек инде.

— Тезең канаган, — диде Лагуткин. — Акула кан исен сизеп өлгергән.

— Кан исе, — дидем мин, эссе һавада шәрә тәннең куырыла башлавын сизеп. — Диңгез астында да кан исеннән котылып булмый икән. Дөнья тарихыннан кан исе аңкый, дөнья сәясәтендә дә шул ук хәл.

***

Башта ерактагы зәңгәрсу таулар, аннан соң аларның ак сыртлары офык артына кереп эреде. Тагын су. Тагын аксыл зәңгәр күк йөзе. Хәрәкәт. Кораб борыны су өсте тигезлеген актара. Як-яктан су сахрасы ага. Трюмнарда сарык. Куркудан, алар үзара беркеп, тоташ соргылт массага әйләнгәннәр. Золым чорында адәм балалары да шулай бит. Корабны абзар исе чорнап алган. Авыл кешесе өчен тансык тәмле ис.

Помполит Чоломбитько безгә лекция укый. Эссе. Һава юк. Лекция Сәгуд Гарәбстанының артта калганлыгы турында. Сәгуд гарәпләре дин кушканча яшәп артта калганнар дип аңлата безнең помполит. Мин бу турыда күптән беләм һәм артта калып, караңгылыкта яшәүче гарәпләрне кызганам.

Аллага ышану каян килеп чыккан? Шушы сорауга мин кат-кат әйләнеп кайтам. Гади халыкны гасырлар буе ханнарга, патшаларга, төрле урындагы түрәләргә ышанырга, аларга баш иярга мәҗбүр иткәннәр. Тәхеттә утыручы никадәр бөек булмасын, бер заман барыбер аның кимчелеге ачыла. Шундый ачы һәм ачулы була инанган кешенең кимчелеген күрү. Бәлки, аллага инануны патшаларга ышанудан гарык булгач, шуннан котылу өчен уйлап тапканнардыр?

Ышанасы, инанасы килү — безнең канда. Ансыз яшәүнең киләчәк белән тоташлыгы калмый. Киләчәксезлек — шулай ук мәгънәсез яшәү.

Без төнге вахтада Лагуткин белән шушы хакта сөйләштек.

***

Хиҗаз ярлары таң атканда ачылды. Карасу-кызыл моңсу кояш ерактагы таулар артыннан сүлпән генә күтәрелеп килә. Җир өстенә

шомлы кызыллык иңгән. Картага күз сирпеп алдым. Шәфәкъ нурына күмелгән таулар артында ярдан кырык чакрым ераклыкта Мәккә шәһәре һәм диннәрнең кыйбласы — Кәгъбә урнашкан иде. Җир шарында яшәүче мөселман өммәтләренең йөзләре тәүлегенә биш тапкыр шушы таулар артындагы калага таба борыла.

Лоцман килгәнен көтеп, тышкы рейдка якорь салдык. Ниһаять, лоцман килде. Баштанаяк актан киенгән инглиз кешесе. Ябык, тәкәббер. Туктаусыз трубка пыскыта. Фарватерны каплап торган кыялар һәм су асты рифлары арасыннан лоцман «Чолман»ны Җиддә портына кертә башлады.

Сарыкларны бушатып бетергәч, тагын кузгалдык. Одессага буш кайтабыз. Буш корабның винты судан чыга. Шуны суга батырыр өчен пароходның танкларына диңгез суы — балласт тутыралар. Диңгезчеләр телендә буш йөрү «балласт йөртү» дип атала.

Сүәеш каналын тагын караңгыда уздык. Төнге күренешләр бу юлы көньяктан төньякка таба шуышып уздылар. «Чолман», Урта диңгезгә чыгу белән, давыл кочагына эләкте. Мачталарга тия язып, соргылт болытлар агыла. Ак яллы яшькелт дулкыннар корабны кыйныйлар. Кораб ыңгыраша, аумаска, юлын дәвам итәргә тырыша. Ярамый аңа аварга. Кораб ауса, «Чолман» эчендәге утыз тугыз диңгезченең җаннары ел саен диңгез ала торган илле мең корбанга кушылачак. Кораб шушы хакыйкатьне аңлаган шикелле, туктаусыз көрәшә. Үлемнән безне шушы көрәш саклый.

Тирә-якта үлем үкереп йөри башлагач, яшәү сере ачыла. Яшәү шундый газиз тоела андый чакларда, яшәү искиткеч кыйммәт. Дулкын шаулавы, корабның шәфкать сорап ыңгырашуы тормыш ваклыкларын юып төшерә. Яшәүнең шушы мизгелләрдә төп максатын аңлый башлыйсың. Вакчыллыкка бирешмәмен, киләчәктә лаеклы яшәрмен дип ант итәсең. Давыл басыла. Кораб тынычлана, һәм — шул ук тормыш, шул ук ыгы-зыгы.

Беренче ерак сәяхәттән кайтып киләм. Алда тагын Босфор. Дрейфка ятып, лоцманны көтәбез. Мәчет манаралары. Кояш чыгып килә. Манара очына утырткан алтын айларда чаткылар уйный. Күкрәк эчендә кайту, күрешү моңы, сагыну, төрле тойгылар. Чыгып килгән кояшка карап, үткән гомеремне исәплим. Каршымда Босфор ярларына җәелеп яткан кала. Сылу манаралар, чәчәк клумбалары, җимеш бакчалары. Шушы калкулыкларны күрү өчен үткән авырлыкларны тагын кабатларга әзер мин.

Лоцман пароходка менә. Төрек кешесе. Лоцман кузгалырга кушты. Ярлар хәрәкәткә килде. Мәчетләр, солтан сарайлар, кунакханәләр, үзара укмашып утырган сәер корылмалар бер-бер артлы яныбыздан йөгереп уза башладылар. Яр буендагы асфальт юлдан машиналар йөгерә. Тан каршылаучы турист халкы, кармакчылар, яр буена килгән ялгызлар, балконга чыгып, җәймә селкүче яшь хатыннар, ашыгып эшкә баручылар — кемнәр генә юк монда. Сугыш ирсез калдырган хатыннар шикелле, калкулык битенә тезелешеп утырган моңсу кипарислар бугаз суына карап уйланалар. Кипарислар артында зират. Әнә, ак мәрмәрдән юнып эшләнгән кабер ташлары. Борынгы заманда безнең якларда да кабер өстенә мәрмәр таш кую гадәте булган. Адәм баласы гомер буе ихтирамга сусап яши. Адәм баласын ихтирам итү гүргә кергәч тә тукталмаска тиеш.

Кинәт кораб машинасын туктаттылар һәм мин сандугач тавышын ишеткәндәй булдым:

Кайда ла сайрый сары сандугач,
Су буйларында ла таң булгач...

Мин сәяхәттән кайтам. Хәзер мин — Истамбул каласын күргән кеше. Аларны беркем тартып ала алмый. Истә калганнарны беркем,

бернichек үзгәртә алмый. Күңелдә ихтирамга охшашлы тойгы уянды. Зират ташлары, моңсу кипарислар, балкон рәшәткәсенә күкрәге белән ятып, сөйгән ярын көтеп торучы төрек кызы — алар хәзер минем байлыгым.

* * *

Томан пәрдәсен җил таратты. Одессаның ярлары ачылды. Туган үскән иленнән аерылмаган кешегә аңлатып булмый бу тойгыны. Туган илеңне яратып, гел ихтирам итеп торыр өчен тормыш агымын үзгәртергә кирәк. Ашханәдә суынган тәмсез аш китерсәләр — хәтерең кала. Туган авылыңа кайтырга канатланып йөрисең — кассада билет юк... Еракка китеп, туган җиреңнән аерылсаң, йөрәктә Туган илнең газизлеге, аңа булган кайнар ихтирам арта.

«Чолман»ны каршыларга килгән хатын-кыз, балалар безне причалда көтеп торалар иде. Причалга терәлү белән, көтеп торучылар корабка менә башларлар дип өметләнеп, мин ялгыштым. Яр белән кораб арасында күзгә күренмичә дәүләт чиге ята иде.

Балалар әтиләренә кул болгыйлар. Бер бала әтисен чакырып, көйсезләнеп елый. Чик саклаучылар килде, таможенниклар пәйда булды.

Чикне ачканда, төш вакыты узган иде инде.

Мине өлкән штурман чакырды.

* * *

— Рахманкулов, кадрлар бүлеге үз инициативасы белән сиңа алмаш җибәргән. Без сорамаган идек, — диде Лохмачев, ишек янагына сөялеп торган җирән чәчле егеткә күрсәтеп.

— Рәхмәт, — дидем мин, — сорарга күптән җыенып йөри идем.

Лохмачевның кашы җимерелде. Шуны яшерер өчен ул йөзенә ясалма елмаю чагарды.

— «Чолман» ошамыймыни сиңа?

— Мин бит штурман. Кесәмдә кораб йөртүче дипломы.

— Әллә нинди кеше син, Рахманкулов. Мин сине корабта калдырыр өчен күпме тырыштым, — Лохмачев миңа алмашка килгән матроска таба борылды. — Юк, безгә матрос кирәкми. Сине кире җибәрәбез.

— Виктор Филимонович, мин барыбер китәм. Калдырыгыз бу егетне, — дидем.

— Капитанның боерыгы — закон, — Лохмачев урыныннан кузгалды. — Минем вакытым юк. Бу турыда демагогия куертып тормыйбыз. Син каласың!

Ул корабтан чыгып киткәч, алмашка килгән матроска ташландым:

— Дус кеше, китмәгез, зинһар өчен. Капитан килү белән мәсьәләне хәл итәчәк. Көтик, яме. Зинһар өчен.

— Нигә ялынырга! Алмауларына мин риза...

Матрос китеп тә барды.

Ике сәгать ярымнан вахта башланачак. Нишләргә? Кадрлар бүлегенә барыргамы? Анда да капитанның сүзе үтәчәк. Экипажны ул җыя. Бер тын үземне нишләтергә белмичә чабаланып йөрдем дә шәһәргә чыгып киттем.

* * *

Бульварда тормыш кайный. Яшәү без сәяхәттә чакта да тукталмаган. Һәр очраган кеше чиксез матур күренә. Нишләп шушы көнгә кадәр мин бу кешеләрне күрми йөргәнмен? Болар бит минем туганнарымнан да якыннар! Ә үзләре янымнан битараф узалар?

Алар минем өзелеп яратканымны белмиләр микәнни? Һәр очраган кешене кочаклап үбәсем килә башлады. Кирәк булса, мин аларга, күкрәгемне ярып, йөрәгемне бирә алыр идем. Бу дөньяда кешеләрне ратудан да куанычлы нәрсә бар?

Минем беренче ерак сәяхәттән кайткан көнем. Өстемдә зәңгәр трикотин күлмәк. Чалбарым, туфлием — бар нәрсәм сәяхәттә сатып алынган. Әллә ышанмыйсызмы? Ышанмыйлар шикелле. Күз сирпеп кенә карыйлар да (әйтерсең, мин аларга йөрәгемне ярып бирергә әзер түгел) янымнан үтеп китәләр. Хәтер калудан йөрәгем әрни.

Әйе, аларның үз мәшәкатьләре күчле. Шунлыктан мине күрми үтәләр. Ал чәчәк төшкән зәңгәр нейлон күлмәк кигән чибәр хатын витринага куелган кәбестәне тикшерә. Әйтерсең, кәбестә миннән кыйммәтрәк. Минем сәяхәттә йөреп кайтуым бу хатынга бер тиен тормый шикелле. Менә ничек бит ул дөнья...

Хәтер калудан симез бер ирга ияреп киттем. Симез кеше, гадәттә, шәфкатьле була. Юк, бу андыйлардан түгел иде. Яныннан узган һәр хатын-кызны күз карашы, теләкләре белән чишендерә дә күзе белән ашый. Син, туган, нигә болай комсыз? Әллә синең хатының юкмы? Әллә, юанлыгыңнан куркып, сиңа кияүгә чыгарга теләмиләрме? Юк, дус кеше, сиңа Босфорда таң атканны сөйләп булмас. Барыбер аңламассың. Сиңа тән кирәк. Хатын-кыз тәне. Тәмле аш, аш янына куелган шешә Босфор буендагы калкулыклар артыннан әкрен генә калкып килгән мәһабәт кояш матурлыгыннан артыграк сиңа!

Ә син, авыр сумка күтәргән ябык апа? Тимсах күлендәге суда кешенең бата алмавы турында сөйлимме сиңа? Гафу ит, вакытың юк икәнлеген беләм. Тәнәфестән файдаланып, син тизрәк азык кибетенә йөгерәсең. Ирең эштән кайтканчы, аш әзерләп өлгерергә тырышасың син. Синең үз мәшәкатең җиткән. Ireңнән алданрак кайтып җитү өчен, беренче автобуска өлгерергә тырышасың син. Автобуста тыгыз, кайтып җиткәнче, кабыргаларың авырта башлый. Синең күңелең шунда...

Соры гофрэ юбка кигән кыз, минем ике айлык сәяхәтем сине дә кызыксындырмыймыни? Юк шул. Синең кемеңдер бар. Син шуны көтәсең. Ярый, көт, мин каршы түгел. Бәхетле булыгыз. Ә мин менә ялгызлыкта бәхетле була алмыйм. Нишләргә?

Юк, миңа һаман акыл керми. Сәяхәттән мине оркестр уйнап каршы алырлар дип, юләрләрчә өметләнгәнмен... Күргәннәремне сөйләсәм, кызыксынып тыңларлар, тагын сөйлә дип, тиңкәмне корытып бетерерләр дип тә өметләнгәнмен. Өмет каршында сак булырга, артыкка кизәнмәскә кирәк икән. Иң әйбәте — корабка кайтырга да, вахтага басар вакыт җиткәнче, бераз ял итеп алырга.

Корабка яңа йөк төйиләр. Иртәгә тагын юлга. Бу юлы Италия портлары: Венеция, Равенна, «О соле миа»... Швартов бауларын тикшереп чыккач, себерке табып, трап тирәсен себереп алдым. Себерү эше белән мавыгып, уяулыкны югалтканмын икән. Әнә, капитан Деркач «Чолман»га якынлашып килә. Өч тапкыр сигнал төймәсенә басып, вахтада торучы штурманга капитан кайтуын белгерттем. Володя Лагуткин йөгереп чыкты, капитанга рапорт бирә башлады:

— Сез югында корабка алты йөз сиксән тонна күмер төяделәр. Йөк күләме бер мең сигез йөз тонна. Кичкә таба пароход төялеп бетәчәк. Сез югында пожарный инспектор килеп, ут сүндерү коралларын тикшереп китте. Помполитны сәгать ундүрткә парткомга чакыралар. Корабта чит кеше юк. Машина бүлегендә вахтада механик Русаков.

Әнә, кран беренче трюмны төяп бетереп, икенчегә күчте. Юлга чыгарга алты сәгать чамасы вакыт калды. Лохмачев минем бу корабтан китәргә теләвемне сизеп алды. Элек алырга теләмичә интектерделәр, хәзер җибәрмиләр. Елар хәлгә җитеп торганда, пароходка якынлашып килүче Курбатовны күреп алдым. Тизрәк вахтадагы штурманны чакырдым. Василий Степанович траптан менә башлаганда, корылма

ишегеннән Деркач үзе килеп чыкты да Курбатовка рапорт бирергә тотынды.

— Мин сезнең эшегезне тикшерергә килдем, Григорий Григорьевич, — диде Курбатов. — Вахта журналын, рейста кулланган карталарны, комсостав утырышының протоколларын җыеп китерегез. — Һәм Василий Степанович мине күреп алды. — Син, лачын, моннан китмәскә уйладыңмыни? Юкка, сиңа бит алмаш җибәргәннәр иде.

— Алмашка килгән матросны кире озаттылар, — дидем мин, тамагыма кайнар төер тыгылганын сизеп.

— Ничек инде озаттылар? — Курбатов капитанга таба борылды.

— Тоткарлык юк, Василий Степанович, — диде Деркач. — Теләсә, бүген үк, хәзер үк җибәрә алабыз. Менә хәзер Италиягә барабыз. Әйбәт рейс бит. Без аны шуңа күрә калдырган идек.

— Ну, эшләр ничек бара, лачын? — диде Курбатов, икенче штурманга. — Деркачка таба борылып, өстәде. — Тырышалармы минем егетләр?

— Тырышалар, Василий Степанович. Берсеннән-берсе әйбәт. Һәркайсы...

— Черногорский да әйбәт эшлиме? — капитан-наставник сәер итеп елмайды.

Деркач, күзләрен челт-мылт йомып, сүзсез калды. Уңайсыз иде аңа. Ул Курбатовның капитан-наставник булырын һәм үзенең аның кул астына эләгерен белми иде.

— Ничек әйтергә инде, Василий Степанович? Начар дисәм, ялганчы булудан куркам. Яхшы дисәм...

— Ярый, Григорий Григорьевич, матрос тыңлап торганда, өлкән командирны чишендермик әле. Мин сезнең эшегезне тикшерергә килдем, күрсәтегез.

Алар өчәүләп — капитан-наставник, Лагуткин һәм Деркач — бакка таба юнәлделәр. Мин чамалап алдым: өлкән механик Черногорский — экипажның партгруппа секретаре чакырган капитан-наставникны. Әнә, капитан Деркач безне ничек мактый. Суданнан чыгуга, ул Лагуткинны корабтан куарга, аның визасын ябарга җыена иде. Мине — кесәсендә штурман дипломы булган кешене — башка корабка җибәрмичә, һаман матрослыкта йөртмәкче иде. Курбатов корабка күтәрелү белән, дөнья үзгәрде. Хакыйкать уянды, башын күтәрде, һәм Деркач безне ярата башлады.

Әнә, корабка таба Лохмачев йөгереп килә. Аның пароходчылыкта дуслары күп. Кемдер пароходка тикшерү килгәнен әйткән, күрәсең. Янымнан узганда, Лохмачев сорарга өлгерде:

— Ничә кеше тикшерә? Кем җитәкчелегендә? Кайда алар?

— Василий Степанович Курбатов җитәкчелегендә, — дидем мин, шатлыгымны яшерә алмыйча. Лохмачевның буыннары йомшарып китте.

Вахтадан алышынуга, миңа расчет әзер иде инде. Корабта беркем юк. Курбатов эшен бетереп, корабтан китеп барган. Экипаж әгъзалары сәяхәт алдыннан — өйдә, хатыннары, балалары янында. Диңгез йоласы — «отходную» оештырырга кирәк иде. Деримедведь белән Белоштан шәһәрдә. Барсуков трап саклый. Лагуткин вахтада.

Причалга төшкәч, бер тын «Чолман»га карап тордым. Ике елдан артык гомерем шушы кораб эчендә калды. Кайда ул гомер хәзер? Нигәдер күзгә күренми. Гомер хәзер нәрсәгә әйләнде? Тырышулар. Түзүләр. Өметләр. Кайгы-шатлыклар. Аларның хәзер берсе дә юк. Гомер, кораб артыннан калган кильватер агымы шикелле, таралды, вакыт агымына кереп эреде.

* * *

Күк йөзе чалт аяз. Галәм кояш нурларына күмелгән. Шунлыктанмы, инспекторның шелтәсе яшәү рәхәтлегенә зыян китерә алмады.

— Син нишләп адашкан сарык шикелле, нишләргә белми өркеп йөрисең? Әгәр паспортыңны бүген тапшырмаган булсаң, яңа кораб — тютю, син аны төшеңдә генә күрә идең.

Инспектор, безнең паспортларны җыеп, Италия консулына илтергә тиеш. Консулның визасыннан тыш безне чик аша үткәрмиләр. Инспекторның фамилиясе Калабушкин. Атныкына охшашлырак озынча яңаклар. Үзе ягымлы, әйбәт кеше. Әйбәтлегеннән оялып, кырыс, хәтта усал күренергә тырышучыларны мин еш очратам. Бу — шундыйлардан.

Яңа корабның исеме — «Джордано Бруно». Хакыйкать өчен учакта янган кеше исеме кушканнар без эшлисе корабка. Джордано Бруноның нинди ачыш ясавын, фән өчен нәрсә эшләвен артык белмим мин, ә аның хакыйкать өчен учакта янып үлүе мәңге онытылмаячак. Әхлак батырлыгы дип атала аның учакта януы.

Безнең корабны Венеция верфенда төзиләр. Банановоз. Тизлеге — егерме ике узел. Зурлыгы — өч «Чолман»ны бергә кушсаң, нәкъ шуның кадәр булыр иде. Трюмнары суыткычлы. Егерменче гасыр уртасының корабы. Без шуны алырга барачакбыз. Одессадан Мәскәүгә — поезд белән. Мәскәүдән Римгә — самолетка утырып, Римнән Венециягә — автобус яисә тагын поезд. Инде экипаж исемлеге расланган. Корабның капитаны Карл Янович Бригас, «Чолман»да өлкән штурман булып эшләгән кеше. «Джордано Бруно»ның өченче штурманы — Габдрахман Бәкерович Рахманкулов — мин.

Инде поезд билетлары да әзер. Мин югында, экипажны кадрлар бүлегенә җыеп, инструктаж уздырганнар. Әллә тәкъдир дигән нәрсә, чыннан да, бармы икән? Миңа иң кирәк чакта «Чолман»га капитан-наставник Курбатовның килүен башкача ничек аңлатырга? Минем яңа корабка эләгүемдә бик зур, бик катлаулы бер тылсым бар. Мин шуңа ышанам.

— Суэеш каналы аша узганда кулланыла торган кагыйдәләр белән таныштыгызмы?

Каршымда — капитан Карл Янович Бригас, Курбатовтан кала минем иң яраткан, ихтирам иткән кешем. Бригасның өстендә актан теккән диңгезче киеме. Ак туфли. Җиңендә ука шевроннар. Башында яңа фуражка. Капитан формасы бу кешегә шулкадәр килешә! Үзе миңа шундый якын, ягымлы. Җир йөзендә якынлыктан да кадерле тойгы бармы икән? Кайвакыт без якынлык кадерен онытабыз, аңа әһәмият бирми башлыйбыз һәм шуның языгын күрәбез.

— Сез соңгы сәяхәттә канал аша узгансыздыр бит? Кагыйдә исегездә калганмы?

— Мин бит, Карл Янович, матрос идем. Матроска кагыйдә кайда да бер: яссы нәрсәне сөйрә, түгәрәк нәрсәне тәгәрәтеп илт. Василий Степанович «Чолман»ны тикшерергә килмәгән булса, штурман вазифасын әле һаман төшемдә генә күрә идем, — дидем мин.

— Ярый, Рахманкулов, киләчәк турында кайгыртыйк. Конфуций: «үзең күрсәткән игелекләрне, кешедән күргән җәберләрне онытмыйча бәхетле була алмыйсың», — дигән. Без эшкә сәләтле, тату, бердәм экипаж тәрбияләргә тиешбез. Алда — чиктән тыш зур, җаваплы эш.

— Помполит итеп кемне билгеләделәр?

— Моңа кадәр комсомол комитеты секретаре булып эшләгән кеше. Үзе югары белемле — мореходка тәмамлаган.

— Әллә Птушкинмы?

— Сез аны беләсезмени?

— «Чолман»га мин аның ярдәмендә урнаша алдым.

— Бик чибәр кеше, акыллыга да охшаган, — диде Бригас.

Без, кадрлар бүлегеннән чыгып, үзәккә таба юнәлдек. Опера театрын уздык. Дерибас урамына борылдык.

— Регина гамбургча канлы бифштекс пешереп көтәрмен дигән иде. Сез бит аның белән таныш, әйеме?

— «Чолман»да таныштырган идегез.

— Василий Степанович та килергә тиеш. Юлга чыгар алдыннан бераз сөйләшеп утырабыз. Курбатовның үгет-нәсихәтләрен ишетербез. Капитаннар мәжлесендә утырырга иртә иде әле миңа.

— Сез, Карл Янович, Конфуцийны искә алдыгыз. Ул: «Һәр кеше үзенең тормыштагы һәм җәмгыятьтәге урынын белергә, шул урынга тугрылыклы булырга тиеш», — дигән. Зурлап чакыруыгыз өчен рәхмәт. Минем бер бик мөһим эшем бар, — дидем мин.

— Без чыгасы юлдан мөһимрәкмени?

— Одессада минем полкташым яши. Шуның хәлен күптән белгәнем юк. Мин Василий Степановичка рәхмәт тә әйтә алмадым, аңа шул рәхмәтләрне тапшырыгыз әле, — дидем саубуллашканда.

Бригас, Садовая урамына таба китеп, күздән югалды. Мин троллейбуска утырдым. Аерылыштык.

Әле Деркач кулы астында эшләгәндә генә капитан вазифасы кырыс, хәтта аяусыз булуны таләп итә торгандыр дип уйлый идем. Шундый ягымлы, культуралы, йомшак күңелле кеше иде Бригас. Аңа буйсынасым, ул кушканны җиренә җиткереп эшлисем килү риясыз иде. Үзең яраткан, сине сокландырган кешеләргә карата гына туа ул мондый теләк.

Адәм баласы машина түгел, аның кәефе гел үзгәреп тора. Кешенең көчле һәм көчсез, акыллы һәм дуамал чаклары була. Кораб шартларында экипаж әгъзаларының үзара мөнәсәбәтләре шундый катлаулы. Җирдән аерылып, диңгезгә чыгып киткәч, кораб тормышында үзеңнең кимчелекләреңне яшерә алмый интегәсең. Йөзү эшенең иң авыр ягы бәлки шулдыр?

Бигрәк тә капитан вазифасы авыр. Соңгы рейста мин Деркачка ничек кыен булуын күзәттем... Бригас исә беркайчан, беркемне үзенә буйсындырырга тырышмый. Уйламый да ул буйсыну һәм буйсындыру турында. Ул эшли, гаделлек белән, тырышып эшли. Аның эш үрнәге сиңа боерыктан да көчле тәэсир ясый.

Колхозда эшләгәндә, армиядә, менә хәзер диңгез флотында мин җитәкче кешеләрнең эш ысулларын күңел салып күзәтеп йөрдем. Җитәкчелек эшендә ике ысул күрдем. Берәүләр куып, куркытып эшләтәләр. Бу ысул колбиләүчелек һәм феодаллык чорыннан калган булса кирәк. Андыйлар, каты тотмасаң, куркытмасаң — буйсынучылар эштән баш тартырлар, баш бирмәсләр дип уйлыйлар. Икенче ысулдагы җитәкче алдан үрнәк күрсәтеп, әйдәп алып бара. Буйсыну кирәкми андый җитәкчегә. Аңа эш нәтиҗәсе, сыйфат, вазифа ихтирамы кирәк. Ул сиңа ышана, ә син аның ышанычын аклау өчен егылып үләргә әзер торасың. Мондый җитәкчене безнең социалистик чынбарлык тудырды. Курбатов белән Бригас нәкъ шундыйлардан иде.

# ХӘТЕР

Шагыйрьнең соңгы шигырьләрен укыйм. Соңгы шигырьләр... Шәрә калган агачның актыккы яфраклары өзелгәнен күзәткәндә була торган халәт күңелдә. Бер-ике юл шигырь укыйсың да тукталып каласың, җанны сагыш кыса, хатирәләр яңара, ул үзе дә җанланып әйтеп тора сыман: «Әйе, шулай, ашыкма, әкрен генә укы, шигырьләрем, гомерем еллары кебек, ул хәтле күп түгел...»

Бу шигырьләр бәйләме шагыйрьнең 50 еллыгы уңае белән чыгасы китабына кереп, авторның үзен, дусларын, меңләгән поэзия сөючеләрне куандырырга тиеш иде. Әмма аңа, кульъязманы үзе теләгәнчә эшләп бетереп, китап чыгу шатлыгын тоярга насыйп булмады. Ул, шигъри тәлгәшләрен безнең хөкемгә — халык хөкеменә калдырып, вакытсыз арабыздан китеп барды...

Зиннур Насыйбуллин — ашыкмыйча, салмак кына иҗат итүче шагыйрьләрнең берсе иде. Үзе исән чакта нибары бер генә китабы чыгып калды. Бөтенесен исәпләсәң, 6—7 табак шигырь. Әлбәттә, күп түгел, шагыйрьнең мирасы булса, тагын да күңеллерәк булыр иде. Әмма иҗат — хуҗалык өлкәсендәге шикелле, йөкләмәләр алып, планнар арттырып эшли торган эш түгел. Күңелгә әмер биреп булмый. Тумый икән — кирәкми, начарның булмавы яхшы. Зиннур Насыйбуллин бу хакыйкатьне яхшы аңлап яшәде һәм иҗат итте. Чагыштырмача аз язса да, бар булган иҗаты белән каләмдәшләре һәм әдәби җәмәгатьчелек аны талантлы шагыйрь итеп таныды, ихтирам итте.

Татар поэзиясенең ватаны булган Казанга ул моннан егерме еллар элек килгән иде. Сибелми-чәчелмичә генә ике дистә елга якын Татарстан радиосында хезмәт итте. Шунда эшләгән дәвердә СССР Язучылар союзы әгъзасы булды. Эфирда яңгыраган бик күп әдәби һәм музыкаль тапшырулар аның ярдәме белән тыңлаучылар күңеленә барып иреште. Көн саен язучылар, композиторлар, галимнәр, журналистлар белән аралашып яшәү аның үз иҗатына да шифалы йогынты ясады. Ул композиторлар белән берлектә матур-матур җырлар иҗат итте. «Кара шәле килә сөйрәлеп», «Көтә күңел» — әнә шундыйлардан.

Чиктән чиккә ташлана, күтәрелеп бәрелә, чәбәләнә, кеше күзенә керә торган зат түгел иде Зиннур. Сабырлык, үзенә генә хас олпатлык, күзгә бәрелеп тормаган әчке бер горурлык хас иде аңа. Йөрәр җиренне җегәр чигеңне белеп яшәү, очар биеклекләреңне бутамау — аз нәрсә түгел дөньяда! Ерак экзотик илләр турында хыялланмыйча, елга бер тапкыр, ял вакытында, Башкортстанга олы яшьтәге әти-әнисе янына утын-печән әзерләргә кайтыр иде, ә радио эшендә исә, булмастай дан артыннан кумыйча гына, үзенең гадәти, әмма бүтәннәр өчен бик тә кирәк эшен башкарып утырыр иде... Әйе, болары шулай. Ә шагыйрь? Сабырлык, басынкылык, тыйнаклык белән генә шигырь туамы соң? Күрәсең, тыштан шулай тыныч күренгән кешенең күңелендә әллә нинди шашкын хисләр, яшенле уйлар уйнаган.

> Шундый чаклар була: дөнья — кайгы,
> Күз яшьләрең кайный, син — утта...
>
> Дөньяга без, ялкын ярып,
> Мең үлемгә тудык үч белән!
>
> Шуңа безнең нерв җепләренә
> Тоташтырган Заман Җир шарын...

Йомыкый күңелдә мондый гамьле һәм ярсулы юллар туа алмастыр. Хәер, сабыйлык һәм яшьлек чакларын сугыш уты өтеп тә, югалып калмыйча, тормышның олы мәйданына юл ярган, ил чикләрендә солдат хезмәтләре үткән ир-егетнең күңеле ничек йомыкый булсын икән! Дөрес:

> Күкрәк киереп, сынны туры тоту
> туры килә кайчак авырга...

Шагыйрьнең соңгы язганнарында гражданлык рухы белән сугарылган шигырьләр дә, лирик шигырьләр дә, робагыйларны хәтерләткән ике яки дүртьюллыклар да, сурәтле-картиналы

парчалар да бар. Алар традицион алымда ныклы профессиональ кул белән язылган. Сөю-мәхәббәт, кавышу-аерылышу шигырьләрен, кыска фәлсәфи шигырьләрен тәкъдир иткән һәм хуплаган халдә, миңа аның Туган ил һәм халык тарихы, туган тел турындагылары күбрәк ошый төшә. Аларда ныклы иманны, җитлеккән ир сүзен күбрәк сизеп була. «Хәрабаләр арасында», «Тарих — чорлар чылбыры», «Туган тел», «Хаттатлар», «Киселгән карама», «Без җаваплы» кебек шигырьләр әнә шул әйтелгән фикерне раслыйлар.

...Шәһәр читендә кышкы эңгер үзенә бер төрле. Күзгә күренеп ак кар зәңгәрләнә, күк белән офык тоташа, бөтен дөнья бер серле тоскэ керә, ул төс — але шәмәхәләнеп, але күкселләнеп әкертен генә караңгылыкта эри. Шагыйрьнең күзләре Такташныкы кебек зәп-зәңгәр иде. Соңгы көннәрендә аның күзе офыклар күренеп торган балкон ягы тәрәзәсендә булды. Кичке зәңгәр эңгергә аның күзләре төсе дә кушылгандыр.

Ана күңеле дә ирешмәслек
еракларга китеп барышым...

...Кеше китә — җыры кала. Ә җыр инде ул — яхшы хәтер. Гамьле шагыйрьнең хәтер дәфтәренең бер сәхифәсе бу шигырьләр.

**Равил ФӘЙЗУЛЛИН**

# Зиннур Насыйбуллин

## Без җаваплы

Үткән чорлар...
Сугыш. Вәхшәт. Кан-яшь...
Авыр, хәтәр чоры замананың...
(Үткәннәргә богауланып куйган
Прометей күк кайчак минем җаным).

Мин гаепле түгел моның өчен,
Юк үткәнне үзгәртерлек көчем.

Уйга чумып,
Еллар гәрәбәсен
Берәм-берәм сүтеп барган чакта,
Уем уза чорлар хәрабәсен —
Өнсез ташлар ялварышып ята.

Мин гаепле түгел моның өчен,
Юк үткәнне үзгәртерлек көчем.

Бүгенгегә карыйм.
Җир хәвефле.
Кешелеккә һаман сугыш — юлдаш.
«Берәү үлми — берәү көн күрми»,— дип,
Кемдер тукый һаман фикри мираж.

Без җаваплы бүген моның өчен,
Бардыр, Кешем, каршы торыр көчең.

Киләчәкне уйлыйм:
Ракеталар калса мирас булып
Синең улың, минем улым өчен,
Без җаваплы фәкать моның өчен,
Без гаепле фәкать моның өчен!

## Хатирәләр йөри

Борынгы Ай, моңсу нурдан тукып,
Чирәмнәргә серле челтәр япкан.
Тупылларның сыек күләгәсе
Чирәмнәргә чалкан төшеп яткан.

Яфракларга кунып чыклар йоклый,
Тажга йомылып, гөлнең төсе йоклый.
Кемнәрнеңдер хәтере-хисе йоклый.
(Ваемсызга заман гаме йокмый).

Тәрәзәләр кара күзлек кигән...
Алжыган жир сабыр оеп ята,
Ләкин катламнарда тамырларның
Жыбырдавын хәтта тоеп ята.

Катламнарда еллар, чорлар йоклый,
Көпә-көндез килгән төннәр йоклый,
Йорт-курадан калган көлләр йоклый,
Меңнәр йоклый.

Күпне күргән акыл ясседәй,
Иягенә таянып, төн уйлана.
Борчуларын төнгә сөйләр өчен,
Йокылары качып, кем уяна?

Учакларда эссе көл астында,
Сүнмәс хәтер кебек, күмер көйри.
Өй тирәли жилләр белән бергә,
Кыштыр-кыштыр хатирәләр йөри.
Хатирәләр йөри...

## Араларны якынайту өчен

Ниләр генә эшләмәгән кеше
Араларны якынайту өчен!
Сарыф иткән моңа беләк көчен,
Сарыф иткән моңа акыл көчен,
Араларны якынайту өчен.

Кыргый атны иярләгән кеше
Араларны якынайту өчен,
Жилкән ясап жилне эшкә жиккән,
Күгәрченне хат ташучы иткән
Араларны якынайту өчен.

Табигатьнең күпме серен ачкан
Араларны якынайту өчен,
Бөекләргә сын-һәйкәлләр куйган,
Гади таштан гөлчәчәкләр уйган
Араларны якынайту өчен.

Тик аралар һаман ерак әле,
Йолдызларга үрелсәң дә, Кешем.
Илләрара, континентларара
Дипломатик сөйләшүләр бара
Араларны якынайту өчен.

Араларны якынайту авыр,
Таркатуы жиңел атом төшен.
Сугыш сүзен таркатырга кирәк
Араларны якынайту өчен!
Араларны якынайту өчен...

*

Сугыш кыры.
Ялкын, вәхшәт монда.
Бар тирә-як үлем бөркә.
Көчле магнит тарткан тимер кебек,
Солдат туган жиргә беркә.

Һәр ярчыкта үлем, һәр карышта.
Канлы туфрак кызгылт төстә.
Тик барыбер хаклык, яшәү өстә.
Үлем аста, яшәү өстә!

Солдат түгел, ә жир ыңгыраша.
Дәһшәт һаман арта, арта.
Калкынырга гаять зур көч кирәк,
Жир үзенә тарта, тарта.

Тик калкына солдат атакага,
Селкеп ташлап курку йөген.
...Югыйсә без Жирнең тарту көчен
Жиңә алмас идек бүген!

## Солдат үлеме

Кемнәр генә белгән ул чакта
Каберенең кайда буласын:
Атакага барган җиреннән
Ауды солдат, җәеп колачын.

Хәлсезләнеп, соңгы тибүдән
Туктамастан элек йөрәге,
Тик бер колач җирен булса да
Капларга ул гүя теләде.

## Ветераннар

...Хәл-әхвәлме? Шөкер әле, энем,
Бирешми ул Салих бабагыз.
Әйтер сүзне ярып салабыз без,
Титаклап та туры барабыз.

Тирәкледән кайтып килеш әле,
Ибрай дусның хәлен белешеп:
Бер сөйләштек,
Нәфрәтләнер җирдә нәфрәтләнеп,
Ә көлешер җирдә көлешеп.

Хәтерләрдә чордашларны барлап,
Урап чыктык тагын зиратны.
Кайткан чакта шартын китереп кенә,
Яңгыр явып үтте, чылатты.

Көлә Ибрай: «Бер аякка үтте,
Икенчесе әле коп-коры».
(Шушында да Ибрайлыгын итә,
Үз кортлары үзен чаккыры!)

Асфальт сыек. Туфли әрәм була,
Туфлиләрнең шәбе, яңасы.
Җебеми дә, өшеми дә менә
Үзебезнең урман агачы.

Кырык биштән бирле икебезгә
Бер пар итек алдык, булганда.
Сыңар аяк ярты хакка төшә,
Икенчесе үсә урманда.

«Бер аягың — җирдә, берсе — гүрдә»...
Сүзләре бит нинди, сүзләре!..
Әй, моңаймыйк, бәлки әле Әҗәл
Ялгышадыр: ята, диеп, гүрдә
Салих белән Ибрай үзләре.

Тик ялгышсын гына, ә без монда
Рәхәтләнеп яши бирербез.
Тагын күпме кирәк дөпелдәтеп
Агач аяк белән йөрербез.

*

Нинди ел бу, нинди хәтәр ел бу?
Шомлы хәбәр артлы шомлы хәбәр.
Вулканнарның ярсый бишәр йөз ел
Җан борчымый ятканына кадәр.

Мәрхәмәтсез кыргый куәт белән
Ябырыла гарасатлар килеп,
Гамь-шатлыклы изге нигезләрне
Мәңгелеккә туфан каплар кебек.

Бер төшендә җирнең су-һәлакәт,
Суга — нәфрәт, кеше суга гарык;
Бер төшендә су — әҗәлгә дару,
Йотым суга тилмерешә халык.

Җирне генә түгел, илләр җанын
Дер селкетә быел җир тетрәве.
Нинди хәвефләргә ишарәләп,
Тетрәнә соң шулай Җир күкрәге?

Җир-анабыз ачулыдыр, бәлки,
Уларының кылган гамәленә,
Арсенал дип караучылар бар бит,
Җиргә генә түгел, Галәменә...

Табигатьнең ярсуларын бу Җир
Гыйбрәт өчен, бәлки, күрсәтәдер?
«Узынмагыз!» — диеп, үз уларын
Зур афәттән, бәлки, кисәтәдер?!

## Күз күреме

Синең янда узган бу көннәрем
Булды, әни, гүя төш кенә.
Менә тагын озатып калдың мине,
Кулың куеп кашың өстенә.

Күз күреме җир узганчы, йөзең
Бер чыланыр инде, бер кибәр...
Синең йөрәк сулык-сулык итеп,
Кит-те, кит-те, диеп, гел тибәр.

Юллар, еллар кай тарафта гына
Йөретсә дә, әни, улыңны —
Күз алдымда басып торасың син,
Каш өстенә куеп кулыңны.

Әнкәй, моның серле мәгънәсенә
Җаным инде күптән төшенде:
Берөзлексез күзәтәсең икән
Узган юлым, кылган эшемне.

Синең йөздә, синең карашыңда
Хуплау яки шелтә чагыла.
Намусыма тап төшмәсен диеп
Торасың син гүя сагында.

Сау бул, әнкәй, җаның рәнҗемәсен,
Тагын китәм. Китми чара юк...
Ерак китәм, ләкин аналарның
Күз күреме җитмәс ара юк.

## Бер аңларбыз кебек

Язын кайтып күлен табалмаган
Киек казлар, ничек хәлегез?
Көне килер, сезне торып-торып
Бер аңларбыз кебек әле без.

Сазлыкларны үзебез киптерәбез,
Корый бара күлләр үзләре.
Суы беткән икән — кадере киткән,
Тиз җуела чишмә эзләре.

«Культурасыз» болыннарың кая,
Туган төбәк, кая тугаең?
Бу кырларга нидер җитми, дисәм —
Эзлим икән сабан тургаен.

Еллар авыр чакта, сез тартайлар:
«Тарт! Тарт!» — диеп киңәш иттегез.
Төнге басу яме — тартай кайда?
Бытбылдыклар, кая киттегез?

Югалтулар исәбенә була —
Еш түгелме? — безнең табышлар.
Чү! Ялгышмы, чынмы — ишетелә
«Кыйгак! Кыйгак!» — дигән тавышлар!

...........

# Роберт Рәкыйпов

## Сакта

Йолдызлар да, ай да кечкенә бер
Тау артына төшеп сыйдылар.
Вика иңнәренә борын төртеп,
Тыныч кына йоклый солылар.

Күл буенда борчылусыз гына
Утлап йөри пошый ялгызы.
Бер хәвефсез, тыныч-имин генә
Бүген дә бер җәйге төн узды.

Коңгырт ефәк себеркәчен җәеп,
Фикерләрен җуйган тарылар.
Юл янында баскан ак каеннар,
Бөдрәләре яшькелт-сарылар.

Бишек янындагы ана кебек,
Тургай оясына иелгән...
Шушы матурлыкка хуҗа булып,
Басып торам соры шинельдән...

●

Концерт бара.
Татар кызы бии —
Июнь төнендәге серле ялкын:
Дүрт төс булып балкый ак калфагы,
Өч төс көмеш, дүртенчесе алтын.

Концерт бара.
Тальян гармун чыңлый.
Авыл көе йөрәкләргә якын:
Бу гармунны көмеш телле диләр —
Өч тел көмеш, дүртенчесе алтын.

Концерт бара.
Шигырь укый бала.
Кызыктыра шигырь яшен-картын:
Тукай шигырьләрен тыңлый халык —
Өч юл көмеш... юк, һәммәсе алтын!

---

РОБЕРТ РӘКЫЙПОВ *(1936)— шагыйрь, «Яшьлегем башкаласы», «Җилкәннәрдә зәңгәр җилләр» һ.б. шигырь китаплары авторы. Әлмәттә яши.*

## Диңгездә

Кар түбәле салкын кыялардан,
Саубуллашып утлар күз кыса.
Күңелләргә никтер җылы кебек
Шул кыядан утлар балкыса...

Юлларыбыз кара-яшел дулкын,
Өстә инде тоташ күк пәрдә.
Яр утлары булып күренмәкче
Шук йолдызлар гына күкләрдә.

Әллә кайчан санын югалттык без
Янybыздан чапкан төн-көннең.
Зәңгәр төсен күреп җылындык без
Офыктагы ялгыз төтеннең.

Яшермимен, очрашулар көтү
Һәммәбезне бераз арытты.
Юк, сүнмәгән әле, сүнмәгән тик
Безне озатучы яр уты...

*

Баскан җирем, туган җирем — сагышларсыз,
Баш өстемдә йолдызларның шат яктысы.
Мин тоямын бәхетемне хезмәтемдә
Йөрәгемдә мәхәббәтнең саф чаткысы.

Карда, чүлдә, җирдә калсын минем эзем,
Йөзләремә каршы иссен яшен җиле:
Мин Җир улы, Җиргә читен миннән башка,
Белеп яшим... димәк, юкка яшиммени?

## Әлмәттә көз

...Зәңгәр күктә эри аккошларның
Ерагаеп барган чылбыры...
«Мин дә сезнең белән»— дигән кебек
Канат җилпи нефть чыгыры.

## Чыпчык

Болытлардан төньяк исе килә,
Тиздән ахры, тиздән кар явар.
Сыерчыклар инде күптән китте,
Саубуллаша кара каргалар...

Чыпчык китми... Салкын, эссесе дә
Рәхәт аңа, кары-ләйсәне...
Туган җире өчен җаны фида —
Чын рәсәйле чыпчык, рәсәйле...

## Самат Шакир

# УТЛЫ ЕЛЛАР ЭЗЕННӘН

### 1. Мөҗәй сугышкан якларда

Күптән түгел миңа Украинаның Сумы шәһәрендә булырга туры килде. Зур һәм бик матур бу кала өчен 1941 елның октябрендә каты сугышлар барган. Сугыш дәһшәтен күргән кешеләр әле дә шәһәрнең җимерелеп бетүе, фашистларның ерткычлыклары турында ачынып сөйлиләр. 227 нче укчы дивизиянең 789 нчы полкы дошманга каршы батырларча сугышкан. Шәһәрнең олы яшьтәге кешеләре бу полкның командиры Мөҗәһит Хәйретдинов булуын да яхшы беләләр. Сөйләшеп утырганда, мин батыр командир М. Хәйретдиновның шагыйрь һәм язучы булуын әйттем. Украин кардәшләр аның рус телендә басылып чыккан «Сугыш язмалары» дигән китабын кулдан-кулга йөртеп карадылар, кайбер бүлекләрен укып та чыктылар. Кайбер агайлар:

— Без ул командирны Хәйретдинов дип кенә белә идек. Ул «Х. Мөҗәй» дигән шагыйрь һәм язучы да булган икән! — дип, хәйран калып тордылар.

Х. Мөҗәйнең «Сугыш язмалары»нда 1941 елның 9 нчы октябре турында болай язылган:

«Таң атуга, Сумы шәһәренә килеп туктадык та, кояш чыкканчы, оборонага урнаштык. Сумы сугышка чаклы җыйнак кына, шул ук вакытта бай гына шәһәр булса кирәк. Хәзер аның урамнарында ком тутырылган капчыклардан баррикадалар корылган. Берничә көн элек зур гына бомбардировка булган. Урамның ике ягында да җимерек йортлар, чыбыклары өзелгән баганалар.

Баррикадалар булган урамнарда шәһәрнең сугышчан дружиналары сакта торалар. Дошманга каршы бик каты бәрелешләр булды. Без вакытлыча чигендек. Дошманның беренче сафлары кичке сәгать алтыда шәһәргә керде. Күпер төбендә (Харьков күпере) немецлар белән бәргәләшү булды. Артиллерия атулары башланды, йортлар яна башлады, күпер төбендәге безнең орудие берничә дошман машинасын җимерде. Байтак немец солдатлары һәм офицерлары үтерелде. Безнең снайперлар чиркәү башындагы дошман күзәтүчеләрен дөмектерделәр».

Сумы өчен булган канлы сугышлар турында Х. Мөҗәй шактый яза. Ул язмаларда без кызылармеецларның һәм командирларның үз-үзләрен аямыйча сугышулары, тиңсез батырлык күрсәтүләре турында беләбез. «Кичке сәгать бишкә хәтле сузылган сугыш нәтиҗәсендә дошман ярты меңгә якын кешесен югалтты»,— ди полк командиры Х. Мөҗәй ул көнге сугыш турында.

Бу зур операциядә Мөҗәй полкы сугышчысы Поляков Леонид Евдокимович та катнаша. Ул хәзер дә исән-сау. Сумы шәһәрендә яши. Батыр командиры Мөҗәһит Хәйретдинов турында ул:

— Атакалар вакытында үзе иң алдан күтәрелә иде,— дип сөйләде.— Шәхси батырлыклар күрсәтә, үзе артыннан сугышчыларны да дошманга каршы күтәрә һәм фашистларны тар-мар итә иде. Ул бервакытта да каушау, куркуны белмәде!

1942 елның җәендә Харьков юнәлешендә зур сугышлар башланып китә. Немецлар, өстәмә көчләр алып, һөҗүмне яңарталар. Ике айга якын кан коюлы бәрелеш

---

САМАТ ШАКИР *(1924) — шагыйрь һәм прозаик. Татарстанның атказанган культура гезмәткәре. «Легенда егетләре», «Яраннар чәчәк аткан» һ. б. китаплар авторы. Кайбер китаплары рус һ. б. телләрдә дә чыкты. Казанда яши.*

бара. Немец генералы Клейстның танклар армадасы, зур югалтуларга карамастан, алгы сызыктагы күп кенә авылларны ала. Безнең гаскәрләр вакытлыча чигенергә мәҗбүр булалар. Азык-төлек, сугыш кирәк-яраклары бик аз кала. Хәтта штык һәм кул сугышларына кадәр барып җитәләр. Шул бәрелешләрдә полк командиры Хәйретдинов, яраланып, дошман кулына эләгә. Аннан соң ул фашистларга каршы көрәшне тоткынлыкта — концлагерьларда дәвам итә. Бу турыда Сумыдагы Бөек Ватан сугышы ветераннары ишетмәгән икән. Мин аларга М. Хәйретдиновның андагы батырлыгын да сөйләдем. Полк командирына Сумы шәһәрендә мемориаль такта куярга кирәклеген әйттеләр. М. Хәйретдинов полкы сугышчысы Поляков Леонид Евдокимович Харьков янындагы чолганыштан котылып чыгу бәхетенә ирешкән. Аннан соң ул икенче дивизиягә, икенче полкка кереп, фашистларга каршы зур батырлык күрсәтеп сугыша һәм 1944 елны Советлар Союзы Герое дигән мактаулы исемгә лаек була. Мин Леонид Евдокимович белән озак кына сөйләшеп, узган сугыш гарасатларын искә алдык. Поляков үзенең полк командиры Мөҗәһит Хәйретдиновның батырлыгын югары бәяли. Сорагач, М. Хәйретдинов турындагы характеристикасын язып та бирде ул. Бу документка:

«Полк командиры Мөҗәһит Хәйретдинов сугыш кырында үзенең кыюлыгы, ныклыгы һәм батырлыгы белән танылды,— дип язылган.— Аны сугышчылар һәм командирлар шул батырлыклары өчен якын күрәләр, хөрмәт итәләр иде. Ул үзе дә сугышчыларны якын күрә, алар янында окопларда һәм блиндажларда була, атакаларга һәрвакыт үзе алгы сафта күтәрелә һәм җиңүне тәэмин итә иде.

Иптәш Хәйретдиновтан үрнәк алып, солдатлар һәм командирлар да батырларча сугыштылар. Мин үземнең Советлар Союзы Герое булуымны аннан үрнәк алу нәтиҗәсе дип саныйм. Иптәш Хәйретдинов куркуны белми торган баһадир, кыю командир иде. Аның батырлыгына мин югары бәя бирәм».

М. Хәйретдинов полкы 1941 елда Лепляво авылында торган. Авыл халкының сөйләвенә караганда, монда бик каты сугышлар булган. Авылдагы партизаннар Кызыл Армия сугышчыларына ярдәм итеп, фашистларның тылыннан да һөҗүм иткәннәр. Немецлар өстәмә көчләр кертергә мәҗбүр булган. М. Хәйретдинов Лепляво авылы өчен сугышларда берничә атака вакытында үзе алгы сафта барган. Ләкин көчләр тигез булмый, фашистларның танклары авылга бәреп керә. Хәйретдинов полкы сугышчылары вакытлыча чигенергә мәҗбүр була.

Лепляво янындагы урман аланында күренекле язучы Аркадий Гайдар дошманның пулемет утына эләгеп һәлак була. Лепляво авылында аңа мемориаль такта куелган.

Х. Мөҗәй Лепляво авылы турында болай дип яза: «Без Лепляво янында, землянкада. Оборонаның алгы буе Днепр ярында. Дошман миналар төшереп тора.

Леплявода Мөҗәй Аркадий Гайдар белән очрашканмы-юкмы, бу турыда берниндн мәгълүмат та табылмады. СССР Оборона Министрлыгы Үзәк архивында саклаган документларга караганда, 789 нчы полк (командиры М. Хәйретдинов) Лепляво янында ике көнгә якын каты сугышлар алып барган. Көньяк-көнбатыш фронтның бу участогында «Красный боец» дигән фронт газетасы чыккан. Газетада 1942 елның 16 маенда: «М. Хәйретдинов полкы сугышчылары үзләренә йөкләнгән бурычларны уңышлы үтиләр,— дип хәбәр итә.— Кискен һөҗүм белән сугышчылар дошманны М. пунктыннан бәреп чыгардылар. Фашистлар зур югалтуларга дучар булдылар: дошманның 200 дән артык солдаты һәм офицеры үтерелде һәм яраланды. Күп санлы трофейлар: тулы булмаган мәгълүматларга караганда, 5 автомашина, 6 туп, 11 пулемет, 60 мең патрон, сугыш кирәк-яраклары төялгән берничә склад һәм азык-төлек складлары кулга төшерелде...»

1942 елның 23 февралендә Кызыл Армия көненә багышланган санында газета менәниләр бастыра.

«Белдерүләр тактасы.

Иптәш Хәйретдинов командалыгындагы сугышчылар немецларга түләүсез өчәр аршин җир бирде. Фрицлар һәм гансла! Өч аршин җир алып калырга ашыгыгыз!»

Газетаның яңа ел санындагы сатира почмагында:

«Данлыклы генералларым фон-Шмидт һәм фон-Бокк! Приказларымны тулысынча үтәвегез — рус гаскәрләренең басымы астында чигенүегез һәм Калинин, Тихвин, Клин, Волоколамск һәм башка шәһәрләрне калдырып китүегез белән тәбриклим. Адольф Гитлер»,— дигән «телеграмма» чыга.

Мондый сатирик белдерүләр газетада шактый. Комиссар Почагин Фрол Андриянович әйтүенә караганда, аларны язуда Х. Мөҗәй дә катнашкан. Газетада аның очерклары да басылган.

Фронт газетасында М. Хәйретдиновның үзе турында да күләмле мәкалә бар. Анда: «Подполковник М. Хәйретдинов үзенең сугышчыларының йөрәгенә кереп ур-

нашырлык ялкынлы сүзләр таба белә,— дип язылган.— Ул полкны берничә мәртәбә чолганыштан алып чыкты һәм, дошманның өстен көчләрен тар-мар итеп, алга юл ярды. Сугышчылар үзләренең командирлары белән горурланалар һәм аңа охшарга тырышалар».

Украинаның күп кенә авылларында һәм шәһәрләрендә М. Хәйретдинов полкы сугышчылары зур батырлыклар күрсәтеп сугышкан. Исән калган полкташлары командирның кыюлыгы, ныклыгы һәм куркусызлыгы турында горурланып сөйлиләр. М. Хәйретдинов полкында хезмәт иткән сугышчы Данило Бакуменко — хәзер Украинаның күренекле язучысы. Ул Х. Мөҗәйне күреп белә, сугыш кырында очрашуларын бик тәфсилләп сөйли. Д. Бакуменко подполковник М. Хәйретдинов һәм аның сугышчылары турында «Исәннәр онытмаска өнди» дигән китап та чыгарган. Шулай ук Украинаның атаклы язучысы, Ленин премиясе лауреаты, Социалистик Хезмәт Герое О. Гончар да «Кеше һәм корал» дигән китабында Хәйретдиновчылар батырлыгына аерым туктала.

Бөек Җиңүнең 40 еллыгы уңае белән Киевта «Утлы юллар» дигән китап чыкты. Китапка Мөҗәһит Хәйретдинов батырлыгы турындагы очерк та кертелгән. Украина Совет Язучылары союзы органы булган «Литературная Украина» газетасында легендар батыр Х. Мөҗәй турында «Муса Җәлил токымы» исемле зур материал басылган.

М. Хәйретдинов полкы Корсунь-Шевченковский районындагы авылларда да дошманга каршы искиткеч ныклык, кыюлык күрсәтеп көрәшкән. Районда чыга торган «Ленинським шляхом» («Ленин юлыннан») газетасында да «Үлемсез сугышчы һәм шагыйрь» дигән мәкаләдә М. Хәйретдиновның немец-фашист илбасарларына каршы батырларча көрәшүе дәлилләр белән тасвирлап бирелә.

Украин дуслар Х. Мөҗәйне онытмыйлар, һаман хөрмәтлиләр, аның турында шигырьләр, җырлар иҗат итәләр.

## 2. Лачыннарны әйдәп очучы

Львов шәһәренә Бөек Ватан сугышы ветераннары җыелген иде. Алар «Дан монументы»на чәчәкләр куйдылар, соңыннан, баш киемнәрен салып, бер минутка тын калдылар. Аннары мин алар белән якыннанрак таныша башладым. Араларында элекке очучылар да бар иде. Бер ветеран көр тавыш белән сөйләп китте:

— Бу шәһәр тирәсендә фашистларның бик көчле ныгытмалары тупланды. Гитлерчылар Совет Армиясе гаскәрләрен Львов юнәлешендә туктатырга һәм контрһөҗүмгә күчәргә исәп тоттылар. Әмма авиация полковнигы, һава армиясенең баш штурманы Мөхәррәм Галимов очучылары фашист ныгытмаларының астын-өскә китерделәр.

Кызыксынып сорау бирдем:

— Мөхәррәм Галимовның үз язмышы ничегрәк булды?

— Батырлардан үлем курка! Ул сугыштан соң генерал дәрәҗәсенә күтәрелде.

Очучылар аны яхшы беләләр иде. Галимов турында бик җылы итеп сөйләделәр:

— 1938 елда Испаниядә фашистларга каршы сугышкан бит ул.

— 1939—1940 елларда ак финнарның котын алган. Маннергейм линиясен бомбага тоткан кеше ул Мөхәррәм!

Бу легендар генерал турында Казанда вакытта да ишеткәләгәнем бар иде. Инде бу мәгълүматларны да алгач, аның үзен күреп сөйләшү теләгәм тагын да көчәйде. Адресын белдем дә квартирасына юнәлдем.

Отставкадагы генерал-майор Мөхәррәм Галимов белән озак кына сөйләшеп утырдык. Ул үзе безнең якташыбыз икән. Әнисе Хатирә апа Мамадыш районыннан. Мөхәррәм үзе 1907 елда Копейск шәһәрендә шахтер Нигъмәтҗан гаиләсендә туган. Гаиләләре ишле булганлыктан, Мөхәррәмгә бик кечкенәдән эшкә тотынырга туры килгән.

Ул башта мәдрәсәдә укый, соңыннан Чиләбедәге урта мәктәпкә керә, алдынгы укучылардан санала. 1926 елга кадәр шахтада эшли, актив комсомол буларак, яшьләр арасында аң-белем таратуда да булыша. Шуннан соң аны райкомол путевкасы белән Свердловскига Совет-партия мәктәбенә укырга җибәрәләр. Аны тәмамлагач, Катай районында комсомол комитеты секретаре була. 1929 елда Мөхәррәм Галимов Кызыл Армия сафына алына. Башта Казандагы Татар-башкорт хәрби мәктәбенә укырга керә, татар әдәбияты белән бик нык кызыксына. Кремльгә урнашкан хәрби мәктәптә «Кызылармеец» дигән татарча газета чыга. Анда Мөхәррәм язган мәкаләләр дә басыла. Газетаның җаваплы редакторы Кави Нәҗми, җаваплы секретарь Закир Сәмитов һәм әдәби хезмәткәрләр Мөхәррәмне якын күрәләр. Газетада үзенең шигырь-

ләре, очерклары һәм хикәяләре белән актив катнашучы, үзе Урта Азиядә татар полкында хезмәт итүче Хәйретдин Мөҗәй белән дә Галимов хатлар алыша.

Курсант егет үзенең хәрби эшкә сәләтле булуы, тырышлыгы белән аерылып торган, стена газеталарына аны мактап язганнар. Мөхәррәм Галимов Һади Такташны да күреп белә, аның шигырьләрен яратып укый. Яшь курсантның Казандагы тормышы аның киләчәге өчен батырлык мәктәбе була. Ул ат өстендә бик яхшы йөри, кылыч һәм сөңге сугышларында беренче урыннарны ала, төз ата, чаңгы ярышларында җиңеп чыга. Авыллардан килгән татар егетләренә ул русча лекцияләрне тәрҗемә итә, аларны укырга-язарга өйрәтә, хәрби күнегүләр вакытында да булышлык күрсәтә. Ял көннәрендә хәрби мәктәп курсантлары Кабан күлендә көймәләрдә йөриләр. Менә шул вакытларда Мөхәррәм яңгыравыклы тавыш белән җырлап җибәрә:

Казан каласы таш кала,
Уртасында Болагы.
Уралым еракта калды,
Сагындыра шулары.

Әйе, балачакларында уйнап үскән Копейск шәһәрен ул өзелеп-өзелеп сагына, җәйге ял вакытларында анда кайта, әти-әниләре, туганнары белән очраша.

Казан Мөхәррәм язмышына икенче яктан да тирән эз сала. Егет монда аэроклубка йөри башлый һәм авиация аның бөтен җанын биләп ала. Ул төннәр буе очучылар турындагы китапларны укый. Ниһаять, Мөхәррәм, үзенең очучы булырга теләгән белдереп, гариза язарга тәвәккәлли. Сәламәтлегенең җитенкерәмәвен сәбәп итеп, аның үтенечен кире кагалар.

1931 елны Мөхәррәм полк мәктәбен тәмамлап чыга. Аны взвод командиры ярдәмчесе итеп билгелиләр. Ленинградта артиллерия хәрби мәктәбен тәмамлагач, ул артиллерия полкында взвод командиры була.

Әмма армиядәге хезмәт тә аның яшьлек хыялын оныттыра алмый. Киресенчә, егет монда шушы теләген тормышка ашырырга тырыша һәм 1934 елны Оренбург шәһәрендәге очучылар мәктәбенә укырга керә. Аны «отлично» билгеләренә тәмамлап, һава армиясендә очучы-штурман булып хезмәт итә башлый. 1937—1938 елларда үзе теләп Испаниядә фашистларга каршы сугыша. Гитлер һәм Муссолини тарафыннан җибәрелгән һава пиратлары белән бәрелешләрдә катнаша. Урта диңгездә фашист солдатлары төялгән корабларны бомбага тота. Ул республикачылар армиясендә Родриго Мартинеса исеме белән йөри. Саламанка шәһәрендәге Франко штабын тар-мар итүдә катнаша. Фашистларның Майоркап утравындагы хәрби базаларын, ныгытмаларын юкка чыгара. Очучы-штурман Мөхәррәм Галимов-Родриго Мартинеса Испания Коммунистлар партиясе җитәкчеләре Хосе Диас һәм Долорес Ибаррури белән берничә тапкыр очраша. 12 нче интернациональ бригада командиры, язучы Матэ Залка белән очрашып сөйләшә, аның әсәрләрен яратып укуын әйтә.

Мадрид, Валенсия, Барселона... Испаниянең гүзәл шәһәрләре. Мөхәррәм бу шәһәрләрне фашистлардан саклау өчен барган каты сугышларда да катнаша. Күк йөзендә бер генә болыт әсәре дә юк, саф зәңгәрлек, бакчаларда әфлисуннар өлгерә. Шәһәр урамнарында ... канлы сугыш. Фашистлар тыныч халыкны кыралар. Республикачылар аларга каршы торалар, мылтыклардан ут ачалар. Дошман мәкерле һәм явыз. Ул, Италиядән һәм Германиядән корал алып, һөҗүмгә күчә. Сугыш озак дәвам итә. Зәңгәр күлләр һәм елгалар, бакчалар һәм йортлар өстенә фашист самолетлары үлем бомбалары ташлыйлар. Зәңгәр күккә кара төтен болыты күтәрелә, бакчалар яна, йортлар җимерелә... Республикачылар чигенергә мәҗбүр. Дошман басып алган урыннарда фашистик режим урнаштырыла.

Бер эскадрилья, штабта киңәш иткәннән соң, фашистлар урнашкан урынны бомбага тоту өчен, һавага күтәрелә. Кызыл очучылар арасында Галимов-Родриго да бар. Аларга зенит тупларыннан ата башлыйлар. Берничә самолетка снаряд тия, ут каба. Моны күреп торган очучы Мөхәррәм тагын да ярсыбрак оча.

Тиешле урынга якынлашкан саен, зениткалар ешая бара. Ләкин кыю лачыннар фашистлар оясына килеп җитәләр һәм авыр бомбаларын коялар. Очучы Мөхәррәм, тешләрен кысып, ачулы хәлдә түбәнрәк төшә һәм дошманның корал складларын бомбага тота. Башка очучылар да үзләренең «күчтәнәчләрен» фашистлар өстенә ташлыйлар. Мөхәррәм Галимов аска карый һәм бер йортның ишегенә беркетеп куелган свастикалы байрак күрә. Ул тиз генә шул йорт өстенә бомбасын төндыра. Тагын очып килә, тагын берничә бомбасын ташлый. Йорт, байрагы-ние белән бергә, җимерелеп төшә. Бу йорт фашистларның штабы икән. Ә аның тирә-ягында корал һәм азык-төлек, гаскәри кием складлары. Фашистлар оясы дөрләп яна. Республикачы

очучылар, дошманның җанлы көчләрен, техникасын тар-мар итеп, үз базаларына кайтырга чыгалар. Мөхәррәм-Родриго радио аркылы иптәшләренә эндәшә:

— Алло, бу — Родриго! Сезнең хәлләр ничек?

Икенче очучы аңа җавап бирә:

— Отлично!

Мөхәррәм дә җавапсыз калмый:

— Минеке дә бик яхшы!

Казармага кайткач, ул үзенең Урал буйларын, туганнарын сагынып, әкрен генә җырлап җибәрә:

Алдыр Урал буйлары,
Гөлдер Урал буйлары...

Испан егете, очучы Мачадо аңа борылып:

— Кайда соң ул Урал буйлары? — дип сорый.

Мөхәррәм аны карта янына алып килә һәм Урал таулары итәгендәге Свердловск шәһәрен күрсәтә:

— Минем туган җирем шул шәһәрдән ерак түгел. Ә менә монысы — Урал таулары.

— Ай-яй, ерак икән туган җирең!

— Фашистларны тәмам җиңгәннән соң мин анда кайтып, Испаниягә, синең исемеңә хатлар язармын әле, Мачадо!

— Мин дә сиңа язармын,— ди испан очучысы.

Алар озаклап сөйләшеп утыралар. Бик соң гына йокларга яталар. Таң алдыннан тревога була. Фашист самолетлары якынлашуын хәбәр итәләр. Кызыл очучылар дошманга каршы күтәреләләр. Алар арасында Англия, Германия, Франция, Куба, Бельгия, Польша патриотлары да була. Үз теләге белән килүчеләрнең иң күбе — Советлар Союзыннан. Алар аерата батыр. Малиновский, Мерецков, Кузнецов кебек сугышчылар үзләре генә дә ни тора! Алар Испания халкының иреген һәм намусын саклап калу өчен баһадирларча көрәшәләр. Соңыннан алар Бөек Ватан сугышында фронт командующийлары, армия һәм дивизия командирлары булдылар, фашизмны тар-мар итүдә үзләренең зур батырлыклары белән танылдылар.

Һава сугышларының берсендә Мөхәррәм Галимов, башка милләт очучылары белән берлектә, Гитлер тарафыннан җибәрелгән немец очучысының самолетын сафтан чыгара.

Фашистларга каршы көрәшү өчен, дөньяның 54 иленнән азатлык сөючеләр килә. Алар арасында язучылар, художниклар, юристлар, укытучылар һәм башка һөнәр ияләре күп.

Испания фашистларына ярдәмгә Италия ашыга. Италиянең фашистик җитәкчесе Муссолини Испаниянең азатлыгын буарга 150 мең солдат һәм офицер җибәрә. Ләкин республикачылар нык торалар. Франко гаскәрләрен дә, немец һәм Италия фашистларын да алга барудан туктаталар. Бу сугышларда зур батырлыклар күрсәткән очучы-штурман Мөхәррәм Галимов ике мәртәбә Кызыл Байрак ордены белән бүләкләнә.

1938 елның ахырында ул туган илгә кайта. Ак финнар белән сугыш башлангач, Маннергейм линиясен бомбага тотуда катнаша.

Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк ул дошманга каршы сугыша башлый. Майор Галимов очучылары немецларның бик күп техникасын һәм җанлы көчләрен тар-мар итәләр. Галимов Төньяк фронтта һава армиясенең баш штурманы була. Немецларның өч-дүрт тимер тәре алган, Лондонны, Парижны, Афинаны, Мадридны бомбага тоткан «ас»лары белән очраша, аларны җитәлдерә. Төньяк Кавказга үрмәләүче кара тәреле танклар да Галимов очучылары тарафыннан тар-мар ителәләр.

1942 елны Галимовка подполковник дәрәҗәсе бирелә. Ул фашистларның танк дивизияләрен, очучыларын кыруны дәвам итә. Галимов исемен ишетү белән, немец очучылары бер-берсен кисәтәләр:

— Сак булыгыз! Татар Галимов өере килә!

Немец очучылары, бу сүзләрне ишетү белән, тизрәк качу ягын карыйлар.

Һава армиясенең баш штурманы Галимов иң җаваплы бәрелешләргә турыдантуры үзе бара, гитлерчыларның тимер-бетон ут ноктaларын шартлата. Бу турыдагы хәбәрләр Гитлер генералларына да җитә. Баш штурманы Галимов булган һава армиясендә бөтен фронтка билгеле булган, батырлыклары өчен өч тапкыр Советлар Союзы Герое исемен алган А. И. Покрышкин да хезмәт итә. Өч тапкыр Советлар Союзы Герое исеменә лаек И. Н. Кожедуб та шушы ук армиядә данлы сугышчан юл үтә.

Мөхәррәм Галимовның үзе катнашындагы бер бәрелешкә аерым тукталасы килә. Украинаның Корсунь-Шевченковский юнәлешендә фашистларны бомбага тотарга

приказ алына. Һава армиясе очучылары һавага күтәреләләр. Ләкин очучыларны көчле ут каршылый. Беренче һөҗүм коткән нәтиҗәне бирми. Икенче көнне кызыл йолдызлы самолетлар яңадан күтәреләләр. Бу юлы штурманнарга җитәкчелек итүне Галимов үз өстенә ала. Менә дошман зениткалары ут ача, безнең самолетларның кайберләре яна башлый. Галимов, очучыларга көч-куәт биреп, иң алдан үзе бара һәм дошман ныгытмаларына бомбаларын ташларга тотына. Башка штурманнарга да ышаныч иңгәндәй була, барысы да батырларча сугышалар. Озак та үтми, «мессершмитт»лар күренә. Ике арада көрәш башлана. Галимов үзенә таба килүче немец самолетына пулеметтан ата, самолет, янып, түбәнгә мәтәлә. Икенче кара тәреле очкыч та янарга тотынгач, өченчесе качу ягына борыла. Галимов аны куып җитә, пулеметтан атып, сафтан чыгара.

Дошманның Корсунь-Шевченковскийдагы ныгытмалары һәм җанлы көчләре тармар ителә.

Сугышта күрсәткән батырлыклары өчен Галимов полковник дәрәҗәсенә күтәрелә. Ул дошманны, куа-куа, Молдавиягә килеп җитә. Аның батырлыгы турында фронт газеталарында языла, җырлар, легендалар чыгарыла.

— Галимов кайда — шунда җиңү! — диләр очучы-штурманнар, үзләренең командирларына сокланып. Кишинев шәһәрен азат иткәннән соң, совет очучылары Румыния җирендә каты сугышлар алып баралар. Полковник Галимов җитәкчелегендәге штурманнар һәр заданиене уңышлы үтиләр. Бухарестны азат итү өчен Галимов очучылары аеруча батырлык һәм ныклык үрнәкләре күрсәтеп сугышалар. Моның өчен аларның күбесе орденнар һәм медальләр белән бүләкләнә, фронт командованиесе тарафыннан рәхмәтләр белдерелә.

Фашистлар Будапешт шәһәрен бик көчле ныгытмага әйләндергәннәр иде. Һавадан берничә тапкыр бомбага тотуга карамастан, гитлерчылар каршылык күрсәтүләрен дәвам иттерәләр. Шуннан соң һава армиясе штабында киңәшмә үткәрелә. Галимов штурманнар алдына зур һәм җаваплы бурычлар куя. Ул әлеге һөҗүм планын төзүдә катнашкан. Иртәгесен очучылар шәһәрдәге ныгытмаларга кереп урнашкан фашистларны һавадан бомбага тотуны дәвам иттерәләр.

Озакка сузылган каты сугышлардан соң Будапешт азат ителә. Галимовка һәм аның очучы-штурманнарына Башкомандование тарафыннан рәхмәт белдерелә.

Австриягә чигенүче гитлерчыларны куа-куа, совет гаскәрләре Вена шәһәренә килеп җитәләр. Очучы-штурманнар дошманның коры җир гаскәрләрен, танк колонналарын, сугыш кирәк-яраклары һәм кораллар төялгән эшелоннарын яндыралар. Австрия җирендә сугышны тәмамлап, Мөхәррәм Туган илгә кайта.

1958 елда ул авиация генерал-майоры дәрәҗәсенә күтәрелә һәм һава армиясе белән җитәкчелек итә башлый. Сугышларда күрсәткән батырлыклары һәм тырыш хезмәтләре өчен ул Ленин ордены, биш мәртәбә Кызыл Байрак ордены, Александр Невский ордены, ике мәртәбә «Ватан сугышы» ордены, Кызыл Йолдыз ордены, унлап медаль белән бүләкләнә.

Генерал үзенең бергә сугышкан дуслары белән хатлар алыша, фронт истәлекләре яза, Львовта һәм үзе азат иткән башка шәһәрләрдә очрашуларда катнаша, яшьләр һәм укучылар арасында, үзе кичергән сугыш вакыйгаларын сөйләп, сугышка карата ачы нәфрәт хисе тәрбияләүдә, тынычлыкны саклауда актив катнаша.

Мөхәррәм ага Галимов — Сугыш ветереннары комитетының Львов шәһәре секциясе председателенең беренче урынбасары.

Мөхәррәм аганың кызлары да әтиләре кебек тырышлар һәм уңганнар. Барысы да югары белем алганнар, Львов, Фрунзе һәм Дүшәнбе шәһәрләрендә инженер, укытучы, врач булып эшлиләр.

Легендар очучы-штурман Мөхәррәм Галимов турында үзәк һәм өлкә газета-журналларында рус, украин, молдаван телләрендә язып чыкканнар. Аның рәсеме, Советлар Союзы маршаллары һәм генераллары рәсемнәре белән бергә, Львов шәһәренең Хәрби музеена да куелган.



**И. Х. Мәүлетхуҗин,**

КПССның Баулы райкомы беренче секретаре.

# ТАРИХЫ БАЙ, КИЛӘЧӘГЕ ЯКТЫ

*...Ерак-еракларга ага*
*Баулының нефтьләре.*
*Җир астыннан алтын таба*
*Кызлары-егетләре.*

Мәгълүм җырдан китерелгән әлеге юллар журнал укучыларының күбесенә таныш, әлбәттә. Җыр сүзләрен куәтләп, шуны да әйтергә кирәк: районыбыз аша салынган «Дуслык» нефть үткәргече Баулы нефтен Туган илебез чикләреннән дөнья киңлекләренә алып чыкты. Республикада иң өлкәннәрдән исәпләнгән «Баулынефть» идарәсе бүгенгә кадәр «озын гомерләләр» исәбендә һәм «Татнефть» берләшмәсендә иң тотрыклы эшләүче коллективларның берсе булып кала бирә. 1980 елда Баулының нефть ятмаларыннан 100 миллионынчы тонна нефть чыгарылды һәм ул вакыйга тантаналы төстә билгеләп үтелде.

Безнең төбәктә нефть табылганнан соң булган үзгәрешләр гаҗәпләндерә дә, сокландыра да: кыска гына вакыт эчендә Баулы, аның белән бергә Әлмәт, Лениногорск, Азнакай, Актүбә шәһәрләре һәм эшчеләр поселоклары калкып чыкты. Нефть республикабызның көньяк-көнчыгышында урнашкан районнарына ныклап үсү өчен уңдырышлы җирлек булды.

Баулының аңа кадәр булган тарихы да кызыклы. Язма әдәбиятта ул, XVII гасырда рус миссионерларының чукындыру политикасына каршы патша хәзрәтләренә халык исеменнән язылган шикаять аша билгеле. Төп баулыларның нәсел шәҗәрәләрен өйрәнү исә бу төбәккә нигез салучыларның бик борынгы кабиләдән булуын күрсәтә. Шәҗәрәгә 31 баба кертелгән һәм аларның иң борынгыларын мәҗүсилек чорындагы исемнәр тәшкил итә. Баулыга нигез салучыларның типтәр дип аталулары исә аларны башкорт җирендә яшәгән татарлар булган дип фикерләргә мөмкинлек бирә. Районда Хансуәр, Бәйрәкә, Шалты, Кәрәкәшле, Иске Урыссу, Исергәп, Татар Кандызы кебек борынгы авыллар бар.

Борынгы заманнардан бирле татар авыллары белән янәшәдә Удмурт Ташлысы, Урыстамак кебек удмурт, Потап-Томбарлы, Васькино-Туйралы кебек чуваш, Дмитриевка кебек мордва авыллары яшәгән Узган гасыр башларында бирегә Курск губернасыннан да берничә авыл күчерелә һәм шул чорда Поповка, Фоминовка, Кырым-сарай (элекке исеме Большая Епифановка) авылларына нигез салына, соңрак рус авыллары саны ишәя төшә. Бүген бездә 21 милләт вәкиле, зур интернациональ гаилә булып, тату һәм дус яши.

Баулы районының хәзерге территориясендә элекке берничә волость кертелгән. Алар башта Самара губернасының (хәзерге Куйбышев өлкәсе) Бөгелмә өязенә караганнар. Баулы авылы волость үзәкләренең берсе була. Бирәдә барлыгы биш башлангыч земский һәм чиркәү-приход мәктәбе, мәчетләрдә халык хисабына асралучы мәдрәсәләр эшләп килгән. Культура-агарту учреждениеләре булмаган 74 мәчет һәм ике дистәгә якын чиркәү кешеләргә даими рәвештә дин хезмәте күрсәткән. Баулы волостенда 87 эре һәм вак торак пункт исәпләнгән. Промышленность предприятиеләреннән Петербургта яшәүче патша советнигы Бутлеровның Акбуа һәм Александровка авылларында ике спирт заводы һәм алпавыт Ждановның кирпеч заводы булган, 1912 елда Волга-Бөгелмә тимер юлы һәм Ютазы станциясе салына. Халык

игенчелек белән шөгыльләнгән. Революциягә кадәр һәр крестьян хуҗалыгына уртача 1—1,5 дисәтинә (казенный дисәтинә 0,96 гектарга тиң) җир туры килүе мәгълүм.

Бүгенге көндә районда 103618 гектар сөрү җире, 29529 гектар урман исәпләнсә, революциягә кадәр сөрү җирләренең яртысыннан күбрәге һәм урманнарның барысы да диярлек алпавытлар кулына тупланган. Күпчелек авылларда крестьян хуҗалыкларының 25—30 проценты җирсез дә, атсыз да булып, алар нык изелүгә дучар ителгәннәр. Хәерчелектә һәм рухи изелүдә яшәгән крестьяннарның югары катлам даирәләргә каршы баш күтәрү очраклары билгеле. Районыбыз территориясе аша узган Пугачев гаскәрләренә бабаларыбызның да катнашкан булуы турында риваятьләр бар. Крестьян күтәрелешләренең иң күренекле һәм документларга теркәлеп калганы — беренче рус революциясе елларында Бәйрәкә авылы крестьяннарының алпавыт Ждановка каршы баш күтәрүләре. Әмма крестьяннарның стихияле бу күтәрелеше канга батырылып бастырыла. Яхшы коралланган стражниклар отряды крестьяннарга каршы ут ача, берничә кеше үлә. Бик күпләр яралана, байтагы аңнарын җуйганчыга кадәр суктырыла, 68 кеше төрле срокка төрмәгә ябыла, фетнә җитәкчеләре каторгага хөкем ителәләр.

Совет власте урнаштыру һәм гражданнар сугышы елларында бу төбәктә дә давыллы вакыйгалар булып уза. Баулылар «сәнәкчеләр» фетнәсен бастыруда, күп җирдә булдырмый калуда актив катнаштылар. Ак чехлар корпусы һәм Колчак бандаларына каршы көрәшкә дә Баулы кешеләре өлеш кертә, арада легендар Чапаев дивизиясе сафларында дошманны җиңеп, авылларыбыз аша тантаналы марш белән узучы якташларыбыз да булган. 1919 елның җәенә территориябез дошманнан тулысы белән азат ителә. Әле дә Баулы тауларында гражданнар сугышы елларының истәлекләре — окоп калдыклары, туп урнаштырылган корылма эзләре, каберлекләр очраштыргалый.

Унтугызынчы елның ноябрендә Исергәп авылында — беренче комсомол ячейкасы, декабрьдә Ташлы авылында РКП(б) ячейкасы оеша.

Совет власте урнаштыруда, аны ныгытуда коммунистлар һәм комсомоллар керткән өлеш чиксез зур. Революция эше, бүгенге киләчәгебез өчен тормышларын корбан иткән Кәрәкәшле авылы укытучылары комсомолкалар Сәрби Ишмәкаева, Гайшә Батыршина, Бәйрәкә партия ячейкасы члены Мияссәр Нәбиуллин, Мортазадан Мотыйгулла Фәрукшин, Каразиректән Мөгаллим Гәраев һәм башкаларның мәңгелек истәлеге һәйкәлләрдә, язма истәлекләрдә, халык күңелендә саклана. Бүгенге буын кешеләре районыбыздагы Исергәп, Бәйрәкә, Баулы һәм Поповка большевикларының батырлыгы белән горурланалар, аларны рәхмәт хисе белән искә алалар.

Егерменче елларда авылда культура революциясе үткәрү, мәктәпләр, культура-агарту учреждениеләре ачу, үзешчән сәнгать түгәрәкләре оештыру буенча бик күп эшләр башкарыла.

1928—29 елларда авыл яңадан революция елларындагыдай гөж килә. Ярлылар җыелышларында да, авыл җыеннарында көн тәртибендә бер мәсьәлә тора — күмәкләшү. Авылларга унбиш 25 меңче килә. Алар партиянең авыл комитетлары белән бергә крестьяннарны колхозга тарту буенча нәтиҗәле эш башкаралар.

1930 елда Баулы районы оештырыла. Аның составына 43 авыл Советы керә. Халык саны 48000 була, шуларның 29 меңе татар, 11 меңе рус һәм 8 меңе башка милләт вәкилләре.

Шушы ук елның 25 августында партиянең районкүләм I конференциясе була. Шул көннән башлап партиянең Баулы район оешмасы Бөгелмә кантоны оешмасыннан бүленеп, коммунистлар партиясе эстафетасын мөстәкыйль дәвам итә.

1931 ел ахырына Баулы районы коллективлашу буенча республикада беренче урында бара. Бу вакытка районда яшәүче барлык крестьян хуҗалыкларының 94,7 проценты күмәк хуҗалыкка керә. Бу зур җиңү райондагы партия һәм комсомол оешмаларының никадәр көчле икәнлеген ачык күрсәтә. Шушы ук елны Татарстан АССР Үзәк башкарма комитеты (ЦИК) президиумының 26 октябрь карары нигезендә, республикада беренчеләрдән булып, икмәк хәзерләү планын срогыннан алда үтәгәне өчен районга махсус премия бирелә. Бу — Октябрь революциясенең 14 еллыгына баулыларның лаеклы бүләге була.

Утызынчы еллар уртасында Баулыда һәм Ютазыда кирпеч җитештерү буенча промышленность һәм азык комбинатлары, Ютазы элеваторы үсеп чыга, халыкка көнкүреш хезмәте күрсәтү идарәсенең беренче цехлары да шул елларда эшли башлый.

1940 елга районда 86 колхоз, бер совхоз һәм дүрт МТС исәпләнә. Шул ук елда районда 228 мең сумлык промышленность продукциясе җитештерелә.

Немец-фашист илбасарларының илебезгә вәхшиләрчә бәреп керүе нәтиҗәсендә тыныч төзелеш туктала. Районның 18 меңгә якын кешесе Бөек Ватан сугышына

китә. Шулардан 7 меңләбе яу кырларында ятып кала. Ватаныбыз бәйсезлеген саклауда 100 дән артык хатын-кыз да катнаша. 45 кеше Халхин-Гол, Хәсән күле бәрелешләрендә һәм ак финнарга каршы сугыша. Якташларыбыздан дүрт кеше — Иван Зиновьев, Фатих Шәрипов, Гавриил Евсеев, Михаил Панарин — Советлар Союзы Герое.

Бөек Ватан сугышының иң авыр чорында, 1942 елда Урыссу ГРЭСы төзелә башлый һәм 1944 елда ук аның беренче турбина агрегаты энергия бирә.

1946 елның 17 сентябрендә районыбыз һәм бөтен республикабыз тарихында әһәмиятле вакыйга була — мастер Степан Баклушинның девон катламына житкәнче бораулаган скважинадан бик көчле нефть фонтаны бәреп чыга.

Нефть чыгару һәм электр энергиясе бирү арткан саен, районда промышленность предприятиеләре саны күбәя бара. Хәзер алар кырыктан артты. Әпсәләм төзелеш конструкцияләре һәм материаллары комбинаты, Урыссу тимер-бетон эшләнмәләр заводы, «Газспецмашремонт» заводының филиалы, Урыссу бемит заводлары продукциясен илебезнең күп өлкәләрендә яхшы беләләр. Үз вакытында Баулы ятмаларын үзләштергәндә ныклы чыныгу алган нефтьче якташларыбызны хәзер илебездә нефть чыккан барлык төбәкләрдә дә очратырга мөмкин. Баулы нефтьчеләре Көнбатыш Себер ятмаларын бораулауда да югары күрсәткечләргә ирешә.

Промышленность белән бергә, авыл хуҗалыгы да яхшы үсеш алды. Кырыгынчы еллар уртасында бирегә нефть ятмаларын үзләштерергә илнең төрле төбәкләреннән җыелган нефтьчеләр, җирле халыкның да, колхоз-совхозларның да бик зур бәрәңге плантанцияләре булуына гаҗәпләнеп, безнең якны «бәрәңге иле» дип атый башлаганнар иде. Чыннан да, бәрәңге игү белән безнең якта күптәннән шөгыльләнәләр. Акбуа һәм Александровка авылларында урнашкан спирт заводлары өчен бәрәңге төп чимал була. 1921 елда Урта Идел буендагы корылык нәтиҗәсендә булган ачлыктан да Баулы халкын бары тик бәрәңге коткарып кала. Хәтта тирә-якта: «Баулыларның шунысы яхшы, чәй янында — бәрәңге»,— дип җырлау гадәте таралган. Кайбер крестьян хуҗалыклары бәрәңгене бүлбедән утыртып түгел, алмасыннан алынган орлыкны чәчеп, бик тәмле яңа төр бәрәңге алган. Күрәсең, шул вакытлар истәлегедер, халык бүген дә «бәрәңге утыртабыз» диясе урынга «чәчәбез» дип сөйли. Бездә бәрәңге ярыйсы гына уңыш бирә. Әмма игенчелек өчен табигать шартлары уңайсыз. Район республиканың иң көньяк-көнчыгыш өлешенә төньяктан көньякка 89 километрлап сузылган тар һәм озын мәйдан булып урнашкан. Көнчыгыштан ул барлык озынлыгы буенча Башкортстан, Ык елгасы һәм бихисап тау тезмәләре белән, көньяк-көнбатыштан Оренбург өлкәсе, көнбатыш һәм төньяктан Бөгелмә һәм Азнакай районнары белән чиктәш. Рельефы борынгы тау җыелмалары белән юмарт ергаланган.

Елның һәр фасылында районыбыз территориясендә җилләр өзелеп тормый. Шуны гына да әйтү җитә: ел әйләнәсенә искән җилләрне тәүлекләргә күчереп исәпләгәндә, секундына 15 метр тизлектәге җил республикабызның Арча районында 8 тәүлек иссә, бездә 25 тәүлек һәм аннан да озаккарак сузыла. Төньяк Казахстан һәм Оренбург далаларыннан искән коры җил, яз башлануга, Ык үзәгенә ташлана һәм районның зур-зур мәйданнары озак вакытка «җилләр тозагы»нда тора. Багана булып тузан өермәләре күтәрелә. Туфрактагы дым бик тиз кими. Халык телендә «Оренбург торбасы» дип атала торган әлеге җил капкасы аша яз көннәрендә, үсемлекләрнең вегетация чорында вакыт-вакыт 20—35 әр көн дәвамында коры җил исә. Җир өстендәге уңдырышлы катлам туздырыла, җил аны чокырларга, Ыкка илтеп ташлый. Җил һәм су эррозиясеннән район авыл хуҗалыгы ел саен уртача ярты миллион сумлык зыян күрә.

Җитмешенче еллар башында районыбыз республикада беренчеләрдән булып сугарулы көтүлекләр булдырды. Кайбер хуҗалыкларда сугарулы басулардан 500 центнер һәм аннан да күбрәк яшел масса алына. Сугарулы тамыразык һәм бәрәңге кырлары да уңышны мул бирә. Бу юнәлештә әле тагын да зуррак эшләр тора. Хәзер бездәге авыл хуҗалыгы елына уртача 30—35 миллион сумлык продукция җитештерә, шуның яртысыннан күбрәге терлекчелек җилкәсенә төшә.

Район агропромышленность берләшмәсе составында 23 колхоз-совхоз, «Госкомсельхозтехника» һәм «Сельхозхимия» берләшмәләре бар. Аларның экономикасы елдан-ел ныгый, куәте арта. Танылган иген үстерүчеләребез һәм терлекчеләребез бар. Киров исемендәге колхозның сарык фермасы мөдире Т. Зарипова һәм «Баулы» совхозы механизаторы Х. Зәйдуллин Социалистик Хезмәт Герое исемен йөртәләр. Авыл хезмәтчәннәреннән 32 кешегә мактаулы исемнәр бирелде. Шулар арасыннан колхоз төзелеше ветераннары К. Маркс исемендәге колхоз председателе Г. Йосыпов һәм «Коммунизмга» колхозының элекке председателе М. Абдуллин — РСФСР һәм ТАССРның атказанган агрономы, «Урал» колхозының элеккеге механигы М. Хәйруллин РСФСРның һәм ТАССРның атказанган механизаторы ди-

гән югары исемнәргә лаек булдылар. Җитмешенче еллар башында өчмеңче савымчыларыбыз бармак белән генә санарлык булса, бүгенгә өчмеңче һәм дүртмеңчеләребез йөздән артты. «Правда» колхозы сыер савучысы Зәйтүнә Хәләфиева 1985 елны һәр сыердан 5200 килограмм сөт савып алуга иреште. Бу — районда иң югары күрсәткеч. Хәзер терлекләрнең отышлы токымнарын үрчетү, дуңгызчылык һәм сарык үстерү тармакларын камилләштерелгән технологиягә күчерү буенча шактый эшләр алып барыла. Авыл хуҗалыгын үстерүдә унберенче бишьеллыкта гына да 44 миллион сум капитал салынды. Авылның социаль үсешенә КПСС Үзәк Комитетының май (1982 ел) Пленумы карарлары аеруча зур йогынты ясады. Соңгы ике елда гына да авылларда 7904 квадрат метр торак мәйдан, дүрт мәктәп, ике мәктәпкәчә балалар учреждениесе, авыл культура йорты һәм клуб, 13 кибет һәм башка социаль-көнкүреш объектлары төзелде. Соңгы ун елда районыбыз өч мәртәбә Бөтенсоюз социалистик ярышында җиңеп чыкты.

Районда автомобиль юлларының киң челтәре булдырылды. Хезмәт ияләренең сәламәтлеген саклау буенча да шактый эшләр башкарыла. Район кешеләренә 121 врач һәм 612 урта медицина работнигы хезмәт күрсәтә. Нефтьчеләребез өчен — «Иволга», колхозчылар һәм совхоз эшчеләре өчен «Березка» санаторий-профилакторийлары эшли. Аларның һәркайсы 200әр урынга исәпләнгән, заманча җиһазлар белән тәэмин ителгән. Күптән түгел 150 урынлы яңа санаторий ачылды, анда авырулар кымыз белән дәваланалар.

Халык мәгарифе ирешкән уңышлар да шактый. 51 мәктәптә 8016 укучы белем ала, төп фәннәрдән керүче укытучыларның 99,3 проценты югары белемле. 13 педагог РСФСРның һәм ТАССРның атказанган укытучысы дигән мактаулы исемне йөртә. Дүрт укытучыбызга — СССР Мәгариф отличнигы, 42 укытучыга Халык мәгарифе отличнигы исеме бирелде. Профессональ-техник училищеда 412 егет һәм кыз автоматика һәм контроль-үлчәү приборлары слесаре, электромонтер, киң профильле тракторчы-машинист кебек һөнәрләргә өйрәнә.

Культура-агарту эшендә дә уңышларыбыз байтак. Районның культура-спорт комплексы 171 культура-агарту учреждениесен берләштерә, алар арасында 61 культура йорты һәм клуб, 49 китапханә, 58 кино күрсәтү җайланмасы, ике музыка һәм рәсем мәктәбе, сәнгатьчә бизәү остаханәсе, спорт корылмалары, парклар бар. Алар хезмәт ияләренең культуралы ялын оештыру буенча күпкырлы эш алып баралар.

Районыбыз халкы якташларыбыз, бүгенге көндә фән, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә танылган галимнәребез, язучыларыбыз һәм артистларыбыз белән чын күңелдән горурлана. Шулар арасында профессор, филология фәннәре докторы М. Зәкиев, Казан ветеринария институты ректоры, профессор, ветеринария фәннәре докторы Н. Хаҗипов, Новосибирск шәһәрендә эшләүче профессор, физика-математика фәннәре докторы Н. Ибраһимов, Уфадагы профессор, техник фәннәр докторы Ә. Биккулов, 15 фән кандидаты бар. Аларның икесе Баулыда эшли.

Күренекле татар язучылары Сирин Батыршин, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Рафаэль Мостафин, Фәнис Яруллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Миргазиян Юныс, Әнисә Ибраһимова, чуваш язучысы А. Афанасьев, удмурт язучысы Е. Самсонов, рус язучылары Митряшкин-Тимин, Виктор Зиновьевка, Татарстанның атказанган артисты Ганс Сәйфуллинга, артист Илдус Әхмәтҗановка халыкчан талант булып өлгерер өчен Баулы туфрагы уңдырышлы җирлек ролен уйнады.

Баулы эшчеләр поселогы үзенең матур урынга салынуы белән күпләрне сокландыра. Безнең якта ял иткән кунаклар яңадан Баулыга килүне сагынып көтеп алалар. Поселок урамнары да елдан-ел матурая бара. Баулының борынгы исеме Баллы Елга булган. Исеменә җисеме, дигәндәй, баулылар тәмле телле булулары өстенә кунакчыллар да. Кунакка килегез, үкенмәссез.

**Фәрит Хатипов,**

филология фәннәре докторы

# ПСИХОЛОГИЗМ ОСТАСЫ

Иҗатының башлангыч чорында ук Г. Ибраһимов әдәби әсәрләрдә хис-кичерешләрнең ничек яктыртылуына зур игътибар бирде, кешеләрнең күңел тибрәнешләренә сизгер булырга чакырды. Ул Ф. Әмирханның «Хәят», Ш. Камалның «Курай тавышы», «Сердәшләр» әсәрләренә бик югары бәя бирде һәм рецензияләрендә мисалга нәкъ менә рухи халәт, эчке серләрне сурәтләгән зур-зур өзекләрне китерде.

Тора-бара әдип психологизмга мөнәсәбәтен теоретик яктан да ачыклап күрсәтте, «... уңае туры килгәндә, лирика матдәләренең дә кереп китүе»н (Ибраһимов Г. Әдәбият кануннары. Казан, 1919, 81 б.), ягъни уй-хисләр тасвирлануын романның әһәмиятле бер сыйфаты дип карады. Ул Октябрь революциясе тәэсирендә төрле социаль катламнар күңелендә туып торган үзгәрешләрне дикъкать белән күзәтеп барды, крестьяннарның тар карашлардан, вак милекчелек психологиясеннән арынып, «коллективчылык психологиясенә күчүен» (Ибраһимов Г. Әдәбият мәсьәләләре. Казан, 1960, 213 б.) күрсәтте, пролетариат язучылары «үз каһарманнарының җаннарын, йөрәкләрен тулы көенчә ачып бирү өчен» күңел хәятенә үтеп керәләр, дип язды, тәрҗемә өчен халыкның «психологиясенә вә тәрәккыят фикериясенә» туры килердәй әсәрләр сайларга киңәш итте. «Капитализмның черек нигезендә җитешеп, эшче-крестьян коллективыннан аерылган язучыларның психологиясен» кискен тәнкыйтьләде, «чыннан да пролетариат шигыре туа алсын өчен, художникның иҗат куәте белән бергә, аның психикасы да пролетариатча булырга кирәк!» — дип белдерде, язучы рухы белән халык рухының бердәмлеген яклап чыкты. Ул билгеле бер профессия кешеләрен психологик сизгер, үткен итеп сурәтләде.

Г. Ибраһимов татар әдәбиятына халыкның гаять бай, катлаулы күңел дөньясын алып килде, аны күп яклары белән баныкытты. Аның тәүге хикәяләрендә күңел тибрәнешләре беренче нәүбәттә табигать процесслары йогынтысында туалар. Яшь язучы табигать стихиясе тәэсирендә кеше рухының давылланып, бөтерелеп алган мизгелләрен күрсәтә. Табигатьтә туган үзгәрешләр, шомлы гарасат рухи халәтне пассивлыктан тартып чыгаручы, кузгатып җибәрүче актив көч итеп бирелә.

«Табигать балалары» (1914) һәм башка кайбер хикәяләр физик хезмәт ләззәтен тасвирлыйлар, авыр һәм киеренке басу-болын эшләренең җанга рәхәтлек, тынычлык, горурлык бирүен, сәламәт, табигый хисләр поэтикасын сиздерәләр.

Шулай да сизгер художник иҗтимагый эчтәлекле тойгыларның аеруча әһәмиятлеләрен социаль мөнәсәбәтләр өлкәсеннән алып күрсәтә. «Карт ялчы» (1912), «Көтүчеләр» (1913) хикәяләрендә геройлар табигатькә тагын да якынрак торалар, күп гомерләре басу-кырда үтә. Әмма алар күңеленә андый ләззәтләнү, хозурлану хисләре килми. Моның төп сәбәбе, хикәяләрдән күренгәнчә, көч җитмәстәй авыр эшләр башкарып ватылуда гына түгел, бәлки социаль изелүдә, байларга ялланып эшләүдә, кеше кешесе булуның ачылыгын тоюда. Персонажларның сүзләрендә, кичерешләрендә күңелнең иң түреннән чыккан иңрәү, рәнҗү авазы ишетелә. Бу әрнү иҗтимагый гаделсезлекне һәр даим үз җилкәсендә татып яшәүдән килә.

Г. Ибраһимов бу дәвердә үзенең геройларын үтә хисләнүчән, тәэсирләнүчән, хыялланырга яратучан шәхесләр итеп тасвирлый. Ул безнең прозага тойгы-кичерешләр муллыгын, тулылыгын алып килде, романтик күтәренкелек беренче чиратта рухи дөнья өлкәсендә чагылды. Кичерешләр, күргәнебезчә, табигатькә, хезмәткә, социаль шартларга мөнәсәбәт нигезендә, нәфрәт яки мәхәббәт җирлегендә туа.

Психологик хикәяләрнең һәммәсе дә персонаж исеменнән сөйләтеләләр. Бу форма әсәрләргә күп төрле стиль төсмерләре бирә. Һәр герой үзенең индивидуаль рухи

дөньясы белән килә, башлыча хикәяләүче персонажның эчке дөньясы тулы тасвирлана. Болардан үзгә буларак, «Йөз ел элек», «Карак мулла» (1911) хикәяләре автор исеменнән бәян ителә, башлыча тышкы вакыйгалар ягына басым ясала, гүяки автор да чит кешеләр күңеленә үтеп керергә кыюлык итми.

Әмма романнарда инде өченче заттан хикәяләү күңел биләмәләренә керергә комачаулык итми, әдип боларда кабат мул психологик үзәнгә кайтып төшә. Бигрәк тә «Яшь йөрәкләр»дә (1912) рухи халәт, тойгы-кичерешләр үтә бөртекләп, тәфсилле ачыклана. Биредә композицион үзәк итеп Зыяның солдатка карalу күренеше алынган. Әдип шушы бер үк вакыйгага күп кенә персонажларның мөнәсәбәтен, шуңа бәйләнешле кайгылы кичерешләрен тасвирлый, бер герой хисеннән икенчесенә, өченчесенә, дүртенчесенә күчә бара. Шулай итеп, роман сюжетының киң планлылыгы психологик киң планлылыкны китереп чыгара, психологизм роман табигатенә җайлаша.

«Яшь йөрәкләр»нең баш геройларыннан берсе Мәрьямне без нигездә үз булмәсендә күрәбез. Тышкы дөньяны да ул булмә тәрәзәсе аркылы гына күзәтә. Геройлар күбесенчә рухи тормыш белән яшиләр. Автор аларның күңел дөньясының үзенчәлекле булуына, аерылып торуына, үз эчләренә бикләнгәнлекләренә басым ясый. Зыя музыка белән, Мәрьям мәхәббәт романнары белән юана. Үтә нечкә, сизгер күңелле Зыя өчен музыка дөньядагы бар нәрсәдән дә кадерлерәк тоела, җыр-моң, матур көй аны әйтеп бетергесез дәрәҗәдә әсәрләндерә, хисләндерә, күңелендә тирән кичерешләр уята. Музыка — аның омтылышы, шатлыгы-куанычы да, ислам фанатизмы шартларында — хәсрәте, көенече дә.

Морза кызы Мәрьям җитеш тормышта яши. Әмма шулай да ул җанын кая куярга белми газаплана, бәргәләнә, күңел бушлыгын ни белән тутыру әмәлен күрми. Актив хәрәкәт, физик хезмәт булмау да аны шактый вата, йончыта. Төннәрен ул йокысызлыктан интегә. Мондый халәт Н. Г. Чернышевскийның «Сәнгатьнең чынбарлыкка эстетик мөнәсәбәтләре» дигән хезмәтендә бик тулы чагылдырылган. Г. Ибраһимовның хезмәтләрендә Н. Чернышевский иҗаты белән таныш булганлыгы күренә. Беркадәр соңрак Г. Ибраһимов үзе дә мәкаләләрендә Н. Чернышевский фикерләрен, нәкъ менә сәнгатьнең чынбарлыкка мөнәсәбәтен аңлаткан карашларын ышанычлы авторитет рәвешендә китерә.

Автор әнә шул яшь йөрәкләрнең үзара мөнәсәбәтләрен, интим хисләрен, Фатыйма бикәнең эгоизмы аркасында, мәхәббәтнең бәхетсезлек, фаҗига белән тәгәлләнүен сурәтли. «Яшь йөрәкләр» аеруча мул кичерешле роман булды.

Билгеле, психологизм ташкыны үзе генә әле әсәрнең сәнгатьлелек дәрәҗәсен билгеләп бетерә алмый. Әйтик, «Казакъ кызы» (1911—1924) романы Г. Ибраһимовның башка әсәрләре арасында да үзенең гүзәллеге белән аерылып тора. Биредә инде күңел хәятын тасвирлау да үзенең табигый эзенә төшә, «Яшь йөрәкләр»дәге үзмаксатка әйләнеп китү очракларыннан, психологик кабатлаулардан арына. «Яшь йөрәкләр»дә эчке һәм тышкы дөнья мөнәсәбәтендә психологик як өстенлек ала иде. «Казакъ кызы»нда исә кеше яшәешенең һәр өлкәсе дә чынбарлыктагыча реаль, табигый пропорциядә бирелә.

Биредә төп вакыйга, кичерешләр казах ыруы башлыкларының власть өчен көрәшләре тирәсенә җыела. Үзара тыгыз үрелешкән иҗтимагый вакыйгалар, интим мөнәсәбәтләр персонажлар күңелен чайпалдырып җибәрәләр, каршылыклы, катлаулы, үзенчәлекле фикер-хисләр ташкынын кузгаталар. Монда, табигый, иҗтимагый-политик эчтәлекле уй-кичерешләр шактый зур урын алалар. Найманнар башы Байтүрәнең — зур власть иясенең каты чирләп китүенә төрле кешеләр төрле мөнәсәбәт белдерәләр. Берәүләр ачыктан-ачык нәфрәт хисләрен сиздерә, аның дөньялыкта кылган гөнаһларын, явызлыкларын искә төшерә, икенчеләрнең «тышкы кайгы пәрдәсе астында йөзендә һәм күзендә зәһәрле шатлык күренә», өченчеләр асыл уй-мөнәсәбәтләрен тирән яшерәләр. Сарманнар башлыгы Сарсымбай ыру көрәшләренең планы, көчләрне урнаштыру тактикасы турында баш вата. Дала кешеләрен, бигрәк тә ыру башлыкларын сайлауда кайсы төркемнең өстенлек алуы хакындагы шомлы уйлар дулкынландыра. Шундый талашлар тегеләйме-болаймы ярлы крестьян вәкилләрен дә үз эченә бөтереп ала. Ләкин шул ук вакытта әдип сайлау-тартышларының ялчылар өчен принципиаль әһәмияте булмавын да, аларның моңа бик сабыр, битараф карауларын да күрсәтә. «Боларның Сарсымбае да, Янгырбае да барыбер эт түгелме? Бу талашларда найманнар җиңсә ни файда да, сарманнар җиңсә ни зарар?.. Ни дип мин Кызыл Ком серләрен Якты күлгә ташып йөрим?» — дип уйлый ялчы Җолкынбай. Автор каршылыклы гамәлнең күңелдә каршылыклы уйлар тудыруын хикәяли.

Язучы Карлыгач-Сылу белән Арсланбайның саф мәхәббәт тойгыларын бик матур сурәтли, яшь күңелләрнең сүзсез хәбәрләшеп торуын, бер-берсенә омтылуын оста тасвирлый. «Арада көмеш кыллардан үйналган музыка кебек саф яңгырап, Карлыгач-Сылуның көлгәне ишетелде. Өйдәгеләрдән һичкем моңа колак салмаса да, кунак җегете моның үзен чакыру икәнен аңлады». Кызның көлүе, күрәсез, аерып кына бирәүгә дә

тәбәлмәгән, тик гомумән күңел күтәренкелеген генә чагылдыра кебек. Ләкин кызны сизгер тойган егет моннан үзе өчен тирән мәгънәле нәтиҗә ясап куя. Соңга таба менә шулай сүзсез хәбәрләшү картиналары башка язучылар иҗатында, аерым алганда, И. Газиның «Онытылмас еллар» трилогиясендә үстереп җибәреләчәк.

Автор мәхәббәт хисләренең, үтә интим, шәхси мөнәсәбәтләрнең иҗтимагый вакыйгалар, төрле төркем талашлары белән тыгыз бәйләнгән булуын күрсәтә. Ул аңлы рәвештә мәхәббәт мөнәсәбәтләрен җитди сайлау вакытына туры китерә. Татлы мәхәббәт кичерешләре арасына ырут талашлары килеп керә. Ләкин шулай да йөрәк хисләре көчлерәк булып чыга, күрәләтә янап торган куркыныч белән дә исәпләшми.

Г. Ибраһимов ислам кануннары хөкем сөргән җирдә хатын-кызлар язмышында очрый торган тирән драматик кичерешләрне дә тасвирлый. Сарсымбайның икенче хатыны ире алдында кадере булмауга гарьләнә, газаплана. «Тәнем сау, җаным авырта, — ди ул. — Күп көннәр үтте инде, баем минем төннәремне бикәгә бирә». Аны кешелек хисе кимсетелүе газаплый. Әдип бу теманы күп кенә әсәрләрендә төрле вариацияләрдә дәвам иттерә. «Безнең көннәр»дә яшь хатын Һаҗәрне карт иренең үтә салкынлыгы, туң йөрәк булуы әрнетә. «Илаһем, хуҗам, кем гөнаһ кылмас, кем түзәр... хатын булып яратыл. Тамырларында утлы кан кайнап ташсын! Син ир кочагында ят, ләкин хатынлыкны белмә, татыма! Ходаем, үзең чыдам бир! Үзең сабырлык бир! Ни булыр, гомер шулай үтәрме?» — дип уйлый ул. «Татар хатыны ниләр күрми» повестенда көндәш хатыннарның үзара киеренке мөнәсәбәтләре тасвирлана, интрига чыганагы ачыклана.

Шуның белән бергә без «Казакъ кызы»нда дала кешеләренә генә хас үзенчәлекле кичерешләр белән дә очрашабыз. Безнең халыкта: «Юл газабы — гүр газабы» диләр. «Казакъ кызы»нда исә, киресенчә, яңа җәйләүгә йончыткыч күченү геройларда куаныч, күңел күтәренкелеге уятып җибәрә. «Чөнки кәрван кебек төялеп күчүләр, мәшәкатьле булса да, казах өчен бер бәйрәм, уен-көлке кебек бер ихтыяҗ иде».

«Казакъ кызы»нда без революциягә кадәрге казах тормышының үзенчәлекле иҗтимагый-көнкүреш детальләре белән генә түгел, геройларның үзенчәлекле рухи дөньялары белән дә очрашабыз.

Этнографик, гореф-гадәт, йола картиналарына якынлыгы ягыннан бу романга «Татар хатыны ниләр күрми» (1929) повесте якын тора. Монда көнкүреш детальләрен, семья мөнәсәбәтләренә бәйле кичерешләрне бөртекләп сурәтләүгә зур игътибар бирелә. Чөнки ахыр чиктә әнә шул көнкүреш ваклыклары Гөлбануны һәлакәткә китереп җиткерә дә бит инде. Аны уңганлыгы, булдыклылыгы да коткарып кала алмый.

Биредә дә автор бер генә герой кичерешләре белән чикләнми. Әсәрдә хәтта бөтен массаның уртак тойгыларын чагылдыру омтылышы да сизелеп калгалый. Йола нормалары билгеләгән психологияне сурәтләп, әдип болай ди: «кодалар, туйдан кайтканда, ат тирләгән булсын дип, урау юл белән Бикъяргa чаптылар». Ләкин шулай да үзәктә Гөлбану язмышы тора. Башка персонажларның күңел тибрәнешләре өзек-өзек кадрларда бирелсә, Гөлбануның рухи тормышы тоташ агым рәвешендә күрсәтелә. Автор сурәтләвенчә, мәхәббәткә ирешү, гаилә кору мәсьәләләрендә Гөлбану пассив натуралардан түгел. Ул яратып йөргән егетенә ябышып чыгарга да риза. Әмма тормыш сукмагы башка юнәлеш белән китә. Закирга чыккач, ул ир канаты астына сыенырга, шунда ышык табарга тели. Ләкин Закирның буыны сыек, канатлары хәлсез булып чыга. Каты куллы Шибай карт та озак яшәми.

Гөлбану тормышында моннан соң тоташ кара көннәр башлана. Язучы аның рухына, күңеленә тирән яра салып узган, һәлакәткә китергән хәлләрне чагылдыра, үкенечле карарның күңелдә ничек өлгерүен, җитлегүен күрсәтә. Г. Ибраһимов биредә авыр язмышның иҗтимагый-политик чыганакларын да, йола сәбәпләрен дә, шуларның рухи дөньяга ясаган йогынтысын да күрсәтә.

Бөек Октябрь социалистик революциясе, халыкларга социаль-экономик милли азатлык алып килү белән бергә, хезмәт иясләре аңын томалап, тышаулап торган рухи богауларны да өзеп ташлады. Халыкның зиһенe иҗтимагый үзгәреш тудырган яңа карашфикерләр белән баеды. Шулай итеп, әдәбиятның психологик офыклары бик нык киңәйде. Аның алдына илебезнең рухи куәтен, яңа уй-хисләрне чагылдыру бурычы килеп басты. Бу мәгънәдә Г. Ибраһимов, Ш. Камал, М. Гафури иҗаты критик һәм социалистик реализмны тоташтырып кына калмады, әүвәлге психологизм белән революциядән соңгы психологизмны да ялгап җибәрде. Яңа чынбарлыкны ачыклаганда, алар психологизм традицияләрен дә файдаландылар һәм аңа беркадәр динамизм, хәрәкәтчәнлек өстәделәр. Психологик анализ кебек нечкә, нәфис инструмент социаль анализ эшенә хезмәт итә башлады, иҗтимагый үзгәрешләр барышында шунда катнашучыларның үзләренең дә рухи яңаруы тасвирланды.

Г. Ибраһимовның «Кызыл чәчәкләр»е повесть жанрында иҗат ителгән, вакыйгалар персонаж исеменнән сөйләтеләләр. Ләкин биредә сүз шул герой хакында гына бармый. Әлеге форма язучыга катлаулы, каршылыклы, киң масштаблы, тарихи әһәмиятле рево-

люцион вакыйгаларны хикәяләүченең үзе тирәсенә җыеп күрсәтергә мөмкинлек биргән.

Революция чорында баш герой Солтанда яңа психология туа — көрәшче психологиясе. Яшьлегендә тик өйләрен авыл уртасына күчерү өмете белән генә яшәгән крестьян егетнең күңелен сыйнфый, хәрби көрәш мәсьәләләре биләп ала. Ул көрәштәш дуслары Гыйлаҗиларга әйтеп бетергесез теләктәшлек, мәхәббәт белән карый, яңа тормыш төзү өчен барган рәхимсез бәрелештә аяксыз калуын күркәм сабырлык белән кабул итә, кимсенми, киресенчә, горурлана гына. Революция дошманнарына карата аның күңелендә ачы нәфрәт кайный. Г. Ибраһимов иҗтимагый хәлләр тәэсирендә кеше күңелендә яңа рух — революцион көрәшче психологиясе тууын сурәтләүче прозаикларның беренчеләреннән булды. Бу тема аның «Безнең көннәр», «Тирән тамырлар» романнарында да, совет әдәбиятының башка әсәрләрендә дә төп тема булып китте. Бу әсәрдән берничә ел гына соң иҗат ителгән «Рәүфә» (1920) повестенда, мәсәлән, А. Шамов моңарчы изелеп яшәгән хезмәт ияләренең, бигрәк тә хатын-кызларның рухи тураюын зур художество көче белән сурәтләп күрсәтте. Яңа тәртипләрнең гуманистик асылы, ярдәмчеллеге шәһәрдән килгән хатын образында гәүдәләнде. Яшь совет прозасы катлаулы, киеренке көрәшләрнең иҗтимагый-политик, экономик тармакларда гына түгел, үзара бәйләнеш-мөнәсәбәтләр өлкәсендә, күңел дөньясында да баруын тасвирлады, рухи үзгәрешләр процессын чагылдырды. Яңа хис, фикерләр хисабына психологизмның баюы, күңелдә яралган борылышларны сәнгатьчә яктырту социалистик реализм методының үзенчәлекле мөһим сыйфатларының берсенә әверелде.

Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» (1928), «Безнең көннәр» (1934) романнары революцион бәрелешнең эпик картиналарын гәүдәләндерә. Әмма композицион оештырылыш ягыннан болар бер-берсеннән нык кына аерылалар. «Безнең көннәр»дә вакыйгалар, сюжет җепселләре, аерым геройлар язмышы дәвамлы рәвештә, тоташтан буйга үстерелми, һәр персонаж чикләнгән сандагы эпизодларда гына күренеп кала да, хәрәкәт күбесенчә киңлеккә җәелә, автор бер типтан, күренештән икенче, өченчеләренә күчә бара һәм бу үзенчәлек бүлекләргә бирелгән исемнәрдә дә ачык чагыла. Әсәрнең трилогия буларак уйланып та, тәгәлләнми калуы аркасында да бәлки әлеге киңлеккә җәелү күзгә ташлана торгандыр. Әсәрдәге үзәк вакыйга — революция.

Биредә рухи халәтнең чыганагы яңа. Геройлар революционер юлының хәтәр, сикәлтәле булуын ачык беләләр, ләкин курку кичермиләр, киресенчә, хәвефле бәрелешкә катнашулары белән горурланалар. Аларның байтагын көрәшчеләр сафына эксплуатация дөньясына нәфрәт, хезмәт ияләрен бәхетле, азат итү идеалы китергән. Автор үзе берничә урында революционер психологиясе турында басым ясап әйтә, аның төрле сынаулардагы чагылышын күрсәтә. Баязит сорау алу вакытында шәфкатьсез җәзалау ихтималына алдан ук күңеленнән әзерләнеп бара, әмма газаплау көткәндә, йомшак сүз ишетеп, каушап кала.

Әсәрдә кайбер морза, сәүдәгәр балаларының да, модага ияреп, революционлашып алуы, реакция башлангач, тиз генә революционер кабыгын салып ташлавы күрсәтелә. Язучы шулай ук урталыктагылар, обывательләр психологиясен дә чагылдыра.

Әдип хәрәкәтнең үзәгенә яшьләрне куйган. Табигый, ул яшьлекнең үзенә генә хас бизәкләренә, мәхәббәт тойгыларына, хис-кичерешләр бәрелешенә, гаилә мәсьәләләренә дә кагылмыйча узмаган. Революцион көрәш иреге белән мәхәббәт, семья мәсьәләсен төрле геройлар төрлечә аңлыйлар. Кыскасы, автор биредә төрле социаль катлам кешеләренең революцион ситуациядәге психологик халәтен яктырта.

«Тирән тамырлар» революция солдаты Фәхринең үтерелү фаҗигасы тирәсенә җыеп бирелгән.

Тикшерү әшен башта ялгыш юнәлеш белән алып киткән факт — ул Фәхри гәүдәсе янында табылган канлы кендек. Байтак вакыт буена бу предмет уй-кичерешләрнең дә «кендеге»нә әверелә. Ул берәүләрне сискәндереп җибәрә, икенчеләр күңелендә каршылыклар көрәшен тудыра.

Шул ук вакытта автор кендеккә бәйләнешле дәлилнең нигезе бик үк нык булмаганлыгын да искәртеп үтә. Моны ул нәкъ менә рухи яктан килеп аңлата, игенченең психологик сизгерлеген күрсәтә.

Романның икенче өлешендә Вәли Хәсәновның җинаятен сурәтләгән күренешләр алгы планга чыга. Биредә персонажларның да күңел серләре Вәли Хәсәновка мөнәсәбәттә ачыла.

Кыскасы, әсәрдә геройларның эчке хәятен яктыртуга әһәмиятле урын бирелә. Персонажларның уй-кичерешләре яңа эчтәлекле иҗтимагый вакыйгалар белән бәйләнештә күрсәтелә. Ләкин шулай да бу инде язучының хикәяләрендәге яки «Яшь йөрәкләр»ендәге үтә җентекле психологизм түгел, шактый җыйнак, динамик психологизм. Роман тукымасында биографизмнар, язучы үзе әйтмешли, тышкы вакыйгаларның өстеннән йөгереп үтүләр хәтсез урын били. Автор сюжет динамикасының җитезлегенә омтыла. «Безнең көннәр»нең баштагы өлешендә әдип: «... вакыйгалар яшен тизлеге белән акты», — ди. Эчке дөньяны да ул җитез, җыйнак сурәтләрдә бирергә тырыша, күңел кар-

тиналары шушы җитез агышлы тышкы хәлләр ритмына җайлаша. Автор үзенең романнарын мөмкин кадәр тыгыз иҗтимагый әчтәлекле итәргә, әсәр мәйданына күп төрле социаль көрәш күренешләрен сыйдырырга тели. Урыны-урыны белән рухи хәяткә бераз кысыла төшәргә туры килә.

Егерменче елларда рухи сферага үтеп керү юлы такыр, тигез генә булмады. Кайбер әдипләргә зур социаль яңарышлар фонында күзгә чалынмый торган эчке кичерешләр, аерым шәхеснең хисләре әһәмиятсез, кызыксыз булыр кебек күренә иде, язучылар чорның аз белемле укучылары аларны аңлап җиткермәс дип шикләнәләр иде. Ф. Әмирхан 1921 елда, «Беренче ашкыну» хикәясен иҗат иткәндә, көндәлегенә: «Вакыт-вакыт шул бер дә әһәмиятсез шәкертнең беренче гыйшкының шул тәфсилле психологиясе берәүгә дә кирәкмидер, аны язып тору бик габәстер (файдасыз эш, буш нәрсә. — Ф. Х.) төсле тоелып куя» (Әмирхан Ф. Сайланма әсәрләр. Ике томда. I т. — К., 1957, 19 б.) дигән юлларны теркәп уза. Җентекле психологизм Г. Ибраһимовның аеруча романтик әсәрләренә хас иде. Бу елларда әдип үз иҗатындагы романтизмны үтелгән этап, реакция чоры белән бәйләнешле күренеш дип карады, әсәрләренең реализм рухында язылуына басым ясады. Романтизмнан баш тарту психологизмны да бер чама саектырып узды. Бу елларның әдәби тәнкыйтендә геройның беренче нәүбәттә эш-хәрәкәтләренә игътибар юнәлтелде, хис-кичерешләрнең эстетик әһәмияте аз дип каралды.

Тулаем алганда исә Г. Ибраһимов сәнгатьчә психологизм өлкәсендә татар әдәбиятына байтак ачышлар, яңалыклар алып килде. Әдип ирешкән казанышлар — үзе бер иҗади мәктәп ул.

Кеше күңелен сурәтләү юнәлешендә Ф. Әмирхан, Ш. Камаллар белән берлектә Г. Ибраһимов эшкәрткән туфрак татар совет прозасы өчен бик бәрәкәтле, уңдырышлы булды. Әдипләребез иҗтимагый тормыштагы казанышлар белән беррәттән кеше күңелендә туган яңалыкларны күп төрле төсмер-бизәкләр белән чагылдырдылар. Алар классиклар иҗатына хас булган күңел диалектикасын уңышлы дәвам иттерәләр, ягъни рухи хәятне диалектик рәвештә үзләштерәләр, эмоцияләрне гади теркәү, статик тойгыларны анализлау, психологик нәтиҗәләрне гади әйтеп китү белән генә чикләнмиләр, кеше җанын реаль хәрәкәттә, эчке каршылыклар бәрелешендә, күп төрле күренешләр белән бәйләнештә, кыскасы, реаль байлыгында, катлаулылыгында күрсәтәләр.

Совет чорында әдәбиятка килгән язучылардан К. Нәҗми, Г. Кутуй, М. Әмир һәм башкалар хезмәт кешесенең рухи тураюын сурәтләп кенә калмадылар, аларның инде иҗтимагый тормышта актив роль уйнауларын, рухи яктан бик югары күтәрелүләрен дә чагылдырдылар. Алар яңа чор көрәшчесенең эчке һәм тышкы гүзәллеген органик бердәмлектә, гармониядә гәүдәләндерделәр. Караш, фикерләр үсешен лирик аһәңле, романтик күтәренке бизәкләр аша күрсәттеләр.

«Намус» романында Г. Бәширов җыйнак, динамик психологизмга өстенлек бирде. Романның лирик аһәңе, хис-кичерешләрнең күтәренкелеге, киеренкелеге хәтергә уелып кала. Чөнки әдип аерым бер алым белән генә чикләнми, психологик сурәтләү аренасындагы барлык ысуллар байлыгын эшкә җигә. Аның «Җидегән чишмә»се исә психологик тирәнлек, фикер-хисләр байлыгы белән аерылып тора. Әсәр персонажлары, бигрәк тә сәнгать әһелләре, кеше рухын яктыртуның җитди әһәмияте турында кат-кат, басым ясап әйтәләр. «Җидегән чишмә» — фәлсәфи-психологик, фикер-хис романы ул.

Бүгенге әдәбиятта Ә. Еники иҗаты үзенчәлекле урын били. Әдип Г. Ибраһимов, Ф. Әмирханнарның җентекле, мул психологизм традициясен уңышлы дәвам иттерә, аны җитди ачышлар белән баета. Ул чынбарлыкны кеше күңеле позициясеннән карап яктырта, яшәешнең эчке дөньяда чагылышын сурәтли һәм беренче чыганакны — яшәешне җентекле өйрәнү җирлегендә мөһим иҗтимагый-политик, рухи-әхлакый мәсьәләләр күтәрә. Аның әсәрләрендә иҗтимагый-политик үткенлек, психологик зирәклек һәм сәнгатьчә камиллек бик ипле үрелә.


Психологизмның бер тармагы бүген лирик проза әсәрләрендә уңышлы үстерелә. Р. Төхфәтуллин, М. Мәһдиев, Ә. Баянов, Х. Сәрьян, В. Нуруллин укучыларга матурматур лирик повестьлар бирделәр. Ул әсәрләрнең төп аһәңен эмоциональлек, хисләр муллыгы билгели. Күңел хәятен сәнгатьчә чагылдыру юнәлешендә киеренке иҗади эзләнүләр бара.

Ләкин бу өлкәдә хәл итәсе җитди генә мәсьәләләр дә бар әле. Әдәбиятыбыз классигы Г. Ибраһимов иҗаты белән чагыштырып караганда, алар тагын да ачыграк күренәләр. Бүген бездә еш кына фикер-тойгылар байлыгы сюжет бердәмлеге белән ныгытылмый, әсәр таркау килеп чыга. Урта кул әсәрләрдә без сәнгатьчә психологизм үрнәкләрен дә очратмыйбыз. Аларда примитивлык, әһәмиятсез, вак нәрсәләрне драмалаштыру, күңел картиналарының икенчеллеге күзгә ташлана, геройның эш-хәрәкәтләре психологик мотивлаштырылмый.

Классик әдипнең зур әдәби традициясе әдипләребезне яңа иҗади биеклекләргә әнди.



Г. Ибраһимовның «Алмачуар» хикәясенә иллюстрация



СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты

Т. Хаҗиәхмәтов эше.

# Г. ИБРАҺИМОВ УКЫГАН ИСКЕ МӘДРӘСӘДӘ

*Күренекле әдипнең тормышын һәм иҗатын өйрәнү, билгеле булганча, егерменче елларда ук башланды. Шул вакыттан алып әдәбиятыбыз классигының күпкырлы иҗатын һәм тормыш юлын чагылдырган дистәләрчә китап, мәкаләләр язылды, истәлекләр җыентыгы дөнья күрде. Әмма Г. Ибраһимов турындагы истәлекләрнең, документларның әлегә билгеле булганнарыннан барысы да басылып чыкмаган. Журнал укучыларга шундый характердагы материаллардан Г. Ибраһимов белән бер чорда Оренбургтагы Вәли мулла мәдрәсәсендә укыган Хөсәен Абушаев истәлеге һәм әлегә кадәр матбугатка чыкмаган документаль чыганаклар тәкъдим ителә. Аларны редакциягә озак еллар буе Г. Ибраһимовның тормыш юлын һәм иҗатын өйрәнгән өлкән язучы Афзал ага Шамов тапшырды. Документларның кайберләре русча язылган. Аларның татарчага тәрҗемәләрен дә Афзал ага Шамов эшләде. Бу материаллар классик әдибебезнең тормышы һәм иҗатының төрле дәверләрен яктыртулары белән зур әһәмияткә ия. Алар киләчәктә Г. Ибраһимовның тәфсилле биографиясен язуда мөһим чыганаклар булып хезмәт итәр. Кыскасы, бу документлар әдәбият белгечләре өчен генә түгел, туган әдәбиятыбыз тарихы белән тирәнтен кызыксынучы киң катлау укучыларыбыз өчен дә файдалы булыр.*

*Түбәндә Х. Абушаев истәлеге тәкъдим ителә. Документаль чыганаклар журналыбызның киләсе санында дөнья күрәчәк.*

Кызыл кирпечтән салынган гади генә ике катлы өйнең югарыгы катында тар гына коридор, коридорның ике ягында икедән — дүрт бүлмә бар. Дүрт бүлмәгә дүрт хәлфәнең аты бирелгән: Заһидулла бүлмәсе, Ахун бүлмәсе, Габдулла бүлмәсе, Җәмил бүлмәсе дигән кебек. Бу — Оренбургтагы Вәли хәзрәт мәдрәсәсе.

Егерменче гасырның икенче елыннан башлап җиденче елына кадәр мин шул мәдрәсәнең шәкерте булдым. Югарыда әйтелгән дүрт бүлмәгә урнашкан шәкертләрнең саны, чама белән әйткәндә, 100—150 ләр тирәсендәдер. Төрле губернадан килгән төрле яшьтәге шәкертләр булганлыктан, киемнәрендә дә, телләрендә дә, гореф-гадәтләрендә дә, йөреш-торышларында да үзләренә махсус аерымлыклары күренеп тора иде. Шәкертләрнең дәрескә әзерләнүләре дә, ашап-эчүләре дә, йоклый торган урыннары да, башка мәдрәсәләрдән килгән шәкертләр белән бәхәсләшүләре дә (моназарә дип атала иде) шул үзләре яши торган бүлмәләрендә иде. Укучыларның көндәлек вакытлары ничек үткәнлеген искә төшерә китсәк, ул болай булыр иде.

Таң атар-атмастан торып, бозлы су белән юынабыз, ягъни калтырый-калтырый тәһарәт алабыз, чалмаларыбызны киеп, ашыга-ашыга, мәчеткә йөгерәбез. Мәчеттән кайткач, ашханәдәге уртак казаннан су алып, чәй эчәбез. Чәйдән соң, бүлмәләребездәге шүрлекләрдән китапларыбызны алабыз да, идәнгә утырып, кычкыра-кычкыра, сабакларыбызны такрарларга керешәбез. Аннан соң «намазга» дигән авазлар ишетелә башлый. Тагы тәһарәт алып, тагы мәчеткә йөгерәбез. Өйлә намазыннын кайткач, каткан ипиләребезне кимерә-кимерә, һәйбәтләп чәй эчәбез дә ял итәргә керешәбез. Ничек ял итү һәр шәкертнең үз ихтыярында: берәүләр йоклый, икенчеләр урамда йөреп, яисә базарга барып кайта, өченчеләр хат яза, дүртенчеләр, нәрсәдер пешереп, ашханәдә кайнаша, берәүләр яшеренеп ятып, әллә нинди китаплар укый...

Ял итү сәгатьләре үткәч, икенде, ахшам, ястү намазларын укыр өчен, кайта-кайта, мәчеткә барып киләбез дә, аннан-моннан капкалап, кичке сабакка керешәбез. Бу уку инде төн уртасына кадәр дәвам итә.

Вәли хәзрәт мәдрәсәсе шул чаклардагы иң иске әсаска корылган дини мәдрәсәләрнең бере булганлыктан, андагы уку-укыту ысулы сыйныфларга, ягъни классларга бүленмәгән, ә һәрберен укып тәмамлау нәкъ бер елга сузыла торган билгеле уникe китап буенча йөртелә иде. Гарәп һәм фарсы телләрендә язылган һәм берничә гасырлардан бирле төзәтелми, үзгәртелми килгән китапларның алдынгы бишесе гарәп теленең кагыйдәләре белән грамматикасы, алардан соңгы бишесе аять һәм хәдисләрнең тәфсирен таныту өчен, соңгы икесе мантыйк, ягъни формаль логика кагыйдәләре буенча дини моназарәгә (бәхәсләшүгә) остарту өчен укытыла иде.

Дини мәдрәсәләрнең һәммәсенә диярлек уртак булган уникe китапны, тел белән әйткәндә, нәкъ уникe елда укып тәмамлау шарт булып торса да, уку-укыту эшләрендә билгеле тәртип булмаганлыктан, кайбер шәкертләрнең шәкертлек дәверләре унбиш,

хәттә егерме, егерме биш елларга кадәр сузыла иде. Шунлыктан укучылар арасында «кырау сакаллы», «карлы башлар» белән «сакаллы сабыйлар» да аз түгел иде.

Башка кадим мәдрәсәләрендәге шикелле Вәли хәзрәт мәдрәсәсендә дә газета-журналлар, сәяси-әдәби әсәрләр уку катгый рәвештә мәмнугъ, ягъни дөньяви фикерләр язылган кәгазьләрне кулга алырга да рөхсәт ителми иде. Бу хактагы тәртипнең чиктән ашканлыгы шулкадәр иде: әгәр дә берәрсенең газета-журнал укыганлыгы яисә шул елларда ачылган кыйраәтханәгә барып, җәдиди китап укыганлыгы, я булмаса, «народный дом»га барып йөргәнлеге, яки киного барганы, тагы шундый «бозык» җирләргә аяк басканлыгы сизелә калса, аз дигәндә андый «азгыннарга» берничә тапкыр аяусыз искәртү, икенче тапкыр суык сарайга ябу, өченче тапкыр хәзрәтнең бәддогасын йөкләтеп, мәдрәсәдән каңгыртып җибәрүгә кадәр чаралар кулланыла иде.

Ләкин гарәпнең «һәр Фиргавенгә бер Муса» дигән мәкаленә, казахның «һәр асканга бер тускан» дигән мәкаленә охшаш, нәүбәте килгәндә, замана кемнәрне зир-зәбәр китермәгән?

Тарихи бишенче елда исә башлаган инкыйляб җиле безнең мәдрәсә бүлмәләрендәге тончыктыргыч зәһәрле һаваны да сизелерлек дәрәҗәдә үзгәртеп, күп кенә шәкертләрнең иркенләп тын алуларына мөмкинлек бирде. Бик сакланып кына булса да, китапханәгә барып, Казанда, Әстерханда, Уральскида чыга башлаган гәзит-журналларны уку, хәлфәләр тарафыннан мәмнугъ ителгән кайбер китапларны алып кайтып уку, җәдиди «Хөсәения» шәкертләре белән танышу, йөрешү, дуслашу, «Галия» шәкертләре белән хатләр аркылы хәбәрләшү, фикер алышу, әллә кемнәр чыгарган хөррият җырларын җырлау шикелле «бер дә ярамый» торган гамәлләр көннән-көн күбәя, үсә башлады.

— «Кояш чыкты, нур җәелде,
Тәрәзәдән өйгә керде,
Ятма йоклап, уян, шәкерт,
Файдаланыр вакыт җитте»...

— «Күп яттык без мәдрәсәдә,
Аңламадык бернәрсә дә,
Селкенмәдек таш төсле без,
Җилбер-җилбер җил бәрсә дә»...

дип башлана торган «инкыйляби» җырларны баштарак әкрен-әкрен генә, як-ягыбызга карана-карана гына җырласак та, бара-бара, кыза-кыза, үзебезнең кайда торганыбызны онытып, әллә нинди моңлы һәм күтәренке тавышка салып, түбәнге каттагы ашханәне, утынханәне, алар белән янәшә торган башка бүлмәләрне шаулатып, яңгырата башлый идек.

Болардан башка, тагы:

— «Ташлыйк, туганнар, иске тормышны,
Бу тормыштан безгә файда юк;
Булса, байлар илә тик түрәләр
Аркабызда рәхәт күрәләр...

Кирәкми, ташлыйбыз иске юлны,
Кирәкми... яңа юл башлыйбыз,
Яңа юл, яхшы юл, бер җәберсез,
Тигез рәхәт тора башлыйбыз!..»

дип башлана торган инкыйляби яки «Марсельеза» исемле җырны да бик дәртләнеп җырлый идек. Бу җырны безгә «Хөсәения» шәкертләре өйрәткән иде. Аларның әйтүләренә караганда, аларга моны шул мәдрәсәдәге Сәгыйть Рәмиев дигән яшь мөгаллим өйрәткән икән.

Беркөнне безнең «яшерен» бүлмәбезгә Сәгыйть Рәмиев үзе килде. Ул кыяфәтен үзгәртә төшкән шикелле иде.

— Әй, малайлар, әй, иптәшләр! — дип башлады ул үзенең ялкынлы сүзен.— Сез алданган икәнсез. Сез, валлаһи, харап булган икәнсез. Сезнең чәчәк кебек яшь гомерегез бушка гына үтеп бара икән. Сез гыйлем һәм мәгърифәттән мәхрүм калган суфыйлар белән дәрвишләр юлына, димәк, теләнчеләр юлына төшкәнсез икән. Юк инде, әшнәкәйләрем, алай булмасын. Сезгә үз заманыбызга кирәкле гыйлем һәм мәдәният белән коралланү лязим. Сез инде тузып беткән, әллә кайчангы сафсаталардан ваз кичегез. Сезгә тарих, җәгърәфия, хисап, гыйльме әшья, гыйльме кимия, гыйльме һәйәт кебек дөньяви фәннәрдән хәбәрдар булу, җәдиди мәдрәсәләрдә укып йөргән шәкертләрдәй

шәрык әдәбияты һәм ватандашыбыз урыс халкының телен өйрәнеп, Мохит диңгезеннән[1] дә тирәнрәк итеп әдәбияттан өлеш алу кирәк. Хасыйле кәлям, дәрвишләр юлын ташлап, гыйлем юлына төшүегез кирәк.

Җәдид мәдрәсәнең бик җитез мөгаллиме тарафыннан әйтелгән бу сүзләр авыздан-авызга күчеп, күп кенә шәкертләр арасында әңгәмә тууга сәбәп булды.

Ләкин шулай да... мондый фикерләргә кул куючылар азчылык иде, ә каршы торучылар күпчелек иде әле безнең мәдрәсәдә. Башкача әйткәндә, җәдидләр азрак иде, ә кадимиләр күбрәк иде әле...

Шуны да әйтеп китик әле.

Әгәр мәдрәсәдәге шәкертләрнең һәммәсе диярлек җәдидләрнең фикеренә кушылыр булса,— кушылып, үзләренең теләкләрен фанатик хәзрәтләр белән мөтәгассыйб (фанатик) хәлфәләргә белдергән булсалар, нәрсә булыр иде? Уку-укыту эшләрендә аз гына булса да үзгәреш булыр идеме? Ул ягы безнең өчен караңгы иде. Аның өстенә искелек белән даны чыккан дини мәдрәсәгә шәкерт бул дип, кем чакырды, кем тәклиф[2] итте безне? Килгән икәнбез, кемнәр соң безне җибәрми тота? Әйе, кемнәр җибәрми тора?! Без аңгыра бәрәннәр аны да уйламадык.

Шулай итеп, җәдитләр белән кадимиләр арасындагы фикер каршылыгы көчәйгәннән-көчәя барып, бу каршылык, ахры, кычкырышуга, талашка, бер-беребезгә кырын карап йөрүгә кадәр барып җитте.

Җәдидләрнең мәдрәсәдән тыш җирләрдә кемнәр белән, кай мәдрәсәнең шәкертләре белән танышып, нәрсәләр хакында сөйләшкәннәрен, китапханәгә барып, кемнең нинди китап алып кайтканлыгын, кемнең сандыгында кайлардан, кемнәрдән килгән хатлар барлыгын инәсеннән җебенә кадәр тәфтишләп, хәлфәләргә, хәлфәләр аркылы хәзрәтнең үзенә җиткереп торучы җасуслар[3] да аз түгел иде шәкертләр арасында. Тора-бара беленде: шундый монафикъларның берсе яшь ягыннан егерме бишләргә якынлашып барган Галләмхан Исламов дигән «җәдидче» юлдашыбыз икән. Ул зур буйлы, баһадир кыяфәтле, таза, матур һәм сүзгә оста гына бер егет иде. Кадимчеләр белән җәдитчеләр арасында булгалап торган мәсләк моназараларында ул, һәркайчан җәдитчеләрнең сүзләрен куәтләп, бәхәс кыза төшкән чакларда, үзенең комган кадәр йодрыкларын да күрсәтеп, янап-янап куючы иде. Баксак, анысы аның хаинлык белән безне алдавы икән... Соңгы көннәрдә ул, бер дә оялмыйча, кадимчеләр белән дуслашып, йодрыклары белән инде безгә яный башлады.

Онытмасам, январьның бишләре иде шикелле.

Кичке намаздан кайтып, кичке сабакка керешә башлаган чагыбызда дүрт бүлмәнең ишегенә икешәрләп, барлыгы сигез сакчы куеп, «шикле», «ышанычсыз» шәкертләрнең сандыкларын тентеделәр. Тентүне берничә «кырау сакал» белән хәзрәтнең «уң күзе» дип аталган Заһидулла үзе үткәрде. Бу эш шактый озакка сузылды. Сандык һәм кәрзинкәләрнең астын-өскә китереп, андагы кәгазьләрнең барысын да күздән кичерделәр. Ахыры нәтиҗәдә, дүрт бүлмәдәге җәдитләрдән дүрт кочак кәгазь «конфисковать» ителеп, тиешле хөкемне чыгару өчен, Вәли хәзрәтнең үз кулына тапшырылды.

— Бүгеннән башлап тәүбәгә килегез. Тәүбәгә килегез дә хәлфәләрнең һәм хәзрәтнең аягына егылыгыз. Әгәр шулай итмәсәгез, яхшылык көтмәгез! — дип, киңәш бирә башлады безгә Хан Исламов шикелләләр. Ләкин без андый «тәүбәләргә» әйләнеп тә карамадык.

Берәр ай вакыт үткәч, «конфискацияләнгән» кәгазьләр үзебезгә кайтарылды да хәзрәтнең хөкеме игълан ителде:

— Әллә кайларга барып, әллә нинди китаплар укыган, әллә кемнәр белән дуслашып, әллә нинди хатлар язышкан, шулай итеп, безнең әмеребезгә итагать итмәгән, ягъни мәсәләән, дин вә шәригать юлыннан тайпылып, шайтан сукмагына төшкән җәдитләр белән безнең мәдрәсә арасындагы бәйләнеш бүгеннән башлап мөнкатыйг булды[4]. Бүгеннән башлап алар бу мәдрәсәнең шәкерте булып саналмасын. Куылсын!..

Аннан соң, бу хөкемгә эләккән утыз җиде шәкертнең аты һәм фамилиясе укылды. Кадимнәр бик куанды ахры — берәүләре: «Вот сиңа!» — дип кычкырды, икенчеләре кул чапты.

Без, сафка тезелеп, телгә җиңел, җанга җайлы «Уян, шәкерт»не кычкырып җырлый башладык.

Кояш чыкты, нур җәелде...

---

[1] Мохит диңгезе — әйләнә-тирә, тирә-юнь.

[2] тәклиф — көчләү.

[3] Җасус — шымчы.

[4] Мөнкатыйг булды — тыелды.

Әйе, иң кыйммәтле елларыбызны ялмап йоткан Вәли хәзрәт мәдрәсәсе белән без менә шулай итеп саубуллашкан идек.

Бик кыскартылып, көндәлек дәфтәреннән күчерелгән ошбу «Мәдрәсә белән саубуллашу» маҗарасы бер мең тугыз йөз җиденче елның 19 февралендә булып үткән бер вакыйга иде.

Мәрхүм Галимҗан Ибраһимовның үз кулы белән язылган автобиографиясендә: «Унбердән унсигез яшькә чаклы Оренбургтагы иске схоластик типтагы мәдрәсәдә (кадим); аннан яңа фикерле булуым һәм уку-укыту эшендәге Көнчыгыш схоластик нигезләргә каршы көрәшкән өчен куылдым»,— дигән сүзләр бар («Казан утлары», 1967, 2 сан). Галимҗан Ибраһимовның «иске схоластик мәдрәсә»сен югарыда телгә алынган Вәли хәзрәт мәдрәсәсе дип төшенү кирәк. Чөнки мин укыган елларда ул да шул мәдрәсәнең шәкерте иде. Миннән өч ел элек килеп, Җәмил хәлфә бүлмәсенә урнашкан иде. Мин дә нәкъ шул бүлмәдә тордым. Шунлыктан булса кирәк, аның шул мәдрәсәдәге күренешләре миңа зур күзгедәй ап-ачык. Мин мәдрәсәгә барып төшкән елның көзендә ул күп булса, 13 яки 14 яшендәге малай гына иде әле, ләкин шуңа карамастан, үзеннән әллә никадәр зур һәм, бәлки, 20-25 ләргә җитеп килгән Хатиф, Сәйфулла, Әхъяр шикелле мыекларын бөтергәләп йөрүче егетләр белән шәрик булып укый иде. Шунлыктан булса кирәк, без һәркайчан да ул малайга сокланып, гаҗәпсенеп карый идек.

...Зур гына бер мәдрәсәнең аерым бер бүлмәсендә бергә укып, бергә торган, кайчакларда бергә йөреп, бергә урам гизгән бер малай хакында, укуда алдынгы, сүзгә оста, ләкин күрер күзгә бик юаш һәм һәркайчан да кәләпүш урынына бүрек киеп йөри торган гади генә бер малай хакында, атап әйткәндә, укып җитешкәндә нинди мулла, нинди кеше булып чыгачагы әле ул вакытта билгеле булмаган Галимҗан исемле яп-ябык бер малай хакында күп кенә истәлекләр язарга булыр иде булуын. Ләкин бу юлларны язучы картның исенә гайре бер хатирәләр төшкәнлектән, күп-күп әсәрләр язып калдырган Галимҗан Ибраһимов турындагы сүзне кыскартып, тик аның хакында түбәндәге берничә сүзне әйтәсе килә.

Без мәдрәсә белән хушлашкан уку елының кышкы айларында Г. Ибраһимовтан (бу вакытта ул «Галия» мәдрәсәсе шәкерте иде) еш-еш кына хатлар алгалап тордык. Аның хатлары һәркайчан да озын-озын кәгазьгә язылган булып килә иде. Ул хатларда «Галия» мәдрәсәсендә нинди фәннәр укылганлыгы, ул фәннәрне укытучы мөгаллимнәрнең нинди сахибел гыйлем[1] икәнлеге, Вәли хәзрәт мәдрәсәсендәге шәкертләр белән чагыштырганда «Галия» шәкертләренең белем дәрәҗәсе әллә кайда югары икәнлеге хакында төрле фикерләр язылган була иде.

Шуның белән бергә ул хатларда — схоластик мәдрәсәләрнең инде мәдрәсә түгеллеге, заманы үтеп, тузды гы җиткән иске хәрабә икәнлеге, ул хәрабәләрдә сабак бирүче хәлфәләр белән хәзрәтләр замана таләбеннән мәхрүм калган мөтәгассыйблар икәнлеге, шунлыктан, алардан яхшылык көтү — шайтаннан иман көтү кебек акылга сыймаслык буш хыял икәнлеге, алай булса, киләчәккә өмете булган яшьләр өчен бердәнбер маяклы юл — рус мәктәпләренә, я яңа типтагы мәдрәсәләрнең берсенә кереп уку икәнлеге хакында гыйбрәтле, дәгъвәтле һәм ялкынлы сүзләр була иде.

Әле күптән түгел, безнең мәдрәсәдә укыган чагында, андый-мондый сүзләргә ул кадәр күп кагылмый, үз-үзе белән мәшгуль буларак, иске һәм яңа китаплар уку, төн буе шәм ягып, дәрес әзерләү, әллә нәрсәләр язгалау, үзе белән үзе сөйләшкәндәй, «әй, валлаһи!» дип йөри торган юаш кына, оялчан гына булган татар малаеның безгә язган мондый хатлары әкиятләрдә сөйләнә торган әфсенле догалар белән хикмәтле таякларны искә төшерәләр иде.

«Минем иң кыйммәтле биш ел гомерем җәһәннәмдә үтте. Шундагы биш ел гомерем чалмалы зобаныйларга итагать итү белән үтте. Инде аллага шөкер, котылдым алардан. Ә сез, иптәшләр?!» — дигән сүзләр бар иде аның безгә җибәргән бер хатында.

**Хөсәен АБУШАЕВ.**

*1968 ел, 5 сентябрь.*

---

[1] Сахибел гыйлем — гыйлем иясе.

# ЗУР ШӘХЕСЛӘРНЕҢ БЕРСЕ



Татар мәдәнияте һәм сәнгатенең революциягә кадәрге тарихында иң артта калган бер өлкә булса, ул — рәссамлык сәнгате. Моның, билгеле, тарихи үз сәбәпләре бар. Бу урында аларга тукталмыйбыз, әмма бездә — татарларда бу өлкәдә беренче башлап эш күрсәткән, мәйдан тоткан зур шәхесләрнең берсе кем дисәк, ул Бакый ага Урманче булыр. Билгеле, иң элек бу күренеш Бакый ага Урманченың үз шәхси талантына бәйләнгән.

Революциягә кадәр миңа да Казанда Бакый ага Урманче укыган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укырга насыйп булды. Ул миннән югары сыйныфта иде. Бакый ага бик яшьли рәссамлык белән мавыга иде. Аның ясаган рәсемнәре, портретлары, дусларча шаржлары ул чагында ук шәкертләр кулларында йөри иде.

Бакый ага үзенең укымышлылыгы, хәзерлеге, интереслары, дөньяга карашы киңлеге белән күпьяклы, бик этрафлы, киң колачлы кеше. Ул — җыр, музыка ярата (үзе дә җырлый). Композиторлар белән еш аралаша. Музыкаль кичәләргә, концертларга берсен дә калдырмый йөри. Көнбатыш классик музыкасы белән кызыксына. Шулай ук ул әдәбиятны бик ярата, әдипләр белән аралаша, үзе дә шигырь яза, гарәп, фарсы һәм барлык төрки телләрне белә һәм шул телләрдәге әдәбиятларны да укый.

Бакый ага Урманче татар әдипләренең, галимнәрнең һәм җәмәгать эшлеклеләренең сыннарын гәүдәләндергән кебек рус, калмык, казах, кыргыз, үзбәк, башкорт халыкларыннан мәшһүр кешеләрнең сыннарын да мәңгеләштерде. Бакый ага, 90 яше тулуга карамастан, әле һаман да үзенең остаханәсендә, аның чүкече һәм рәссамлык каләме, палитрасы — кулында.

Шулай итеп, без татар рәссамчылык һәм сынлы сәнгать өлкәсендә беренче башлап нигез салучылардан берсе булган Бакый ага Урманчены 90 яше тулуы белән котлыйбыз һәм һаман шулай бирешмичә үзенең 100 еллыгын да иҗади көч белән каршылавын телибез.

**Нәкый ИСӘНБӘТ,**
Татарстанның халык язучысы.

# БӘХЕТЛЕ ИҖАТ

Бакый ага Урманче белән мин якыннанрак аның әсәрләре аша таныша башладым ахрысы... Мин кергәндә аның остаханәсендә беркем дә юк иде. Шулай да як-ягыма карану белән мин үземне фәукылгадә бер мәҗлескә килеп керген кебек хис иттем. Халкыбызның бик борынгы заманнардан ук башланып киткән тарихын, әдәбиятын, мәдәниятен үз җилкәсендә күтәреп килгән иң мәшһүр шагыйрь, әдип, галимнәренең иң югары дәрәҗәсендәге киңәшмәсенә охшаган иде бу. Мәҗлеснең түрендә борынгы легендар шагыйрь — Кол Гали утыра. Аның белән янәшә узган гасырның мәгърур кыяфәтле тарихчы галиме Шиһабетдин Мәрҗани белән күренекле мәгърифәтче Каюм Насыйри урын алганнар. Алар янында ук халыкның әдәби, мәдәни тормышында зур урын тоткан тарихи шәхесләр — Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Дәрдмәнд, Х. Ямашев, М. Вахитов утыралар. Әгәр дә бу мәҗлесне «җыючы» нинди дер сәбәпләр аркасында бирегә халыкның сөекле уллары булган С. Сәйдәшев һәм М. Җәлилне дәшмәгән булса, ихтимал, бу форум тулы хокуклы ук булып җитмәгән булыр иде. Менә шушы бөтен халык тарафыннан танылган һәм абруй казанган гали затлар һәммәсе бергә җыелып халыкның үткәне, хәзергесе, киләчәге хакында философларча сабырлык белән тирән һәм акыллы фикер йөртәләр иде шикелле.

Үзләренең иҗатлары һәм башка гамәлләре белән халыкны үз-үзенә һәм башка халыкларга таныткан, бөтен кешелек дөньясы алдында аның дәрәҗәсен күтәргән бу талант ияләрен барысын бергә күрү горурлык хисе тудыра. Зур талант иясе кулы белән иҗат ителгән бу тарихи шәхесләр образы аша туган халкыңның башыннан үткәннәре, аның гомуми тарихка керткән күренекле өлеше күз алдына килеп баса, Г. Тукайның кешелек тарихында «без әсәрле, эзле без» дигән сүзләре искә төшә, күңелләрдә җаваплылык хисе уяна. Бу дөньяда син узгынчы мосафир гына түгел. Бу бөек затлар калдырган бай тарихи һәм әдәби мираска син тулы хокуклы варис, алар ирешкәнне тагын да алгарак әйдәү — тәрәккый иттерү синең өстеңдә, ил каршысында ул синең изге вазифаң!

Бу тарихи шәхесләрнең оста эшләнгән образлары янында Бакый абзый үзе дә читят кеше түгел. Ул элекке заманның бай культура мирасын тирәнтен аңлап, аны үз осталыгы белән тагын да баетып, хәзерге заманга китереп тоташтыручы васитачы булып күз алдына килеп баса.

Минемчә, Бакый абзый бик бәхетле кеше.

— Ихтимал, һәркем үзенчә бәхетле була торгандыр,— ди ул.— Әдәбият-сәнгать әйләнә-тирә мохитны, бөтен яшәешне, алай гына да түгел, хәтта үз-үзеңне дә тирәнрәк аңларга ярдәм итүче зур көч, эстетик һәм әхлакый тәрбия чарасы. Мин үз иҗатымның халыкка кирәклеген, аңа баерак рухани тормыш белән яшәргә ярдәм итүен хис кылып, озак еллар буена шуның белән рухланып яшим.

Һичшиксез шулайдыр. Бакый Урманче бик күп иҗат җимешләре арасында менә шушы бөек шәхесләрне тарих караңгылыгыннан хәзерге заман яктысына чыгарып җанландырып күрсәтә алуы белән дә бәхетледер. Оста аларның скульптура портретларын кайсын мәрмәр чукып, агачтан юнып ясаган, кайсыларын балчыктан ясап гипстан койган. Әмма нинди генә материалдан эшләмәсен, оста аларның тышкы кыяфәтләрендә, йөз чалымнарында замана бизәгән дә, шәхси хасиятләрен дә гәүдәләндерергә тырышкан. Димәк, бу образларны иҗат иткәндә ул, кешесенә карап, күпмедер вакытка әдип тә, шагыйрь дә, тарихчы да, политик эшлекле дә «булып» алгандыр. Нәтиҗәдә, бу җансыз мәрмәр, агач яисә балчык кисәкләренә шундый «тере суы» сеңдерелгән ки, гүя аларга җан кергән дә элекке тормышларын дәвам иттерәләрдер кебек. Игътибар беләнрәк карап торсаң, аларның хәзерге буынга ниндидер әйтер сүзләре дә бар шикелле. Алар сиңа акыллы кешеләр белән сөйләшкәндәге кебек, җан азыгы өстиләр, күңелеңне баеталар.

— Менә, шулай, дустым,— ди рәссам.— Техника дигәнебез тормышка тирәнрәк үтеп кергән саен, кешенең рухани хәзинәсенә анда урын тарая бара. Мәгълүм ки, тарихыңны яхшы белмичә торып алга тәрәккый мөмкин түгел. Менә болар, ягъни мең еллардан бирле тупланып килгән мәдәниятебезнең алдынгы вәкилләре, аларның иҗаты хәзерге заман кешесенең күңел хәзинәсен баетуда ярдәм итәргә тиешләр...

Әдәбият-сәнгать әһелләре арасында иң өлкән яшьтәге аксакал булса да, һаман да мәһабәт гәүдәле, алсу йөзле ир-егет әле Бакый абзый. Мин аңа күз тидерүдән шигәеп кыяр-кыймас сагаеп кына карап алам. Җиңнәрен сызганып, кәләпүшен бераз кыңгыррак салып, кулына каләм, күмер карандаш, яисә башка берәр иҗат

коралы алган хәлдә остаханәсендә эшләп утырганда, ул хыялларны борынгы заманнарга ук алып китә. Мондый чагында ул киләчәк буыннар өчен шәм яктысында гыйбрәтле калын китаплар язып утыручы борынгы шагыйрь яки әдипләргә, галимнәргә яисә мәшһүр каллиграфларга охшап куя. Икенче карыйсың, алтын-көмештән, гәүһәр, якуттан без хәзер музейларда күреп кенә соклана торган затлы зиннәт әсбаплары эшләп калдыручы алтынчы-көмешче оста бабаларыбызны күз алдына китерә.

Мин рәссамның гомере буена ару-талуны белмәгән көчле, талантлы кулларына сокланып карыйм. Һәрбер хезмәт иясенең кулы кебек үк күпне күргән, эссесен дә, суыгын да татыган, әмма сизгерлеген арттыра гына барган бу куллар. Әнә стенасында төрле нәфис төсләре белән үзенә җәлеп иткән зур рәсем. Һәрберсе яшькелт нуры белән мөлдерәп торган әнә ул йөзем җимешләрен, алар арасыннан дөньяга сыймастай мул булып агылган Урта Азия кояшын шул оста куллар бар иткән. Тау ягы халкының яшел болында киенеп-ясанып печән кабартуын, печән өеп йөрүләрен, әнә шулай шатлыклы хезмәт бәйрәме итеп, шул ук куллар күз алдына китереп бастырган.

Табигать бу рәссамга талантның төрлесеннән өлеш чыгарган, әйтергә кирәк, бәхеткә каршы, шактый ук мул өлеш чыгарган. Бакый аганың скульптура тармагындагы эшләре, ягъни чукып, коеп, юнып һәм башка ысуллар белән иҗат иткән әсәрләре миңа аеруча көчле тәэсир итә. Адәми затның тирән уйга чуму, әсәрләнү, шатлану, гаҗәпкә калу, хафалану кебек күп төрле рухани халәтен сүзләр белән язып аңлату да җиңел шөгыль түгел. Менә шуларның һәм кешенең холкы-фигыленең тасланмаган тупас мәрмәр кисәгендә, агач түмәркәсендә яисә гади балчык измәсендә хасил булулары монысы инде могҗизага якын торган ифрат нечкә маһирлекне таләп итүче сәнгать. Гаҗәп түгелмени? Әйтик, җансыз тупас материалдан озын гомер юлы узган, башыннан гыйбрәтле тормыш михнәтләре кичергән зирәк акыллы, ихтирамга лаеклы карт кеше образы барлыкка килгән. А. М. Горький «кешенең йөзе — аның эчке дөньясының көзгесе» дигән. Шуңа өстәп, тагын тел кешенең фикерләрен, уен белдерсә, йөзе холкын-фигылен ачып бирә дип тә әйтәләр. Бик дөрес. Җентекләбрәк карасаң, картның калын кашлары астында, боек күзләрендә, ирен кырыйларында тирән сагыш, нәрсәгәдер офтану, шул хакта нидер әйтеп бирергә теләге барын күрәсең.

Яисә менә оста гади агач кисәгенә «җан өргән». Моннан биш-алты гасыр элек яшәгән могтәбәр ханымнар образы бу. Без аның нәзакәтле чибәр йөзеннән, киләчәккә төбәлгән ярым йомык күзләреннән тирән моңын, башка катлаулы күңел серләрен укыйбыз. Шундый ук гади агач кисәгендә хәзерге заман образы, яшьлек, наянлык бөркелеп торган бер кызый пәйда була. Бакый ага бу «кызын» Нәфисә дип атаган. Бу сында чыннан да нәфислек, матурлык күзгә бәрелеп тора. Аның күңеле түрендә сакланган газиз тойгылары да, әйтергә теләгән фикерләре дә йөзе кебек үк пакьтер, сафтыр, кешеләргә ул һәрвакыт хәерхаһтыр кебек күренә.

Бакый аганың төрле жанрдагы әсәрләре белән танышып йөргәндә сынлы сәнгатенең замана кешесен эстетик һәм әхлакый яктан тәрбияләүдә зур урын тотуына тагын бер мәртәбә ышанасың. Бакый Урманче үз әсәрләрендә татар халкының бай мәдәниятен, аның эстетик карашларын озак еллар буена гәүдәләндереп килде. Аның әсәрләре гуманистик пафос, нечкә лиризм белән сугарылган. Алар уйландыралар, аларны тирәнрәк аңларга, аларның нәфислеген, поэтик матурлыгын күңеленә сеңдерергә тырышасың, алар безнең рухани тормышыбызга эстетик байлык булып өстәлеп киләләр.

XIX гасыр рус язучысы В. Одоевский «Әгәр дә кара савытына берничә тамчы гына булса да үз каныңны да тамызмасаң, каләм начар яза» дигән. Язучы иҗатына төбәп әйтелгән бу акыллы фикерне, минемчә, гомумән, бөтен сәнгатькә карата да кулланырга мөмкин. Иҗат мәсьәләләре хакында сөйләшеп утырганда, әнә шул хакта да сүз кузгалганы бар. Рәссамның, скульпторның да, аның һөнәренә генә хас үз куанычы, үз иҗат газаплары да була бит?

— Бар, әлбәттә, һичшиксез,— диде Бакый ага.— Бер генә сәнгать әсәре дә дулкынланмыйча, салкын кан белән генә язылмый. Әмма безне аерата канатландыра, рухландыра торган аеруча шатлыклы минутлар да була әле.

— Шуңа берәр мисал да китерсәгез...

— Мәсәлән, болай: әйтик, синең кул астыңдагы кырлы-сырлы тупас материалга, эшли торгач, бервакыт «җан керә башлый». Анда азлап-азлап синең хыялыңдагы образның төрле сыйфатлары — матурлыгы, нәфислеге яисә усаллыгы, холкы-фигыле, башка үзенчәлекләре хасил була. Ягъни, моңарчы синең хыялыңда гына булган образ хәзер инде сын булып, сәнгать әсәре булып яшәвен башлап җибәрә. Минемчә, бу иҗат эшенең иң мавыктыргыч, иң бәхетле минутлары. Әгәр инде ул образ, тә-

мам камиллеккә ирешеп, кешегә җан азыгы була алса, моңысы аеруча зур куаныч.

Өлкән замандашыбыз мәшһүр рәссам, скульптор булуы белән бергә сәнгатьнең хәзерге заманда сирәк очрый торган тагын бер тәренең остасы бит әле: ул ифрат нечкә зәвыклы каллиграф[1] та. Ул үз заманының алдынгы караштa булган мәшһүр мәдрәсәләрендә һәм сәнгать мәктәпләрендә тәпле белем алган, катлаулы тормыш юллары узган өлкән зыялыларыбызның берсе. Аның белән утырдаш булганда еракта ук калган тарих караңгылыгына кереп китәсеңме, әдәбият-сәнгать дөньясына аяк атлыйсыңмы, һәркайчан әңгәмәдән канәгать булып каласың, тарих, әдәбият яки сәнгать сәхифәсенең моңа кадәр күренми яткан ниндидер бик кирәкле бер яңа сәхифәсе ачылып китүен сизәсең. Киң карашлы булу ул бит узган заманның бай тәҗрибәсенә таяну, шул ук вакытта хәзерге заман таләпләрен дә, киләчәкнең бездән ниләр көтүен дә игътибар үзәгендә тоту дигән сүз.

Хәзерге заман яшьләре бөек революциянең беренче елларында калкып чыккан күренекле әдәбият-сәнгать әһелләрен аларның безгә калдырган мираслары аша гына беләләр. Бакый ага ул мәшһүр затларның байтагысының замандашы булып, алар белән аралашып яшәгән кеше. Ул, мәсәлән, Габдулла Тукайны әсәрләрен укып кына түгел, бәлки үзен күреп, шигырьләрен үз авызыннан ишетеп белә. Бу озын гомернең башында аларның тормыш сукмаклары да берникадәр вакыт янәшә эздән барган. Тау ягының бу яшь үсмере дә Казанга нәкъ Тукай килгән елда килеп, аның белән мәдрәсәдә очрашкан. Г. Тукай үлемсезлек биеклегенә ашкан елларда яшь егет Бакый да Казаннан китеп барган, чөнки аңа белемнең тагын да югарырак баскычына күтәрелү өчен, башка шәһәргә күчәргә кирәк булган.

Туксан яшькә сау-сәламәт килеп җитү үзе генә дә ул кешегә чиксез ихтирам хисе уята. Инде шул яшькә кадәр иҗат сәләтен дә саклый алу, аны өзлексез дәвам иттерә алу — анысы инде нур өстенә нур булып төшә. Чөнки бу гомер буена һәм физик, һәм рухани җәһәттән камиллеккә омтылу, җәмгыять каршысында үз өстеңә зур җаваплылык алып яшәү нәтиҗәсе.

— Шәхес буларак үзеңнең кадереңне белеп, вакытыңны һәм көчеңне вакка-төяккә сарыф итмичә, зур максатларга омтылып яшәргә кирәктер, күрәсең, — диде рәссам.

Бакый аганы хөрмәтле өлкән яше белән чын күңелдән тәбрик итеп, аңа моннан соң да сүнмәс-сүрелмәс иҗат куанычы теләп калыйк.

**Гомәр БӘШИРОВ,**
Татарстанның халык язучысы.

# МӘГЪНӘЛЕ ЯШӘҮ

Туксан яшь!.. Бөтен бер гасырга җитә язган бу озын гомер үзе генә дә ирексездән безгә чын гаҗәпләнү һәм соклану тудыра. Моңарчы бит безнең халыктан чыккан акыл ияләреннән бу яшькә бары Сәйфи ага Кудаш кына җитте һәм узып китте. Мәдәният тарихыбызда менә икенче кеше — Бакый ага Урманче! Һәм иң мөһиме, иң куанычлысы — Бакый ага шушы яшенә иҗади егәрлеген, дәртен, өмет-хыялларын саклаган хәлдә килеп җитте. Ходай бирмеш һәркөн ул үзенең остаханәсендә — алъяпкычын бугган, җиңен сызганган... Мәгънәле яшәү һәм армый-талмый эшләү дәвам итә!..

Мин бу кыска гына сүземдә Бакый ага Урманченың гаять бай, гаять төрле, чын мәгънәсендә гуманистик милли сәнгатенә профессиональ күзлектән бәя бирүне өстемә алмыйм — ул кадәресен белгечләр хөкеменә калдырыйк. Минем Бакый аганың мәдәният тарихында тоткан урынын беркадәр билгеләп үтәсем килә. Чөнки җае, вакыты шуны таләп итә.

...Безнең мәдәният — яшь мәдәният. Тамыры бик еракта башланса да, мәдәниятебезнең аеруча үсеп, көчәеп, ачылып китүе шушы гасырның башларына туры килә. Мәгърифәттән кала, мәдәниятнең асылын тәшкил иткән яңа әдәбият, сәнгатьнең яңа төрләре бездә, календарь буенча, Бакый агадан да соңрак туды. Һәм һәркайсының тарих тарафыннан танылган, халык күңелендә онытылмыйча яшәгән «тудыручысы» бар. Мәсәлән, демократик рухтагы яңа әдәбиятның тууын без Тукай исеме белән бәйлибез, Тукайдан башланды дибез. Аз гына соңрак туган театр сәнгатен инде без Габдулла Кариев исеме белән бәйлибез — аны, ягъни Кариевны,

[1] Каллиграф — махсус рәвештә матур язу остасы.

татар сәхнәсенең а т а с ы дибез... Шулай ук профессиональ музыканың тууын без бик хаклы рәвештә Салих Сәйдәштән башлыйбыз.

Бүгенге мәгънәдәге сынлы сәнгать исә бездә барысыннан да соңрак туды. Әмма «тудыручысы» кем соң?.. Бер дә икеләнмичә мин: «Бакый ага Урманче!» — дияр идем. Чөнки аңа хәтле бездә татарның милли сынлы сәнгате юк иде (Сүз биредә рәсем һәм скульптура сәнгате турында бара). Менә шуны тудыручы, үстерүче, чын сәнгать итеп танытучы буларак, Бакый ага Урманченың мәдәният тарихында тоткан урыны билгеләнер дә инде... Аның озын гомере дәвамында өч буын рәссамнар туып җитеште, моннан соң да яңа буыннар киләчәк, алмашынып торачак, әмма алар дәвам иттерәчәк сынлы сәнгатьнең танылган атасы булып, һичшиксез, Бакый Урманче калыр.

Кари, Сәйдәшләр шикелле!..

**Әмирхан ЕНИКИ,**
язучы, Татарстан АССРның Г. Тукай
исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

# ТЫЛСЫМЛЫ АКСАКАЛ

Бакый ага Урманче — татар сынлы сәнгатенең корифее, безнең милли горурлыгыбыз. Аның яше дә, Алып батырдай сәламәтлеге дә, озак еллар күрсәткән хезмәте дә, бер-берсе белән ярыша-ярыша дигәндәй, бергә дәвам итеп килә.

Ул сынлы сәнгатьнең төрле жанрларында үзен тиңдәшсез талант итеп, киң колачлы, көр авазлы халыкчан художник итеп танытты. Скульптурада булсын, җанлы язуда, графикада булсын, бизәү сәнгатендә монументаль композицияләр төзүдә булсын, Бакый ага Урманче — җиң сызганып армый-талмый эшләүче, безнең чагыштырмаслык тырыш, гаять зур ихтирамга лаек рәссамыбыз. Ә аның тарихта, әдәбиятта, тел гыйлеме мәсьәләләрендә гаҗәп күп белүенә, татар халкы мәдәнияте белән тирән кызыксынуына, шуларга сәнгатьтә нык бәйләнеш табып фикер йөртүенә, киң эрудицияле галим булуына сокланмыйча мөмкин түгел!

Мин Бакый аганы инде ярты гасырдан артык беләм. 1928 елда, ерак Казахстаннан, сәнгать мәктәбендә укырга дип, Казанга килдем. Анда мине сынауларга Бакый ага кабул итте. Ул вакытта аның вазифасы укыту эшләре мөдире иде. Шул сәнгать мәктәбендә мин өч ел буена аның шәкерте булып уку шәрәфенә ирештем.

Нык һәм зур гәүдәсе, пөхтә киеме, матур һәм ир-егетләрчә йөзе, ирен киңлегендә генә итеп кырылган, тырпаеп торган көрән мыегы әле дә җанлы кебек күз алдымда. Килешле-килбәтле, кешеләр белән ягымлы мөгамәләле Бакый ага, күренгән саен, безнең барыбызга да бик әйбәт тәэсир калдыра иде.

Аннан, тормышта күп үзгәрешләр булды. Фин һәм Бөек Ватан сугышы еллары узып китте. Мин фронтлардан исән-сау әйләнеп кайттым. Бакый ага да, Казахстан һәм Үзбәкстан җирләрендә күп иҗади эшләр башкарып, Казанга кайтты. Шулай итеп, озак еллардан соң, безгә тагын очрашырга насыйп булды. Ләкин инде бу юлы ул остаз, мин шәкерт булып кына түгел, ә ул — РСФСРның халык художнигы, зур рәссам, мин исә урта яшьләрдәге шагыйрь булып очраштык.

Кол Гали, Тукай, Дәрдмәнд, Мусаларның һәм башка бик күпләрнең скульптур портретларын ясау белән бергә, Бакый Урманче иҗатында Тукай темасы, минемчә, аеруча зур һәм күренекле урынны алып тора. Кырлайда музей-йорт мемориал комплексындагы бөек шагыйребез Тукай һәйкәленнән алып, Тукай әсәрләренә төрле елларда ясалган сыннар, рәсемнәргә кадәр шул хакта сөйли.

Билгеле, әле мондый иҗат җимешләре чикләнмәгән, аларның алда әле яңа язлары, җәйләре бар. Әле Бакый ага һәр иртәдә кояш белән бергә торып үз мастерскоена төшә, әкияттәге серле тылсымчы шикелле, я күмер-карандаш, я пумаласын алып, илһамланып, рәхәтләнеп, үзенең инде Локман Хәким яшенә җитә язуын да онытып, иҗади серләре белән бүлешә башлый. Гаҗәп матур тормыш бит бу!

Иҗат тылсымы нәфасәт хадимен яшәртә дә, яшәтә дә.

**Нури АРСЛАН,**
шагыйрь, Татарстан АССРның Г. Тукай
исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты.

# ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ РУХЛЫ РӘССАМ

— Мәдәният күгендә халыкның рухи дөньясына нур сибүче, юл күрсәтеп балкучы йолдызлар бар. Шигърияттә Габдулла Тукай, музыкада Салих Сәйдәшев, драматургиядә Галиәсгар Камал, артистлар арасында Габдулла Кариев... Шул якты йолдызлар балкышында мин татар сынлы сәнгатенең аксакалы Бакый ага Урманчены да күрәм. Тарих түреннән килгән сәнгатебезгә яңа яңгыраш биргән, аны яңа баскычка күтәргән илһамлы оста һәм остазыбыз ул. Әйе, курыкмыйча, кемнеңдер абруена күләгә төшерүдән шикләнмичә, авыз тутырып, шулай дип әйтә алабыз. Сыннар ясауда булсын, рәсем сәнгатендә булсын — профессиональ башлангыч аннан. Ул — әсәрләрендә үз аһәңен, үз мелодиясен, оптимизм белән сугарылган үз моңын тапкан художник.

Мин үзем, сәхнә кешесе буларак, аның иҗатына соклanудан туктамыйм. Аның әсәрләре сәхнәдә төрле чорларны, төрле шәхесләрне гәүдәләндергәндә, миңа ачкыч, чыганак хезмәтен үти. Чөнки Бакый ага — гаять зур тормыш тәҗрибәсе туплаган, дөньяны күп күргән, интернациональ рухлы рәссам. Татар сәнгатен генә түгел, тугандаш халыклар, аеруча казах сәнгатен үстерүгә зур өлеш керткән кеше.

Бакый Урманченың үзе белән дә, иҗаты белән дә якыннан таныша башлавым әле дә хәтеремдә. Моннан утыз-утыз биш еллар элек Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Кәрим Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» пьесасы буенча спектакль куелган иде. Аның оформлениесен әле күптән түгел генә Казанга Урта Азиядән кайткан рәссам Бакый Урманчега тапшырдылар. Миңа ул спектакльдә Хәмит ролен уйнарга туры килде. Әлбәттә, Бакый аганың элек тә спектакльләр бизәүдә эшләгәне бар иде. Ләкин минем үземә аның белән иңгә-иң торып, аралашып, сөйләшеп, киңәшеп, әнә шул вакытта беренче тапкыр эшләргә туры килде. Үзенең рәсем сәнгатен генә түгел, театрны да, музыканы да, халыкның этнографиясен һәм рухи дөньясын да тирән белүе, иҗатында шуларны аңлап һәм кулланып эш итүе белән сокландырган иде ул. Театр, әдәбият һәм сәнгатебез эшлеклеләреннән Кол Гали, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Дәрдмәнд, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Кариев, Г. Камал, С. Сәйдәшев, Фәрит Яруллин, Н. Исәнбәт образлары — кыскасы, тулы бер галерея ташта аның тарафыннан мәңгеләштерелде. Бу сыннар белән очрашу һәркемнең күңелендә якты соклану уята торгандыр. Бу яктан караганда, Бакый аганың күңеле белән артист булуын әйтми мөмкин түгел. Ул тәмен белеп кенә халкыбызның озын моңлы көйләрен җырларга ярата. Аның әсәрләрен караганда, ирексездән әнә шул моң ташка да җан керткәндер сыман тоела башлый миңа.

Бәхетебезгә, табигать Бакый агага озын иҗат гомере бүләк иткән. Ә гомер озынлыгы халыкка якын булу, аның рухын, тарихын, әдәбиятын һәм сәнгатен тирәннән аңлау, аны үз язмышың итеп карау белән дә аңлатыла торгандыр.

Могтәбәр рәссам тагын-тагын яңа әсәрләре белән куандырыр дип өметләнәбез.

**Шәукәт БИКТИМЕРОВ,**
СССРның халык артисты,
СССР Верховный Советы депутаты.

# ДАВЫЛЛЫ ЕЛЛАР ҖЫРЧЫСЫ

СИРИННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

Шагыйрь Сиринның актив иҗади эшчәнлеге төрле сәбәпләр аркасында озак дәвамлы булмады, шунлыктан аның әдәби мирасы күләм ягыннан зур түгел. Шулай да ул — Октябрь революциясеннән соң, хезмәт халкы арасыннан күтәрелеп, татар совет поэзиясендә билгеле эз калдырган үзенчәлекле шагыйрьләрнең берсе. Аның «Тегүче кыз», «Булмый! Булмый!», «Язгы тамчылар» һәм башка талантлы шигырьләре, үз чорының авазы буларак, бүген дә әһәмияткә ия, культура хәзинәбезнең бер өлеше булып тора.

Сирин (Батыршин Сирин Хәниф улы) 1896 елның 14 декабрендә Татарстанның хәзерге Баулы районы Кәрәкәшле авылында күп балалы игенче гаиләсендә туа һәм кечкенәдән крестьян эшенә җигелеп, тормышның ачысын-төчесен татып үсә. Ул бала чактан белемгә омтылучан була, кыенлыкларга бирешмичә, бераз үсә төшкәч укырга керә. Бәйрәкә мәдрәсәсен тәмамлагач, авылда укытучы булып эшли башлый.

Октябрьдән соңгы елларда алдынгы, прогрессив укытучылар авыл җирендә Совет власте политикасын пропагандалау буенча зур эш алып баралар, шуның өчен канечкеч кулаклар, дин әһелләре тарафыннан төрле җәберсетү, һөҗүмнәргә дучар булалар. Кәрәкәшленең үзендә генә фанатик сәнәкчеләр кулыннан өч укытучы кыз һәлак була.

Әнә шундый киеренке шартларда актив эшләүче алдынгы укытучы Батыршин Сиринны педагогия курсларына җибәрәләр. Бөгелмәдә укыган вакытта ул әдәби иҗат белән шөгыльләнә башлый, шунда беренче шигырьләре басыла.

Озакламыйча Сирин Казанга күчеп килә. Көнчыгыш педагогия институтында укый, шәһәр мәктәпләрендә татар теле һәм әдәбияты укыта, завод, фабрикаларда эшче яшьләр белән якыннан аралаша, алар тормышына багышланган шигырьләр яза. Менә шул чорда язган һәм тиз арада популярлашып киткән «Тегүче кыз» исемле (1926) шигыреннән бер өзек:

Без тегәбез
Үлчәп-
Үлчәп
Иңен-буен;
Яңа тормыш,
Яңа кием...
Әйдә киен!
Кием тегәм,
Бу киемне кемнәр кияр?
Һәрбер җире
Нинди матур килгән, чибәр!
Кем күрәшче?
Бу киемне ул, дим, кияр,
Һәр күрәштә
Ул инде һичшиксез җиңәр.
Күкрәгенә тегеп куям
«КИМ» тамгасын:
Кигән кеше
Үзе дә шуннан аңласын:
«КИМ»ле мәхәббәтем шулай
Тегеп бирәм,
Күрәшләрдә
Шушы билгемне салмасын.

Заманында татар совет әдәбиятында авыл хуҗалыгын күмәкләштерүгә багышланган әсәрләр күп язылды. Шагыйрь Сирин бу мөһим темага беренчеләрдән алынучы булды. Һәм җәмәгатьчелек тарафыннан җылы кабул ителгән, авыл һәм шәһәр клублары сәхнәләрендә күп тапкырлар яңгыраган «Булмый! Булмый!» дигән зур күләмле шигырен (1929) язды. Аңы хосусый милекчелек белән агуланган крестьян психологиясен, каршылыклы авыр кичерешләрен тормышчан детальләр белән сурәтләгәннән соң, хәерчелектән башы чыкмаган игенчене якты күмәк тормышка чакырып, автор болай ди:

Ашлыгыңны җилгәрәмсең,
Җилгәр,
Җилгәр!
Милек-минлекләрне очыр,
Җилгә
Җибәр!
Бертуган күк

Бергә эшлик,
Бергә яшик,
Машиналы
Күмәк тормыш
Төзеп җибәр!
Аерым-аерым
Матур тормыш
Булмый, булмый!
Булмый, булмый!
Ялгыз, ялгыз
Тормыш корып
Булмый, булмый!
Булмый, булмый!

Мәгълүм ки, татар совет поэзиясенә беренче нигез ташларын салучы күренекле шагыйрьләр яңа әдәбиятны пропагандалау, әсәрләрен халыкка җиткерү буенча зур эш алып бардылар. Һ. Такташ, К. Нәҗми, Ф. Бурнаш, Ә. Фәйзи кебек зур әдипләр белән бергә әдәби очрашуларда, диспутларда Сирин да катнаша, Татар мәдәнияте йорты, клуб сәхнәләрендә эшчеләр, укучы яшьләр, кызылармеецлар алдында шигырьләрен укый. Шәһәрдә һәм авылда сыйнфый көрәш барган киеренке чорда язган «Йөрәк каны белән» исемле шигырендә лирик герой исеменнән:

Беләм мин:
Корбансыз җиңү юк.
Авырлыклар күрмичә,
Рәхәтләр күрү юк,
— ди автор.

Сиринның иҗади активлыгы башлыча егерменче елларның икенче яртысына, утызынчы еллар башына туры килә. Бу чорда матбугат битләрендә әледән-әле шигырьләре басыла, 1930 елда З. Гали сүз башы белән «Тамчылар» исемле беренче җыентыгы дөнья күрә. Аның аерым шигырьләре Ф. Бурнаш төзегән «Көрәш җырлары» (1923), «Октябрьнең ун еллыгына безнең бүләк» (1927), «Тәзү көннәрендә» (1929), «Безнең яшьлек» (төзүчесе Ф. Кәрим, 1934) исемле җыентыкларда басылган.

Сиринның балалар әдәбиятында уңышлы эшләгәнлеген аеруча күрсәтеп үтәргә кирәк, 1931—1932 елларда аның кече яшьтәге балаларга адресланган «Тимер юл», «Җиләк бакчасы», «Трамвай ник туктаган», «Бә-ә-ә дә мә-ә-ә», «Кыш», «Яз», «Җәй», «Көз» дигән рәсемле китаплары басылып чыга.

Бөек Ватан сугышы вакытында Сирин фронтта булды, анда каты контузияләнеп кайткач, колхозда умартачы булып эшләде.

Сирин 1969 елны 73 яшендә вафат булды, район җәмәгатьчелеге катнашы белән Баулы эшчеләр поселогы зиратында хөрмәтләп күмелде.

Сугыштан соңгы чорда Сиринның «Шигырьләр» китабы 1959 елда, аерым әсәрләре «Татар поэзиясе антологиясе» (1956), «Татар балалар поэзиясе антологиясе» исемле (1979) җыентыкларда басылды.

**Сафа САБИРОВ.**

**Габделхак Кудашев**

# ХӘСӘН ТУФАН — СТУДЕНТ

Хәзерге «Совет» гостиницасы бинасына урнашкан Татарстанның Үзәк крестьян йорты 1924 ел көзендә Казан вузларына укырга килгән абитуриентлар торыр өчен үзенең бер зур бүлмәсен биргән иде. (Ул елларны вузларда укулар октябрьдә башланды, ә керү имтиханнары сентябрьдә үткәрелде).

Көнчыгыш педагогия институтына керер өчен Казанга килгәч, мин бер айдан артыграк шушы бүлмәдә тордым, шунда Хәсән Туфан белән таныштым. Ул да шул ук институтка керү нияте белән Уралдан Казанга килгән иде.

Бүлмәдә яшәүче абитуриентлар тормыш күргән зур яшьтәге кешеләр, Хәсән алар арасында яшь егет — ул вакыт аңа бары 23 кенә яшь иде. Ләкин, үзенең яшьлегенә карамастан, ул авыр тормыш кичергән өлкән яшьтәге кеше кебек салмак, уйчан: сүзен ашыкмый, урынына җиткереп сөйли, кеше сөйләгәнне игътибар белән тыңлый, бер дә кычкырып көлми — җиңелчә генә елмаеп куя.

1924 елның көзе бик матур, кояшлы, җылы булды. Ләкин бүлмәдәге абитуриентларны көннең матурлыгы, кояшның җылылыгы да кызыксындырмады. Алар имтиханнарга әзерләнделәр, «укырга кереп булырмы?» дип борчылып яшиләр иде. Билгеле, Хәсән белән без дә борчылабыз: аз сөйлибез, күп укыйбыз, һәркөн институтка консультацияләргә йөрибез.

Югарыда искә алынган бүлмәдә торган вакытта крестьян йортында юрисконсульт булып эшләүче Сәрвәр Әдһәмова Хәсән янына еш кына кереп утыра һәм аны кунакка да чакырып китә иде. Вакыты бик санаулы булуга карамастан, Хәсән аларга барып йөрде. Безнең карашыбызча, Казанга килүенең беренче көннәрендә Кави Нәҗми семьясы Хәсәннең беренче танышларыннан, якын дусларыннан булды.

Крестьян йортында торган вакытта Хәсән янына кечкенәрәк гәүдәле, ачык йөзле, гаять хәрәкәтчел, 14-15 яшьләр тирәсендәге Луиза Салигаскарова дигән кыз килеп йөрде. Бу кызны Хәсән ачык йөз белән каршы ала, аның белән туганнарча мөгамәлә итә, аны чәй белән сыйлый, чәйдән соң озата да чыга иде. Башта Луиза рабфакка укырга кергән иде, Хәсәннең киңәшен тыңлап, ул рабфактан театр техникумына күчте. Билгеле булганча, соңыннан алар өйләнешеп, тормыш кордылар. Хәсәннең Луизага багышлап, тирән хисләр, көчле сагынулар белән язылган шигырьләренә таянып, без бу семьяда саф мәхәббәт, рухи дуслык хөкем сөрде дип әйтә алабыз.

Борчылулар артта калды: тиешле сынауларны биргәннән соң, безне институтка кабул иттеләр. Хәсән институтның Көнчыгыш телләре, ә мин физика-техника бүлегенә укырга кердем. Безнең белән бер үк елны Гадел Кутуй да институтның рус теле бүлегенә укырга керде. Сүз уңаенда шуны да әйтергә кирәк: Көнчыгыш педагогия институтының физика-техника бүлегенә татарлардан мин икенче студент булып кердем. Институтның физика-техника бүлеген тәмамлап чыккан беренче татар студенты мин булдым.

1924 елны Көнчыгыш педагогия институтына керүчеләр күп булды. Аның 5 бүлегенә 200 гә якын студент алынгандыр. Институтка керүчеләр арасында илебезнең төрле өлкәләреннән килгән татарлар да шактый күп иде. Аларның күпчелеге Көнчыгыш телләре һәм табигатьне өйрәнү бүлекләренә керделәр.

1924—1925 уку елында Көнчыгыш педагогия институтының беренче курс студентлары бөтен бүлекләр өчен уртак план буенча укыдылар. Бу планга аерым бүлекләрдә үтелергә тиеш махсус фәннәрнең берсе дә кертелмәгән иде. Билгеле, бу хәл студентлар өчен күңелсез вакыйга булды.

Хәсән Туфанның Көнчыгыш педагогия институтында укыганда фамилиясе Кусыйнов иде. Ләкин студентлар аны фамилиясе белән атамадылар — Хәсән дип кенә йөрттеләр. Хәсән Туфанның студент вакытына караган бу истәлектә без дә аңа Туфан фамилиясен теркәмичә, Хәсән сүзен генә кулланырга булдык.

Укулар башлану белән, студентлар зур дәрт, көчле теләк белән лекцияләргә йөри башладылар. Хәсән — тырыш студент. Ул һәрбер лекциягә күңел биреп йөри, лекторның сүзләрен йотылып тыңлый, лекциянең кайбер урыннарын дәфтәргә язып ала, бүлмәгә кайткач, дәфтәргә язылганнарны каткат тикшереп, озак кына уйланып утыра иде.

Егерменче елларны Казан дәүләт университетының зур бер аудиториясендә Галимҗан Ибраһимов, Газиз Гобәйдуллин, Гали Рәхим һәм башка тел, тарих белгечләренең катнашы белән еш кына гыйльми җыелышлар үткәрелде. Бу җыелышларда шул чор өчен актуаль мәсьәләләр, фәнни яңалыклар буенча докладлар ясала, фикер алышулар була иде. Көнчыгыш педагогия институтындагы татар студентларының күбесе бу җыелышларга йөрделәр. Хәсән бу җыелышларның берсен дә калдырмады. Ул алгарак, докладчыга якынрак урнашырга тырыша, доклад һәм чыгышларны зур игътибар белән тыңлый, җыелышта әйтелгән кайбер фикерләрне дәфтәренә язып та куя иде.

Институттагы лекцияләргә йөри башлагач, Хәсән Гадел Кутуй белән дуслашып китте. Алар Икенче тау (хәзерге Волков) урамында бүлмә алып, бергә тора башладылар. Мин дә алардан ерак түгел, арзан гына бер бүлмәгә күчтем, аларда еш кына була идем.

Алар торган квартирны мин түбәндәгечәрәк күз алдына китерәм: стенага ябыштырылган кәгазь искереп каралган, кечкенә ике тәрәзәле зур һәм тәбәнәк бүлмә. Бүлмәнең бөтен җиһазы, — ике тимер карават, тәрәзә каршына куелган зур өстәл һәм өстәл янындагы ике урындыктан тора иде. Болардан тыш, бүлмәнең нәкъ уртасында өстенә клеенка ябылган, эченә газета, журнал, китаплар тутырылган ящик. Ящик өстендә кысып кына яндырылган керосинка утыра. Керосинка өстендәге корымлы чәйнектә җылымса чәй өзелми. Хуҗалар эш арасында шул чәйнектән чәй агызып, аяк өстендә генә тамак ялгап алалар.

Бу квартирда торганда, хуҗалар минутларын санап яшәделәр: алар өзлексез укыйлар я язалар иде. Вакытлары бик санаулы булуга карамастан, килгән кешеләрне алар ачык йөз белән каршы алдылар. Кунакка корымлы чәйнектән чәй бирәләр, өстәлдә чәчелеп яткан каты конфетны кулына тоттыралар; кунак та мәсьәләне аңлый; чәй эчкәндә йомышын йомышлап китәргә ашыга иде. Бу квартирда тел кашып, юкны бушка бушатып утыру гадәте булмады.

Хәсән белән Кутуйның холык-фигыльләрендә зур аерма бар иде: Кутуй һәрвакыт шат, көләч йөзле, тиз уйлый, тиз эшли, уен-көлке, шаян сүзләр сөйләргә дә ярата. Ә Хәсән, югарыда күрсәтелгәнчә, гаять салмак, уйчан, уйлап сөйли, уйлап эшли, уен-көлке сөйләргә яратмый иде.

«Холык-фигыльләре төрле, хәтта капма-каршы булган бу ике яшьне нәрсә якынлаштырды, нинди җирлектә дуслашып, алар бергә тордылар икән?» кебек сорау туарга мөмкин.

Безнең карашыбызча, Хәсән дә, шулай ук Кутуй да, яшьтән үк белем алу, гыйльми карашларын киңәйтү теләге, илгә-халыкка хезмәт, яшь буынны тәрбияләү дәрте белән янып яшәделәр. Шушы җирлектә алар очраштылар, гаять авыр шартларда да рухи сафлыкларын саклаган хәлдә яшәделәр.

1924 елның көзендә Көнчыгыш педагогия институтында беренче тапкыр татар телендә стена газетасы чыга башлады. Бу газетаны чыгаруда Хәсән белән Кутуй да актив катнаштылар. Кутуйның тәкъдиме буенча, газетага «Укы — төзе» исеме бирелде.

Хәзерге көндә теге яки бу уку йортында стена газетасы чыгару бик кечкенә мәсьәлә булып тора. Ләкин ул елларны тормыш бөтенләй башка иде. Ул елларны газета язар өчен кирәк булган зур үлчәмле яхшы сыйфатлы кәгазь, төрле төстәге буяу, каралар да хәзерге кебек кибетләрдә тулып ятмый, аларны төрле оешмалардан эзләп алырга кирәк була иде. Аннан

соң ул елларны стена газеталарын яхшы итеп эшли белүчеләр дә сирәк иде әле. Кутуйның тырышлыгы, тапкырлыгы аркасында, «Укы — төзе» һәрвакыт кирәкле материал белән тәэмин ителде. Стена газетасы эшләүдә Хәсән бик оста кеше булып чыкты. Газетаның беренче санын тулысынча ул язды, ә башка студентлар газетаны төрле төстәге буяулар белән бизәделәр. 1924-25 уку елында «Укы — төзе» газетасы даими рәвештә ике атнага бер мәртәбә чыгып килде. Уку елы дәвамында 12 сан газета чыгарылды, аларның һәрбер санында Хәсән актив катнашты.

«Укы — төзе» газетасы институтның төрле бүлекләрендә укучы татар студентларын оештыруда, аларны җәмәгать эшләренә тартуда әһәмиятле фактор булды. Институттагы татар студентларының күпчелеге газетаны оештыруда, аңа язышуда еш катнашты. Газета редакциясенә кулъязмалар күп керә иде, аларны грамматик һәм стилистик яктан эшкәртү, башлыча, Хәсән белән Кутуй тарафыннан башкарылды.

Хәзерге кебек күз алдымда: зур өстәлгә җәелгән зур табаклы кәгазь. Хәсән газета эшли. Өстәлнең икенче ягындагы кызлар, көлешә-көлешә, газетаны бизиләр, шаян сүзләр белән Хәсәнгә дә кагылалар. Хәсән әллә ишетми, әллә ишетеп тә игътибар итми: ашыкмый гына җөмләне язып бетерә дә, калын итеп нокта куя. Башын кырынрак салып, үзенең язуына сокланып тора да яңа җөмләне язарга керешә.

Көнчыгыш педагогия институтында Хәсән бер генә ел укыды. 1925 елның көзендә ул танылган педагогларыбыздан Габдрахман ага Рәфыйков директорлык иткән Бишбалта мәктәбендә укыта башлады.

Институттан китүен Хәсән үзенең тел, әдәбият белән ныклап шөгыльләнергә теләве, институт программасындагы тел, әдәбиятка бәйләнеше булмаган фәннәрнең бу теләкне үтәргә уңайсызлык ясаулары белән аңлатты. Ул тел, әдәбият буенча белемен күтәрү өчен иң кирәкле хезмәтләрне алып, үзлегеннән укырга теләп, институтта укуын ташлады.

Хәсәнгә Туфан фамилиясе кайчан һәм кем тарафыннан беркетелүе безнең өчен бик үк ачык түгел. Хәер, шагыйрьнең 1964 елда басылган китабына профессор Хатип Госман язган кереш сүздә Хәсәннең бабасының кушаматы Дуфан булу әйтелә. Шагыйрь «д» авазын «т» белән алмаштырып Туфан фамилиясе ясаган икән. Ләкин ничек кенә булса да, бу фамилия Хәсәннең зур талантын дөрес чагылдыра иде. Хәсән Туфанның шигырьләре көчле ташкын (туфан) рәвешендә илгә таралды, күңелләргә, йөрәкләргә тулды; телебездәге шигырь жанрына яңа сукмак салды, әдәби телебезнең алга барышына, камилләшүенә гаять зур өлеш кертте.

1925 елдан башлап, Хәсән халкыбызның танылган язучы, шагыйрьләре белән катнашып китте, аның шигъри таланты ачылды, ул шагыйрь булып танылды, аңа Туфан фамилиясе ныклап беректе.

1925 елның көзеннән безнең бүлеккә күп санда махсус фәннәр кертелде, уку, укыганны үзләштерү дә авырлашты. Дәресләр, йөкләмәләр берсен-берсе куалап, үкчәгә басып килделәр — кунакка йөрергә вакыт җитмәде. Хезмәт юлларыбыз төрле булганлыктан, Хәсән белән дә сирәк очраштык. Ләкин көчле давылларда сынмаган, авыр юлларда егылмаган — кешелек сыйфатын, рухи сафлыгын саклаган Туфанга без соклануй яшәдек, аңа зур ихтирам белән карадык.

Инде менә безнең институтка керү өчен борчылып, кергәннән соң шатланып йөрүләргә дә 63 ел вакыт үтеп китте... Безнең кордашлар картайды. Күпләр дөнья калдырды...

Миңа да хәзер 92 нче яшь. Шуңа күрә беркая да чыга алмыйм, өй эчендә генә йөрим. Күп уйлыйм, очрашкан кешеләрне, таныш-белешләрне күздән кичерәм. Яшь Хәсән еш кына күз алдына килә: ул, элеккечә, игътибар белән карап тора. Нәрсәдер уйлаган, нәрсәдер әйтергә теләгән сыман!..

библиография

## Конкурс дәвам итә!

*Узган ел «Казан утлары» журналы иң яхшы рецензияләргә ачык конкурс игълан иткән иде. Конкурс 1987 елның декабренә кадәр дәвам итә.*

*Рецензия язу өчен татар язучыларының татарча яисә бүтән телдә басылып чыккан проза, поэзия, драма, очерк, әдәби тәнкыйть һәм балалар өчен булган китапларын яисә аерым әсәрләрне алырга мөмкин. Рецензияләрнең күләме машинкада 8-10 биттән артмаска тиеш. Иң яхшы рецензияләр өчен түбәндәге бүләкләр биреләчәк: I бүләк — 200 сум (берәү); II бүләк — 150 сум (икәү); III бүләк — 100 сум (икәү).*

*Конкурска язучыларның, тәнкыйтьчеләрнең һәм киң катлау укучыларның катнашуын телибез!*

# ГАЙРӘТ, АКЫЛ, ГЫЙБРӘТ

Мөсәгыйт Хәбибуллинның «Кубрат хан»[1] романы безнең татар совет әдәбиятында күтелмәгән вакыйга булды. Халык ябырылып укый шул әсәрне! Бәхәсләр, рәхмәтләр...

Көтелмәгән түгел, бик табигый хәл бу. Халкыбызның күптәнге рухи ихтыяҗы бу. Чөнки аның канына, җанына сеңгән: гыйбрәт, сабак алыр өчен, соңрак үзенең нәселен белер өчен халык әледән-әле үткәннәргә борылып карый. Гадәти көндәлек тормышыбызда да «җиде бабаңны белү» йоласы зарур әдәп кагыйдәсе буларак яши. Әмма кызганыч: ватан җанлы, үзенең шөһрәтле-мәртәбәле тарихына тугры җанлы шушы халык, мәгълүм сәбәпләр аркасында, шәҗәрәсен, ерак бабалары кылган данлы, шанлы, игелекле зур эшләрне, дәһшәт-фаҗигаларны озын-озак чорлар буена юньләп белә алмаган. Реаль тарихи елъязмалар, чыганак документлар исә киң халык массаларына тиешенчә җиткерелмәгән. Әйтик, Шәрыкнең, болгар-татар халкының зур прогрессив эшләр кылган вәкилләре, гамәлләре турында Шиһаб Мәрҗани, Риза Фәхретдинов, Газиз Гобәйдуллин кебек тарихчы галимнәр язган хезмәтләрне уку бәхетенә ирешүчеләр әле дә күп түгел...

Дөрес, халкыбыз үзенең тарихын, аның гыйбрәтле вакыйгаларын, үзе яраткан, идеал иткән шәхесләрнең язмышларын җырларда, бәетләрдә, дастаннарда, риваятьләрдә бик кадерләп сакларга тырышкан. Ләкин шул үткәннәрне конкрет дәлилләп, гомумиләштереп, тиешле нәтиҗә-хөкем чыгарылган фәнни хезмәтләргә дистә-дистә буыннар мохтаҗ булган...

Бәлки татар әдәбиятында тарихи жанрның бары XX йөз башында гына «тәпи йөреп киткәнлеген» югарыда әйтелгән сәбәпләр белән аңлатырга кирәктер?! Европада һәм рус әдәбиятында исә тарихи жанр XVIII йөздә үк үсә башлый, ә XIX гасырның беренче яртысында инде безне әле дә сокландырырдай гүзәл әсәрләр дисталәп тудырыла. В. Шекспир, В. Скотт, Стендаль әсәрләрен яки А. Пушкинның «Борис Годунов»ын гына искә төшерик... Тарихи жанрның кагыйдә-кануннары, теоретик таләпләре дә Европа һәм рус әдәбиятында шул чорда ук күп акыл ияләренең хезмәтләрендә язылган. Безгә Шекспирның ук "всякому веку и сословию — его подобие и отпечаток" дигән чакыруы, Буалоның, Дидроның бу жанрга карашлары, Гегельнең «Эстетика»сы, Стендальнең «Мәхәббәт турында»гы трактаты, В. Белинскийның В. Скотт, А. Пушкин иҗат иткән тарихи әсәрләргә сокланып, олы бәя бирүе билгеле. Ә татар әдәбиятында бу жанр, кабатлап әйтергә мәҗбүрбез, соңлап, шактый соңлап үсенте чыгарган шул. Нишләмәк кирәк, халкыбызның «Соң булса да — уң булсын» дигән сабыр киңәшен тотыйк...

Тарихчыларыбыз хезмәтләрендә Идел-Кама буендагы Болгар дәүләтенең тарихы халкыбызга шактый тәфсилле һәм дәлилле бәян ителде. Әмма болгарлар каян килеп чыккан соң бирегә? «Кубрат хан» романында сурәтләнгән географик киңлекләрнең, төбәкләрнең ерак үткәннәрен генә искә төше-

[1] Хәбибуллин М. Кубрат хан. Казан. Татарстан китап нәшрияты, 1985.

реп уйлансак, тарихның политик-экономик, социаль көрәшләр дулкыны, йолалар, әхлаклар, телләр, диннәр өчен газават дулкыны булуына инанырбыз.

«Кубрат хан» романы, минемчә дә, язучы Мөсәгыйт Хәбибуллинның чын-чынлап иҗат фидакарьлеге! Күп кенә әдәбиятчы, тарихчы галимнәр һәм шулай ук укучыларыбыз бәяләгәнчә, «Кубрат хан» — чынлап та заманыбыз культурасы таләпләренә җавап бирердәй киң полотнолы роман. Әсәрнең нигезендә тарихи, политик-иҗтимагый, әхлакый дөреслек, конкретлык ята. Язучы Бөек Болгар илендәге сәясәтне, халыкара һәм дипломатик мөнәсәбәтләрне шактый объектив, дөрес сурәтли. Төрки халык белән Византиянең шул чордагы прогрессив та, хәйләкәр-мәкерле дә булган мөнәсәбәтен, Кытай һәм Византия императорларының төрки халыклар көчәюдән куркып, аларны бер-берсенә каршы котыртып, яшәүләрен, һәр дәүләтнең куәтле идея-иман коралы булып әверелачәк диннәр өчен газаватларның (көрәш-сугышларның) нәкъ менә VII гасыр башында көчәеп китүен без башка чыганаклардан да укып беләбез.

Яки менә романда телгә алынган башка бер-ике тарихи дәлилгә генә игътибар итегез. Автор Бөек Болгариянең башкаласы булган Фанәгүргә яки хәзәрләр иленә яһүдләрнең килеп тулуларын хәбәр итә. Диннәр тарихында да билгеле бу хәл. Чөнки бу чорда инде (аеруча Византиядә) шактый куәтләнеп җиткән христиан дине яһүдләрне хыянәттә гаепләп кыса, иллардән сөрә, аса, кисә, яндыра башлый. Янәсе, яһүдләр изге Марьям ана белән алланың үз улы булган Гайсаны, башта ук әле аларның үз патшасы, үз яклаучысы булырга ниятләгән Иисус Христосны властьларга сатып, тәре баганасына кадаклатканнар...

Менә автор Хорезм шаһының хәзәр-төрекләргә булышуын хәбәр итә. Дипломатия тарихында монысы да билгеле. Гомумән, әдип ул чорның катлаулы, чуар тарихын, илләрнең ыру-кабиләләрнең этнографиясен бик тырышып өйрәнгән, әлеге искиткеч бай хәзинәдән үз идея-максатына яраклысын сайлап алып, кыю рәвештә ышанып иҗат иткән.

Тарих һәм шәхесләр мәсьәләсендә автор, В. Скоттның, А. Пушкинның, А. Толстойның һәм башка тарихчы-әдипләрнең матур традицияләрен онытмыйча, бик аек, материалистик һәм диалектик караштә тора. Көчле шәхес белән халык арасындагы мөнәсәбәт, көчле шәхеснең җәмгыятьтәге, тарихтагы роле мәсьәләсендә дә әдип дөрес позициядә тора. Гайрәтле кырыс та, зирәк акыллы да хөкемдар, юлбашчы, нечкә политик-дипломат, батыр һәм тәвәккәл яу башы Кубрат хан «һәр мәзәктән... тәм табып, күңел ачып яшәгән, дәүләт эшләрен тулысы белән логофетына тапшырган», икейөзле, шәфкатьсез, азгын, үзсүзле император Ираклийдан бөтенләй аерылып тора. «Муенга тавык тәпие тагып кына халыкны буйсындырып булмый, философ... Халкым үз итсә, миңа беркем дә куркыныч түгел»,— ди Кубрат хан. Яки менә бер өзеккә генә игътибар итик.

— Философ, әйт әле, кем ул кол?

— Борынгы греклар колны сөйләшә белгән ике аяклы хайван дигәннәр, олуг хан.

— Иоанн Фасиан, бабаларың бик яман кеше булганнар. Кол ике аяклы хайван, имеш... Төркидә кол зур хокукларга ия, философ. Ул өйләнә, җәйләү ала, алып булып орыша ала. Мин үземне халкымның колы итәр идем, философ.»

Икенче бер урында Кубрат хан:

«— Мин тәңре дә, пәйгамбәр дә түгел, Философ. Тәңре — күктә, мин — җирдә, халкым белән»,— ди. һәм Кубрат ханның бар кылган гамәлләрендә без аның сүзе эштән аерылмавына ышанабыз. Әйе, бу көчле шәхес беренче чиратта нәкъ менә иле, халкы мәнфәгатен кайгыртуы, дәүләтнең куәтен, бердәмлеген ныгытырга тырышуы белән көчле. Шул шәхес йогынтысында хәтта император шымчысы Фасианның да тирән уйларга бата-бата, якты эволюция кичерүенә ышанабыз без. Шул халыкчан хөкемдар үстергән Аспарух, Балкыр, Кодрак илханнарның да көрәш-орышларның һәрвакыт хәлиткеч алгы сызыкларында булуларына ышанабыз. Әнә, ил-көн язмышы хәл ителәчәк хәтәр чакта, хәтта Кубратның сөйгән хатыны Аппак та Бөек Болгар әләмен күтәреп яу кырына ташланды, халыклар язмышы хакына гүзәл кызы Чәчкә һәлак булды...

Без дистә еллардан артык инде әдәбиятыбызда олы җанлы, киң карашлы, көрәшче-каршылыклы дәү, монументаль образлар тумавыннан зарланабыз шикелле. һәм бу хаклы да иде. Әмма, шөкер, шул еллар агымында, әнә, драматург Туфан Миңнуллин үзенең легендар карты Әлмәндәрне сәнгать мәйданына, халык күңеленә чыгара алды. Прозаик Мөсәгыйт Хәбибуллин исә бу романында, гомумән, монументальлеккә омтылган, әле озак еллар ерактан ук күренеп торачак ныклы кыялар яулый алган дисәк, ялгышмабыздыр. «Артык дәү гәүдәле, чәч-сакалы агара башлаган, алтын җепләр белән аралаштырып тегелгән рум чапаны кигән Кубрат хан торып баскач, барысы да үзләрен кечерәеп калгандай хис иттеләр». Әмма Кубратның монументаль образ булуы аның портретында гына түгел, әйткәнебезчә, әсәрдә бик дәлилле һәм якты сурәтләнгән гамәлләрендә. Язучы хәтта Александр Македонский да бәйләнергә курыккан амазонкалар нәселеннән булган кыю, акыллы ханша Аппакның, гаҗәп җегәрлебулдыклы да, бар төркиләр бердәмлегенә, аларның кояшына-күгенә фанатик тугры да,

хәйләкәр-мәкерле дә булган йола башы Ирсанның, гыйлем-акыл иясе Фасианның, шымчылар башы — алостаз-Дәянның индивидуаль портрет-образларын тудыра алган. Якты монументализмга омтылып, автор хәтта байтур Илбарысның героик образын кай ара идеаллаштырып та җибәрә сыман.

Безне ерак бабаларыбызның әдәпле, эшкә уңган, һөнәргә оста аек акыллы, киң күңелле интернационалистлар булуы аеруча сөендерә. Бу тарихи чынбарлык әсәрдә дә матур һәм дәлилле чагыла, башка ыру, башка халыкларның вәкилләре булган укытучы Константинның, грек уты остасы Симокатта-Симай атаның, тимерче-шымчы Агасикенең, төрки мәргәне Ташбулатның, тәвәккәл, елгыр, әмма бик тә хисле-самими һөнәрче Дәниснең образлары озакка хәтердә кала.

Басым ясап әйтәсе килә: язучы Мөсәгыйт Хәбибуллин персонажларының мәхәббәтен, психологиясен сурәтләгәндә дә, Стендаль таләп иткәнчә, «тарихчы һәм политик» булып калырга тырыша. һәм шуңа ирешә дә алган.

Әсәрдә тарих сабакларын бүгенге көннең-җирнең иң актуаль проблемалары белән бик табигый бәйләгән идея-фикерләр дә аз түгел. Әйтик, менә байтур Илбарысның орыш-сугышлар турында ачынып уйланулары...

«Орыш һәрчак баланы анадан, туганны туганнан, атаны улдан, улны анадан, сөйгәнне сөйгәннән, хатынны ирдән аерды. Кеше дөньяга кылычтан, уктан үләр өчен килми, ямьле кояш астында гомер итәр өчен килә...»

Яки менә грек философы Фасианның уйкичерешләр нәтиҗәсе: «...Болгарга килгәч, мин бер нәрсәгә инандым, олуг хан нинди телдә генә сөйләшмәсен, нинди йолага гына табынмасын, һәр халыкта акыл ияләре бар, һәр халыкның мөстәкыйль дәүләт төзергә хокукы бар...» Кубрат аңа болай дип җавап бирә:

«— Син хаклы, философ. Кеше нинди генә телдә сөйләшмәсен, нинди йолага гына табынмасын, аның күңеленә ышаныч, бары тик ышаныч аша гына якынаеп була, ышанычның теле бер — дуслык».

«Кубрат хан» романындагы тарихи-милли колорит, аның тел хәзинәсе, структурасы турында киләчәктә дә бәхәсләр булыр. Мөсәгыйт Хәбибуллин кайчандыр төркиләр телендә булып та, заманнар йогынтысында төшеп калган дистә-дистә сүзләрне тарихи контекстта янә ялтыратып-балкытып җибәрә яки үзе үк «алостаз», «алимче», «истәлекче», «каравылбаш», «илтотар», «албагар» кебек күп кенә яңа атамалар ясый. Арада гаҗәп кулай, тәэсирле, матурлары бар. Ләкин әсәрне башка телләргә тәрҗемә иткәндә «төптәңре» атамасын үзгәртергә кирәк. Чөнки хәзәр-болгарларда төптәңре, Хан Тәңре — ходай ул үзе, ә аның җирдәге илчесе дип саналган йола башы «бахши» дип йөртелгән. Хәзәр-болгарлардагы әләмнең төсе дә башка күчмә халыклардагы кебек зәңгәр булмавын, бәлки тарихи документлар раслаганча, аланнардан калган төстә — кызыл булуны истә тотыйк.

Әсәр уйларны аргы тарихи чор, вакыйгаларга да алып китә, гүя, романда гәүдәләнгән акыл ияләре — философ Фасиан белән бахши Ирсанның юраганнары юш килә. Кубрат хан үлгәч тә аның, автор ишарәләгәнчә, «тәңре... акылын кимрәк иткән, кызганган» улы Батбай үзенең энесе — «кара сакаллы, тутсылрак йөзле зәңгәр күзле» илхан Аспарух белән җәйләү-биләмәләр өчен талаша башлый, атасының «бердәм булган — береккән» диган васыятен тотмый. Ә хәзәр-төрекләргә исә шул гына кирәк... Беренче Бөек Болгар иле таркала.

Әмма Аспарух илхан нәсел горурлыгын җуймый, янә куәт туплап, Дунай буйларына юнәлә, Византия императоры Константин Погонатның гаскәрен тар-мар итеп, Добродҗу каласын ала, славяннарны румнар изүеннән коткара. Хәзерге социалистик Болгариянең шәҗәрәсе әнә шуннан башлана, мөгаен...

«Акылы кимрәк» булган Батбай исә үз җир-биләмәләре, алае белән хәзәрләргә баш иеп яши. Илтуар бәкнең үз ризалыгы белән үк албан епископы Исраил җитәкчелегендә хәзәрләрне шәфкатьсез чукындыру башлангач, болгарлар дулкын-дулкын булып Кубрат ханның икенче тугыр улы Кодрак биләмәләренә — Иделнең өске агымына, Кама-Чирмешән буйларына күтәреләләр. Тарихта мәгълүм яңа дәүләт — Идел-Кама буендагы икенче Бөек Болгар иле күтәрелә...

Шул олы вакыйгалар, чорлар турында да, бу дәүләт-илнең казанышлары һәм фаҗигасы чагылдырылган яңа әдәби әсәрләр языла әле дип өметләнәбез.

**Фаяз ДУНАЙ.**

Брежнев шәһәре

# ӘКИЯТ ЧЫНЛЫГЫ

Быелтыр «Казан утлары» журналында (6-7 саннар) Батулланың «Алып батыр маҗаралары» исемле повесть-әкияте дөнья күрде. Батулла — төрле жанрда кызыклы әсәрләр язып, әдәбият сөючеләрнең мәхәббәтен яулаган автор. Беренче тапкыр әкият язуы да түгел. Ләкин, укып чыгуга ук, «Алып батыр маҗаралары» турында язмый калырга ярамый дигән фикер туды. Бу әсәр Батулла иҗатында әерым, мөһим урын алып тора, аның зур уңышларының берсе дип уйлыйм. Ни өчен дип әйтсәң, бу әсәрне укыганда үзеңне туган телебезнең, халкыбыз тарихының бәйрәмендә йөргән кебек хис итәсең. Һиҗри ел исәбенә таянган шаян хронологиядән башлап, йомшак юмор белән сугарылган маҗаралы вакыйгаларга кадәр, безне бу хистән әкият беткәнче аермыйлар. Ул кечкенә, тарихи, милли детальләр дисеңме, ул килешле, серле, шигъри исемнәр дисеңме — барысы да бу әкияттә табигый рәвештә кушылып, бөтен бер ямьле бизәк хасил итәләр.

Әдәби әсәрдә, бигрәк тә әкияттә, ишарәләр хакыйкате күзгә ташланып, ярылып ятмаска тиеш. Беренче сүзләрдән үк юнәлеше, адресы ап-ачык булган, серле, тирән акыллы, читләтеп әйтелгән аллегорик маҗаралар зирәклеге җитешмәгән әйберләрне уку кызык түгел. Чөнки, кем әйтмешли, без үзебез дә — ярыйсы гына китаплар укыган кешеләр, бөтен илебез белән белемлеләр. Без үзебез рухи көч куеп, уйланып, икеләнеп, шикләнеп, үз акылыбыз һәм үз карашларыбыз аша, һәр нәрсәнең асылына үзебез барып җитәргә тырышабыз...

Батулланың әкиятендә акыл эшчәнлеге өчен азык җитәрлек, хәтта артыгы белән... Артыгы белән дигәннән, Иблиснең Яхур патшаны алыштыруы безнең өчен әллә ни гаҗәп хәл түгел, чөнки кечкенәдән әби-карчыкларның «җен алыштырган» дип пышылдаулары колакка кергәләде. Үсә төшкәч, кызганычка каршы, тормышта да күргәләдек андый сәер үзгәрешләрне. Башта «җүнле генә» җан иясенә охшаган Җантык кандаланың җиңелгән явыз зат Ялмавыз кабыгына кереп, корткычлык кылып йөрүе дә аңлашыла, андый хәлләр белән дә таныш без. Инде килеп, менә Алып Бәргән белән Гыйфрит бер-берсен алмаштыралар. Булсын, алмашсыннар да ди. Әкияттәниләр булмас. Ләкин, шул урынны берничә тапкыр укып чыктым, ә кайбер сорауларга җавап тапмадым: «Кем кем булды да ни кылды? Ни өчен шулай булды да, бу нигә кирәк булды?» Батулла үзе бу алмашынып беткән геройларны, төрле этаптагы башваткыч әверелешләрне классификацияләп бетерде микән? Бәлки ул шушы урындагы вакыйгалар катлаулыгына тиз генә аңлашылмаслык олы мәгънә салгандыр? Мондый очракта әдәбият белгечләреннән шушы темага фәнни хезмәтләр көтеп калабыз... Ә миңа калганда, ямьле болын буйлап сикергәләп, уйнаклап аккан чишмә шикелле килгән әкият барышы бу урында әллә нәрсәгә әйләнә. Ярый әле, бу алмашыну озакка бармый, әкияттәге кебек, кире үз җаена, үзенең матур агымына кайта, ягъни яңадан үз-үзенә әверелә.

Төп герой — алып Бәргән — идеаль герой түгел. Ул безгә — гади халыкка якын. Ялгышлар да җибәргәли, көлке хәлләргә дә калгалый, җиңелүләр аша да үтә. Анда күпмедер өлеш Дон Кихот чалымнары да бар. Аты да аның «чәндер сыйраклы, кыска торыклы...» Юыртканда, «егетнең итеге башы юл кырыендагы чәчәкләргә тиеп-тиеп китә». Менә шундый, карап торышка, бераз елмаю тудыра торган батыр ул Алып Бәргән. Шулай шул — шәфкать, игелек эшләргә, җирне явызлыктан азат итәргә тырышкан фидакарьләрдән, кайвакыт, адәм көлкесе дә ясыйлар бит... Ләкин Алып Бәргән, күңеле төшеп, өметсезлеккә күмелеп, елак көчсезлеккә бирелми, ә үз юлын, батырлыгын дәвам итә. Ул — халыкның үзе.

Әсәрдә шигъри моң да, фәлсәфи югарылык та бар. Алып Бәргән сөтле арыш башагы белән тукланучы Ачәрвахка каршы сугыша. Ул бәрәкәтле, тыныч тормыш өчен мәңгелек көрәш символына әйләнә. Офыктагы Аҗаган безгә һәрвакыт шуны искәртеп торырга тиеш. Арышлар серкәләнә, Аҗаган уйный. Димәк, халык көрәшә, яши, тормыш дәвам итә.

...Мәкалә журналда басылып ятканда, «Алып батыр маҗаралары» китап булып та чыкты. Ләкин, тышлыктагы рәсемне күргәч, мин гаҗәпсенеп калдым. Анда Алып Бәргән урынына монгол йөзле бер егет ясалган. Ул безнең татар кешесенә бер дә охшамаган. Художник В. Павловның татар кешеләрен бөтенләй күргәне юк микәнни соң? Татарстан китап нәшриятының җаваплы хезмәткәрләре нәрсә караган?.. Шушындый яхшы эчтәлекле китапларны матурлабрак бирәп чыгарасы иде бит...

**Рәниф ШӘРИПОВ.**

# ШУШМА БУЙЛАРЫНДА



ФОТОХИКӘЯ

Сөзәк калкулыклар, тын инешләр, ярсу чишмәләр ягы. Аккаен һәм усаклар, юкә һәм өрәңгеләр, җитәкләшеп, җилгә арка терәгән, дистәләгән чакрымнарга сузылган урманнар төбәге. Күбәләк һәм бал кортлары уйнап, кошлар сайрап, шагыйрьләр җырлап туймаган чәчәкле болыннар, мул кырлар иле. Су буйларында кош-корт тавышы, буаларында балык уйный, бакчаларында алма шавы... Татарстанның иң төньяк почмагында урнашкан Арча районының «Северный» совхозы табигате күңелгә әнә шундый булып кереп калган.



Шулай да Шушма елгасының башланган җирендәге бу табигатьнең гүзәллеген аның хезмәт сөючә кешеләреннән аерып карау мөмкин түгелдер. «Северный» совхозы (директоры Таһир Минһаҗев, партия комитеты секретаре Илдар Хәлиуллин) менә ничә еллар инде Арча районында гына түгел, республикада иң зур һәм алдынгы хуҗалыкларның берсе санала. Мари урманнары итәгендә, Шушма елгасы буенда урнашкан Шушмабаш, Акчишмә, Ишнарат, Сәрдәбаш, Шекә, Носы, Илдус, Хатнә, Үгез-елга авылларында яшәүче игенчеләр 12 нче бишьеллыкның беренче елында бөртеклеләрнең һәр гектарыннан уртача 30,1 центнер, бәрәңгедән 225 центнер уңыш җыеп алдылар. Дәүләткә 7 мең тонна икмәк сатып, еллык планны 220 процентка үтәделәр. Терлекчелектәге күрсәткечләр дә елдан-ел үсә, күтәрелә бара. Барлык төр продуктлар сату буенча да еллык план үтәлгән. «Северный» совхозының бу уңышларында Социалистик Хезмәт Герое трак-










торчы Шәрифулла ага Сәгъдуллин, Кызыл Йолдыз һәм Октябрь Революциясе орденнары кавалеры комбайнчы Камил ага Латыйпов, балта остасы Габделхак Җаббаров, умартачы Илгизәр Гатауллин, яшь коммунист тракторчы Ибәтулла Гыйбадуллин кебек дистәләгән фидакарьләрнең өлеше бар. Табигате һәм кешеләре белән дә матур булган авылларда калучы яшьләр саны да артканнан-арта бара.

Җәүдәт **МИННӘХМӘТОВ** тексты,
Риф **ЯКУПОВ**, Виталий **ХАШЕВ** фотолары.



# *Культура тормышы көндәлеге*

## ЯШЬ КОМПОЗИТОРЛАР ФОРУМЫ

Казанда яшь композиторларның Бөтенсоюз фестивале һәм СССР Композиторлар союзының иҗат яшьләре белән эшләү буенча Бөтенсоюз күчмә комиссиясенең пленар утырышы булып узды. Беренче пленар утырышта яшь композиторларның Бөтенсоюз фестивалендә катнашучылар алдында КПСС өлкә комитеты секретаре Р. К. Беляев чыгыш ясады.

СССР Композиторлар союзы идарәсе секретаре А. В. Чайковский КПССның XXVII съезды һәм СССР композиторларының VII съезды карарлары яктылыгында яшь совет композиторларының бурычлары турында доклад белән чыкты.

Илебезнең төрле төбәкләреннән килгән йөзләрчә яшь талантлар — композиторлар, артистлар, музыка белгечләре 11-15 декабрьдә үзара аралашып, иҗат планнары белән уртаклашып яшәделәр. Музыка сәнгатен тагын да үстерү, аны халык массаларына якынайту чараларын билгеләделәр. Казан шәһәренең культура сарайларында үткән дистәгә якын концерт программаларында музыка сәнгатенең төрле жанрларына караган күп санлы әсәрләр башкарылды.

Бөтенсоюз комиссиясенең пленар утырышы эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнашты.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

20 ноябрьдә узган ачык партия җыелышында язучы Мәхмүт Хәсәновның иҗат отчеты тыңланды.

Танылган язучының әсәрләре турында тәнкыйтьче Фоат Галимуллин сөйләде. Фикер алышуларда язучылар Г. Бәширов, Л. Ихсанова, Г. Ахунов, Г. Сабитов, Р. Хәмид, Ә. Галиев чыгыш ясап, язучының иҗатына төпле анализ бирделәр.

## ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ

10 декабрьдә Казанның Актерлар йортында РСФСРның М. Горький, ТАССРның Г. Тукай исемендәге дәүләт премияләре лауреаты, Татарстанның халык шагыйре Сибгат Хәкимнең тууына 75 ел тулуга багышланган шигырь кичәсе булды.

Әдипнең иҗат һәм тормыш юлы турында язучы Гариф Ахунов сөйләде. Танылган артистка Галия Кайбицкая үзенең истәлекләре белән уртаклашты. Шагыйрьләр И. Юзеев, Ш. Галиев, Р. Гатауллин, Р. Миңнуллин С. Хәкимгә багышланган әсәрләр укыдылар.

Әдәби кичә республикабызның сәнгать осталары концерты белән тәмамланды. Аның программасы С. Хәким әсәрләреннән төзелгән иде.

Әдәби кичәдә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире Д. Х. Зарипова катнашты.

## СИРИННЫҢ ТУУЫНА 90 ЕЛ

10 декабрьдә Баулының М. Җәлил исемендәге культура йортында татар совет шагыйре Сиринның тууына 90 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булып узды.

Кичәдә Сиринның тормыш һәм иҗат юлы турында язучы Сафа Сабиров сөйләде, шулай ук шагыйрь Рәшит Әхмәтҗанов, язучы А. Хәсәнов, сынчы-рәссам Г. А. Зяблицев һәм шагыйрьнең замандашлары, туганнары Сирин турында истәлекләр сөйләделәр, аңа багышлап язылган әсәрләрен укыдылар.

Шундый ук кичә шагыйрьнең туган авылы Кәрәкәшледә дә узды.

Шагыйрьнең Баулы зиратындагы каберенә, аның сурәте төшерелгән обелиск куелды.

## ИҖАТ КИЧӘСЕ

Г. Тукай исемендәге Татар Дәүләт филармониясе, Татарстан Язучылар союзы белән берлектә, инде менә икенче сезон традицион «Шигърият кичәләре» үткәрә. Әлеге циклдан быелгы беренче очрашу 24 ноябрьдә Казанның С. М. Киров исемендәге Культура сараенда, танылган шагыйрь Нәби Дәүли иҗатына багышлап үткәрелде.

Кичәне, шагыйрьнең иҗаты турында кереш сүз белән, «Казан утлары» журналының җаваплы секретаре Салих Маннапов ачты.

Н. Дәүли әсәрләрен тамашачыларга танылган сәнгать осталары — А. Арсланов, И. Шакиров, Э. Җәләлетдинов, Р. Шәрәфиев, Х. Җәләлов, М. Галиев, Р. Сәхәбиев, Х. Тимергалиева, И. Биктаһиров, А. Фәйзрахманов, И. Әхмәтҗанов һәм М. Ибраһимов тәкъдим итте. Кичәдә шулай ук күренекле композитор, СССРның халык артисты Р. Яхин катнашты һәм чыгыш ясады. Режиссер Т. Юсупов әзерләгән бай әдәбимузыкаль программаны артистка А. Илһамова һәм Р. Сабиров алып барды.

## БАШКАЛАДА ӘДӘБИ КИЧӘ

24 ноябрьдә Мәскәүнең Метро төзүчеләр культура йортында татар әдәбияты кичәсе үткәрелде. Ул яңа дәвер беренче татар романы «Хисаметдин менла»ның (Муса

Акъегетзадә әсәре) язылуына һәм Мәхмүт Галәүнең тууына 100, Кави Нәҗминең тууына 85 ел тулуга багышланды. Әлеге язучыларның тормышы һәм иҗаты турында филология фәннәре кандидаты Г. Хантимерова, кранчы М. Минһаҗев, студент Р. Фәттаховлар сөйләде. Соңыннан биология фәннәре кандидаты Н. Нәбиев, инженер В. Зарипов, укытучы К. Таһирова, стенографистка М. Таһирова h. б. катнашында концерт булды.

## БРЕЖНЕВ ЯЗУЧЫЛАР ОЕШМАСЫНДА

17—26 ноябрьдә Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе драматург Туфан Миңнуллин, язучылар Аяз Гыйләҗев, Мөхәммәт Мәһдиев, Марсель Галиев Брежнев шәһәрендә һәм Тукай районында булдылар. Алар районның «Гигант» совхозы тормышы һәм эшләре белән таныштылар. 21 ноябрьдә кунаклар Брежнев шәһәре «Энергетик» культура сарае үзешчәннәре көче белән үткәрелгән «Уйныйк әле гармуннарда» исемле музыкаль кичәдә катнаштылар. 24 ноябрьдә Алабуга дәүләт педагогия институтының Брежнев филиалы студентлары белән булган очрашу да бик җанлы узды. 25 ноябрьдә язучылар Брежнев шәһәренең Вахитов исемендәге 2 нче номерлы татар урта мәктәбе укучылары һәм укытучылары белән, 26 ноябрьдә Тукай районы мәктәпләренең татар теле укытучылары белән очраштылар.

27 ноябрьдә Брежнев язучылар оешмасында «Ләйсән» һәм «Орфей» әдәби берләшмәсе членнарының берләштерелгән җыелышы үткәрелде. «Казан утлары» журналы редакциясе уздырган әлеге киңәшмәдә очерк, публицистика жанры турында җитди сөйләшү булды. Җыелышта «Казан утлары» журналының баш редакторы Ренат Харис катнашты һәм чыгыш ясады. Җыелышта шулай ук Брежнев язучылар оешмасы җаваплы секретаре Я. Игәнәй, шагыйрьләр — К. Сибгатуллин, Н. Мадьяров, Н. Алешков, Х. Хөснуллин, Л. Зөлкарнәев, прозаик Г. Кашапов, публицист Ф. Дунай һәм башка иптәшләр чыгыш ясады.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

24 ноябрьдә проза һәм тәнкыйть секцияләренең берләштерелгән утырышы булды.

Көн тәртибе итеп бүгенге роман турында сөйләшү куелган иде. Кереш сүз белән тәнкыйтьчеләр секциясенең председатель урынбасары Мансур Вәлиев чыкты.

Г. Ахунов ясаган доклад буенча фикер алышуларда язучылар һәм тәнкыйтьчеләр — М. Хәсәнов, Н. Фәттах, И. Нурулллин, Ә. Баянов, Ф. Миңнуллин, Р. Мингалимов, Р. Мөхәммәдиев, Р. Хәмид, Р. Низамиев h. б. катнашты.

Әдәби тәрҗемә секциясенең 1 декабрьдә булып узган утырышында Фирая Зыятдинованың иҗат отчеты тыңланды. Фикер алышуларда катнашкан К. Миңлебаев, Т. Нурмөхәммәтов, Г. Сабитов, Р. Вәлиева, Р. Миңнуллин, С. Шәмси h. б. иптәшләр яшь автор хезмәтләрен таләпчән анализлап, иҗади мөмкинлекләрен билгеләп үттеләр, киңәшләр бирделәр.

Секция утырышы Ф. Зыятдинованы СССР Язучылар союзына членлыкка тәкъдим итте.

## МУЗАЛАР ТУГАНЛЫГЫ

19 ноябрьдә Актерлар йортында «Музалар туганлыгы» дигән кичә үткәрелде. Ул Татарстан Язучылар союзы һәм Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге тарафыннан оештырылды. Кичә республикабызның яшь иҗат көчләренә багышланган иде. Анда яшь шагыйрьләр — Р. Зәйдуллин, Л. Зөлкарнәев, Г. Моратов, Л. Леронов яңа шигырьләрен укыдылар. Яшь башкаручылар композиторларыбызның җырларын, төрле уен кораллары өчен язылган әсәрләрен башкардылар. Казан театр училищесы студентлары спектакльләрдән өзекләр уйнадылар. Биредә яшь рәссамнарның әсәрләреннән күргәзмә дә оештырылган иде.

Кичәне язучы Роберт Батулла алып барды.

## ЯШЬ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘР ТҮГӘРӘГЕНДӘ

«Казан утлары» журналы каршындагы яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәге үзенең эшен яңартты. 14 ноябрьдә булган аның беренче утырышын кереш сүз белән журналның баш редакторы Ренат Харис ачып җибәрде. Яшь тәнкыйтьчеләр яңарыш чоры таләпләреннән карап, татар әдәби тәнкыйте алдында торган бурычлар турында фикер алыштылар. Түгәрәкнең икенче утырышы 27 ноябрьдә узды.

## ВОЛГОГРАД ӨЛКӘСЕНДӘ

20—23 сентябрьдә шагыйрьләр Нәби Дәүли һәм Рәшит Әхмәтҗанов Волгоград өлкәсендә иҗади командировкада булып кайттылар. Алар герой-шәһәр Волгоградта, Светлоярск районында урнашкан татар авылларында булдылар. Шул ук районның Чапурники авылына нигез салынуга 200 ел тулуга багышланган тантанада катнаштылар. Тантана уңае белән авылның үзәк урамына татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай исеме бирелде.

Шагыйрьләр районның әдәбият сөючеләре, яшь иҗат көчләре белән очраштылар, әдәби кичәләрдә үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

## ОНОМАСТИКАГА БАГЫШЛАНДЫ

23—25 сентябрьдә Фрунзеда төрки ономастикасы буенча I Бөтенсоюз конференциясе булып үтте.

Бу конференция эшендә илебезнең төрле шәһәрләреннән (Мәскәү, Ленинград, Алма-Ата, Ашхабад, Баку, Казан, Кызыл, Карачаевск, Кишинев, Ташкент, Тбилиси, Уфа, Чебоксар h. б.) 180 ономастик-тюрколог катнашты.

Конференциянең пленар утырышында атаклы совет ономасты В. А. Никонов

(Мәскәү) «Ономастикада марксистик-ленинчыл принципларның сафлыгы өчен», танылган топонимист-географ профессор Э. М. Мурзаев (Мәскәү) «Төрки этнотопонимнар», күренекле язучы, Ленин премиясе лауреаты Чыңгыз Айтматов (Фрунзе) «Географик атамаларда һәм кеше исемнәрендә — халык тарихы һәм гореф-гадәтләре» дигән һ. б. темаларга тирән эчтәлекле докладлар ясадылар.

Конференциянең секцияләрендә Татарстаннан профессор Г. Саттаров «Татар фамилияләрен өйрәнүнең тел тарихын, халык тарихын һәм этногенезын тикшерүдәге әһәмияте», Л. К. Таҗиева «Татарларга гарәби чыгышлы кеше исемнәренең керүе һәм үзләштерелүе», А. Ю. Филькова «РСФСРда төрки чыгышлы шәһәр атамалары» һәм Р. И. Куряева «Урта Идел буендагы рус авыллары атамаларында төрки сүзләр» дигән темаларга фәнни доклад ясады.

## ТАТАРСТАН КОМСОМОЛЫНЫҢ М. ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ПРЕМИЯСЕ ЛАУРЕАТЛАРЫ

ВЛКСМ өлкә комитеты бюросы Татарстан комсомолының М. Җәлил исемендәге премияләре комиссияләренең тәкъдимнәрен тикшергәннән соң, әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә түбәндәге кандидатларга лауреат исемнәрен бирде:

Ибраһимова Р. М.— совет халкының Бөек Ватан сугышында җиңүенең 40 еллыгына багышланган концерт программасы һәм 1984—86 еллардагы концерт эшчәнлеге өчен.

Казан дәүләт консерваториясе квартеты — 1984—86 еллардагы концерт эшчәнлеге һәм яшьләрне эстетик тәрбияләүдәге зур хезмәтләре өчен.

Бохараев Р. Р.— шагыйрь һәм тәрҗемәче, М. Җәлил һәм Г. Тукай әсәрләрен русчага тәрҗемә иткәне өчен.

Казан шәһәренең А. Алиш исемендәге Пионерлар сараеның балалар хоры — яшьләрне эстетик тәрбияләүдәге зур хезмәтләре һәм балалар хоры сәнгатен үстерүдәге уңышлары өчен.

Казан шәһәре Вахитов районының «Факел» техник иҗат клубы — яшьләрнең ялын оештырудагы һәм яшүсмерләрнең техник иҗатын үстерүдәге эшчәнлеге өчен.

Түбән Камадагы 16 нчы мәктәпнең социаль-педагогик комплексы — яшәү урыннарында яшьләрнең һәм хезмәт ияләренең ялын оештыру буенча нәтиҗәле эшләве өчен.

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен СССР Язучылар союзы члены, Әлмәт районы, Түбән Мактаманың 2 нче урта мәктәбе укытучысы Булатова Клара Гарифовнага, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 30 октябрь Указы нигезендә «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

Һәвәскәр халык иҗатын үстерүдәге һәм хезмәт ияләренә эстетик тәрбия бирүдәге хезмәтләре өчен Сарман районындагы «Сарман таңнары» әдәби берләшмәсе җитәкчесе Габидуллин Әзһәр Сәмигулловичка, Татарстан АССР Верховный Советы Президиумының 1986 ел, 30 октябрь Указы нигезендә, «Татарстан АССРның атказанган культура работнигы» дигән мактаулы исем бирелде.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

Татарстан китап нәшрияты 1986 елда түбәндәге әсәрләрне басып чыгарды:

**Гомәр Бәширов. Тормыш юлында.** 384 бит. Бәясе 1 сум 80 тиен. Өлкән әдипнең бу китабында автобиографик истәлекләре, халык иҗатына, гореф-гадәтләребезгә, әдәби телебезгә багышланган мәкаләләре урнаштырылган. Мәзәкне кемнәр чыгара? Язучы булыр өчен нинди сыйфатлар кирәк? Без дөрес сөйләшәбезме? — автор әнә шундый бик күп сорауларга җавап бирә.

**Кәрим Тинчурин. Сайланма әсәрләр. Өч томлык.** Авторның йөз еллыгы уңае белән чыгарыла торган иң тулы басма. Сүз башы һәм аңлатмалар бирелә. I том. 512 бит. Бәясе 2 сум 50 тиен. «Беренче чәчәкләр», «Назлы кияү», «Соңгы сәлам», «Йосыф белән Зөләйха», «Сакла, шартламасын!», «Тутый кош», «Казан сөлгесе», «Зар» пьесалары тупланган. 2 том. 544 бит. Бәясе 2 сум 70 тиен. «Кандыр буе», «Сүнгән йолдызлар», «Американ», «Җилкәнсезләр», «Зәңгәр шәл», «Алар өчәү иде», «Булат бабай семьясы» әсәрләре тупланган.

**Габдерәхим Утыз Имәни әл-Болгари. Шигырьләр, поэмалар.**
399 бит. Бәясе 2 сум 30 тиен. 1754—1834 елларда яшәгән күренекле татар шагыйренең бу җыентыгы аның әлегә кадәр дөнья күргән китаплары арасында иң күләмлесе һәм тулысы. Монда әсәрләрнең хәзерге татар әдәби теленә юлга-юл күчермәсе һәм шигъри эшкәртелгән үрнәкләре, авторның тормышы һәм иҗаты турында ике мәкалә, белешмәләр һәм библиография тәкъдим ителә.

**Рәис Даутов, Нәзәһәт Нуруллина. Совет Татарстаны язучылары.** 640 бит. Бәясе 4 сум. Укучылар күптән көткән бу белешмәлектә 349 язучының тормыш һәм иҗат юлы яктыртыла, сурәте бирелә, бастырган китаплары һәм аларга карата матбугатта чыгарылган рецензияләр исемлеге урнаштырыла. Бу белешмәлек әлегә кадәр чыгарылган шушындый җыентыклар арасында иң тулысы.

* * *

**Мәхмүт Гәләү. Төеннәр.** Хикәяләр һәм пьесалар. 352 бит. Бәясе 75 тиен.
**Рәдиф Гатауллин. Китмә, хыял!** Шигырьләр. 80 бит. Бәясе 35 тиен.
**Флера Гыйззәтуллина. Утлы минутлар.** Шигырьләр. 158 бит. Бәясе 75 тиен.
**Нәҗип Думави. Тормыш сәхифәләре.** Шигъри әсәрләр һәм проза. 384 бит. Бәясе 1 сум 80 тиен.
**Кави Латыйпов. Хәтер йомгагы.** Шигырьләр. 190 бит. Бәясе 75 тиен.
**Эдуард Мостафин. Туасы көн.** Шигырьләр. 96 бит. Бәясе 30 тиен.
**Зәки Нури. Китап битләренә кергәндә.** Мәкаләләр, күзәтүләр, истәлекләр. 192 бит. Бәясе 55 тиен.
**Роберт Рәкыйпов. Җилкәннәрдә зәңгәр җил.** Шигырьләр. 128 бит. Бәясе 50 тиен.
**Газим Салихов. Идел батыры.** 96 бит. Бәясе 15 тиен.
**Кадыйр Сибгатуллин. Хыял.** Шигырьләр. 70 бит. Бәясе 30 тиен.
**Мөхәммәт Шәйхи. Уткүз.** Шигырьләр. 80 бит. Бәясе 15 тиен.
**Рәфик Юнысов. Җирдә яшим.** Шигырьләр. 88 бит. Бәясе 35 тиен.

Узган елларда басылып чыккан түбәндәге китаплар да сатуда бар:
**Алар сафта.** Бөек Ватан сугышында һәлак булган татар язучыларының күмәк җыентыгы. 216 бит. Бәясе 1 сум 20 тиен.
**Әхсән Баянов. Заман сурәтләре.** Лирик язмалар, мәкаләләр, очерклар. 272 бит. Бәясе 85 тиен.
**Фәрит Яруллин турында истәлекләр.** 152 бит. Бәясе 90 тиен.
**Гадел Кутуй турында истәлекләр.** 184 бит. Бәясе 95 тиен.
**Салих Сәйдәшев турында истәлекләр.** 160 бит. Бәясе 80 тиен.
**Һади Такташ турында истәлекләр.** 288 бит. Бәясе 1 сум 20 тиен.
**Миргазиян Юныс. Шәмдәлләрдә генә утлар яна.** Повестьлар. 328 бит. Бәясе 1 сум 30 тиен.
**Җиңү дәвам итә.** Татар язучыларының шигырьләре, хикәяләре, очерклары, истәлекләре. 360 бит. Бәясе 95 тиен.

Якындагы кибеттә булмаса, бу китапларны почта аша сорап алдырырга мөмкин. Адрес: 420057, г. Казань, ул. Октябрьская, 18. Магазин «Книга — почтой»; 420084, г. Казань, ул. Баумана, 19. Магазин № 1, отдел «Книга — почтой».

# АЛКАЛАРДА — КҮҢЕЛ ЯКТЫСЫ

Идел болгарлары традицияләрен дәвам иттерүче татар ювелир сәнгатенең гасыр тирәнлекләреннән килүче бай тарихы бар. XVIII—XIX йөзләрдә эшләнгән, техник камиллеккә, үзенчәлекле формаларга ия булган бизәнү әйберләре ул чор көмешчеләренең декоратив-гамәли сәнгатьтә зур осталыкка ирешүләрен күрсәтә. Россиядә яшәгән башка халыкларда турыдан-туры моңа охшаш әйберләр күзәтелми.

Журнал тышлыгындагы алкаларда (XVIII гасыр) — әнә шул осталыкның, камиллекнең чагылышы. Бу зиннәтләрнең казан татарлары кием ансамблендә үз урыны, этнографик таралу төбәкләре, үз язмышлары бар. Безнең көннәргә кадәр килеп җиткән груша һәм йөрәк рәвешендәгеләре аеруча киң таралган булган. XIV—XV гасыр болгар алкалары белән үзара охшашлык һәм бердәмлек аларның иң борынгы ювелир традицияләргә барып тоташуы турында сөйли.

Татарстан АССР Сынлы сәнгать музееның милли декоратив-гамәли сәнгать коллекциясендә татар ювелирлары эшләгән алкалар аерым урын били. Алтыннан һәм көмештән пәрәвезләп бөтереп ясалган бу әйберләр парча сыман яктылык уенына корылганнар.

Төп өлешенә турыдан-туры яисә бөҗра ярдәмендә чәчәк сыман калканчык куеп бизәлгән алкалар тагын да камилрәк сурәтләре белән игътибарны җәлеп итә. Вак тәңкәләр яки яфрак сыман асылмалар алкага үзенчәлекле матурлык биреп кенә калмый, аны чын мәгънәсендә яңгырашлы да итә.

Татар ювелир сәнгатенә хас «полихром стиль» бу очракта бизәнү әйберләренең асыл һәм ярым асылташлар белән бизәлүендә ачык чагыла. Бер очракта асылташлар алканың кыр-кыры буйлап, икенче очракта үзәгеннән сибелүче нурлар рәвешендә урнаштырыла. Тагын бер характерлы билге: зур асылташ уртага куела, аның тирәсенә ваграклары тезелә. Фирәзәнең ачык зәңгәрлеге, сердолик, топаз, аметист һәм башка ташларның сарыдан башлап шәмәхәгә кадәр булган балкышы гаҗәеп төсләр гаммасын тудыра.

Бөрчекләү, эретеп ябыштырылган ялтыравык зиннәт әйберләре кую да алкаларга үзенчәлекле төсмер бирә. Ташсыз алкалар, мәсәлән, әнә шул ялтыравык зиннәтләре белән бөтерелгән өслектә яктылык һәм төсләр уены тудыралар.

Әлеге төрдәге зур күләмле алкалар үткән гасырның икенче яртысыннан җиңелрәк, рәвеше буенча хәзерге заман милли бизәнү әйберләрен хәтерләтүчеләре белән алышына башлый.

**Людмила КОРОБЦОВА**,
Татарстан АССР Сынлы сәнгать
музее гыйльми хезмәткәре.

**Юрий ФИЛИМОНОВ** фотосы.


**Тышлыкның дүртенче битендә:** Казанның 1 Май мәйданында Советлар Союзы Герое, Ленин премиясе лауреаты шагыйрь Муса Җәлил һәйкәле. Скульпторы В. Е. Цигаль, архитекторы Л. Г. Голубовский.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотосы.

129

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)